

# КАЗАН УТЛАРЫ

5
МАЙ
1981

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

5
МАЙ
1981

## *Бу санда*

ТАТАРСТАНДА КАРАКАЛПАКСТАН ӘДӘБИЯТЫ ҺӘМ СӘНГАТЕ КӨННӘРЕ

Татарстан сәламе . . . 3
К. МӘКЪСҮТОВ. Безгә көч биргән дуслык . . . 4
Каракалпак шагыйрьләре иҗатыннан үрнәкләр . . 8
Т. КАИПБИРГӘНОВ. Әз-мәз үзем хакында . . . 22
У. АБДИРАХМАНОВ. Туй. Хикәя . . . 33
Г. ТОРСЫНОВА. Яшәү яме. Хикәя . . . 43
М. КАИПОВ. Үз каным. Хикәя . . . 46
У. БЕКБАУЛОВ. Легенда. Әсәрдән өзек . . . 52
Л. ХӘМИДУЛЛИН. Ерак араларны якын итеп... . 55

Г. РӘХИМ. Немец дустыма. Шигырь . . . 60
Ә. ГАДЕЛ. Хәтер. Шигырь . . . 61
Ш. БИКЧУРИН. Тирән катлам. Роман . . . 62
Г. АФЗАЛ. Ага сулар. Шигырьләр . . . 103

РАДИК ФӘИЗОВКА 50 ЯШЬ

Р. ФӘИЗОВ. Җинаять. Хикәя . . . 107

РӘШИТ ГӘРӘЙГӘ 50 ЯШЬ

Р. ХАРИС. Арыш тамырыннан җыр да шыта . 115
Р. ГӘРӘЙ. Ветераннар җырлый. Шигырьләр . 117

Т. КАМАЛИЕВ. Кырык яшьтә. Шигырьләр . . 121

XXVI СЪЕЗД КАРАРЛАРЫН — ТОРМЫШКА!

Ф. АБДУЛЛИН. Чакырулар . . . 125

ОЧЕРКЛАР ҺӘМ ПУБЛИЦИСТИКА

Ш. ХАММАТОВ. Муса Җәлил — журналист, тәнкыйтьче . . . 129
З. ЗӘЙНУЛЛИН. Карбыз сугышыннан — чын сугышка . . . 139

КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ГАФУР КОЛӘХМЕТОВНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Д. ВӘЛИЕВ. Ашкыну . . . . . . . . . . 147
Гафур Коләхметов хатлары . . . . . 154
Г. ШӘРИПОВА. Гафурлар гаиләсе. Романнан өзек 159

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Ф. МИҢНУЛЛИН. Тәнкыйтьче бәхете . . . . 166

ГАМИЛ АФЗАЛГА 60 ЯШЬ

Ф. ШӘФИГУЛЛИН. Көлеп моңая, уйлап елмая . 171

КИТАП КҮЗӘТҮ

Ф. ЗӨЛКАРНӘЕВ. Максатка ни илтә! . . . . . 175
С. МАННАПОВ. Юлы җиңелләрдән көнләшмик 177

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

З. СӘЙДӘШЕВА. Солтан Габәшинең тууына 90 ел 180
Ә. ГОБӘЙДУЛЛИНА. Шириәздан Сарымсаковка 70 яшь . . . . . . . . . . . . . . . 182
Ф. ХӘКИМҖАНОВ. Бай эрудицияле галим . . . 184

ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

З. НУРИ. Ватан сугышы елларының көлке капчыгыннан . . . . . . . . . . . . . . 186

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . 190

Баш редактор: ЗӘКИ НУРИ

Редколлегия: ӘХСӘН БАЯНОВ (баш редактор урынбасары), ШАМИЛ БИКЧУРИН, АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ, МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ, ЗӨЛФӘТ, ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН, ТУФАН МИҢНУЛЛИН, РӘФЫЙК НӘФИКОВ, АТИЛЛА РАСИХ, КОЯШ ТИМБИКОВА (җаваплы секретарь), СИБГАТ ХӘКИМ, НИЛ ЮЗИЕВ

Техник редакторы *Р. Сөләйманова*
Корректорлары *Ф. Кадыйрова, Т. Шакирҗанова*

Редакциянең адресы: Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-61, поэзия бүлеге — 3-07-61, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-63, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Производствога бирелде 28/I-1981 ел. Басарга кул куелды 22/IV-1981 ел. ПФ 09017. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 103 644 экз. Заказ Д-44. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1981 ел.

***Безнең күп милләтле Туган илебезнең барлык халыкларының туганнарча дуслыгы тайпылышсыз ныгый.***

Л. И. БРЕЖНЕВ.

## Татарстан сәламе

*Сәлам сезгә, сәлам сезгә, дуслар,*
*Безнең яклар сезне сагынды.*
*Бу сәламнәр якты күңелләрдә*
*Тургай булып канат кагынды.*

*Бу сәламнәр КамАЗ цехларында*
*Юллар яме булып кабынды.*

*Сәлам сезгә, сәлам сезгә, дуслар,*
*Сәлам сезгә гүзәл Иделдән.*
*Бу сәламнәр безнең күгебезгә*
*Шат йолдызлар булып сибелгән.*

*Бу сәламнәр Казан мехларына*
*Матур бизәк итеп чигелгән.*

*Татарстаннан сәлам сезгә, дуслар,*
*Сәлам сезгә яшьлек языннан.*
*Бу сәламнәр безнең йөрәкләргә*
*Дуслык җыры итеп язылган.*

*Сәлам сезгә, сәлам сезгә, дуслар,*
*Тәбригебез җырда җырлана.*
*Бу сәламнәр Казан утларының*
*Балкышында күркәм нурлана.*

Кабул Мәкъсутов,
профессор, Үз. ССР һәм ККАССРның
атказанган фән эшлеклесе

# БЕЗГӘ КӨЧ БИРГӘН ДУСЛЫК

Татар һәм каракалпак әдәби багланышлары үзенең тамырлары белән бик ерак дәверләргә китә. Аның беренчел нигезе — мең еллар дәвамында уртак юлдан барган төрки халыкларның авыз иҗаты хәзинәсе. Бездә көйләр, җырлар, әкиятләр, табышмаклар һәм эпосларның уртак вариантлары аз түгел. Урта гасырлардан килгән күп кенә язма истәлекләр буенча да төрки халыкларның бер-берсенә охшаш гореф-гадәте, кием-салым, азык-төлек, көнкүреш ягыннан якынлыгы ачык сизелә. Бөек Октябрь социалистик революциясенә кадәр татар һәм каракалпак халыклары да эксплуатациягә каршы авыр көрәш алып бардылар. Берничә гасыр дәвамында бу халыклар сыйнфый кимсетелү, рәнҗетелүләр кичерделәр. Ләкин нинди генә сәяси-экономик басым астында булмасын, хезмәт ияләре, халыкның алдынгы вәкилләре, язучы-шагыйрьләре үз халыкларының азатлыгы, якты һәм бәхетле тормышы, мәдәни үсеше турында кайгырталар, гаделлек өчен аяусыз көрәш сафына бастылар.

Татарстан һәм Каракалпакстанның тугандашлык хисләрен тагын да ныгытучы сәбәпләрнең берсе — әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге элемтәләр, каракалпак халкының татар әдәбияты һәм сәнгате белән зур кызыксынуы.

Сөеклебез Габдулла Тукай үзе исән чакта ук, татар халкының гына бөек шагыйре булып калмастан, талантлы шигырьләре һәм ялкынлы публицистик мәкаләләре белән төрки телле бүтән халыкларның уртак шагыйренә дә әйләнгән иде.

Габдулла Тукай әсәрләре каракалпак теленә Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң гына тәрҗемә ителде. Әмма телләрнең якынлыгы сәбәпле, Октябрь революциясенә кадәр дә Казан, Уфа, Оренбург шәһәрләрендә чыга торган татар газета-журналларын укып, Урта Азиядә яшәгән халыклар Г. Тукай һәм башка татар әдипләренең әсәрләре белән якыннан таныша алалар иде. Әлеге әсәрләр безнең халыклар күңеленә чын мәгънәсендә мәдәни бәйрәм булып килә. Г. Тукай әсәрләре 1960 елда Каракалпак дәүләт нәшрияты тарафыннан аерым китап итеп чыгарылды. Бөек шагыйрь әсәрләренең каракалпак телендә басылып чыгуы республикабызның әдәби тормышында зур вакыйга һәм каракалпак-татар әдәби бәйләнешләрен ныгытуга мөһим өлеш булып саналды. Бу тупламда туксанга якын әсәр бар. Аны каракалпак теленә шагыйрьләр Б. Исмәгыйлев, Ө. Хуҗаниязов, И. Юсуповлар тәрҗемә итте. Бу шигырьләр тематикасы һәм эчтәлеге буенча шактый киң диапазонлы. Алар каракалпак теленә уңышлы тәрҗемә ителгән.

Г. Тукайның «Шүрәле» әкият-поэмасы 1908 елны язылган. Халык иҗатыннан киң файдаланып, Г. Тукай әкияти каһарманнарны кешеләр арасына кертә, безне ак белән караның көрәшенә шаһит итә, әлеге көрәшне үзенчәлекле поэтик чаралар белән сурәтли.

Каракалпак халык әкиятләрендә дә Былтыр образы очрый. Ул тәвәккәл, батыр егет булып күз алдына килә. Әнә шундый уртаклыкларга таянып, без татар һәм каракалпак халык иҗатындагы бердәм нигез барлыгына ышана алабыз.

И. Юсупов Г. Тукайның тирән эчтәлекле һәм югары идеяле поэзиясен ярата, аның рус, көнчыгыш һәм көнбатыш әдәбиятларындагы иң камил үрнәкләрне үзләштереп, оригиналь әсәрләр тудырганлыгын яхшы аңлый иде. Ул Тукайны юкка гына үзенең остазы итеп танымады һәм тикмәгә генә аны «татар поэзиясенең кояшы» дип атамады. Шушы исемдәге китабына кереш сүз язганда И. Юсупов: «Г. Тукай 30 нчы елларда иҗат иткән каракалпак шагыйрьләренә зур тәэсир ясаган. Аның иҗаты белән сокланмаган, аңа иярмәгән бер генә каракалпак шагыйрен дә белмим. 1946 елны мин Г. Тукайның 1936 елда Муса Җәлил редакторлыгында чыккан бер томлык җыентыгын таптым, шул вакыттан бирле Тукай минем иң яхшы киңәшчемә һәм сөекле остазыма әверелде. Аның кайбер шигырьләрен каракалпак теленә тәрҗемә иттем. Тукай шигыренең һәр юлы тирән мәгънәле, җитлеккән эчтәлекле. Ул халык поэзиясенә якын, аның белән бергә үрелеп, халык өметен, халык теләген сурәтли. Аның шигырьләрендә халык моңы, аның уй-кичереше җәйрәп ята»... ди Юсупов.





*Шагыйрь С. Хәким Каракалпакстан шагыйре Ж. Аймурзаев белән*

Чыннан да, И. Юсуповның Тукай иҗаты турындагы фикерләре татар-каракалпак халыкларының әдәби-мәдәни элемтәсен күрсәткән ачык дәлилләрдән берсе булды. Бу әдәби бәйләнешләребез нәтиҗәсендә каракалпак совет әдәбиятына нигез салучыларның берсе булган Сәйфелгабит Мәҗитов иҗаты үсеш алды.

С. Мәҗитов 1867 елны Казан губернасының Өртәм авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. Башлангыч белемне дә туган авылында ала. 1880 елны Мәҗитовлар гаиләсе Каракалпакстанга күчеп килә һәм булачак язучы гомеренең калган өлешен каракалпак халкы белән бәйли. Аның кайгысы, шатлыгы, уй-кичерешләре Каракалпакстаннан аерылгысыз була. Оренбург, Муйнак һ. б. калаларга барган сәүдәгәрләр аркылы ул Казанда, Уфада, Уральск, Петербург, Оренбургларда чыккан газета-журнал һәм китапларны алдырып тора. Каллы Айымбетов һәм шагыйрьнең улы Рәхим Мәҗитовлар тарафыннан төзелгән сайланма әсәрләре китабының кереш сүзендә, ша-

гыйрьне күреп белгән К. Айымбетов, С. Мәҗитовның яңа идеяле мөгаллимнәр белән танышуы, Россиядә татар телендә чыга торган газета-журналлар алып торуы, Г. Тукай һәм башка татар язучыларының әсәрләрен сөенеп укуы турында яза.

С. Мәҗитовның язучы булып өлгерүендә татар язучылары, аеруча Г. Тукайның роле зур. Тукайның милләтне агарту өчен тырышуы аңа яңа революцион идеяләр алып килгән әсәрләр язуы мәгълүм бер нәрсә булса, аның башка төрки милләт вәкилләренә йогынтысы әлегә аз тикшерелгән. Әмма, К. Айымбетов язуынча, Тукай әсәрләренең тәэсире С. Мәҗитов һәм аның чордашлары иҗатына чиксез зур була. Бөек культура белән якыннан таныш булган С. Мәҗитов каракалпак халкының тормышын, гореф-гадәтләрен, аның уй-кичерешләрен тирәнтен өйрәнә һәм үз әсәрләрендә оста күрсәтүгә ирешә.

Язучылык белән беррәттән, С. Мәҗитов каракалпаклар арасында мәгърифәтчелек эше дә алып барды. Ул иске типтагы мәктәп-мәдрәсәләрдә тәпле дөньяви белем алып булмасын яхшы аңлый, шуңа күрә дә яңа типтагы (җәдитчә) мәктәпләр ачу идеясен яклый. һәм бу мәктәпләрне киләчәк буыннарны тәрбияләү өчен иң яңа ысул дип расләй. Мондый мәктәпләрне ул халкы күп булган калаларда ачу тагын да мәгъкуль дип белдерә һәм Чимбай шәһәрендә яңача, җәдитчә мәктәп ачу кирәклеген аңлатып, 1907 елны «Җәмгыять булышлыгы» оешмасына да мөрәҗәгать итә. Ләкин «Җәмгыять булышлыгы» шагыйрьнең бу гозерен җавапсыз калдыра.

С. Мәҗитовның Бөек Октябрьдан соң язылган «Иреклек таңы», «Ирекләккә күчү», «Каракалпак», «Бик яхшы», «Дау булмасын», «Тугрылык һәм хыянәт», «Надан мулла» шигырьләрендә Г. Тукай поэзиясе тәэсире аеруча ачык сизелә.

Әдәбиятыбызда беренчеләрдән булып татар галимнәренең тәҗрибәсеннән оста файдаланган С. Мәҗитов каракалпак мәктәпләре өчен уку әсбаплары, дәреслекләр төзүдә яңа алымнар куллана. Ул балаларга атап «Укуга кил», «Укы», «Файдасын бел», «Абыйсыннан энесенә хат», «Уку бүтән, уен бүтән», «Тәҗрибә», «Килер көнгә», «Ялкауга», «Балалар», «Хәлимә нигә куанган?», «Дүрт фасыл» һ. б. шигырьләр язды.

Татар театрының беренче адымнары турында хәбәрдар булган С. Мәҗитов драматургия сәнгатенә аеруча зур кызыксынучанлык белән карый. Атаклы татар драматурглары һәм язучылары әсәрләре белән татар телендә чыккан газета-журнал, китаплар аша яхшы таныш булган С. Мәҗитов Г. Тукай, Ф. Әмирхан, К. Насыйри, Г. Камал, Г. Ибраһимов, Г. Коләхметов, Ш. Камал, М. Гафури иҗатларын шактый тирән белә. Бу кызыксынуның төп сәбәпләреннән берсе — татар әдәбиятының 20 нче елларда башка төрки әдәбиятларга караганда бик күпкә алда булуы. Каракалпак әдәбиятында сәхнә әсәрләренең барлыкка килүе өчен күп көч куйган С. Мәҗитов үзе дә татар драматургиясенең уңышлы адымнарыннан рухланып иҗат итте.

1919—1920 елларда Каракалпакстанда беренче һәвәскәр драма түгәрәге оештырыла. Аның оештыручысы Казаннан килгән Касыйм Ямашев исемле, театр эшләре белән бөтен нечкәлекләренә кадәр таныш, белемле кеше була. Үзе рәссам, үзе гармунчы, гитара, скрипка уйный белә. Татар һәм башка төрки милләт вәкилләре катнашында оештырылган бу драмтүгәрәктә тиз арада татар драма әсәрләре сәхнәләштерелә. Түгәрәк репертуарында Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану», Кәрим Тинчуринның «Казан сөлгесе», «Зәңгәр шәл», Хәбибулла Ибраһимовның «Башмагым» әсәрләре буенча куелган спектакльләр бар. Сәйфелгабит Мәҗитов та шушы чаралардан читтә калмады, әлбәттә.

Каракалпакстан автономияле өлкәсе төзелгәннән соң, аның башкаласы Дүрткүл шәһәрендә 1924—1925 елларда һәвәскәрләр түгәрәкләренең эше тагын да җанлана төште. Шул вакытларда Дүрткүлдә Каниев җитәкчелегендәге татар драмтүгәрәге югарыда искә алган драматургларның пьесалары буенча дүрт-биш спектакль куеп алдылар. С. Мәҗитов исә ул вакытларда Дүрткүлдә культура агарту эшләрендә җаваплы хезмәткәр булып эшли, культура һәм сәнгать мәсьәләләре белән якыннан шөгыльләнә.

1925 елда Дүрткүлдә педагогия техникумы, совет-партия мәктәбе, авыл хуҗалыгы техникумы студентлары катнашуында «Таң нуры» исемле беренче каракалпак милли драма труппасы оештырылды. С. Мәҗитов шул түгәрәк өчен пьесалар язды. Бу түгәрәккә Зариф Фатихович Касыймов җитәкчелек итә иде. С. Мәҗитовның «Сабак» пьесасы да шушы труппа артистлары үтенечә буенча язылган. Шуннан соң ул кара-

калпак әдәбиятының алтын хәзинәсенә кергән пьесалар иҗат итте. С. Мәҗитов берничә проза әсәренең дә авторы. Аның улы Р. Мәҗитов та, атасы юлын сайлап, «Кара йөрәкләр» исемле пьеса язды. Ул 1935 елларда Каракалпак театры сәхнәсендә берничә тапкыр куелды.

Каракалпак-татар әдәби бәйләнешләры тарихында 1958 елны каракалпак телендә басылып чыккан тагын бер китап әһәмиятле урын тота. Ул — каһарман-шагыйрь Муса Җәлилнең «Җырларым» дип аталган шигырьләр җыентыгы.

Җыентык патриот-шагыйрьнең бөтен иҗатына лейтмотив булып торган «Җырларым» шигыре белән ачыла.

Сездә минем бөтен тойгыларым,
Сездә минем керсез яшьләрем.
Сез үлсәгез, мин дә онытылырмын,
Яшәсәгез, мин дә яшәрмен.

Муса Җәлил әсәрләре — совет әдәбиятына хас патриотик әсәрләрдән иң югары ноктага җиткән үрнәкләр. Совет кешесенең Ватанга тугрылыклы, азамат йөрәкле икәнлеген исбат итә алар. Аның «Моабит дәфтәрләре» җыр сөючән халкыбызны каһарман шагыйрь иҗаты белән якыннан таныштыруда зур өлеш булды. Җәлил әсәрләрен укыган милләттәшләремнең күңелендә аның иҗатына, шагыйрьне үстергән татар халкына чиксез мәхәббәт, самими мөнәсәбәт, хөрмәт уяна. Бу — СССР халыкларының тугандаш гаиләсендә чәчәк атучы татар-каракалпак әдәбиятлары арасында якын кардәшлек хисенең бер чагылышы булып гәүдәләнә.

## Әҗинияз

*1811—1878*

### Булыр

Кара тауның түбәләре
Карлы булыр, карсыз булыр.
Моңлы егет ят илләрдә
Маллы булыр, малсыз булыр.

Диңгез кичеп, килсә язлар,
Елмаешыр сәрвиназлар,
Каңгылдашып очкан казлар
Күлле булыр, күлсез булыр.

Хорезмда калды ваем,
Калды «ах!»ым, калды «вай!»ым.
Тау сулары аккан саен
Җилле булыр, җилсез булыр.

Күчәр кәрваннар чүлләрдә,
Очар киек кош күлләрдә,
Моңлы егет ят илләрдә
Телле булыр, телсез булыр.

Ят җирләрдә хуш егетләр
Йөрәгенә салма утлар.
Гарәпләрдән килгән атлар
Яллы булыр, ялсыз булыр.

Нәфес, теләк — күкләр эше,
Агадыр гел бу күз яше,
Ят илләрдә йөргән кеше
Юллы булыр, юлсыз булыр.

Кемгә сөйлим уйларымны,
Күңелемдә — еллар моңы,
Үткән гомер — калган чыңы
Илле булыр, илсез булыр.

Мескен Зийвар һәркөн елар,
Йөрәгендә иңрәр таулар,
Хыялында бакча шаулар —
Гөлле булыр, гөлсез булыр.

**Әхмәт РӘШИТОВ тәрҗемәсе**

## Сәйфелгабит Мәҗитов

*1869—1938*

### Кит, кит!

Бу җирдә сиңа урын юк,
Ил башыннан, тук хаким, кит!
Синең юлдан бармас бүтән,—
Халкым белә үз хакын... Кит!

Син бит — безгә тозак корган,
Илем синнән йөзен борган...
Ачуыннан янып торган
Кара эчле тук хаким, кит!

Үз бәхетен үзе табып,
Халкым бара, юллар сабып...
Тирең генә синең сарык,
Син бит — бүре, син — хаким, кит!

Көндез койрык болгап йөреп,
Төнлә кураларга кереп,
Әй син, бүре, йөрмә берүк,
Соңгы көнең бик якын, кит!

Синең уйда — безгә тәмуг,
Карашыңда — агулы ук,
Бу хастадан һич дәва юк,
Булмас синең оятың... Кит!

Яшәдең син безне буып,
Юл күрсәтте таңнар туып,
Җибәрәбез сине куып...
Без барасы юл якты! Кит!

Инде максаттан өмет өз,
Хәйләләмә, уйнатма күз,
Кайда барсаң да, шул бер сүз:
Безнең илдә күп яттың... Кит!

Базары үтте ялганның —
Җим элеп кармак салганның —
Без беләбез кем калганын,
Ә син монда артыксың! Кит!

Гади халык илдә калсын,
Пахта чәчсен, йортлар салсын,
Үз тапканын үзе алсын...
Халкым белә үз хакын! Кит!

Разил ВӘЛИЕВ тәрҗемәсе

## Аббас Дабылов,

Үзбәкстан ССРның,
Каракалпакстан АССРның халык шагыйре

*1898—1970*

### Бибисанем

... Тулды сиңа нәкъ унтугыз әле бары,
Синнән үрнәк ала кызлар — якташларың,
Маңгаеңда акыл сизәм... Ә кашларың
Таң калырлык ике канат, Бибисанем.

Сокландым мин зифа буең, битләреңә,
Йолдыз нуры сибелгән бит миңнәреңә.
Насыйп бул син, бәхетле үз тиңнәреңә,
Кайнар иренең — исертерлек, Бибисанем.

Йөзең нурлы. Көч өстәлә беләгеңә.
Коммунизм нурлар сибә теләгеңә.
Иртә таңнан шатлык сыймый йөрәгеңә,
Хисең ташып дәртле эштән, Бибисанем.

Туган якта һәркем сине зурлап сөйли,
Яшьләр хәтта җырда мактый, җырда көйли.
Эшең өчен күңел була, шатлык били,
Әйе, таңга калырлык син, Бибисанем.

Маңгаеңда энҗе итеп күрәм тирне,
Тугыз тапкыр эшкәртәсең газиз җирне —
Үсентеләр көймн-ямьый, белми чирне,
Фән кушканча сугарасың, Бибисанем.

Июнь ае үтеп бара — җирең уңа!
Июль ахыры, әнә кара — мамык була!
Зур уңыштан күңелләргә шатлык тула,
Җыеп өлгерт байлыгыңны, Бибисанем.

Исем китте кара кырда барын-барын:
Җәһәт йөрткән алтын кулың, бармакларың,
Үлчәп өлгерт мамыкның син җыйганнарын...
Уттай яна эштә җаның, Бибисанем.

Гашыйк булган яшьләр синнән күзен алмый.
Горур йөрәк серен ачып салмый, —
Дан казанган буләгеннән күзен алмый,
Нурлы буләк алга әнди, Бибисанем!

Мөхәммәт САДРИ тәрҗемәсе

## Җолморза Аймурзаев,

Каракалпакстанның халык шагыйре

### Дуслык атавы

Казан кызы, каракалпак уллары,
Җырлар җырла, чирттер дутар кылларын,
Мәңге-мәңге бергә булсын юлларың...
Ленин ачты безгә дуслык атавын.

Безнең Ватан — ирекләләр Ватаны,
Кызлар йөзе төсле алсу һәр таңы.
Котлы булсын дусның дуска сәфәре...
Сәлам сиңа, кан кардәшем, татарым!

Каракалпак багы, татарның гөле, —
Барысы да бүген җыйналды бире.
Күтәп алды безне дусларның җире...
Бу җырларны сиңа җырлыйм, татарым.

Безнең халык борын-борыннан, баштан
Мал-мөлкәтен уртаклашкан, алышкан.
Җылы алган бер үк Ватан-кояштан...
Уй-хыяллар уртак безнең, татарым.

Айдай йөзебезгә илегез ачык,
Баскан эзебезгә җирегез ачык,
Якын туганнарга түрегез ачык...
Ленин ачты безгә дуслык атавын.

Разил ВӘЛИЕВ тәрҗемәсе

## Теләүбирган Җумаморатов,

Үзбәкстан ССРның һәм Каракалпак АССРның халык шагыйре

### Биек үткел

ПОЭМАДАН ӨЗЕК

Дөнья — океан, кичтем ярсу дулкыннарын.
Татып белдем авырлыкның барын-барын:
Җил-давыллар аша килдем ашкынып мин,
Күрер өчен тормышымның биек ярын.

Минем гомер җил булыпмы исеп китте,
Әмма мине үстерде ул, егет итте.
Авыр юлдан, биек үткел, синең янга,
Илле яшьлек чорыма да килеп җиттем.

Ятим идем, хәзер бәхет күккә тия,
Халкым мине хөрмәт итеп шагыйрь дия,
Һәр кешегә бәхет биргән, бөек Ватан,
Син һәркемгә газиз, сине һәркем сөя.

Ана кочып үпкән чакта үз баласын,
Башлаганда мәктәп уку тантанасын,
Ятимлектән тартып алып, ил мине дә
Кеше итте, үстерде, дип, шатланасың...

...Аккош бик тә матур зәңгәр һәм саф күлдә,
Картлар матур дан казанса туган илдә,
Сый-хөрмәтен күреп үскән газиз җиргә
Гомер буе бурычлымын, әйе, мин дә.

Халкым, кайнар мәхәббәтең, терәгемә
Әйләнде ул, илһам бирде йөрәгемә:
Йөз яшькәчә бәхет җырын җырлар өчен
Ялкын өстәп сиптең якты теләгемә.

И партия — бөек хөрлек, яз кояшы!
Канатланган ил сулышын син тоясың.
Син яктырткан гомер юлым дәвам итәр
Җырлый-җырлый азат халыклар дөньясын!

Мөхәммәт САДРИ тәрҗемәсе

## Байнияз Каипназаров,

Каракалпакстанның халык шагыйре

### Чәчәк

Мин бакчага, чәчәкләр янына
Чыгам ашыгып һәрбер иртәдә,
Шундый матур алар — кузнең явын
Ала төсле... шундый иркәләр!..

Нәфислеге белән әсир итә,
Иң-иң нечкә кылга кагыла
Алган бер Чәчәк бар... Таҗы белән
Җанны тәрә гүя назына...

Тик карашым белән тиеп узам,
Кагылырга базмыйм аңарга.
Матурлыгын юмарт биргән өчен
Рәхмәт укыйм җылы язларга...

Ялкын кебек гөлем — пешерер күк,
Дымлы җилләр сыйпый битләрен.
Һәм өстенә күктән нур коела,
Авыр чыклар куна кичләрен.

Һәрбер якты, нурлы иртәдә мин
Ул чәчәккә караш саламын,
Җыр җырлыймын аңа сәлам итеп,
Ул иелеп ала сәламем.

Алтын тауның сихри яктысында
Алланып ул үзенә чакыра.
...Тик яшерер бөтен матурлыгын
Кул сузсам мин аңа чак кына.

— Чәчәк турындамы җыр язасың? —
Дип кемнәрдер миннән көләчәк.
Күңелемдә үсә — мәхәббәтем,
Шул бакчада гүя ал чәчәк!

**Рәдиф ГАТАУЛЛИН тәрҗемәсе**

# Хуҗабәк Сәетов,

Каракалпакстанның халык шагыйре

## Эссе күл

Әйләнәң — тау, якаң — җәйләү, Эссе күл,
Хәтфә үлән, камышларың ефәктер.
Карлар эреп, таудан, инеш челтерәп
Сулар акса, салкынча җил исәдер.

Дулкыныңда уйный көмеш чабаклар,
Ә төбеңдә тибә эссе чишмәләр,
Түшәк итеп зәңгәр күктәй суыңны,
Төн кунарга үрдәк-казлар төшәләр.

Таң атканда, гөлдер-гөлдер гөлдерәп,
Мөлдер сулар тау күкрәген имәдер.
Төш вакытында зифа таллар шауласа,
Кичен талгын, моңсу тынлык иңәдер.

Һәр нәрсәгә үзенә хас төс биргән
Кояш-рәссам сине сөя галәмдә,
Иртәләрен кояш нурын көтәдер
Дулкының да, җәйләүдәге гөлең дә.

**Марс ШАБАЕВ тәрҗемәсе**

## Җолдаш Сәетназаров

### Дутарым

Ясалгансың син тут дигән агачтан,
Ә тут үскән нурлар алып кояштан.
Матур баулар тактым сиңа, дутарым.
Уйнаганда талмый минем кулларым.

Ак сөяктән төрле бизәк уйдырдым,
Йөзләреңә күп гүзәллек сыйдырдым.
Синең матур тавышыңны, дутарым,
Йотылып тыңлый минем барлык дусларым.

Дус-ишләрем керә миңа кичләрен
Ял итәргә — калдырып бар эшләрен.
Аруларын онытгырып барсының,
Кузгатасың йөрәктәге хисләрен.

Кулга алам сине ихлас яратып,
Хәсрәтләрне ташлыйсың син таратып,
Әгәр сине уйнасам зур туйларда
Кыз-егетләр тыңлый бар да җан атып.

Чиртеп бирсәм кылларында, дускаем,
Каракалпак халык җыры — Ышпайны,
Диңгез кебек тулып китте йөрәкләр,
Йөрәкләрдә туа матур теләкләр.

Фәнис ЯРУЛЛИН тәрҗемәсе

## Ибраһим Юсупов,

Каракалпакстанның халык шагыйре

### Каракалпак хакында сүз

Кара табан, кара көн итек —
Бабам бик гаярь кеше булган, ди.
Киеме актан, калфагы кара,
Яулар чапкан ул, көчле булган, ди.

Ул олы яуга чыгар алдыннан
Атасы әйткән сөеп улына:
«Бер васыять алып кит, егет, яуга —
Турылыклы бул син калфагыңа!»

Каракалпаклар шул көннән башлап
Калфак белән үк туалар, диләр.
Дусмы-дошманмы, һәркем алдында
Гел калфак киеп куялар, диләр.

Күпме заманның утлы кояшын
Күрсә дә калфак агармый һаман.
Каракалпак күп байлык югалтты —
Кара калфагы югалмый һаман.

Алдап-йолдап та, янап-көчләп тә
Бер хан да аны салдыралмаган.
Илгә ташланган иң-иң дәһшәтле
Яулар да аны салдыралмаган.

Дошманның һәрчак ачуы чыккан,
Бу кыюлыкка хәйран калган ул.
Каракалпакның калфагын — бары
Баш белән бергә кисә алган ул.

Каракалпаклар бер генә җирдә
Бу гадәтеннән читенә ала —
Бөек Ленинның Мавзолеена
Кергән чагында калфагын сала.

**Гәрәй РӘХИМ тәрҗемәсе**

# Таҗетдин Сәетҗанов,

Каракалпакстанның халык шагыйре

## Күз ачып йомган арада

Күз ачып йомган арада
Зур могҗиза туа ала.
Шул ук мизгелдә бүтән көч
Аңа киртә куя ала.

Шуны онытма син, кеше,
Үзең дә бит бер гөл генә:
Мең гөлне кыра бер кырау,
Төшсә дә кинәт бер генә.

Вакыт мизгеле — зур нәрсә:
Бәхет тә сиңа, кайгы да
Була ала һәр минуты —
Табылсын шуңа җай гына.

Әзер язмыш күктән төшми —
Шуны белеп яшә җирдә:
Бер мизгелдә буталмасын
Яман белән яхшы бергә.

Күз ачып йомган арада
Дошманың дус була ала,
Ә якын дусның йөрәге
Нәфрәт белән тула ала.

Күз ачып йомган арада
Алтын була ала таш та,
Ә алтын ташка әйләнеп
Төшә ала синең башка.

Син — кешесең. Игелек кыл:
Буяма акны карага
Һәм эзсез югала күрмә
Күз ачып йомган арада.

Көн дә исәплә һәм сана:
Кояш байый тагын, диген,
Ә мин соң нәрсә эшләдем
Илем өчен тагын?! — диген.

**Зәки НУРИ тәрҗемәсе**

# Бабаш Исмаилов

## Каракалпакстаным минем

Ирек җырларын яңгыратып
Аткан ал таңым минем,
Туган җир белән бәйләгән
Газиз Ватаным минем.
Буйда — җегәр, билдә — дәрман,
Тәнемдә — җаным минем.
Әй, нурланган,
Әй, гөлләнгән
Нурлы бостаным минем,
Сөекле туган илем,
Каракалпакстаным минем.
Күп милләтле дус семья

Әгъзасының бере син,
Эшчеләрнең — алачыгы,
Колхозчының — җире син.
Мамыкчылар, ефәкчеләр,
Игенчеләр иле син.
Сөекле туган җирем,
Газиз туфрагым минем.

Йөзең сыман балкып торган
Тавың, ташың, җирең сылу,
Бәхетеңдәй ташып торган
Дәрья, диңгез, күлең сылу,

Иркенлекнең кочагында
Чәчәк аткан чүлең сылу.
Сөекле туган илем,
Каракалпакстаным минем.

Максатың — коммунизм,
Көн саен гөлләп яшә,
Уңыш, җиңеш юлдаш булып,
Югары үрләп яшә,
Горур йөрт Ленин байрагын,
Шаулап һәм гөрләп яшә,
Сөекле туган илем,
Каракалпакстаным минем.

**Илдар ЮЗЕЕВ тәрҗемәсе**

# Галим Сәетназаров

## Җәйләүдә таң

Шундый матур җәйләү! Таң сызыла,
Ефәк җилләр үйный тирәндә.
Ә һавада әрем, чия исе
Аралашып бергә тирбәлә.

Ак чапаннан иде яңа гына,
Хәзер дала, күр, ал киемле...
Кая таба агыла ул болытлар? —
Белмим, ә каравы күңелле!

Җитез сабантургайлары әнә
Күккә күтәрелеп барышлый,
Мәңгелек сер тулы гаҗәп җырын
Авылыма минем багышлый.

Уянганнар башка кошлар... Ишет
Тавышларын. Кем ул? Ачыкла...
Елмаялар үлән, гөлләр әнә,
Җем-җем килә көмеш, ак чыклар.

Уянганнар кызлар. Әнә берсе —
Тюльпаннарны сөеп атлаган
Чуар яулыклысы нинди чибәр!
...Әнә ничек җырлый яшь чабан,

Кызга карап, тюльпан сөйгән кызга,
Үзенең ялгыз моңы хакында.
Кыя алмыйм серем ачарга ди,
Юкса, яры да бик якында!

Кыз шат: аның күңеленә бу җыр
Шушы иртә кебек кадерле.
...Ничә гасыр инде ул җырларны
Ишетә җир, дала бәгыре.

Һәрчак татлы сулыш ала җырдан,
Ул узганын үзенең, күргәнен
Һәр таң саен сөйли. Тыңлыйм, аңлыйм...
Әй җәйләвем, туган җирләрем!

**Рәдиф ГАТАУЛЛИН тәрҗемәсе**

# Җолдашбай Дилмуратов

## Вакыт үткән саен

Вакыт үткән саен Ленинның сүзләре
Ишетелә бара һаман еракларга.
Авыр чакта безгә көч һәм илһам биреп
Яңгырый алар шәһәрләрдә, кышлакларда.

Вакыт үткән саен бөек Ленин үзе
Юл күрсәткән йолдыздай якты бара.
Кешеләрнең аңа булган мәхәббәте
Көчәя гел, йөрәкләрне биләп ала.

Вакыт үткән саен Ленинның эзләре
Тирәнрәк уела җиргә һәм уелыр.
Бөтен дөнья карый аңа хөрмәт белән,
Ул эзләргә мәңге-мәңге чәчәк куелыр.

Вакыт үткән саен барлык һәйкәлләр дә
Тагы да матур, мәһабәтрәк күренә күзгә,
Ленинны күреп сөйләшкән кешеләр дә
Кадерле һәм изге инде хәзер безгә.

Вакыт үткән саен Аму буйларында
Артыр җимеш бакчалары, бизәп ярны.
Ленин акылы, Ленин фикере торган саен
Бәхетлерәк итәр каракалпакларны.

**Фәнис ЯРУЛЛИН тәрҗемәсе**

## Матен Сәетниязов

### Дөя һәм чүл

Дөя яши, имеш, ком чүлендә
Рәхәт чигеп кенә, бер кайгысыз.
Кызган җилләр, утлы нурлар илен
Рәхәт дия ала, я, кайсыгыз?

Кайнар көлдәй, кайнар ком пешерә
Көннәр буе аның табаннарын.
Нигә тарта аны сусыз дәрья,
Шәрә бушлык нишләп аңа якын?..

Мөмкинлеге булса, эссе комда
Яшәр идеме ул гомер буе?
Чәнечкеләр белән тик җан асрар
Идеме ул, булса үлән куе?

Авыр йөкләр ташый, армый, диләр,
Дөя бит ул әрсез, түзем, диләр.
Эссе давыл күзен сукыройтуын,
Кибегүен чүлдәй ник белмиләр?

Ана сөтен имгән чакта ул да
Тай шикелле сикергәләп йөргән.
Комнар күчкән, уйнар чаклар үткән.
Яшь дөянең башына уйлар кергән.

Кура чәйни-чәйни, ана дөя
Яшәү серен төшендергән аңа,
Су тавышын хәтерләми торган
Үле кырда, буп-буш сахраларда.

Әтрафында шаулап үлән үссә,
Ул, әлбәттә, утлар иде үлән,
Бормаланып сулар агып ятса,
Эчәр иде ул да ләззәт белән.

Ымсындыра аны ерак илләр,
Сулар зәңгәр анда, чирәм яшел...
Ләкин дөя чүлдә туып үскән,
Чүл улы ул... шуңа чүлдә яши.

**Фаил ШӘФИГУЛЛИН тәрҗемәсе**

## Генжемурат Есемуратов

### Дөге кырлары

Әйләнәме кыр өстендә ак казлар?..
Җырлый дөге игүчеләр, яшь кызлар.
Синең уйны бер сүзсез бит аңлыйлар —
Тугры дустың күк бу дөге кырлары.

Хыял оча агым су якасында,
Чабак тоткан акчарлактай җаның да,
— Китәм алтын куллыларның барын да,—
Диган кебек бит, күр, дөге кырлары!

Тук башаклар көяз: сырга такканнар,
Сер бүлешеп, тирбәлешәләр алар.
Һәр урында күңелле җыр яңгырар —
Гаҗәеп дөнья бу дөге кырлары!

Алдыңда йөгергән сулар тоныж,
Суга төшкән күктән Ай — көмеш сыныж,
Егет — ихлас, ә кызда алтын холык,—
Аларга мәйдан бу дөге кырлары!

Исең китеп суларның агышына,
Күзең төшә яшеллек нәкышенә,
Җиләс чатырына — таллы ярына...
Хәйран итәрлек бу дөге кырлары!

Изге уй белән орлыгын чәчкәнгә,
Хезмәтеннән халкым ямь-тәм тапканга,
Кырлар яратып кочагын ачкан ла! —
Бәһасе юк байлык — дөге кырлары!

**Рәдиф ГАТАУЛЛИН тәрҗемәсе**

# Гөлстан Шаһморатова

## Кырыккыз даласында

Бу дала гасырлар буена тын яткан,
Ә хәзер — гөлбакча, кем аны чит күрер?!
Кунакка килсәгез әгәр сез бу якка,
Бүләккә сөйгән яр чәчәкләр китерер.

Кичләрен күкләрдә балкыса йолдызлар,
Әй, уйный агыган каналлар өстендә;
Бакчада йөргәндә тәкәббер яшь кызлар,
Тынгы юк егетләр күңеленә һич кенә.

Эшләре бәхетле йөзендә чагылган —
Дәһканның кулына кем бәя бирә соң?! —
Даланы гөлбакча ясаучы пәһлеван
Үз халкын чын-чынлап сөядер, күрәсең...

Мине бу бакчага чакырды хыялым,
Чакырды язарга заманча дастаннар,
И матур манзара! — хисләрем тыялмыйм —
Як-якка агачлар тезелеп басканнар.

Һәр чәчәк җыр булып килә күгазьгә,
Ә көен ул җырның язадыр былбыллар.

Гөлбакча чәчәккә күмелгән һәр язда
Ашкынган күңелне чакыра ак юллар.

Бу дала гасырлар буенча тын яткан,
Ә хәзер биредә яңу бар, ярсу бар.
Кырыккыз даласы чакыра кунакка —
Бакчачы үз күреп, сөенеп каршылар.

Әхмәт РӘШИТОВ тәрҗемәсе

# Озакбай Пирҗанов

## Каеннар

Юл читендә айкала да чайкала
Ак каеннар, яшь каеннар,
Каеннар...
Тирә-якта шаулый бодай диңгезе,
Сорый кебек: «Әйтче, егет, син безгә —
Күңелеңдә нинди уй бар, кайгы бар?»

Уем тик шул: ятыйм каен төбендә,
Арып-талып бодай ургач хәл алып,
Сайрар кошлар яңгыратсыннар тирәмне,
Серләшсен дә шыбырдашсын һәр яфрак —
Серле булу каеннарга хәләл ул.

Яки ятыйм каеннарның төбендә,
Есенинның томын тотып, уйланып.
Ай тулышкан һәм болытсыз кичләрдә,
Таң чыкларын кетеп алалмый һич тә,
Тирбәлешсен ак каеннар — уянып.

Марс ШАБАЕВ тәрҗемәсе

# Олымамбет Хожаназаров,

Үзбәкстан ССРның комсомол премиясе лауреаты

## Тауларда болытлар очраша

Еракта күренә биек тау,
Түбәсен ап-ак кар каплаган.
Шушында болытлар очраша,
Килгәннәр бик ерак яклардан.

Еракта күренә зәңгәр тау.
Әйтә ул: «Мин күкне терәдем!»
Ә аның киң җәйгән куйнында
Чиксез зур диңгезне күрәмен.

Еракта-офыкта олы тау,
Сузылган мәһабәт гәүдәсе.
— Күрегез!— дигәндәй тора ул,—
Бу җирнең мин инде кәгъбәсе!

Тау тора еракта-еракта,
Түбәнгә ыргыла елгалар...
Мин карыйм дәрвиштәй: йөрәктә
Хисләрем моң булып кузгала.

Ерактан күренә биек тау,
Түбәсен ап-ак кар каплаган.
Шушында болытлар очраша,
Килгәннәр бик ерак яклардан.

Самат ШАКИР тәрҗемәсе

## Түләпбиргән Матморатов,

Каракалпакстан комсомолы премиясе лауреаты

### Алты юллыклар

●

Ил дигәннәр иле өчен янганнар,
Янсалар да, илне саклап калганнар.
Җан саклыйм дип икейөзле адәмнәр
Дусларын да янган утка салганнар.
Җансыз кеше намус сатып көн күрер,
Намуссызлар пычрак атып көн күрер.

●

Азамат ир туган йортын оныпмас,
Үлгәндә дә уйлап үлəр үз илен.
Ә ялагай һәр кешегә баш ияр,
Җанын саклап калыр өчен үзенең.
Батыр егет ил күтәрер иңендә,
Куркак мескен почмак эзләр өендә.

Хәкимҗан ХАЛИКОВ тәрҗемәләре

## Толыбай Кабулов

### Син дип тибә минем йөрәгем

Аму-Дарья, ургып агасың,
Дулкыннарың ярга кагасың.
Агышыңны, бөтен дөртеңне
Ашкынулы җырга саласың.
Тыңлар өчен матур көйләрең,
Ярларыңа һәркем киләмен —
Син дип тибә минем йөрәгем.
Төннәрен Ай синдә коена,
Йолдызлардан мәрҗән коела.
Якты төндә синең янына
Ай белән Җир чыга уенга,
Йолдызларның алтын нурларын
Үзенә җыйган синең суларың,
Шуңа ямьле синең буйларың.

Ярларыңда шаулый таллыклар,
Дулкыныңда уйный балыклар.
Сәяхәткә чыксаң әгәр син,
Алып китәр ап-ак каеклар.
Басып торам ярың буенда,
Агымыңа кушыла уем да.
Гүзәллегең чагыла җырымда.
Нинди матур синең агышың,
Гел тыңлыйсым килә тавышың.
Суың синең ефәк тасмадай,
Туган илнең бизәк-нәкышы.
Якын миңа талың-тирәгең,
Дулкыннарың, ярың, җилләрең —
Син дип тибә минем йөрәгем.

Фәнис ЯРУЛЛИН тәрҗемәсе

# Киңәшбай Рахманов,

Бердах премиясе лауреаты

## Мәхәббәт

Илгә булган мәхәббәтемне
Тиңли алмам океан белән:
Ярлары бар аның, төбе бар —
Никадәрле булмасын тирән.
Тиңли алмам океан белән.

Сөюем зур Җир шарыннан да.
Магелланнан башлап, күпме зат
Җир әйләнә кылган сәяхәт —
Илгә булган минем мәхәббәт
Зуррак шул Җир шарыннан да.

Бу чамасыз олы гыйшкымны
Тиңләп булмас таулар белән дә,
Биеклеге җитмәс тауларның,
Хәтта башы күккә тигәндә,—
Тиңли алмам таулар белән дә.

Әгәр ялгыш итсәм хыянәт,
Ярты юлда тотсын йөрәгем,
Илем бирсен зурын җәзаның,
Калмасын һич минем кирәгем —
Әгәр итсәм ялгыш хыянәт.

Мәхрүм булыйм ул чак барсыннан:
Җирнең бер уч туфрагыннан,
Океанның тамчы суыннан
Һәм тауларның сыңар ташыннан —
Мәхрүм булыйм ул чак барсыннан.

**Фәнис ЯРУЛЛИН тәрҗемәсе**

# Әҗинияз Таҗибаев

## Бала дип...

Бала дип, баш булып йөрмә балаңа,
Бала дип, яшь диеп йөрмә балаңны.
Яхшылыкка өйрәт аны — онытма
Балаң синнән һәрчак үрнәк алганны.

Безсез белмәс бала караны-акны,
Бездән башка бала булыр көр-шатмы?
Пакъ күңеленә чәч изгелек орлыгын,
Үсеп чыксын — ычкындырма форсатны.

Кулдан килгән кадәр өйрәт балаңны...
Көне җиткәч, кош канаты таладыр —
Берәм-берәм китәрбез без... Бездән соң
Җир язмышы балаларга каладыр.

**Марс ШАБАЕВ тәрҗемәсе**

# Марат Карабаев

## Кулъяулык

Серен сөйли миңа бүләк кулъяулык,
Көлеп сөйли, сөенеп көлгәне кебек.
Миңа бүләк кулъяулыкның чуклары —
Сөеклемнең күз керфекләре кебек...
Бизәкләре — сүзләре сөеклемнең.

Укып була, аңлап була үзләрен.
Бу кульъяулык сыйпый мине битемнән,
Бу кульъяулык үбә минем күзләрне.
Аннан җайлап төш кесәмә урнаша
Һәм йөрәгем белән минем серләшә.

Рөстәм МИНГАЛИМ тәрҗемәсе

# Сәйдәбулла Пирҗанов

## Дөнья

Көннәр уза бер-бер артлы тезелеп.
Былбыл булып сайрар идем өзелеп.
Җир бүлеште синең белән барсын да.
Безнең белән дә бүлеш, күк, тарсынма!
Яшь идем мин ул чакта!
Сугыш кырларында була алмадым,
Бурычлы да булып ләкин калмадым.
Сугыш безнең икмәк белән туенды.
Йолдызлар күз яше булып тоелды.
Яшь идем мин ул чакта!
Ул вакытта йолдызлар күп атылды.
Ятимлек тә, кайгылар да татылды.
Ак-караны бутама, дип бәйләндең.
Уйларымның асты-өскә әйләнде.
Яшь идем мин ул чакта!

Кочагыңа ана кебек кыстың син,
Бу сәфәрдә ялгышмаска куштың син.
Юл күрсәтте миңа синең йолдызың.
Ул күрсәткән юлдан киттем. Юл — озын!
Яшь идем мин ул чакта!
Элеккедән сине ныграк яратам.
Күк йөзеннән болытларны таратам.
Кояшлы һәм айлы зәңгәр күгеңне
Карап тору әллә бәхет түгелме?!
Ә дөнья гел яшәрер!
Көннәр һаман артта кала, арттарак...
Хыялларым әверелә аккарак.
Сиңа карап күзләрем гел яшьләнер.
Дөнья әле миннән соң да яшәрер!
Миннән соң да яшәр ул!

# Хикмәтулла Айымбәтов

## Билгесез солдат һәйкәле янында

Дөнья якты бүген! Ә мин карыйм
Балкып торган зифа сынына.
Нидер әйтер өчен чаганнар да,
Каеннар да миңа сыгыла.
Сугышчылар кебек тора алар
Солдат каберендә. Тынлыкта.
Килгән саен ала алмыйм күзне
Ялкынланып янган тын уттан.
Утлы еллар искә төшә монда.
Кара ташны ялмый, яна ут!
Кем өчендер үкси, үкси ул ут!
Таш тәнендә күпме яра, ут?!
Кошлар күккә күтәрелгән саен
Йөрәк дулый, өскә үрелә.

Кара ташта, ялкын телләрендә
Мин матурлык телим күрергә!
Шәрык-гарәп уртасында — Урал!
Горур тотып тора ул сынын.
Идел ага! Басып ята ул да
Ике материкның сусынын.
Ак каеннар күккә сузылганнар,
Ә үзәннәр гөлләр эчендә.
Һәрбер чәчәк — үзгә, һәр җыр — үзгә.
Сөенәм мин шуның өчен дә.
Кайда яшәсәк тә, дөнья матур!
Матурлыкның беләм телен мин.
Мин илләргә, барлык халыкларга
Халыкара Бәхет телимен!

Роберт МИҢНУЛЛИН тәрҗемәләре

Түләпбирген Каипбиргәнов,
*Үзбәкстанның Хәмзә исемендәге һәм Каракалпакстанның Бердах исемендәге премияләре лауреаты*

# ӘЗ-МӘЗ ҮЗЕМ ХАКЫНДА



Иң ансаты да, иң кыены да үзең хакында сөйләү һәм язу. Ансатлыгы аның шунда — кеше үз-үзен шул дәрәҗәдә яхшы белә ки, бу дөньяда аны башка һичкем һәм һичкайчан алай белә алмаячак.

Кыенлыгы исә шунда — бер генә кеше дә үзе хакында бар булганын әйтеп бетермәячәк. Әйтә алмаячак ул аны. Бер урында үзең хакында бәйнәбәйнә сөйләп йөрү җайсыз булса, икенче бер очракта чит-ят бәндәләргә барлык сереңне чишеп ташлаудан тыелып калачаксың. Бәгъзе бер урында инде үзең хакында җәелеп сөйләү, үз бәһаңне үзең күтәрү, мактану сыман тоелыр иде. Кыскасы, ничек итсәң дә читен булачак.

Менә мин дә, үзем хакында әңгәмәне нидән башларга да белми, аптырап, бик озак утырдым.

Бальзак үзе турында сөйләр алдыннан иң әүвәл, хөрмәт йөзеннән, баш киемен салып куя торган булган. Әлбәттә, әңгәмәдәшен олылап хөрмәтләгәнгә ул шулай иткән.

Үзем хакында язар алдыннан мин дә, гәрчә баш киемемне читкә алып куймасам да, укучым алдында ни дәрәҗәдә җаваплы булуымны тагын бер кичердем. Бу, димәк, әлегә мин үземне әүлиягә санамыйм дигән сүзләр.

Бу язмада үз иҗат юлыма тукталырга, дөресрәге, укучыма үз-үземә булган мөнәсәбәтемне төшендерү өчен ике сәбәп бар сыман. Беренчесе шул: бер танышым, очраган-саен «язучылар нииндирәк була соң ул?» дип йөдәтә иде. «Язучы ул иң элек эш үгезе булырга тиеш, башкалар кебек эш сәгатендә генә түгел, ә иртәдән кичкә чаклы туктаусыз, гел дә тынмый һәм беренче, һәм икенче сменада эшләргә тиеш. Менә кем ул язучы», дип җавап бирдем мин аңа. Ул миннән башкачарак җавап көткән иде ахры. Шул көннән башлап миннән читләште, мөнәсәбәте үзгәрде моның. Инде күрешкәндә үзен өстен тотып сөйләшә торган булды.

Икенче сәбәп тә беренчесеннән аерылгысыз. Берәү миннән: «Каракалпакстанда ничә язучы бар?» дип сораган иде, мин аңа «икәү» дип җавап бирдем. «Алайса атап әйт» диде бу. «Түләпбирген Каипбиргәнов һәм башкалар» дидем мин. Ул, «әй, мактанчык» дигән шикелле, борынын гына җыерды да, кабат минем белән сөйләшмәс булды, шул «башкалар» белән катнашып китте. Бер заман без моның белән тагын очраштык. «Теге вакытта син атаган ике язучының кайсысы беренче

соң?» диде бу. «Әлбәттә, башкалар» дидем мин ике уйлап тормастан. Миндә кече күңеллек сыйфатлары чамалапмы, әллә икенче генә булуыма сөенепме, бу юлы әңгәмәдәшем бик рәхәтләнеп көлде.

*
* *

**Булган вакыйга.** Газетада беренче язганнарым басылып чыкканнан соң, «инде әдәбият әһелләре арасына керерлек булдым» дип, күкрәк киереп, куанычымны уртаклашу өчен үзем үскән авылдан чыккан, миннән чак кына өлкәнрәк кешегә киттем. Газеталарны күрсәттем. Ул мине куанычым белән котлаган кебек булса да, соңыннан, нечкә озын мыекларын сыпыргалап, бик серле итеп көлеп тә куйды.

— Нәрсә? Ятышмыймы әллә? — дидем мин.

Ул бер ара сүзсез утырды. Аннары:

— Шагыйрьләр арасында йөргән бер анекдотны беләсеңме?— дип сорады.

— Байтак шагыйрьнең гомер юлын яттан беләм. Пушкинны, мәсәлән, Гете хакында да бик күп укыдым. Бөтендөнья әдәбиятының гиганты Лев Толстой хакында да бераз мәгълүматым бар. Ләкин аларга кагылышлы бер дә анекдот ишеткәнем юк.

— Юк, мин алар хакында түгел, үзебезнең каракалпак шагыйрьләрен әйтәм. Алар даирәсендә йөргән анекдотны ишетмәдеңме дип соравым,— диде ул.

Мин хәйран калып:

— Юк, ишеткәнем юк,— дидем.

— Алайса тыңла. Бөек Ватан сугышы елларында бер акыллы башның башына каракалпак шагыйрьләреннән генә торган бер кечкенә команда төзү хыялы килә. Билгеле, шагыйрьләр — патриот халык, барысы да моның белән килешәләр. Билгеләнгән сәгатькә килеп стройга басалар. Командир:

— Беренче, икенче дип санарга! — дип команда бирә. Ни хикмәт, һәр шагыйрь, чираты җитү белән, «беренче!.. беренче!» дип кычкыра икән. Болар команданы аңламадылар ахры дип, командир:

— Янә бер кат, мин беренче, мин икенче, мин өченче, мин дүртенче дип нәүбәт белән санап чыгыгыз! — дип, озаклап төшендерә.

Әмма шагыйрьләр тагын, бер-беренә карана-карана:

— Мин беренче!.. Мин беренче!.. Мин беренче!..— дип кычкырына башлыйлар. Шулай итеп, ни тырышсалар да, шагыйрьләрне нәүбәтләп саната алмыйча команданы таркатырга мәҗбүр булалар. Берсенең дә «мин икенче» дип кычкырасы килми. Шуннан соң һәр шагыйрьне аерым-аерым сугыш кырына озаталар.

Якташым үтә дә каһәрле итеп, мыскыллы көлү белән озаклап көлде.

Тик ул минем ачуымны гына чыгарды. Мин аңа болай дип җавап бирдем:

— Ялгышасың, бу анекдот шагыйрьләр хакында гына түгел, ул һәммәбезгә кагыла,— дидем.— Әйтче, тормышта беренче булырга теләмәгән кем бар? Әйтик, цехта эшләүче эшче беренчелеккә омтыламы? Омтыла. Колхоз бригадалары беренче булырга тырышамы? Тырыша. Нинди генә кәсеп иясен алма — алдынгы, беренче булырга теләмәүчене очратмассың. Чөнки кеше дигән затның күңеле шулай яратылган. Минем дә беренче буласым килә. Синең дә максатың шул. Минемчә, бу һәркемдә була торган иң яхшы ният. Беләсең килсә, яшәү таләбе!

Ул минем әйткәннәрне инкарь итмәстән:

— Сүз бит бирелә шагыйрьләр арасында йөргән анекдот турында бара,— дип куйды.

— Чөнки шагыйрьнең бөтен коралы сүздән гыйбарәт. Күркәм сүздән... Ә бит беләсез, һәр сүзнең берничә мәгънәсе бар. Начары һәм яхшысы. Минемчә, күркәм сүз иялоре — шагыйрьләр арасындагы көнләшүне дә әнә шул яхшы мәгънәдәге көнләшү итеп кабул итәргә кирәк. Хәтта алар бер-берен тәнкыйтьләгәндә дә, моңа аларның берберсен яманлавы итеп түгел, өйрәтүе, ялгышын төзәтергә тырышуы дип аңларга тиешбез.

Шуннан соң авылдашым күп уйланмый:

— Тормышны әз-мәз чамалыйсың икән, болай булса, теләгәнеңә ирешерсең,— диде.

Күпме гомер үткән, ә ул сөйләгән анекдот һичкайчан хәтеремнән чыкканы юк. Әдәбият дөньясында исемем күренә башлаганнан бирле, хактан яисә нахактан әйтелгән һәм язылган һәр сүзгә игътибарлы булырга тырыштым. Берәр әсәр яза башлар алдыннан туган әдәбиятымның тәҗрибәсен кат-кат барладым, элгәрге чыгармаларны кайтакайта карап, аларда сурәтләнгән характерларны үз халкым характеры белән чагыштырып аныклауны хуп күрдем. Кешеләргә яманлыкның нәрсә икәнлеген күрсәтеп бирү белән генә канәгатьләнми, аларның яхшылыкка, яктыга булган омтылышларын да диккатьтә тоту кирәк иде! Шунлыктан, беренче чиратта халкымның тәкъдирен, аның әйләнә-тирәсендәге халыкларның язмыш-көнкүрешен, үз кабиләмнең шул күршеләре белән яшәү мөнәсәбәтләрен — уртак тәкъдирләрен белү, өйрәнүне максат итеп куйдым. Шуңа бил бәйләдем.

*

* *

Үз гомеремдә хәйран калырлык күп кенә вакыйгалар булды. Шуның берсе һаман да истән чыкмый, онытылмый әле. Ул көнне мине Каракалпакстан АССРның Верховный Советына депутат итеп сайладылар. Мин әле ул вакыт үз хезмәтемнең алай югары бәяләнүен уйламый да, көнелемә дә китерми идем. Иң әүвәл үз-үземә: бу олы хөрмәткә син лаеклымы дип сорау куйдым.

Әйе, бу очракта кешенең бүгенгә чаклы эшләгәне генә түгел, эшләячәге дә искә алына дип уй йөртәм. Әйе, бу әле сиңа аванс кына, дим. Гомереңнең соңгы чигенә хәтле син тагын да әйбәтрәк, тагын да уйланыбрак иҗат итәргә тиеш буласың, дим. Халкым ышанычын һичшиксез акларымын дип сүз бирәм. Халкыңның бер яхшылыгына син кырыгы белән җавап кайтарырга тиешсең дип күңел беркетәм.

Шул мәлдә атам сөйләгән бер мәгънәле сүз исемә төшә. Суфыйлыкта яшәгән шагыйрь Бердахның күңеле тулып китсә, дөнья сүзе белән якыннарын борчып, хафага салмас өчен, ул Арал диңгезе буена бара яисә Аму-Дәрья ярына чыга икән дә диңгез дулкыннарына, жай гына аккан дәрья суына карап:

— Әй, Күгаллам, күк диңгезем! Әй, агымсу дәрьям! Әйтегезче миңа, ни өчен мин бу дөньяның серләренә һаман төшенеп җитә алмыйм соң!? Нишләп кешеләр мине аңламыйлар! — ди икән.— Берәүләрнең күңелен күрим дип эш итәсең — алар аны киресенчә аңлый. Инде шуның киресен әйтеп, туры юрарларымы дисең — тагын ялгышасың, тагын үзеңә кыенга кила. Юри ялгышты бу, диләр. Әй, адәмнәр! Шагыйрь булсам да мин җиһанның сездәй үк бер кешесе ич! Ә кешенең үз-үзен аңлап бетермәгән, үз-үзе белән идарә итә алмаган, ялгышкан чаклары да була бит. Ара-тирә бәлки мин дә ялгышкалыймдыр. Тик белегез, минем бар теләгәнем — хаклык. Мин әйткәннәрне кем һәм ничек кенә аңламасын — хаклык өчен һәм халкым өчен әйтергә теләдем мин аларны. Барлык шигырьләремне, бөтен гомеремне шуңа багышладым, аңлагыз мине. Инде бөтен теләгем дә шул: берберебезне аңлашсак, төшенешсәк икән дип ялварам!!!

Кайвакытларда олуг шагыйрь дулкыннарга карап шулай дип ялварган икән диләр. Үз күңелендәгеи халкына тулаем аңлатып әйтеп бирә алдыммы дип икеләнүдән шулай иткәндер инде ул. Аңлашыр, төшенешер чор килүенә дә өметен өзмәгәндер, билгеле.

Шулай да шагыйрьнең бу фикере үз заманында яшерен сер булып калды, ул үзе хакында бервакытта да ачык итеп әйтә алмады. Инде безнең заманыбыз бөтенләй башка, күңелләребездәгеи ачык итеп әйтер көн килде. Үзең турында хаклыкны әйтү гаеп ителми. Хәтта совет художнигы Коненков мәрмәрдән үз автопортретын ясаганы өчен Ленин премиясенә лаек дип тә табылды. Тик эшләгән эшең, әйткән, сүзең барлык кешелек дөньясының төп юнәлешенә, төп максатына туры килерлек, аның көрәш юлында көч өстәрлек кенә булсын.

Әйе, мин үзем хакында барын да батыр һәм ачык итеп әйтүне нәзер итсәм дә, нилектәндер һаман кыенсына бирәмен, сакланамын сыман. Бердахтай олы затларны тартынчак иткән халкымның минем каныма да үтеп кергән психологиясенең әле үзгәрмәү билгеседер бу, мөгаен. Әллә юкса, үзем турында үзем яза башлап та, үзем дә аңлап бетермәгән кимчелекләремне укучыма ачып салырмын дип шикләнәмме? Я булмаса, мине төшенмәсләр дип куркаммы соң? Анык кына ни дип тә юрый алмыйм, әмма ләкин нидер тота кебек, тартындыра кебек.

Каракалпакстанлы каләмдәшләрем белән укучыларымны күбесенчә бер нәрсә хәйранга калдыра: мин, ягъни Каипбиргәнов Түләпбиргән, шул чаклы кыска вакыт арасында ничек итеп берничә зур роман авторы була алганмын соң? [1] Һәм ни өчен мин тап бүгенге көнне түгел, ә үткән тарихны сурәтләргә керешкәнмен? Шундыйрак сораулар туа күп кешедә.

Бу очракта мин аларга җавап итеп: әгәр дә сез Каракалпакстанның миңа кадәр яшәгән бер буын язучылары белән генә тыңлап калмый, башка халыкларның язучылары белән дә чагыштырып укысагыз, мине болай аптыратмас идегез димәкче буламын. Тик алай дип әйтеп, укучымны да рәнҗетәсем, билгесезлектә калдырасым килми.

Ә бит дөресен генә әйткәндә, мин әле күп нәрсәгә өлгерә алмаганмын. Күңелдә барның күп өлеше әле язылмаган бит. Моның төп сәбәбе: әдәби әсәрне язу серләренә, аның вазыйфасына мин шактый соң төшендем. Беренче повестем бары тик егерме алты яшемдә язылды. Беренче тарихи романым миңа утыз тулганда дөнья күрде. Шуннан соңгы егерме елга якын дәвер эчендә язганнарымны, бар мөмкинлегем нисбәтендә карасам да, житәрлек дип әйтә алмыйм. Моның төп сәбәпләреннән мин бары бер нәрсәне — инде бетте дип нокта куелган әсәрләремне дә кайта-кайта эшләүгә киткән вакытны гына күрсәтә алам. Мәгәр анысына үкенмим. Үкенечем — яшьли күп итеп эшли алмавымда. Мин үземне егерме биш яшемдә ир булып житкән кешегә исәпли башладым. Ә бит без укып белгән бик күп каһарманнар, шул җәһәттән Пушкин, Лермонтов, Добролюбовлар инде бу яшькә тиклем дөньяга чыгарлык эшләр эшләгәннәр. Замандашыбыз Шолохов егерме биш яшендә илгә танылган. Шуларны искә төшерсәм, миңа моңсу булып китә.

Инде килеп халкыбызның тарихи үткәненә, минем шул үткәнгә багышлап әсәр язуыма тукталсак — бу хакта инде мин шул романнарның кереш сүзендә үз карашымны берникадәр белдергән идем. Мин укып, халыктан өйрәнеп белгән тарихны, тарихи вакыйгаларны, төкми-чәчми, бозмый гына сурәтләргә теләүдән башланды ул эш.

---

[1] Бу әсәр 1979 елда язылган. Ана чаклы ул 5 повесть һәм 6 роман, хикәяләр авторы (тәрҗемәче искәрмәсе).

Кемнендер халык тарихын бозуыннан да курыктым дияр идем мин. Шул сәбәпле ул ерак үткәннәрне өйрәнүгә, аннары, белгән кадәрен укучы күңеленә җиткерерлек итеп бәян итүгә мин шактый хезмәт куйдым. Бу юлдагы төп максатым шул: аз санлы халкым бүген автономияле республика булып, өч орден алган Каракалпакстан булып яши. Борын заман шуның кемлеген дәлилләү кирәк иде. Һәркемгә мәгълүм бер факт: спорт тамашачылары да ярышта узган спортчыга кызыгып карый, аның бу ярышка тикле нинди күнегүләр үтүе, нинди тормыш узуы белән якыннанрак танышасылары килә бит.

Минем Каракалпакстанымны алсаң — ул да көчле, нык, чыныккан спортчы кебек, бүген һаман алга бара. Бу уңышның нигезен, үткәнен белергә теләү, белгәненңне башкаларга җиткерергә теләү — иҗатымның чишмә башы шул булыр.

Без, 1929 елгылар туганда, инде Каракалпакстан республикасы төзелгән булган. Мин совет мәктәбендә укыдым, тиңдәшләрем, чордашларым башыннан нинди авырлыклар узса, алар нинди бәхетләргә ирешсәләр — мин дә алар белән булганмын, алар кичергәнне кичергәнмен.

Атам-анам белемсез диярлек: ликбезгә йөреп, латин хәрефләре белән берсе Каипбиргән дип, икенчесе Гөлхан дип үз исемнәрен бик авырлык белән язарга өйрәнгәннәр. Белеме ягыннан һичкемнән аерылып тормаган атам, үз тырышлыгы нәтиҗәсендә, колхозның звено җитәкчесе булып йөрде, шуннан югарырак күтәрелә алмады. Ярым-ярты хәреф таныган анам тракторны өйрәнде, Бөек Ватан сугышы елларында кырларыбызда трактор йөртте. Хәзер инде алар икесе дә өлкәннәр, хаҗәте булмагач, латин хәрефләрен дә онытып бетергәннәрдер.

Гадәттә, ата белән бала арасында төшенмәүчәнлек, каршылык яши диелә. Әти белән безнең арада андый хәл булганын хәтерләмим мин. Тик бер вакыт мин аңардан:

— Әти, мәрхүм атаңның нинди сүзе хәтереңдә калган?— дип сорадым.

— Мин ир-егет булганда атам «балам, нигәдер мин сине аңламый башладым әле» дигән иде,— дип җавап кайтарды әти.— Шулчак мин аптырабрак калган идем. Хәзер үзем сезне төшенеп җитә алмыйм сыман. Бәлки, улым, син дә үз улыңа минем һәм бабаң сүзләрен кабатларсың,— диде.

Хәзер үз балам буйга үсеп җитте. Безнең арада да вакыт-вакыт килешмәүчәнлек булгалап куя. Мәгәр каршылык юк шикелле. Бала үстергәндә һәр ата аның тизрәк акылга утырып, үсеп җитүен, арага керүен тели, бергә-бергә озак яшәүне тели. Бала исә, үсеп җитеп акыл туплаганның соңында, үз юлын эзли башлый. Бу инде табигатьнең шулай яратуы, ихтыяҗы. Алга китеш ихтыяҗы. Ата белән бала арасындагы иң зур каршылык, минемчә, менә шушы.

Мин туганда атама егерме бер, анама унтугыз яшь булган. Шулай итеп мин аларның беренче мактанычы булганмын. Беренче тәрбияне мин күбрәк әбидән алганмын. Аның тормыш фәлсәфәсе бик борынгы, тотрыклы иде. Кабатлаган сүзе шул: «Кеше баласы кем булып туса шулай гомер уздырачак, аны бер кем дә, берничек тә үзгәртә алмаячак», дия иде. Мин аның белән күпме сүз көрәштердем, китаплардан аңа каршы күпме мисал китердем, тик бу фәлсәфи карашын үзгәртә алмадым.

Әбиемнең үлгәнчегә хәтле үзгәрмәгән икенче бер гадәте (ул 1945 елда дөнья куйды) — бәрәңгене һичкайчан ашамлык дип, мөселманга килешә торган ризык дип кабул итмәве булды. Бар булган ашамлык бәрәңгедән генә торган елларны да ул фикерен үзгәртмәде. Әбиемнең дини йогынтысыннан мин алай тиз генә арына алмадым шикелле. Педучилищены тәмамлап, өч ел укытучылык иткән елларда да

әле, кайта-кайта, ул тәрбия үзен сиздереп куйгалый иде. Пединститутта марксистик диалектиканы үзләштергәннең соңында гына әбием һәм өлешчә атам фәлсәфәсе белән иңгән ул дини төшенчәләрдән ваз кичтем.

Шулай итеп, үсмер егет булганчы гомерем гаилә белән, үз туган авылымда үтте. Илдә авыл, калаларның күплеген белеп үссәм дә, ул чакта үз авылым дөньяның кендеге кебек тоела иде. Билгеле инде, авыл халкының шатлыгы уртак, кайгысы һәрчак бергә була. Ул да минем тәрбиямдә билгеле бер урын тота.

* * *

Пединститутта мин рус теле һәм әдәбияты факультетында укыдым. Инде минем барлык уемны, ихласымны рус телен тизрәк үзләштерү хыялы биләгән иде. Ябырылып рус әдәбиятын укырга керештем. Шулчак үзебезнең каракалпак әдәбияты ничектер тоныкланыбрак калды сыман. Әлегә кадәр үземчә бик тә олылап, хөрмәт итеп йөргән язучыларыбызның китаплары буйга үскән кешегә кыскарыбрак калган кием кебек тоелды, тарайды шикелле.

Әйе, рус әдәбияты белән яхшылабрак танышкач та үземне берьюлы үсеп киткәндәй хис иттем. Инде үзем дә буш вакытны әрәм-шәрәм итми, бар булган тәэссоратны кәгазьгә матурлап яза башладым.

Бу елларда үзбәк әдәбиятының алдынгы вәкилләре Айбәк, Абдулла Каһһәр, казакъ Мохтар Әүэзов иҗаты белән дә якыннан таныштым. Аларның да алдынгы рус әдәбиятыннан үрнәк алып, үз җирлекләрендә үз юллары белән киткәнлекләрен чамаларга чамам житүгә бик сөендем.

Бәхетемә, пединститутны тәмамлаган елымда «Аму-Дәрья» журналын кабат чыгарырга дигән карар килде. Бу хәл 1955 елда булды. Каракалпакстан язучылар союзы җитәкчеләре рәсми кәгазь язып мине дә шунда эшкә алдырдылар. Журнал редакциясендә эшләү шулай ук мине күп нәрсәгә өйрәтте. Без, яшьләргә, институтта алган белемебезне, рус һәм дөнья әдәбиятыннан алган үрнәк-өлгеләрне үз җирлегебездә эшкә җигү, файдалану юлын уйлар көннәр иде ул.

Проза өлкәсендә көч сынап карарга теләгем дә үскәннән-үсә барды. Инде элек язган шигырьләр белән генә канәгать түгел идем. Чәчмә белән язганда Чеховның тапкырлык, кыскалык кебек иҗат үзенчәлеген дә, Лев Толстой, Достоевский кебек фикер иясләренең фәлсәфи фикерләвен дә өлге итеп булыр иде дип уйладым. Халык тормышының бөтен катлаулыгын Михаил Шолоховтай итеп тасвирларга булсаң да бу юл отышлырак тоелды миңа. Шушы олы шәхесләр иҗаты аша үз иҗат юлыңны табу, үз йөзеңне булдыру төп максат икәнен дә истән чыгармаска кирәк иде, билгеле. Әнә шул максатка күпмедер дәрәҗәдә ирешә алуыма, үз әдәбиятымда үз юлымны тапканыма бүген ышанамын.

* * *

Кыңрәк тукталсаң, минем язучылык юлымда өч баскыч булды. Аларның берсе дә үзем белеп күтәрелгән баскычлар түгел иде дисәм дә ялгыш булмас. Шулай ук читтән берәү дә күтәрешеп менгезмәде мине анда. Тормыш агышы шулай туры килеп, тартыша-тәртешә атлаган юлым шуңа илтте.

Ул баскычларның беренчесе итеп мин авылдан чыгып китүне, укуга юлыгуымны саныйм. Бу хәл 1945 елның җәендә булды. Бу вакыт әле

мин алтынчы класста гына укый идем. Артка калуның сәбәбе — 1942 елны зур ташкын булып, авылның су астында калуы, соңыннан яңа җиргә күченеп утыру мәшәкатьләре иде. Әйе, төшкә чаклы укыйм, ә төштән соң икенче һәм дүртенче классларны җыеп үзем укытам. Чөнки авылда укытучылар җитешми. Бер ел шулай үтте. Инде җидәнчедә дә укырмын да, укытырмын да диебрәк тора идем.

Теләгемә каршы, җәй урталарында авылга районо инспекторы килеп чыкты. Мине үз янына чакыртып алды. Мин Бибифатыйма белән Бибизәһрә исемле игезәк сеңелләрем һәм башка бала-чага белән бергә урамда, тузанда уйнап йөри идем. Бер яше тулмаган шул игезәкләрне күтәреп инспектор янына киттем. Үзем яланаяк, кулымда бала елый. Әмма инспектор, чакырткан булса да, минем белән сөйләшеп тормады. Мине укытучы дип танымады булса кирәк. Ә минем бик тә укытучы буласым килә иде. Аның чакыртып та сөйләшмәве мине гарьләндерде.

Өйгә кайтып шул хакта әнигә сөйләдем, ул мине ачуланырга тотынды. «Килгән кешегә сүз әйтергә дә ярамагач, кит, күземнән югал, күз көеге булып йөрмә каршымда»,— дип тиргәргә кереште. Хәтта сугып та алды. «Уку тавып укы» дип бетерде ул сүзен. Аннары атна дигәндә азык-төлек хәстәрләп букча белән аркама асты да, «уку тавып укы» дип өйдән чыгарып та җибәрде.

Шул китүдән инде мин өйгә кайтмадым. Күп җирләрдә йөреп, күп үткелләр үтеп педучилищега барып кердем.

Икенче баскыч итеп институтта үзем сайламаган факультетка эләгүемне исәплим. Педучилищедан соң өч ел авылда укытып, аннары Каракалпак дәүләт педагогия институтына килеп каракалпак теле һәм әдәбияты факультетына имтихан тапшырдым. Беренче сентябрьдә кабат Нөкистә җыелдык. Институт директоры Бекимбәтов берничә кеше ияртеп аудиториягә килеп керде, «әй, бала, син тор әле» диядия берничә егетне урыннарыннан кузгатты да, үзе белән әйдәп алып чыгып та китте. Шулар арасына мин дә эләктем. Шулай итеп, кырыклаган кешене башка бер аудиториягә җыйдылар да, директор: «Сез бүгеннән рус теле һәм әдәбияты факультетына күчереләсез. Теләмәгән кеше документларын алып өенә кайтып китә ала» дип белдерде.

Студент булуыбызга сөендек тә, болай килеп чыгуына көендек тә без. Болай да, рус теленнән көчкә-көчкә өчлегә имтихан тапшырып кергән идем, ничекләр генә укырмын дигән хафага төштем. Укудан калмас өчен миңа кене-төне утырырга туры килде. Шулай итеп йөрийөри, мин озак имләнә торган авыру алдым. Мәгәр чиргә бирешеп укуны ташлап китмәдем. Бигрәк тә авылдашларымның «Түләпбирген укый алмый кайткан икән» дигән сүзеннән курыктым. Түздем, тырыштым. Укуны җиңдем.

Нәтиҗәдә, үзем теләмәгән факультетта укуым минем офыкларымны ачып, киләчәк язмышыма бик уңай тәэсир итте.

Өченче баскыч итеп беренче повесть язуымны саныйм. Яшьли шигырь язу белән мәшгуль идем. Институтта уку елларында берничә хикәя иҗат иттем. «Почтальон килгәндә» исемле беренче хикәям яшьләр газетасы «Җас лениншы»да басылган иде. Шул ук газета редакторы икенче хикәям «Тракторчы»ны да бик яратты, ике санда бирде. Мине канатландырып җибәргән бу хәл, күңелемдә бөреләнеп килгән повестьны язуга бер адым булып хәтердә калган иде. Шулай да әле тиз генә андый зур эшкә тотына алмый йөрдем. «Аму-Дәрья» журналында эшли башлагач та талпынып карадым, әмма көзсез вакыт тимәде.

Менә көзге олы бәйрәм көннәре дә җитте. Кәеф-сафа коруга, аракы эчүгә артык маһирлыгым булмау сәбәпледерме, ул бәйрәмгә ни мине чакыручы булмады, ни мин беркемгә дә дәшмәдем. Урамга чы-

гып, айкалып-чайкалып йөрүчеләрне бер күреп кердем дә, барыннан да гайрәт чигеп, бикләнеп өстәл артына утырдым. «Нишләп әле мин әлегә кадәр ни шагыйрь ни прозаик түгел. Ике арада йөргәнче юк булуың хәерле» дип, көндәлдә йөргән повестьның беренче юлларына сүз туплый башладым. Шул утырудан ул язылып китте. Декабрь ахырларына машинкага бирерлек булды. Шулай итеп күләмле беренче әсәрем туды. Башка әсәрләремә юл ачылды.

*

* *

Яшьлегемдә, әдәбият дөньясына керергә хыялланып йөргәндә, бу юлның, бу хезмәтнең гаять тә катлаулы, авыр хезмәт икәнен искәрми идем, билгеле. Ул вакытта мин Гете биографиясен беркадәр белсәм дә, гениаль шагыйрьнең тирә-юнендәге тормыш кызыкларын күрү өчен һич тә бушамаганын, гомеренең соңгы көннәрендә шул сәбәпле үкенеч белдерүен укымаган идем. Лев Толстойның «Төш» дигән хикәясен егерме тугыз мәртәбә, гигант күләмле эпопея «Сугыш һәм тынычлык»ны унбиш кат күчереп язганлыкларын һәм шунан соң да әле, китап басыла башлагач, кайбер өлешен яңадан эшли алмавына үкенүләрен белми идем. Укымаган идем. Чеховның, кая гына бармасын, куен дәфтәрен үзеннән калдырмавын, теләсә нинди шартларда да язарга тиеш булуын да, Гоголь, Бунин кебек бөек шәхесләрнең дә ак кәгазь алдында сәгатьләр буе газап чигеп утыруларыннан да хәбәрдар түгел идем. Иҗат серләре шулай, бер укуда гына ачылмый да икән бит әле. Әнә, Шолохов та бит, «Тын Дон» романын бер китапта төгәлләргә ниятләп эшкә утыра да, ничә елдан соң гына, дүрт калын китап язгач кына үз дигәненә ирешә.

Беренче повестем аерым китап булып чыккач, башым күккә тиярдәй булып куандым. Аны кемнәр сатып ала икән, ниндирәк фикерләр әйтәләр икән дип тиз генә китап кибетенә йөгердем. Карасам, китабымны киштәгә Толстой, Шолохов, Чехов, Мопассан, Гоголь, Хемингуэй, Достоевскийлар китабы белән янәшә куйганнар. Моңа тагын бер кат чиксез сөендем дә, бик уңайсыз да булып китте. Китабымның ул бөек затлар иҗаты белән янәшә торуына шул кадәр уңайсызландым, кибетчедән сорап алып кулыма тотып карарга да, аның үз иҗат җимешем икәнен кемгә дә булса белгертергә дә базмадым. Ашыгып кибеттән чыгып ук киттем. Гүя ул бөек затлар, минем өскә ябырылып «Алып ташла ул китабыңны безнең киштәдән» дип әйтер сымак булды. Кеше арасында кала алмый, кыр-далага ук чыгып киттем.

Алдарак әйткәнемчә рус һәм дөнья әдәбияты классикларыннан мин күп нәрсәгә өйрәндем, аларның әсәрләрен кайта-кайта укыдым. Хәтта бер ара аларга ияреп кенә язмыйммы икән дигән шик тә туды. Иҗат эшендә бу иң ансат юл, тик аннан һәрвакыт саклану кирәк. Моның өчен сине һичкем гаепләмәсә дә бу ярый торган, үз әдәбиятыңны үстерүгә булыша торган юл түгел. Шәрык әдәбиятының күп гасырлык тарихы моңа ачык дәлил. Әнә шул, бер-береңә охшатып язу традициясе, бер ирешелгән уңышны кат-кат кабатлау, һәр яңа килгән шагыйрьнең остазы юлыннан тайпылмый барырга тырышуы көнчыгыш әдәбиятында бик күп исемнәрне югалту белән төгәлләнде дисәк ялгышмабыз. Нәваи, Гомәр Хәйямнар эзеннән килүчеләрнең исемен бүген белмибез диярлек. Бердахтан соң яңа Бердах та тумады. Дәвер итү белән халык ул кемгәдер ияреп язганнардан кызык тапмый, шул беренчел, остаз әсәрен генә үз итеп, кабул итеп ала.

Менә ни өчен күпме гасырлар инде кешеләрнең рухи азыгы булып Гомернең «Одиссия», «Илиада»лары яши, «Сугыш һәм тынычлык», «Тын Дон» эпопеяларын да шундый язмыш көтә. Бу әсәрләр безнең

өчен мәңгелек. Гомер, Шекспир, Толстой, Шолохов иҗат иткән берен-чел әдәбият, үз чорларының төп юнәлешен, төп хәрәкәтен билгеләгән әсәрләр буларак, шул чор каһарманнарының тулы канлы характерла-рын калку итеп тасвирлаган әсәрләр буларак мәңге онытылмаячак-лар. Бөек Пушкин моны белеп «Мин үземә гаҗәп һәйкәл салдым» дип тикмәгә генә әйтмәгән.

*
* *

Инде килеп, үзебезнең милли әдәбиятка тукталсак — ул бездә ки-чегеп, соңлап туды. Бигрәк тә бу хәл проза жанрында күренә. Башка бик күп әдәбиятлар инде үткән дәверләрне бәйнә-бәйнә тасвирлап, язып чыкканнар. Безгә әле халкыбызның үз тәкъдирен, аның язмы-шындагы үзгәреш, борылышларын эзләп язу хасияте тора. Үткәнне белмичә, тасвирлый алмыйча торып киләчәкне чамалап булмый диләр.

Халкымның әнә шул үткән юлындагы кайбер кичерешләренә үз бә-һам, үз төшенүем белән бер караш ташлап, аның бүгенге һәм киләчәк юлларын күзалларга тырыштым мин. Образлы итеп әйткәндә, үземнең шул аз санлы халкымның рухи байрагын югары күтәрергә, кирәк ва-кытта, эсседән яисә суыктан сакланган кебек, шул байрак астына сые-нырга тырыштым.

**Әнием сөйләгән бер риваять.** Авылда Әдилбәк дигән берәү яшә-гән икән. Бердәнбер көнне ул гомеренең үтеп баруы, кешеләргә бер-нинди дә саваплы эш эшләмәве хакында уйланып кайгыга кала. Нин-ди саваплы эш, нинди яхшылык эшләп кенә кешеләргә ошарга мөм-кин икәнен белер өчен ул авылдашларыннан сораштырырга керешә. Шулчак аның каршына күпне күргән, күп җирләрдә булган дәрвиш очрый. «Ии, балам,— ди бу.— Әүвәл каракалпак илен көнбатыштан көнчыгышка кисеп үткән олы, тапталган юл бар иде. Ул безнең такыр Өстерт аша, чүлләр аша үтә иде. Хәзер ул юл югалып бара. Ник ди-сәң, иске коелар ишелгән, сусыз сахрадан ун көнлек сәфәргә йөреп булмый бит. Син шул чүлстанның уртасында бер йорт булдырып, үт-кән-сүткән юлаучыны су белән тәэмин итеп торсаң, аннан да олы са-вап булмас, балам» дип киңәш итә дәрвиш.

Изге эшкә алынган Әдилбәк шулай итә дә. Ун көнлек юлның кыл уртасында, Өстерт калкулыгында йорт-кура корып куя да, дөяләрдә су китертеп, юлаучыларны су белән тәэмин итәргә керешә. Шулай итеп тиздән ул күп-күп рәхмәтләр ишетә. Бик саваплы эшкә алын-гансың дип мактыйлар моны.

Көннәрдән бер көнне сусаудан тәмам үләр дәрәҗәгә җиткән бер юлаучы моның өй түренә килеп егыла. Әдилбәк аңа да булыша, туй-ганчы су эчертә. Хәл алгач теге бәндә моңардан чилем сорый. Әдил-бәк чилем тартмый торган кеше була. Тәмәке заты тотмыйм бит дип җавап бирә. Юлаучының моңа бик ачуы килә. Ул Әдилбәкне бик яман тиргәп, сүгеп чыгып китә.

Әмма Әдилбәк тә сабыр, түзем кеше була. Бу хәлдән соң кешеләр-гә булган ихласы бермә-бер кимесә дә, хәтер калудан эче уттай янса да, ул җүнсез юлаучыга ачу итеп кенә эшен ташлап китми. Икенче юлы, суга барган уңайдан, өенә тәмәке дә кайтарып куя.

Мин дә язучылык хезмәтенә алынганда төп вазифамның шушы риваятьтәге Әдилбәк вазыйфасы шикеллерәк икәненә төшенеп алын-дым. Әлеге бер суырырлык чилем җитмәсә дә рәхмәт урынына тиргә-ләсемне, нәләт аласымны истә тотыбрак керештем. Нинди генә әр, тиргәү ишетмим, үз эшемне камилләштерә барып, ялгышларымны тө-зәтә-төзәтә булса да бу саваплы вазифамны гомерлеккә ташламаска дип бил бәйләдем...

*
* *

Яңа гына яза башлаган елларымда бер хикәямне аеруча ошаттым да, эти белән әниемә кычкырып укып чыктым. Шуннан, ни әйтерләр дип, башым күтәрдем. Әтием үз фикерен әйткәнче борылып әнигә карады.

Әнием, һәрвакыттагыча, күңелендәгеп яшерми әйтеп тә бирде.

— Монда нәрсәдер житешмәгәндәй кебек, балам,— диде ул.

Аңа эти дә кушылды.

— Миңа да шундыйрак бер кимчелеге бар сыман тоелды,— диде.

Әмма нинди кимчелек ул, әсәргә нәрсә житешми, икесе дә ачык кына әйтеп бирә алмадылар. Алар әйткәч үземә дә хикәягә нидер житми шикелле тоелды. Тик никадәр уйлап карасам да, ул кимчелекнең серенә үзем дә төшенеп житә алмадым.

Икенче көнне иртән әни миңа:

— Балам, ул язган язуыңда синең йорт-жиреңне, күрше-күләнне сагынуың ачык сизелми кебек. Никтер мин аларны күрмәдем,— диде.

Аннары әтием, аны куәтләп:

— Әйе шул, әйе, иген кырларыбызга, киң далабызга булган мәхәббәтең дә бик ачык түгел, беленми кала,— диде ул.

Мин үземне акларга тырышып карадым.

— Ул безнең киң, җазык далаларыбызны, кырларыбызны сагынуны иленнән еракка, читкә киткән кеше генә татыячак иде бит,— дигән булдым.

— Юк, балам,— диде анам.— Юк. Нишләп соң алайса без һәр иртәдә әйләнә-тирәдәге дала-кырларыбызны, күрше-күләнне, сагынып, искә алып уянабыз. Нигә ул бер дә безнең истән чыкмый!

— Бик дөрес! — дип, эти тагын әни сүзен куәтләргә керешге.— Ул әйләнә-тирәдәге дөньяны бер генә көн дә күрми түзә алмыйбыз ич. Алай булмаган адәм гамьсез адәм була инде ул. Сез дә бит андыйны тиргисез әнә.

Һәрвакыттагыча, атам-анамның бу әйткәннәре дә минем күңелдә калды. Аннан соң язганнарымны мин кат-кат укып, туган илемә, туып-үскән жиремә карап соклану һәм сагышлану хисләремне тулы итеп бирә алдыммы, укучыма житкерерлекме икән ул хисләр дип борчыла, эзләнә торган булып киттем.

Үз иле, үз халкына бу хисләрне белдерә алмый, сөенечсез дә, көенечсез дә тереклек итүгә караганда үлем бер хак, минемчә.

*
* *

Дөресен әйткәндә, әле әдәбияты, мәдәнияты тулы чагылышын тапмаган, тиешле югарылыкны яуларга өлгермәгән ил-халыкта кечерәк бер талант иясе пәйда булса, караңгыда үлемсерәп янган чытык чыраның ай булып күренүе шикелле, ул халык шул кечкенә талантына да аеруча әһәмият биреп, күгендәге иң якты йолдызы итеп йөртәчәге шөбһәсез. Халыкның берникадәр аңын, уен кузгаткан андый талант иясе, аның иҗат жимеше булган әсәрләре, әлбәттә, югары күтәреп бәһаләнәчәкләр, мактау сүзен ишетәчәкләр. Бу кадәрен мин беләм, аңлыйм. Хәтта, чынын әйткәндә, үз балаларымны тәрбияләгәндә дә мондый ысулдан оста ук файдаланып киләм. (Ягъни, дәресләрен тикшергәндә, укуларын кабатлатканда тулырак фикер йөртүче берәр кече яшьтәгесен мактап, башкаларга аңардан үрнәк алырга кушам. Андый баламны башкаларга өлге итеп куям.)

Шушыларның барысын да истә тотып, үз иҗатыма бирелә торган

бәһагә миндә ике төрле караш яши. Иң беренчесе, тотрыклысы — артык макталудан курку. Вакытсыз макталган укучы бала кебек, оныттылып китмәгәем дип яшәү. Шул сәбәпле мин укучы карамагына тапшырганчы һәр әсәремне, кечкенәме ул, күләмле, зур әсәрме, сигез-тугыз кат күчереп, яңадан-яңа вариантларда эшләргә тырышам. Романнарымны язганда классик әдәбиятны үрнәк итеп алсам да, бүгенге укучыны, җиңел укыла торган детектив әдәбият үрнәгендәрәк тәрбияләнгән укучыны да истән чыгармаска, калын-калын әсәрләрне мавыгып укып китәрлек итәргә тырышам. Моңа ни дәрәҗәдә ирешкәнбез — анысы инде укучы хөкемендә.

Әдәбият дигән бик олы юлга чыкканда боларның барын да уйламый булмый, билгеле. Халкыбыз бит юкка гына «юлга чыксаң, юлдашыңны табып чык, юл азыгы алып чык» дип кисәтмәгән. Ягъни юлдашларың үзеңә тиң, юл азыгың күп булсын, дигән сүз.

Әнием сөйләгән тагын бер риваять күңелемә килде. «Бик борынгы заман икән. Бер төбәктә утырган халыкның икенче төбәктәге халыклар белән сирәк аралашкан чагы. Шул вакыт бер илнең бер төркем халкы ерак юлга чыга. Көн баралар, төн баралар да, арып, ял итәргә туктыйлар. Шулчак болар янына бер дәрвиш килеп туктый. Дәрвишнең таягыннан башка берние юк, ә боларның биштәр-капчыклары тулы юл ризыгы икән. Шуңа күрә, дәрвиш:

— Үзегез белән мине дә ияртегез,— дип үтенгән, болар, коры гына:

— Юк инде! Синең безгә кушылырдай ризыгың юк,— дип җавап кайтаралар.

— Дөрес, минем азыгым юк,— ди дәрвиш.— Тик шулай да сезнең барасы озын юлыгызны кыскартыр чарам бар,— ди.

— Нинди чара соң ул? — дип төпченәләр моңардан.

— Сез ишетеп белмәгән әкият, риваятьләрне күп беләм мин. Аягым йөрүдән, телем сөйләүдән калганчы мин сезгә шул дастан, әкиятләрне сөйләп барырмын,— дип ышандыра дәрвиш. Арада бер өлкәне:

— Әйдә, кушыл, безгә кирәк кеше икәнсең,— ди.

Мин дә халкыма юлдаш булудан һәм аны үземә юлдаш итүдән дә ышанычлырак, артыграк һич нәрсә тапмадым. Һәм шулай ук, аның уртак казанына кушылырга тиеш ризык урынына, риваятьтәге дәрвиш кебек, күзләрем йомылып телдән калганчы халкымның гомер юлын дастан итеп, үзенә туктаусыз сөйли бирүне вазифам итеп муеныма асканмын.

Андый вазифаны җиңел дип белеп, җиңелчә генә җыенып юлга чыкканар да бар арада. Һәркемгә мәгълүм ки, бер үк эшкә берничә кеше тотынса — арада көрәш, ярыш башланачак. Шул ярышта җиңелеп калмас өчен һәммәбезгә ул эшкә зур хәстәрлек белән, кат-кат уйланганнан соң гына тотыну хәерле. Дөнья әдәбияты, илебезнең төрле телдә иҗат ителгән әдәбияты арасында минем дә «бу каракалпак әдәбияты» дигән сүзне ишетәсем, үземнең исә, зарлы тормыш үткән ата-бабаларым кебек, һич илемнән аерылмый «мин каракалпакмын, каракалпакмын...» дип тәкрарлап торасым килә. Үзебезнең шушы олы мәмләкәтебездә, Ильич нурыннан файдаланып шушы яктылыкка чыккан халкымның кем булуын, кем икәнлеген күрсәтүгә барлык акыл зиһенемне, гомеремне багышладым.

Минем өчен иң куанычлы тагын бер көн — ул да булса каракалпак халкының үзе теләп Россиягә кушылганлыгына 100 ел тулу бәйрәмендә миңа «Каракалпакстанның халык язучысы» дигән олы исем бирелүе көне булды. Инде калган гомеремдә аны акларга бөтен көчемне куячакмын. Үзем дә, халкым да миннән яңа әсәрләр көтә.

**Лирон ХӘМИДУЛЛИН** *тәрҗемәсе.*

Уразбай Абдирахманов,

Каракалпакстанның комсомол премиясе лауреаты

# ТУЙ

ХИКӘЯ



Минем бер күршемнең ишегендә кайчан карама йозак эленеп тора. Ул йортның хуҗасын без күптән инде күргәнебез юк. Йортның ишек тоткалары, тупсалары күгәреп беткән — әйтерсең, ул йортны моннан йөз еллар элек салганнар һәм ул инде тарихи ядкарь булып калган. Инде аның ишек яңакларында, бусагаларында ничәмә-ничә буын үрмәкүчләр пәрәвез җәтмәләре кордылар. Йортның хуҗасы кайда йөргәнне һәм кем булып эшләгәнне белсә Вәли абзый гына белә торгандыр. Аның халык бәхетен кайгыртып, кеше аягы басмаган җирләрдә газ ятмаларын эзләүче геолог булуы ихтимал, диләр.

Бүген бу йорт алдында озын буйлы, чандыр гәүдәле бер егет пәйда булды, күгәреп беткән йозакны ачкыч белән ача алмыйча, азапланып бeткәч, ул Вәли абзыйларга кереп, лом алып чыкты, йортның ишеген лом белән каерып ачарга теләде, әмма ишек ачылмады. Арыпталып, ул ишек төбендә утырды, сигарет кабызып җибәрмәкче иде, урам уртасыннан килгән ак күлмәкле, галстуклы, кара күзлекле өлкән яшьтәге бер абзыйны күреп алды, аның кем икәнен танып, кинәт урыныннан күтәрелде. Мин килүчене шундук танып алдым: Үтәкәй бит бу, безнең Үтәкәй! Ул күптәнге танышы кебек итеп, парк директоры Җаркабак абзый белән ике куллап күреште:

— Саумысез, хөрмәтле аксакал! — диде ул, кулларын сузып.

Тегесе сискәнеп куйды, күзлеге төшеп китте. Һәм ул, күзләрен кояштан каплап:

— Кем син? — диде.

— Әллә танымыйсыздамы, агай? Мин бит сезнең янгын сүндерүчеләр бүлеге хезмәткәре Дүршекәев. Сез бит мине үзегез укырга җибәргән идегез.

— Дүршекәйеп. Дүршекәйеп... Һмм, кайда ишеткән идем соң мин мондый фамилияне? Алай дисең алайса, кайчан укырга җибәргән идем мин сине?

— Кара сана, хәтерегез начар икән, аксакал. Сез мине эшкә дә үзегез алган идегез...

— Ә-ә-ә, алаймыни, син шул Дүршекәевмени? Һе-һе, исемә төшә башлады. Алайса, син Дүршекәев буласың инде, әйме? Ә нигә соң син башта ук шулай димәдең? Я ни хәлләр, картлар исән-саумы?

— Аллага шөкер, аксакал. Картларның дөнья куйганына ун ел булды инде. Сезнекеләр исән-саумы?

Аксакал аңа җавап бирeп тормады, ашыгып-ашыгып үз сүзен кабатлады:

— Миңа эшкә керәм дисеңмени?

— Һаман шул заводтамы соң әле сез?

— Май заводы яңа урынга күчкәннән соң, мин икмәк заводына күчтем, аннары сыра заводын сайладым. Югары оешмалар менә шушы паркны гөрләтеп үстерергә кирәк дигәннән соң, кайда директор бул-

сам да барыбер түгелмени дип, бирегә күчтем, әкрен генә эшләп яткан көй.

— Әмин эшләгән май заводы кая күчте соң?

— Кая дигәннәр иде соң әле?.. Хәзер әйтәм, хәзер... исемә генә төшерим. Муйнакка күчте шикелле. Хәтерем ялгышмаса, шулай бугай.

— Муйнакка дисезмени?

— Муйнакка.

— Мамык үсмәгән җиргә май заводын ничек күчерәсе иттеләр соң?

— Кем әйтә сиңа Муйнакта мамык үстермиләр дип? Муйнак хәзер мамык үстерүдә ел саен алдынгылыкны алып килә, шуның өстәвенә буш калган вакытларда балык тоту белән дә шөгыльләнә. Күрәм, син, агай-эне, туган якларыңнан аерылгач, дөньяларның кая таба барганын да онытып җибәргәнсең.

— Нинди эшкә керим икән соң мин, аксакал?

— Анысын җайларбыз. Син, күрәм, безнең урамга кунакка дип килгәнсең. Менә монысы безнең йорт, рәхим ит, узган елны гына сатып алдык, әйдә, аш-судан авыз итәрсең.

— Рәхмәт, ага. Менә монысы минем йорт иде. Гомерем гел читтә, командировкаларда узды, кайтсам, ишекне ачар хәл юк.

— Соңгы елда мин бу йортка кергән-чыкканны белмим.

— Соңгы елда дисез, бу йортның инде дүрт ел ачылганы юк.

— Син нәрсә, хатының белән аерылдыңмыни?

— Юк, ага, минем әле өйләнергә өлгергәнем юк.

— Ярый, агай-эне, кайгырма, баш исән булсын, өлгерерсең әле: өйләнерсең дә, хуҗалыгыңны да рәткә салырсың. Үзем булышырмын. Иңде күршеләр дә булып чыккач, мин сине паркка үз туганымнан да болайрак кадерле кеше итеп урнаштырырмын. Сул яктагы йорт, әнә тегесе, минеке, буш вакытларыңда кереп утыр.

Директор коры гына саубуллашты да, чайкала-чайкала атлап, үз йортына кереп китте. Дүршекәев, элекке түрәсе белән очрашканга шатланырга да, шатланмаска да белмичә, уйга калды. Аның күз алдына сөенечле вакытлары, шатлык белән узган көннәре килә башлады.

...Аны Ташкентка өч айлык курсларга җибәргән юньсез адәм шушы бит инде. Китми булдыра алмады, ник дисәң — башлык аңа ике сүзнең берендә иң кулай кеше син, дип тукый торды. Ташкентта кукуруз уңышын күтәрү ысуллары хакында көн саен лекция укып тордылар. Янгын сүндерүгә ул лекцияләрнең нинди мөнәсәбәте бар иде икән соң? Көч-хәл белән курсларны тәмамлап, өйгә кайтыр вакыт килеп җиткәндә генә тагын бер телеграмма килеп төште. Анысында Куйбышевка китәргә, яшь механизаторлар киңәшмәсендә катнашырга кушылган, акча җибәрәбез, диелгән иде.

Дүршекәев икенче көнне самолет белән Куйбышевка китте. Киңәшмә ике атнага сузылды. Кайтырга бер генә көн калганда, янә ашыгыч телеграмма алды Дүршекәев. Монысында Владивостокка ике еллык курсларга китәргә кирәклеге әйтелгән, хезмәт хакыңны шунда җибәреп торырбыз диелгән һәм «директор» дип кул куелган иде.

Бик озакка сузылган ике елны ул көч-хәл белән үткәреп җибәрде. Туган-үскән якларын өзелеп сагынды. Ярый әле, өйләнергә өлгермәгән иде. Ялгыз башка кайда да бер, таң ата да кич була, дигәндәй, ерак-та, Владивостокта яшәде Дүршекәев ике елы бик тә кызыклы булып, күз күрмәгән җирләрне күреп, әмма шәһәрен үзәк өзгеч сагынулар белән сагынып уздырды. Кайтып керсә, медицина училищесы тирәләрен бер әйләнсә, өйләнгән дип тә санарга була, аннары инде аны аркан белән дә читкә алып китә алмассың.

Нөкис аэропортында, туган якларны сагыну тойгыларына бирелеп, тирә-юньне күзли башлаган иде, җир астыннан килеп чыккандай әлеге

директор каршыда пәйда булмасынмы! Каян белгән диген аның кайтыр көнен?

— Әй, агай-эне, укудан арыгансындыр инде син аруын. Менә хәзер мин синең өчен Минводыга бара торган самолетны тоткарладым. Менә сиңа бушлай путевка, хәзер үк юлга чык, рәхәтләнеп бер ял итеп кайт, шуннан соң, җиң сызганып эшкә тотынырсың.

Менә шунда инде Дүршекәев үз гомерендә беренче мәртәбә аңар каршы төшәргә батырчылык итте.

— И агай-эне,— диде директор, сөмсерләре коелып,— син бармасаң, путевка яна бит. Учреждениедә синнән башка бер генә дә кулай кеше юк. Бар инде син, бара күр инде. Туп-туры самолетка чык, билетны теркәттем инде...

Өзелеп-өзелеп сагынган Нөкисне тагын бер мәртәбә күздән үткәргәч, ул авыр сулап, самолетка таба китте.

Минводы — матур кала икән. Аркылысын — буен карап чыкты ул аның, анда сугылды, монда сугылды, ничәмә ничә ел курсларда йөреп өйрәнгән кешегә кыен булып китте. Яшь уйлап табучылар киңәшмәсе бара икән, анда катнашты. Чакырылмаган-нитмәгән килеш. Монысы ярап куйды, эч пошканы басылды. Курорт дәверен бетереп, самолетка билет кына алган иде,— тагын телеграмма: Архангельскида үткәрелә торган киңәшмәдә катнашырга кушылган, акча җибәрелде, директор, диелгән.

Менә сиңа мә! Архангельскида да күңелсез булмады. Янә дә үзе күрмәгән җирләрне күреп, истәлекле урыннарын карап, рәхәтләнеп йөрде. Биредә инде ул берничә киңәшмәләрдәге кебек, һәр занятиедә авыз ачып утырмады, вакытын күбрәк шәһәр карап уздырды. Югыйсә мәктәпкәчә тәрбия проблемалары белән янгын сүндерүчеләрнең хезмәте арасында нинди уртаклык булсын?!

Озын сүзнең кыскасы, слетлардан семинарга, семинардан конференциягә, конференциядән киңәшмәләргә, белем арттыруга, курсларга йөри торгач; дүрт ел искән җил төсле узып та киткән.

Ул әле, бәлки, курсларда, киңәшмәләрдә тагын да булган булыр иде, әмма Ургенечка акча килмәде. Бүген килер, иртәгә килер дип бер ай көтеп тә бүген дә барып чыкмагач, Дүршекәев, тәвәккәлләп, өенә кайтып китте. Инде менә ишеген ача алмыйча аптырап утыра... Дүршекәев үз уйларына шул хәтле дә бирелгән иде, кемнеңдер: «Нишләп утырасың моңаеп?» — дигән тавышына сискәнеп башын күтәрде. Караса — каршысында Вәли абзый басып тора.

Алар кочаклашып күрештеләр. Сагынулары көчле иде, икесенең дә күзеннән яшь бәреп чыкты, озаклап хәл-əхвәлләрен сораштылар. Тутыккан йозакны икәү бергәләп ачарга керештеләр, ләкин булдыра алмадылар. Ниһаять, ломның ярдәме тиде, күгәнне каерып чыгарып, өйгә керделәр.

— Туганым, әгәр хәтерем ялгышмаса, синең исемең Үтәгалим иде шикелле.

— Дөрес әйтәсез. Сез мине Үтәкәй дип кенә атасагыз, әйбәтрәк булыр.

— Туганым Үтәкәй, инде моннан соң да син йортка килен төшермәсәң, өеңнең карар җире дә калмас бит,— диде Вәли абзый.

— Була ул, агай.

— Юкка әйтмәгәннәр бит, акча тап та, өйлән, хатының йорт тоткасы булыр, дип.

Вәли абзый егеткә олыларча акыллы киңәшләрен биргән чагында, Үтәкәй Дүршекәев ишегалдын күздән үткәрде, коридор ишекләренең инглиз йозакларына шырпылар кыстырылган булуын күреп, тагын бер мәртәбә авыр сулап куйды һәм бусага төбенә утырды.

...Әгәр бу кичне Вәли агай ерактан кайткан күршесен үз өйләренә чакырмаган булса, без хуҗаның бу төндәге язмышы өчен җаваплылыкны үз өстебезгә алмаган булыр идек. Алар төннең төн буе сөйләштеләр, әле дәгъвалашып, әле тагын килешеп, төнне уздырып җибәрделәр. Вәли агай нәсел әтәче турында өченче мәртәбә сүз башлаганда, Үтәкәй авызын зур ачып иснәнде, ә ул иснәнү төп урталары инде узып киткәнне хәбәр итте...

Иртәгесен Үтәкәй Дүршекәев ачылмый калган барлык ишекләрен балта белән каерып ачып бетереп, арып-талып хәл алырга утыргач, койманың теге ягында ниндидер бер кызыйның көмеш кыңгырау тавышы белән чыңгырдап көлгәне ишетелде. Шушы мизгелдә, ягъни аңа утыз биш яшь тә ике ай да уналты көн тулган чагында, Үтәкәйнең күңеле тетрәп китте. Ә көмеш кыңгырау тавышы бу вакытта һаман чыңгырдый, җаннарны айкап чыңгырдый иде. Андый чакта бар — гашыйк булмый кара!

Койманың теге ягында көлгән көмеш тавышлы гүзәлкәй кичә очраган парк директорының иркә кызы иде. Аның кылтаймышы менә беренче мәртәбә,— егерме тугыз яшь тә сигез ай да ундүрт көн тулган чакта,— максатына иреште, егет кешенең йөрәгенә ут булып кадалды. Әмма ул үзе моны белми иде әле...

Бөтен урам, хәтта бөтен шәһәр ихтирам иткән бик тә хөрмәтле бу кешенең бусагасын атлап керү уңайсыз инде уңайсызын, әмма нихәл итмәк кирәк, Үтәкәйне ул кичәгенәк ризыктан авыз итәргә дип үзе чакырган булганлыктан, мин сезне парк директоры йортының бусагасын атлатып кертергә мәҗбүрмен.

Директор, без урамда очрашып танышкан Җаркабак ага Сапаров — кайда туып, кайда үскәнен дә без белмәгән кеше. Ходай тәгалә аны, гүяки, планетада учреждение житәкчеләре җитмәгәнлектән, безгә үз кодрәте белән юктан бар итеп җибәргән. Үтәкәй белән сөйләшүеннән без аның башта май заводында эшләгәнен белгән идек инде.

Мәгълүмдер ки, май заводы Җаркабак агайдан башка урынга күчеп котылды. Икенче көннең иртәгесен үк Җаркабак ага пекарня директоры булып алды. Ул пекарня белән җитәкчелек иткән көннәрдә шәһәрдә булкидыр, бубликтыр, батондыр ише күмәч ризыклары кимеде, аның каравы кибетләргә кара ипи күпләп килә башлады. Ипинең артуын, күмәчнең кимүен карчыклар ачлык ел белән чагыштырып сөйли башладылар. Ләкин Җаркабак аганың пекарня белән идарә итүе озакка сузылмады, аңа соңгы кисәтүне чәпәп, сыра заводына җибәрделәр. Шуннан соң шәһәрдә икмәкнең сыйфаты һәм төрләре артты, аның каравы хәзер сыраның җитмәве билгеле булды. Сапаров җитәкчелек иткән ике елда сыра кайнату өч мәртәбәгә кимеде, ә сыйфаты мәсьәләсенә килгәндә, анысын инде сыра яратучылар гына әйтә ала. Аның бу башлангычы шәһәр җитәкчеләре тарафыннан беренче елны кул чабып каршы алынды. Сыра җитештерүнең кискен рәвештә кимүен һәм аның сыйфаты начарлануын алар шәһәрдә алкоголизмга каршы көрәштә хәл иткеч роль уйнар дип фикер йөрттеләр. Директор сырага мөмкин кадәр күбрәк су кушарга боерды, шуның белән сыраның үзкыйммәтен киметергә исәп тотты.

Бер көнне Сапаров «Белем» җәмгыяте оештырган гыйльми конференциядә «Аракы белән көрәш» дигән темага чыгыш ясады, сыраның ни өчен сыйфатын бозуны конференциядә катнашучыларга ачыктан ачык әйтте.

«Иптәшләр,— диде ул чакта директор,— сыраны эчүдән җаннарына рәхәт табучыларга без гомер буе яхшы сыйфатлы, тәмле сыра чыгарып тора торган булсак, алар аны эчүдән үлгәнче, кабергә кергәнче туктамаячак. Димәктер ки, сыра эчү кубәячәк, шәһәрдә, шулай булгачыннан, талаулар, һәм көчләүләр артачак. Шәһәр айныткычының

исерекләрне сыйдырып бетерә, алмау ихтималы бар. Менә шуңа күрә дә, «яшел жыланнан» рәхәтлек табучыларга начар сыйфатлы сыра тәкъдим итәбез. Кем дә кем без чыгарган сыраның бер кружкасын төбенә хәтле эчеп бетерә ала, без аның өчен махсус приз, ягъни кызыксындыру бүләге бирергә булдык. Әмма без чыгарган сыраны ахырынача эчеп бетерә алган кыюларның табылганы юк әле. Безгә читтән сыра керми. Ә без чыгарган сыраны эчеп бетерәм дип лаф оручыларның бер йотым кабу белән үк гайрәте чигә.

Алкоголизмга каршы көрәш — безнең изге бурычыбыз, шуңа күрә булса кирәк, безнең юрамалый, аңлы рәвештә, начар сыра чыгарып, планны үтәмәвебезне халык аңлый алмый. Ә бактың исә безнең ул югалтуларыбыз промышленностьта, транспортта, төзелештә хезмәт житештерүчәнлеген күтәрү бәрабәренә үз-үзен аклый. Бетсен алкоголь, иптәшләр!»

Әгәр шушы сүзләрдән соң аның мәгърур рәвештә башын югары чөеп, трибунадан төшүен һәм бик горур чырай белән урынына барып утыруын әйтми калсак, тарих өчен зур югалту ясаган булырбыз.

Өч ай чамасы узды микән, юк микән,— Жаркабак ага башлангычының нәтижәләре дә күренә башлады. Кешеләр сыра залларына йөрми башладылар, спиртлы эчемлекләргә ихтыяж арттаннан артты. Кибетләргә аракы алучылар өелде, айныткычка элагучеләрнең саны күзгә күренеп ишәйде.

Шәһәр башлыклары Жаркабак аганың башлангычын икенче бер урында кулланырга кирәк дип таптылар. Атап әйткәндә: аны шәһәр паркының директоры итеп күчерделәр. Бакчада озак та тормый, агачлар корый башлады...

Я, бу ни хикмәт инде, без директор белән иркенләп таныша гына башладык әле, инде ишек тә кагалар.

— Исәнмесез,— диде керүче, бусаганы атлау белән.

Чебен үтерү белән мәш килгән Сапаров ашыкмый гына аңа таба борылды.

— Әһә, килдеңме, агай-эне, уз әйдә, түрдән уз, я, ничек анда, ишекләреңне ачып бетерә алдыңмы?

— Ачтым, аксакал, ачмыйммы соң! Тик менә хәзер ишекләргә яңа йозак куярга кирәк булып чыкты.

— Һмм, алай, алай, ни йомыш иде миндә?

— Онытгыгызмыни, аксакал, кичә бит сез үзегез әйтеп тордыгыз, син эшләгән завод күчте, дидегез. Шәһәрдә үземә яраклы эш эзләргә кирәктер бит, менә сезгә киңәшкә кердем әле.

— Бик әйбәт, бик яхшы, паспортыңны бир әле, карыйк әле.

Үтәкәй кесәләрен актарып чыкты да тузып-таушалып беткән паспортын ике куллап аңа сузды. Жаркабак ага ашыкмый-кабаланмый гына кесәсеннән күзлеген алып, борынына атландырды, тик шуннан соң гына паспортны актара башлады. Күпмедер вакыт узгач, ул сискәнеп китеп, Үтәкәйгә төбәлде:

— Фамилияң кем? — дип сорады ул.

— Дүршекәев.

Парк директоры урынында сикереп куйды. Паспорттан үзе укыган чакта әлеге фамилия аңар ул хәтле үк тәэсир итмәгән иде.

— Әйбәт түгел, агай-эне, әйбәт түгел,— диде ул башын чайкыйчайкый.— Мондый фамилия буламыни дөньяда?! Исемеңнең Үтәгалим булуына түзәргә дә була әле, ә фамилияң әйбәт түгел. Андый фамилия белән беркая да эшкә урнаштырып булмый. Дүр-ше-кә-йев!

Үтәкәйнең йөзе кәфен кебек агарды.

— Монда минем ни гаебем бар, аксакал? Бабайдан ук килгән фамилия бит ул.

— Кадалып китсеннәр синең ул бабаларың, кешегә кешечә исем дә куша белмәгәч!

— Соң бит сез, аксакал, моннан дүрт ел элек, мине әнә шул фамилия белән кочак җәеп каршы алган идегез, эшкә урнаштырган идегез. Соңыннан белемемне күтәрергә дип читкә җибәргән идегез.

— Кайчан җибәргән идем?

— Май заводында чакта.

— Һмм, май заводы май заводы инде ул, агай-эне. Ул май яза. Ә беләсеңме мин хәзер кайда михнәт чигәм? Әгәр бик беләсең килсә, мин хәзер парк директоры. Минем карамакта егерме биш кеше. Парк ул, агай-эне, май язмый, ул — чын мәгънәсендә культура үзәге санала.

— Миңа кирәкле эш табылмас микәнни анда? Кичә бит сез үзегез сүз кузгаткан идегез.

— Белмим шул, агай-эне, мондый фамилия белән син нинди генә эш башкара алырсың икән, башым эшләми. Әйтик, без сине яңгыннан саклау бүлегенә куйдык, ди. Сиңа үз гомереңдә бер мәртәбә булса да, «Янгыннан саклау чаралары» дигән темага лекция сөйләргә туры килер бит, ә афишага «лектор Дүршекәев» дип язсалар, кем соң синең лекцияңне тыңларга килер? Син үзең дә әлеге фамилияңнән оялып, лекция укырга риза булмас идең. Синең бу фамилияң хәтта цирк артистларына да килешми... Ярый, анысын да бер якка куеп торыйк. Мин сине эшкә дә алдым ди, синең җилкәңә җаваплы җәмәгать эше итеп комсомол секретарьлыгын йөкләдем яки, булмаса, стена газетасы редакторы итеп куйдырттым ди, ә син стена газетасына мондый ахмак фамилияңне ничек куярсың икән соң? Ярый, анысын да бер читкә куеп торыйк. Синең бу мәгънәсез фамилияң хезмәт хакы алучылар исемлеген бозмас дисеңмени? Безнең бухгалтер «Дүршекәйеп» дигән сүзне укыган чакта кычкырып көлеп җибәрсә, дебет белән кредитны бутап бетерсә? Монысына ни диярсең?

Үтәкәйнең бик нык хәтере калды. Аның үзен мыскыл иткән, ата-бабасын мыскыл иткән кешенең битенә төкереп чыгып китәсе килә, әмма эчендәге ярсуын шулай да басып торырга мәҗбүр иде әле.

Парк директоры, килеп туган хәлне бизмәнгә салып, инде нишләргә дигәндәй, бик озак сүзсез утырды.

— Өйләнгәнме? — диде ул, ниһаять.

— Юк.

— Һмм, монысы яхшы. Мин сине хәзергә агроном-энтимолог вазифасына алам, бераздан син фамилияңне үзгәртерсең.

— Ничек итеп?

— Мин ничек әйтсәм, шулай эшләрсең. Бер ай эчендә өйләнерсең, хатынлыкка айдан якты, түгәрәк йөзле чибәркәйне алырсың да аның фамилиясенә күчәрсең.

— Сез бик җиңел хәл иттегез бит әле, аксакал. Өйләнү бит ул базардан кәҗә тәкәсе сатып алу гына түгел. Башта, кем әйтмешли, әзерләнергә, мал тупларга, шуннан соң гына уйлый башларга була...

— Карале, синең үзеңнең дә фамилияңнән артык җирең юк икән ләбаса! Лыгырдавык икәнсең бит син, тел бистәсе. Менә шул, агай-эне: синең белән сүз көрәштереп торырга вакыт юк минем! Үзеңә мәгълүм, кат-кат сөйләшергә катыннар түгел мин,— дип Җаркабак ага сүзне кырт кисте.

Үтәкәйгә ризалык бирүдән башка әмәл калмады.

— Ярый, аксакал, сез әйткән энтимолог ни белән шөгыльләнә соң ул? Мин ул эшне башкара алырмынмы?

— Алырсың. Чебен үтерергә кулыңнан килсә, безгә шул бик җиткән.

— Әһә, бу нәкъ минем кулдан килә торган эш,— диде Үтәкәй.

*
* *

Тагын берничә көннән безнең урамнан узган кеше Жаркабак ага белән Үтәкәйнең икәүләшеп капка төбендә туйга килгән кунакларны каршылап торуларын күргән булыр иде. Кияү моңсу, ботинка башы белән жиргә сызыклар сызгалый, ә директор, киресенчә, бик тә канәгать һәм шат күңелле иде.

— Менә, күрәсеңме, улым, син нинди әйбәт эш эшләдең. Нинди ямьсез иде синең фамилияң. Ә хәзер кара! — диде Жаркабак ага, кияве никах таныклыгын күрсәтеп.— Сапаров Үтәкәй Жаркабакович. Әллә ниткән котсыз Дүршекәевкә караганда мең мәртәбә матуррак фамилия! Хәзер мондый фамилия белән сиңа теләсә нинди биеклеккә күтәрелү кыен булмаячак. Иртәгәдән башлап син үзәк паркның агроном-энтимологы. Әгәр мине башка урынга күчерсәләр, син минем урыныма парк директоры булып каласың.

Аларның әңгәмәсен йорт каршына килеп туктаган машиналар бүлдерде. Жаркабак ага кунакларын каршылап, әмерләрен бирә башлады:

— Узыгыз, кадерле кунаклар, узыгыз, табынны дөньяда бер итеп әзерләдек. Комсомол туе уздырсак та йөзгә оят килерлек түгел. Ә син, улым, минем белән бергә бул, яме.

— Түрдән узыгыз, рәхим итегез,— дип кочакларын жәеп каршы алды Жаркабак ага кунакларын. Машинадан төшкән бер кунак белән ул кочаклашып күреште. Кунаклар да гади генә түгел иде шул, затлы кунаклар иде. Аларның һәркайсы дөньяда үз хәлен, үз урынын яхшы белгән дәрәжәле кешеләр иде, аларны шәһәрдә генә түгел, бөтен республикада хөрмәтлиләр иде. Алар бүләккә дип алып килгән әйберләрен шоферларыннан өйгә керттереп, үзләре хужа белән исәнләшергә ашыгалар иде. Ә Үтәкәй ике тиенлек юка дәфтәргә кунаклар китергән бүләкләрне теркәп бара иде. Чакырулы кунаклар бөтенесе диярлек килеп беткәч, аның аяк-кулларына ял бирелде, ул өйгә кереп туй костюмын киде. Яңа гадәтләр буенча ул кәләше белән бергә утырырга тиеш иде.

Таныш-белеш, күрше-күлән — берсе-бер калмый — кадерле кунакларны сыйладылар. Ярты тонналы яшь үгезнең ите күршеләргә кунак сыйлар өчен өләшеп чыгылды. Аракы белән шәрап житәрлек иде, кунаклар өзлексез, бахса булырмы дип сорашып-белешеп тордылар. Жаркабак ага һәр өйгә кереп аңлатма биреп торды: «Бахса, ягъни борынгы дастаннарны яттан белүче, булмаячак, ник дисәң, без туйны искечә түгел, яңача үткәрәбез!»

Туйның түре Жаркабак ага йортында иде. Бирегә затлыдан да затлы, белемледән дә белемле кунаклар жыелды. Ачыктан ачык әйткәндә, шәһәрдәге атаклы учреждениеләрнең жаваплы житәкчеләре. Шуның өстәвенә озын өстәлнең түр башына кияү белән кәләшне утырттылар.

Жаркабак ага, кунаклар тирәли бер мәртәбә әйләнеп чыгып, урынына утырырга жыенган чакта каршы яктагы жәенкерәк битле бер кунакның үзенә бик тә төбәп карап торуын сизде. Кем икән? Кайдадыр күргәне дә бар шикелле. Юк бугай, күрмәгән ахрысы, Үтәкәйнең кунагыдыр. Әмма кунак бик тә күзгә ташланырлык, мәдәниятле, белемле, дип фикер йөртте Жаркабак ага.

Беренче тостлар кияүнең, киленнең, Жаркабак аганың саулыгы өчен күтәрелде. Телгә оста булуы белән дан алган кунакның берсе түзмәде: «Жаркабак ага, менә шулай зур сөенеч белән, шәрабларны мөлдерәтеп, сезнең беренче оныгыгызга исем кушарга да язсын!» — дип теләк белдерде. Шау-шу, жанлану китте, кайберләре хәтта ни сәбәптән жыелганны ялгыштырып: «Сөннәткә утыртылган малайны атка атландырырга кирәк»,— дип кычкыра башладылар. Әмма әлеге

җәенке битле кунак әле һаман да Җаркабак агадан күзен алмый иде. Ихтимал, ул да аны кайдадыр күргән танышым дип уйлый иде булса кирәк. Унлап тост әйтелгәннән соң, җыр-биюләр башланып китте. Тик табында утыручы хатын-кызлардан бии белүчесе аз иде. Танцы-мансылар озакка бармады, кунаклар янә дә үз урыннарына килеп утырдылар.

Табынга табаклар тулып кыздырылган ит килгәч, кунакларның кәефе тагын да күтәрелде. Шунлыктан алар танышларын хурлауның һәм сыткый сагыз төсле хатыннарны алиментсыз калдыруның төрле әмәлләрен яшьләргә өйрәтә башладылар.

Җәенке битле кунак әле һаман Җаркабак агадан күзен алмый иде. Бу исә аңар көлке тоела башлады, ләкин ул көлми түзде, чөнки ул көлсә, корсагы дерелдәячәк һәм табындагы мөлдерәмә тутырылган стаканнар түгеләчәк иде.

Җәенке битле кунак, уйламаган-көтмәгән җирдән, торна кебек муенын сузып, битен Җаркабак агага якынайтты:

— Хөрмәтле ага, әйдә танышыйк,— диде.

— Танышыйк, булмаса. Мин сине кайдадыр күргән дә төсле булам, тик исемә генә төшерә алмыйм. Кем малае син? — диде Җаркабак ага, дулкынланып.

— Алламҗар бит мин, сәүдә министрлыгында эшлим.

Җаркабак ага сискәнеп китте. Ул әле күптән түгел генә министр урынбасары алышынган икән дип ишеткән иде, мөгаен яңа урынбасар шушыдыр? Чакыру җибәргән булсалар да, министр хәтле министр бирегә килеп вакланмас, күрәсең, урынбасарын җибәргәндер. Өнеме бу, төшеме — Җаркабак ага мондый очрашуны күптән көтә иде бит.

— Мин сезне күреп белмәсәм дә, ишетеп беләм. Күптән түгел мин сезнең радиодан сәүдә культурасын үстерү хакындагы бик шәп лекциягезне тыңладым. Әйе, ифрат та шәп сөйләдегез сез, сүзләрне чамалап кына, сайлап-сайлап кына сөйләдегез, мин ихтыярсыздан: шигъри сәләте дә бар икән, дип уйлап куйдым. Әйдәгез, танышлык өчен берәрне күтәрик, сез дә мине беләсездер дип уйлыйм.

Алар чәкәштеләр.

— Туктале, тукта, Алламҗар дус, исемә төшерим әле, минем уйлавымча, әгәр дөрес төшенгән булсам, сезнең өченче бабагыз безнең икенче бабайдан бик әллә ни ерак түгел бит. Сезнең чыраегыз шундый да таныш миңа, шундый да таныш, тик менә кайда очрашканыбызны гына әйтә алмыйм. Туктале, сез бит армия хезмәтен узгансыздыр?

— Юк, мине армиягә алмадылар. Минем чирем бар иде. Әйдәгез, бергәләп искә төшерик.

Җаркабак ага ияген шампанскидан бушаган яшел зур шешәгә терәде. Алламҗар озын нәзек бармакларын чәч арасына батырды — икәүләп уйга чумдылар. Алламҗар карашында Җаркабак ага культура министрына охшап куя, әмма ул хакта сорау уңайсыз. Җаркабак ага карашында бу җәенке бит тыйнаклык йөзеннән генә министрлыкта эшлим дип әйтә, чынында исә ул, әлбәттә, министр урынбасары. Беренчесеме икән, икенчесеме — анысын аеру кыен. Башкача булуы мөмкин түгел. Мондый бәхетле очрашуны истә калдырырга кирәк.

Икесе дә шул хакта уйладылар.

— Алламҗар! — дип кинәт кычкырып җибәрде Җаркабак ага. Җәенке битле дерт итеп китте.— Урта мәктәпне кайчан бетердегез?

— Моннан утыз еллар элек.

— Нинди мәктәпне бетердең?

— Актирәк мәктәбен.

— Алламҗар! — тагын бер генә мизгел булса, Җаркабак аганың йөрәге ярылып китәр иде.— Кадерле дустым минем, сабакташым, кандашым, якыным минем!

Ул, урыныннан сикереп торып, җәенке битлене үзенә тартып китерде. Алламҗар юан корсаклының кочагына сыенды, үксеп җылап җибәрде.

— Кадерлем минем, Җаркабак!

Алар кочаклаштылар, үбештеләр, күз яше койдылар, әмма табындагылар, үзләре аерым-аерым сөйләшкәнлектән, аларга игътибар итмәделәр.

Алар, кесәләреннән кульяулыгы чыгарып, бер-берсенең күз яшьләрен һәм борыннарын сөрттеләр, аннары янә дә үбешеп, үз урыннарына утырыштылар.

— Исеңдәме, Алламҗар, өченче класста чагында без ләңгә уйный идек. Гел син ота торган идең. Ут борчасы идең бит син. Синең ләңгә уйнавыңны гади күз белән күреп тә булырлык түгел иде.

— Әйе шул, әйе, әйтәсе дә юк, мин ләңгә уйнарга оста идем, әмма син миңа оттырган чакларда мине тотып тукмый идең. Исеңдәме, 8 март көнне, кызлар алдында син минем артыма типкән идең?

— Әйттең сүз! Киресенчә, син миңа тынгылык бирми идең, юан корсак, мичкә корсак, дип үрти идең, башка чиертеп җанга тия идең. Ничә мәртәбә син мине җылаттың, укытучыга зарланырга мәҗбүр иттең, исеңдәме? Усал да идең соң син!

— Ул көннәрне искә төшерү бик тә күңелле ул, дустым. Син бит, торып тор, ул чагында класс башлыгы идең. Мәктәпне тәмамлаганчы син безнең классны җитәкләдең һәм туры юлга алып чыктың. Ул чаклар онытыламыни, сабакташ?

— Әйе, бик дөрес, мин класс башлыгы булдым, ләкин беркайчан да син әйткәннәргә каршы килмәдем. Лапта уйнарга туры килгән чакларда син мине һәрвакыт капка сакчысы итеп куя идең. Теләсә кайсы уенда синең боерыгың безнең өчен закон була торган иде.

Алар, өстәлдән берәр конфет алып, кәгазен сүттеләр дә, конфетны бер-берсенең авызына каптырдылар. Аннары стаканнары белән чәкәштеләр.

— Аннан соң нәрсә булды әле? — диде Җаркабак ага уйчан гына.— Һи-һи, без икебез дә Ташкентка, халык хуҗалыгы институтына киттек шикелле. Син укырга керә алдың, мин — юк. Әй синең өчен шатланган идем дә соң шул чагында! Балалык еллары иде бит! Бишагачта чагында шатлык яшьләрен түгеп: «Әгәр Алламҗар укып кеше булса, ул сине аяк астында калдырмаячак, әгәр син дөрес юлдан тайпылсаң, ул сиңа югары белеме белән, акылы белән ярдәм итәчәк»,— дип үз-үземне юатып авылга кайтып киттем.

— Әйе, кадерле, дустым, барысы да исемдә, гел дә бүген булган кебек. Ул чагында минем дә күзләрем яшьләнде, син генә сизмәдең. «Дустым укырга керә алмады, ләкин әле соң түгел, керер, хәзергә ул әти-әнисен киленле итеп сөендерсен»,— дип уйладым мин ул чагында, икенче елны син, хәтерем ялгышмаса, укырга кердең шикелле?

— Юк, армия хезмәтеннән кайткannan соң культура-агарту техникумында читтән торып укыдым. Хәзер культура министрлыгына буйсынган бер учреждениедә җитәкче булып эшлим,— диде Җаркабак ага, парк директоры булып эшлим дип әйтергә уңайсызланды.— Гаилә кордык, балалар үстерәбез. Синең шушы көнгә тикле сәүдә министры урынбасары икәнеңне белми йөрүем өчен җир астына төшеп китерлек булып оялам. Әгәр без бер-беребезгә терәк булмыйбыз икән, дуслыгыбыз хәрам булсын.

— Искиткеч дөрес сүзләр, дустым. Әгәр без бер-беребезгә терәк булмыйбыз икән, җиде ел буе бергә укып йөргәнебез җилгә очсын!

— Ну, Алеке, минем сиңа бердәнбер үтенечем шул: шәһәр универмагы директорының урыны бушаган, диләр, син миңа ул урынны

ничек тә алып бирерсең инде,— дип Жаркабак ага беренче булып гозерен әйтте.

— Мыскыл итәсең бит син мине. Мин бит гап-гади бер...— дип башлаган иде Алламжар, дусты аны шундук бүлдерде:

— Табын янында акланып маташма, дустым. Ул урынга мине күчерү өчен сезнең бер сүзегез җитә. Министр урынбасары әйткәнгә кемнең каршы килергә йөрәге җитсен? Синең бер сүзең...

— Юк, дустым, ялгышасың, мин сәүдә министрлыгында эшләсәм дә, сүзем үтми минем, мин министр урынбасары түгел, министрлыкта оештырылган үзешчән сәнгать түгәрәге белән генә җитәкчелек итәм мин.

— Нәрсә? — дип сикереп торды Жаркабак ага һәм сабакташына исерек күзләре белән берни аңламый карап тора башлады.— Шаярма, Алеке! Синең хуҗалык институтын бетергәнеңне халык белмәсә, мин беләм!

— Юк, бетерә алмадым. Икенче курста, кыенга килә башлагач, театр институтына күчтем. Менә хәзер бер урында да җүнле эш таба алмыйча, шушы сәүдә министрлыгында көн күрәм. Хезмәт хакы да әллә кем түгел. Бер йөз егерме сумнар. Хәзер син культура өлкәсендә эшлисең, дустыңа ярдәм кулын суз, оешмаңда берәр штатың булса, ал мине үзеңә. Гаиләмне ач итмәслек хезмәт хакы бир. Бүген мин синең туеңа чакырмасаң да килдем, менә шушы уңайдан очраштык, калганын үзең беләсең,— диде Алламжар чын күңелдән.

— Әйдә, дустым, бер-беребезне үтенечләр белән аптыратмыйк, гомер буе дус булып калыйк, күтәрик бокалларны,— диде Жаркабак ага. Хыяллары челпәрәмә килгәнгә бик нык кәефе киткән иде. Тик ул аны күрсәтергә теләмәде. Бокаллар чыңлап чәкештеләр. Аннары Жаркабак ага эчке кесәсеннән туйга килгән акчаларны теркәгән дәфтәрне чыгарып, шуны тикшерә башлады, Алламжарны бөтенләй дә игътибарсыз калдырды. Шактый вакыт узганнан соң гына башын күтәреп:

— Алеке, син элек тә әрсез идең, чакырылмаган җиргә йөри торган гадәтең һаман да бетмәгән икән әле,— дип шаяртты һәм сабакташына бүтән бер мәртәбә дә әйләнеп карамады.

Туй дәвам итте. Алламжар, сабакташына кул селтәп, ашарга тотынды. Бүген аларның икесенең дә гамәлләрен күреп торган кеше Антон Павлович Чеховның иртәрәк үлеп киткәнлегенә бик тә үкенгән булыр иде.

Кичкә таба туй сүрелә башлады. Ерактан килгәннәр китәргә рөхсәт сорадылар.

Хат мазарны гел соңга калып китерә торган почтальон, уйламаган-көтмәгән чакта, парк директорының квартирына килеп кермәгән булса, туй мажарасыз-нисез генә узып китәчәк иде. Язмыштан узмыш юк дигәндәй, керде шул менә, берьюлы өч телеграмма алып керде.

Телеграмма Үтәкәйнең әбисе кулына эләккән. Аны укый башлау белән әби кеше күз яше белән такмаклап, кияүнең якасыннан урап ала:

— Без сине тотанаклы дип уйлап, ефәк кебек кызыбызны бирдек. Бу ниткән хурлык? — дип кычкыра-кычкыра, әби кеше кияүнең битен телеграмма белән чәбәкли башлады.

Үтәкәй башта ни икәнен аңламыйча, аптырап-югалып калды, телеграммаларны укыгач, аның җаны тетрәнде. Телеграммаларда менә нәрсәләр иде:

**Ташкенттан:** «Дүршекәевкә нокта кызың сөйләшә башлады өтер эти кайда дип сорый өтер кайчан кайтасың өтер Мәчтүрә».

**Владивостоктан:** «Дүршекәевкә нокта Толигың авырып китте өтер бер көн кичекми кайт нокта Таня»

**Архангельскидан:** «Дүршекәевкә нокта кичә больницадан чыктым

өтер улың үзенә охшаган өтер котлыйм өтер исемен ничек куябыз өтер үбеп Маруся»

Әби кеше өч телеграмманың өчесен дә чаршау артында утырган кызына кычкырып укый, ә такмаклап җылаулар булачак кәләшнеке иде. Аннары әби кеше туй үткәрүнең яңа гадәтләре буенча кунаклар арасында утырган Җаркабак ага янына йөгерде. Иренең кулына телеграмманы төртеп, әби кеше җирне төя башлады.

Җаркабак ага күзлеген таба алмый аптырап беткәч, телеграммаларны укы дип, Алламҗарга сузды.

Кунаклар, шул рәвешле, Җаркабак ага киявенең өч шәһәрдә өч хатыны барлыгын белделәр.

— Адәм актыгы! Җир бит! — дип кычкырды парк директоры.

— Туй тәмам, таралышыгыз, тизрәк булыгыз. Килгәнегезгә рәхмәт, безгә дә шулай сезнең шатлыкны уртаклашырга язсын! Таралыгыз, дим мин сезгә! Берегез бер калмасын!

Шундый әйбәт туй, шундый күңелле туй менә шулай күңелсез тәмамланды.

Ерактан килгән кунаклар саубуллашмый-нитми китеп бардылар. Җаркабак ага оятсыз кияүнең арт сабагын укыту өчен урамнан егетләр дә эзләп караган иде, берәүне дә таба алмады.

Икенче көнне берәүләр Үтәкәйне Нөкис аэропортында очраттык дип сөйләделәр, икенчеләре Хоҗәйли вокзалында күрдек дип ант иттеләр, өченчеләре исә ул гостиницаларда кунып йөри икән дип ышандырырга тырыштылар.

Әмма Үтәкәйне күргән бер генә кеше дә юк иде...

**ГАРИФ АХУНОВ** тәрҗемәсе.

## Гөләем Торсынова

# ЯШӘҮ ЯМЕ

**хикәя**



Карт үзалдына:

— Аба-ау, бөтенләй яктырган, әллә кайчан таң аткан лабаса! — дип, сөйләнә-сөйләнә урыннан торды.

Күптән уянган булса да, кузгалырга кыймый яткан иде ул. Торып нишләсен? Аякка бастыңмы, җанны мәрхүмә карчыгы турындагы шомлы уйлар биләп ала. «Ничек болай булды соң әле бу?! Атылган йолдыз күк бер балкып алдың да, дөньямны караңгылык эчендә калдырып, мәңгегә китеп тә бардың. Салкын тар гүргә кереп яттың. Япа-ялгызымны калдырып ник ташлап киттең? Син бит минем барыр юлларымны яктыртып торучы аем-кояшым идең. Күз сирпеп алуларың гына да бар дөньямны нурга тутыра иде. Инде нишлим? Яшисе килми. Тизрәк мине дә үз яныңа ал! Башка һичнинди теләгем калмады...»

Карт, шундый уйлардан тәмам исергән хәлдә, иртәнге намазга әзерләнә башлады. Комганга су салырга кирәк иде. Калтыранган куллары

нытып тота алмады, чүмеч, бөтен өйне яңгыратып, даңгырдап, идәнгә төште.
Таралып йоклап яткан кечкенә оныгы уянды.
— Ну, бабай, туйганчы йокларга да бирмәдең! Нәрсә калган сиңа шул савыт-саба арасында?
Икенче яктан, итәк-чабуларын җилфердәтеп, өлкән килен килеп керде.
— И-и, эткәй,— дип кабаланырга тотынды.— Ярый әле тавыш салдың, бигрәк озак йоклаганмын, яңа уянып киттем. Кичерә күр инде, җылы су да әзерләп өлгермәдем. Азга гына сабыр ит, ут үрләтәм. Кая, бир әле монда комганыңны!
— Борчылма, балам. Үз мәшәкатьләрегез дә баштин ашкан. Ирең гел табын түрендә генә утыра, берүзең бөтереләсең. Мин, карт-юләр, тавышланып, тагын йокыңны бүлдем.
— Ни сөйлисең, эткәй! Әле ярый син уяттың, көнозын йоклап ятсаң, бу эшләрне кем башкарыр иде.
— Эш бетми инде ул, яшь чакта йокы да бик тәмле була, кадерен белергә кирәк. Әнә, әнкәгез-мәрхүмә китте дә барды...
— Авыр туфрагы җиңел була күрсен! Бик әйбәт кеше иде ул безнең әнкәй. Ни гомер бергә яшәп, авыр сүз ишеттермәде, кайберәүләрнең үз аналары да андый булмый.
Өй эче акрынлап җанлана барды. Килен каенатасының урын-җирен җыеп куйды. Учакка ягып җибәрде, иртәнге чәй табынын әзерләргә вакыт иде. Ул каенатасына да ара-тирә күз салгалый. Аның әнә намазы укылып бетте. Укыганнарын карчыгы рухына багышларга ниятләде ул. Шул чак ике күзенә мөлдерәп яшь тулды, кайнар тамчылар бите буйлап тәгәрәшә башладылар.
Оныгы да моны күреп алды, йөгереп барып, бабасына сыенды, җылы учы белән яшь бөртекләрен сыпырды.
— Я инде, җылама, бабай! Ник җылыйсың?
— Юк, балам, юк, җыламыйм.
Сүзгә кодагый да кушылды.
— Һе! — дип куйды ул, тавышына шаянлык кушып.— Бабаңның ник җылаганын белмисеңме? Әбиеңне сагына, шуңа җылый!
Табындагылар көлешеп алдылар.
— Көлегез, көл! — Картның тавышы калтыранып китте.— Сезгә нәрсә, үскәнсез инде, дәү булгансыз, хәзер сезгә әниең кирәге юк. Миңа кирәк иде әле ул, бик кирәк иде. Миңем бит аннан башка бер кадерем дә юк.
Картның җыерчыклы йөзе кара болыт баскан күк йөзенә охшап калды. Ачуы чыкса гел шундый була ул.
— Җанымны нинди уйлар телгәләвен берегез дә белми шул.— Кайнар яшьләрен башкаларга күрсәтергә теләмичә, ул урыныннан торып ук китте.
Кече килен аны ишегалдында, утын әрдәнәләре арасында очратты. Картның күзләре кызарып беткән иде.
Нигә шул кадәр кыйналырга инде, дип уйлады кече килен. Үлгән арты үлеп булмый, диләр, әнкәйне дә кире кайтарып булмый. Бу картларның холкын аңлау бик кыен. Институтта укыганда, психология укытучысы әйтә торган иде, кеше картайгач, аңа яңадан балалар акылы керә, күңелләре бик нечкәрә, ди торган иде. Җитмешне узган эткәйнең дә шул чоры, күрәсең.
Кече киленнең кайнатасына ярдәм итәсе, хәсрәтен уртаклашасы килә иде, тик моны ничек эшләргә соң? Бер чара да табылмавы мөмкин түгел. Аны мәрхүмә карчыгы турындагы уйларыннан арындырырга кирәк.
Мәктәпкә эшкә барганда да яшь килен гел шул хакта гына баш ват-

ты. Мәктәпнең өр-яңа мәһабәт бинасы зур ачык мәйдан уртасында ничектер шыксызрак күренә. Тирә-юне шыр ялангач. Укучылар агачлар утыртып та азапланганнар иде, берәве дә үсеп китә алмады. Корышып кипкән агачлар мәйданны тагын да күңелсезләндереп кенә калдырды. «Кара, безнең әткәй данлыклы бакчачы лабаса, дип шатланып куйды килен. Нигә аңардан киңәш сорамаска! Кирәкмәгән хәсрәтле уйларыннан арынырга да ярдәм булыр!»

Кичке табын янында кече килен иплəп кенә сүз башлады.

— Әткәй, сиңа бер үтенеч бар иде минем!

— Әйт, балам, тыңлап карыйк!

— Үзең дә күреп йөрисеңдер, оныкларыгыз йөри торган мәктәпнең тирә-юне бигрәк шыксыз. Балалар агач утыртып та карадылар, берсе дә тамырлана алмады, ник икән, әткәй?

— Бот буе бала-чага утырткан агач та үсеп китсә, бакчачыларга ни кала!? — Карт тез башына сугып куйды.— Минем сере бар ул агач утыртуның, тамырланганчы тәрбияләүнең тагын мең сере...

Каенатасының кәефе күтәрелүен сизеп, кече килен елмаеп куйды. Карт моны сизеп алды.

— Ай-һай хәйләкәр булып чыктың әле син, киленкәем!— диде.— Син бит минем ни яратканымны белеп торасың, ярдәм итми калмавымны да яхшы аңлыйсың. Әшлибез аны, килен, иртәгә үк барып, туфрагын-фәләнен карап кайтырмын, үсентеләрне колхоз бакчасыннан алырга була.

— Рәхмәт, әткәй!

— Үзеңә рәхмәт, килен, күңелгә өмет салдың әле.

Икенче көн иртән карт үзенең әллә кайчангы үткен көрәген кулга алды. Капка төбендә тракторын кабызып маташкан олы улы, картның каядыр китәргә җыенуын күргәч, сорый куйды:

— Кай тарафларга юл алдың, эти? Көрәк тә күтәргәнсең түгелме?

— Синең улың, минем оныкларым укый торган мәктәпкә барыш. Акыл — яшьлектә, якут — ташлыкта, дигән сүзнең мәгънәсенә төшендем әле. Кече килен яшь-яшь башыннан, акылы житеп, миңа да бер шөгыль тапкан!

— Тынычлап өйдә генә утырсаң ни була?

— Тәндә җан барында, тик утыру адәм баласына бәла бит ул.

— Киленеңне әйтер идем тагын, ни уйлап чыгарган?!

— Киленгә тел-теш тидермә, улым. Үзең аннан үрнәк ал, картлар исән чакта аларның гыйлеменнән, күргән-белгәненнән файдалана белергә кирәк. Яз житеп килә, нинди хозурлык! Бакчадан керәсе килми, барысы да әниең белән бергә утырткан алмагачлар.— Карт тагын көрсенеп алды.— Нәкъ шундый матур көннәрдә генә гүр иясе булырга кем кушкан инде аңа?! Азрак көтсә, бергә-бергә киткән булыр идек...

Карт, көрәген иңенә куйды да, салмак кына атлап китеп барды.

Кече килен бу вакытта класста дәрес бирә иде. Аны күңеленә кереп оялаган борчулы уй сагалый: «Әткәй килә алырмы? Ниятем барып чыгармы? Әгәр ул авырыксынса?.. Ярый әле башкаларга әйтеп өлгермәгән идем...»

Багдәгөл шомлы уйларының очына чыга алмый калды — ерактагы чат башыннан иңенә көрәк күтәргән карт күренде. «Килә, ашыга-ашыга килә әткәй-җаным»!

Карт башта мәктәп бинасын ике-өч кат әйләнеп чыкты. Тирәли утыртылган яшь үсентеләрнең корышып куырылган җансыз кәүсәләренә хәйран калып тора иде ул. Ахырда берсенең төбен казырга тотынды.

Бу хәлне кабинеты тәрәзәсеннән күзәтеп торган мәктәп директоры да тыныч утыра алмады, карт янына чыкты, көрәген сорап алды, булыша башлады. Карт кайдан казырга икәнен күрсәтеп кенә тора иде инде.

Багдәгөл дәресен түгәрәкләде дә, тәрәзә аша урам якка күрсәтеп:

— Карагыз әле, балалар, кем килгән безгә? — дип сорады.
— Бакчачы бабай!
— Без аны бик яхшы беләбез,— дигән җаваплар ишетелде.
Ул арада, дәресләрнең тәмамлануын игълан итеп, кыңгырау чылтырады, балалар урамга, бакчачы карт янына атылдылар. Укытучылар да чыкты.
— Исәнме, бабай!
— Сәлам безнең хөрмәтле бакчачыга!— диештеләр.
Карт күңеле булып елмайды.
— Бәрәкалла, бәрәкалла! Сәламәтмесез, балалар! Сәламәт була күрегез! Иртәгә ял көнегезме әле сезнең? Ху-у-уш! Мәктәбегезнең гөлбакчага күмелеп утыруын телисезме? Яхшы-ы! Алайса, барыгыз да иртәгә шушы урынга җыелыгыз, мин дә килермен. Председатель белән сөйләштем, ул безгә яшь үсентеләр бирә. Шуларны утыртырбыз. Килештекме, килерсезме?
— Киләбез, бабай, киләбез!— дигән тавышлар яңгырады.
...Якшәмбе көн Багдәгөл өстенә эш киемнәре киде. Мәктәпкә якынлашкан саен тизрәк атлады. Чөнки эреле-ваклы балалар мәктәп янына әллә кайчан җыелганнар иде инде. Берәүләре арыкларны чистарта, икенчеләре чокырлар казый, өченчеләре яшь үсентеләрне таратып йөри. Каенатай исә, әле бер төркем янына килеп, әле ары китеп, балаларны өйрәтеп тора, эшләрен күзәтә.
Картка карап хәйран калырлык, әле кичә генә чүмеч тотарга да хәле булмаган калтыравык куллары да ныгып киткән кебек. Күрәген ул шундый җитез уйната, балалар да аңа охшарга тырышып казыйлар.
Менә ул гәүдәсен турайтты, киң билбавының очы белән тирләгән битен сөртте, елмаеп, тирә-ягына карап алды. Мәктәп янын яфрак бөреләре менә-менә ачылып китәргә торган яшь үсентеләр бизәгән иде. Аларның тиздән тамыр җибәрүенә, яфрак яруына һичнинди шик юк. Карт, үзалдына сөйләнгәндәй, әйтеп куйды:
— Бәрәкалла, нинди матур бу дөнья! Озаграк яшәгән саен аның ямен тирәнрәк тоясың!— Аннары ул тавышын акрынайта төште.— Син, карчык, мине ашыктырма әле, сабыр ит, яме?!

**КОЯШ ТИМБИКОВА** тәрҗемәсе.

## Мамбитали Каипов

# ҮЗ КАНЫМ

хикәя



алаңны иркәлә әзрәк, таш бәгырьле булма,— дип, әбисе онысын улына сузды. Амангилде ипсез итеп малаен кулына алды һәм, нишләргә белмичә, баласы белән бергә тынып калды.
Тормыш Амангилде белән усал шаярды. Малае болай тиз туар дип уйламаган иде ул. Аның исәбенчә, бу җан иясе дөньяга шактый соң килергә тиеш иде әле.
Әнисе бу хакта хәбәрдар түгел әлбәттә. Каян килеп улының шикләрен белсен ул! Бу турыда әнисенә ничек әйтсен инде ул...
Амангилде сиздермичә генә әнисенә карап ал-

ды. Әнә ул, бәхетле елмаеп, онытыннан күзләрен ала алмыйча тора. Оныгын зур үскән итеп күз алдына китерәдер, ахрысы. Беләсе иде, Айгөл киткән вакытта аңа нәрсә дип әйтте икән? Нишләп болай килеп чыкты соң әле бу? Кем гаепле моңа? Айгөлме? Әниме? Минме?

Амангилде уйга бирелеп стенагарак авышты һәм баласын төшереп җибәрә язды. Әнкәсе аны битәрләгәндәй башын чайкап куйды, оныгын үзенә алды, тезләренә яткырып, бәләкәченең авызына имезлек каптырды. Бала, авызын чупылдатып, имезлекне суыра-суыра, нәни маңгаен җыерып йокыга китте.

Амангилде аркасы белән стена салкынын тою рәхәтлегеннән күзләрен йомды, оеган аякларын язып җибәрде.

Шул вакыт аның күз алдына Айгөл килеп басты. Менә ул якында, кул сузымы гына арада басып тора. Аксыл тар мини-юбкадан, аягында биек үкчәле туфли, өстендә чигүле кофта. Түм-түгәрәк йөзе, юка иреннәре, куе кашлары шаян елмаюдан балкый сыман.

— Я, нәрсә? — дип сорый Амангилде күңеленнән.

— Берни дә юк,— дип җавап бирә Айгөл.

— Нигә безне ташлап киттең?

— Китәсем килгәнгә.

Әгәр Амангилде Айгөлнең үзен очратып бу сорауны бирсә, бәлки ул башка төрлерәк җавап бирер иде. Ләкин ул еракта. Бүтән җирдә бәхетлерәк булырмын дип уйлагандыр инде. Әйдә, күңеле теләгән җирдә, җаны тарткан кеше белән яшәп карасын. Нигә кеше тормышына тыгылырга?

Ә теге көнне Айгөл гаҗәп чибәр иде. Ул аккоштай йөзеп сәхнәгә чыкты, үзенең иң яраткан биюен башкарды. Тамашачылар озак итеп кул чаптылар. Ул алкышлардан дулкынланган иде күрәсең, укучы кыз сыман кызарып, ничектер тартынып, бирак баш иде.

Хәер, бәлки, Амангилдегә генә шулай тоелгандыр. Бәлки, Айгөл бөтенләй башка хисләр кичергәндер. Кем белә? Амангилденең бит кыздан бу хакта сораганы булмады. Кыскасы, Айгөл аны тиң итеп, серен ачмас дип курыкты.

Ул әле яңа гына урта мәктәп бетергән иде. Ә Айгөл инде артистка. Аның турында шәһәрнең аксакаллары да сокланып сөйлиләр. Кая инде мондый кызга якын бару!

Ул көнне Амангилде урамга иң соңгы кеше булып чыкты, залда һәм фойеда утлар сүнгән. Ишек төбендә артистлар җыелып тора, нәрсә турындадыр җанланып сөйләшәләр. Араларында Айгөл дә бар. Егет, аны күргәч, ирексездән адымнарын әкренәйтте, башын аска иде.

— Бәлки, мине озатып куярсыз?

Амангилде үзенең артында ук ишетелгән бу тавыштан сискәнеп китте.

— Я, ничек, егет, озатасызмы?

Айгөл баскычның өске сырында тора, егетне сихерләргә теләгәндәй, текәлеп карый иде.

— Әллә озатучыларыгыз бетеп киттеме?

Егетнең соравы артык тупас чыкты, хәтта үзе дә кыенсынып куйды.

— Куркасызмыни? — диде кыз, егетнең икеләнүен күреп.

— Кемнән?

— Миннән, әлбәттә.

— Ник куркыйм, сез тешләмисездер бит?

— Тешләрмен дә.

Амангилде җилкәсен сикертеп алды:

— Карап карыйк.

Тып-тын айлы кич. Аму ягыннан искән йомшак җил яшь агачлар-

га нидер пышылдый. Кайдадыр, кино-театр тирәсендәме, кыз-кыркыннарның чыркылдашуы ишетелеп киткәли.

Алар сүзсез генә атлыйлар.

«Кызык, Айгөл хәзер ни уйлый икән? Миннән көләдер, мөгаен. Күләгә кебек сүзсез кайтам. Аңа нәрсә әйтергә соң?»

Амангилденең уйлары чуалган. Ул сиздермичә генә кызга карап-карап куя. Ә кыз, кулына тоткан сыек чыбыгын селтәштереп, дәшмитынмый атлый.

— Сез кай тирәдәрәк торасыз?

— Сезнең дә телегез бармыни?

— Бар шул.

— Сезне, әлбәттә, минем кем белән яшәвем дә кызыксындырадыр?

— Юк...

— Мин берүзем яшим. Айбиби түтиләрдә.

Амангилденең Айбиби түтиләр йорты янынан үткәләгәне бар иде. Ул Аму буендагы яңа төзелеш ачылган төбәктә.

Тагын нәрсә сөйләргә икән? Минем йорт инде артта калды дияргәме? Юк-юк! Алай дисәм, бу миннән тизрәк котылырга уйлый икән дияр.

Кыз һаман чыбыгы белән койма буендагы үләннәргә селтәнеп бара, үзе тротуардан нидер эзләгән сыман, түбән караган.

— Сезгә ничә яшь?!

— Кызларның яшен сорыйлармыни?

— Гафу итегез, алайса.

«Менә сорыйсы нәрсәләр дә соралып бетте. Гомумән, кызлар белән ни турында сөйләшәләр икән? Һава торышы турындамы? Бәлки ай турындадыр? Чынлап та бүген ай нинди серле кебек. Беренче тапкыр гына күк йөзенә калыккандай, тирә-якка гаҗәпләнеп карый: ул безне күрә микән? Мөгаен күрәдер, менәсе иде шунда».

Амангилде үз уйларыннан елмайды. Әйе, анда менсәң шәп булыр иде. Айгөл белән бергәләп. Тик шунысы яман: анда да Амангилде ни хакында сөйләшергә белмичә интегер иде. Бүтән егетләр дә шулай микән? Ә кыз:

— Менә кайтып та җиттек,— диде.

— Якын икән,— диде Амангилде.

— Якынын якын да ялгызың йөрергә куркыта,— диде кыз. Ул кереп китәргә дә, торып калырга да белмичә икеләнгән кебек иде. Егет шунда капыл гына: «Сезнең белән танышырга мөмкинме»? — диде. Кыз тыела алмыйча пырхылдап җибәрде һәм «мөмкин» — дигән мәгънәне аңлатып баш какты.

Амангилде сүзен ялгый алмый азапланды. Үзенең шундый җебегән булуына җен ачулары чыкты.

— Сез нәрсә?— диде Айгөл,— мине белмисезме әллә?

— Беләм дә... Тик мин... Ни...

Кызның күзендә шаян очкыннар уйнады.

— Әйдә өйгә керик.

Амангилде куркып диярлек Айгөлгә карады.

— Өйгә?

— Әйе.

— Ни...

— Куркасызмыни?

— Курыкты ди!

Амангилде тавышына көрлек бирергә тырышты, әмма Айгөл аның хәлен аңлый иде: егетнең беренче мәртәбә кызлар озатуы. Шуңамы, Амангилде аңа тагы да якынрак булып китте. Ул егетнең кулына сак кына кагылды, мөмкин кадәр гадирәк, табигыйрәк күренергә тырышып болай диде:

— Курыкма, мин сезне төне буе утыртмам. Бер-ике чынаяк чәй эчәрбез дә, кайтырсыз. Я, киттекме?

— Әйдә!

Айгөл Амангилдене үз бүлмәсенә алып керде, тәрәзә янындагы ятагын күрсәтте һәм үзе өчен күптән таныш әйберләргә тиз генә күз йөртеп чыкты да:

— Менә мин биредә яшәп ятам инде,— диде.

Бер тәрәзәле кечкенә генә бүлмә. Тәрәзә астындагы стена уемында тимер карават тора. Караваттан уң якта язу өстәле, өстәл өстендә китап өемнәре. Стеналарга төрле кызларның, егетләрнең фоторәсемнәре ябыштырылган. Алар Айгөлнең сәхнәдәш дуслары булса кирәк.

— Сез чынлап та бер үзегез генә яшисезме?

— Мин монда кызлар белән торган идем.— Айгөл тәрәзә төбендәге рамлы фоторәсемгә күрсәтте:— Алар пединститутта укыйлар иде, былтыр бетереп киттеләр.

— Мин дә укыйм,— диде Амангилде ничектер үзе дә сизмәстән.

Айгөл гаҗәпләнеп әйтте:

— Шулаймыни! Димәк сез галим кеше булачаксыз. Көнләшәм сездән.

— Көнләшәсез? Нигә? Сез бит шундый оста биисез.

— Кая инде! — диде Айгөл кыенсынып.

Ул, тиз арада язу өстәлендәге китапларны җыештырып, эскәтер җәйде, табын әзерләде. Тәм-томнар, көлчәләр китерде.

— Чынлап, сез бик шәп биисез,— дип дәвам итте Амангилде,— сез консерватория бетердегезме әллә?

— Юк. Мин пединститутта укыйм. Сезгә минем биюем чынлап ошыймы?

— Әлбәттә!

— Рәхмәт!

Амангилде кәсәдән әз-әз йотып кына чәй эчә башлады. Аның инде әйтер сүзе беткән иде. Бәлки, Айгөл?.. Ул янәшәдә генә утыра: кочакласаң кочакта югалырлык кечкенә, биле нәзек, үзе шундый чибәр. Амангилденең мондый кызны әле беренче күрүе.

— Нинди тәмле чәй...

— Цейлон чәе,— Айгөл Амангилденең сәгатькә каравын күреп алды,— ашыгасызмы әллә?

Егет урыныннан тора башлады:

— Анда мине әни югалткандыр, мөгаен. Кайтырга кирәк. Минем әле беркайчан да болай озаклаганым юк иде. Мин кайтыйм инде, яме?

— Ярый-ярый, тоткарламыйм.

Амангилде ишеккә юнәлде, ә күңеленнән, Айгөл дәшеп алса ярар иде дигән өмет чаткысы үтеп китте. Әмма Айгөл дәшмичә генә урыныннан торды, тиз генә чыгып, Амангилденең туфлиләрен алып керде.

— Монда киенегез, тышта караңгы.

— Рәхмәт, Айгөл.

Кызның игътибары егетнең күңеленә бик хуш килде. Ул кызга рәхмәтле караш ташлап туфлиен киде һәм ашыкмыйча гына ишекне ачты.

— Туктагыз әле!

Айгөл йөгереп барып, Амангилде онытып калдырган газетаны өстәлдән алды да егеткә сузды, үзе аны эчкә үтәргә чакыргандай артка чигенде.

— Рәхмәт,— диде Амангилде тагын бер кат күкрәгендә ниндидер талпыну сизеп.

— Шимбә көн буш буласыңмы? — диде кыз.

— Шимбә?..

Айгөл Амангилденең икеләнүен күреп торды. Егет шимбә көн ни эшләячәген белми идеме, кызга ничек җавап кайтарырга дип аптыра-

дымы — тиз генә үзен кулга ала алмады. Кыз, аның югалып калуыннан файдаланып, ашыга-ашыга болай диде:

— Шимбә көн минем янга кил. Концертка барырбыз.

Амангилде кызның кыюлыгына исе китте. «Кара син аны, әй! Мин үзем болай эшли алмас идем әле».

Ярты ай чамасы вакыт үтте.

Институт бетергәннән соң гына өйләнергә дип йөргән Амангилде көтмәгәндә-уйламаганда мондый карарга килде: нигә соң бүген эшләп булган эшне иртәгә калдырырга? Тотарга да өйләнергә! Күңелендә мондый ният ничек тугандыр — Амангилде әйтә алмас иде. Бәлки Айгөлне югалтырмын дип курыккандыр (кыз артыннан бер артист кайчаннан бирле өтәләнеп йөри инде), бәлки, киленле итеп әнисен шатландырасы килгәндер, бәлки, тегесе дә, бусы да ашыгырга сәбәпче булгандыр. Ничек кенә булмасын, ул артык түзмәде: Айгөлне ЗАГСка алып китте.

Өйләнеп ике ай узуга аны армиягә алдылар. Айгөл бер утырып елады да, елап кына хәл үзгәрмәячәген белгәч, тынычланып калды.

*

* *

Амангилде хатлар куела торган такта янына тиккә генә ашкынып килә: Айгөлдән хат юк та юк. Амангилде бит аңа иртәсен дә кичен дә язып тора.

Көтелгән хат өч айдан соң гына килде. Айгөл кулы белән язылган конвертны алгач, аның хәтта тез буыннары хәлсезләнеп китте.

«Кадерлем, Алик,— дип язган иде Айгөл.— Син бик сәер кеше икәнсең. Үзеңнең хатларың белән мине тәмам күмеп ташладың. Күрәсең, бер эшең дә юктыр инде. Әллә башыңа берәр җүләр шик кердеме? Нишләргә соң синең белән, ә?

Кара әле, кадерлем, эш хәтта гынамыни? Син язасыңмы миңа, язмыйсыңмы, мин язаммы сиңа, язмыйммы — иң мөһиме йөрәктә берберебезгә мәхәббәт сүнмәсен. Минем сиңа хатлар язарга бөтенләй вакытым юк. Хәзер бигрәк тә — үзең беләсең, урып-җыю башлана, безне колхозга җибәрәләр. Алик, Алик, чын-чынлап юләр син! Я, ярар, әгәр синең бер эшең дә юк икән — әниеңә яз. Ул синең хатларыңны укырга ярата. Килештекме?

Сәлам белән Айгөлең».

Амангилде Айгөл фикере белән килеште. Әйе, эш хәтта мыни. Иң әһәмиятлесе — йөрәкләр суынмасын. Әмма Айгөлдән сирәк булса да хат килгәләп торса начар булмас иде. Монда, туган җирдән еракта, өйдәге кебек түгел бит. Сагындыра. Бәлки әле Айгөл колхоздан кайткач язар!

Көн арты көн үтә торды. Амангилде әйбәт хезмәт итте. Күңелен сагыш баскан чакларда гимнастерка кесәсеннән Айгөлнең хатын алып укый иде. Дөрес, ул инде аның һәр сүзен яттан белә. Шулай да таныш почеркны күрү аны тынычландыра, тормыш алай ук күңелсез күренми башлый.

Айгөл аңа тагын бер хат язды. Колхоздан кайткач ук түгел түгелен, ләкин Амангилде анысына бәйләнеп тормады инде. Айгөлдән килгән хат егетне бәхетле иткән иде.

«Алик! Син белмисеңме, миңа нәрсә булды икән? Мин нигәдер куркам. Валлаһи, әллә нәрсә шунда. Тик син көлмә, яме.

Син әниеңә яз әле, ул миңа юкка-барга бәйләнмәсен. Мин бит әллә кая чыгып йөрмим. Чыксам, репетициягә дә кибеткә генә. Ярый, мин көне буе өйдә утырдым ди, аңардан әниеңә җиңеллек киләме? Син яз әниеңә, ишетәсеңме?!

Их, бу көннәрен әйтер идем: ничек тиз үтә. Институтка әле кичә генә кергән сыман идем, ә хәзер чираттагы сессия килеп җитте. Тиз-

дән госэкзамен. Син күз алдына да китерә алмыйсындыр көннәрнең ничек узуын.
Ярый, әйбәт хезмәт ит, бәхет теләп: Айгөл».
Амангилде бу хатны да яттан өйрәнде. Бу хат та, беренчесе кебек, гимнастерканың сулъяк кесәсендә, нәкъ йөрәк өстендә йөри. Әлбәттә, Амангилде кичекмәстән әнисенә хат юллап, Айгөлгә карата игътибарлырак булуын үтенде. Ул бит бигрәк яклаучысыз, беркатлы, диде. Әнисе җавапны озак көттермәде — улына борчылмаска кушты, аллага шөкер, тормышлар әйбәт бара, Айгөленә берни булмас, дип язды.
Тик барыбер Амангилденең күңеле утырып җитмәде. Айгөлне бик яраткангамы, тормышын аннан башка күз алдына китерә алмады. Айгөл хатларны ешрак язса, аңа нык җиңел булыр иде.
Шушы гомергә нибарысы ике хат ал да, ничек инде җаның пошынмасын?
Беркөн кич Амангилде янына взвод командиры капитан Колосков килде. Ул инде Амангилдене күптән күзәтеп йөри иде: соңгы вакытта егет ни өчендер үз эченә йомылып бара, дусларыннан читләшә, ниндидер борчуы бар сыман. Менә шушы нәрсә сагайтты командирны. Дөрес, ул Амангилдегә сүз катарга ашыкмады. Үз уйлары белән көрәшергә егетнең үзенең көче җитәр дип уйлады. Әмма бу хәл озакка сузылгач, түзмәде, янына килде.
— Нәрсә турында уйланабыз, солдат?
Командирның тавышы Амангилдене сискәндереп җибәрде. Ул утырган җиреннән сикереп торып, честь бирде.
— Хәерле кич, иптәш командир!
— Хәерле кич... утыргыз.— Колосков солдатның янәшәсендәге ташка утырды, кесәсеннән портсигар чыгарып, бер папиросны үзенә, икенчесен Амангилдегә сузды.— Шулай да ни турында уйланабыз, ә?
— Болай гына, иптәш капитан. Берни турында түгел.
— Я, я, Амангилде, мин сезне беренче көн генә белүем түгел. Минем белән ачыктан-ачык сөйләшә аласыз. Бәлки, берәр ярдәмем тияр.
Амангилде чигәсенең кызыша башлавын сизде. Әлбәттә, командир ярдәм итә алыр иде аңа. Ләкин үз борчуыңны ничек әйтергә. Аның болай да эше муеннан.
— Ничек әйтергә дә белмим инде, иптәш капитан. Нигәдер өйдән хат юк. Әллә әнигә бер-бер хәл булган инде?..— Амангилде Айгөлдән хат килмәвен әйтергә уйлаган иде, тыелып калды.— Әни минем үзе генә. Әти өченче ел үлгән иде.
Колосков сүнгән папиросын кулында угалап: «Сезнең хатыныгыз да бар бугай»,— диде.
— Әйе.
— Аннан хат киләме соң?
— Юк.
— Аңлашыла...
Шул вакыт казарма ягыннан кичке ашка чакыру тавышы ишетелде. Амангилде янында командир барын онытып җибәрде ахрысы: бу тавышны ишетүгә, гадәтенчә сикереп торып, казармага таба китә башлады. Шулчак исенә килеп, икеләнеп тукталып калды. Колосков аңа:
— Барыгыз! — диде.
— Тыңлыйм, иптәш капитан.
Амангилде кулын фуражкасына тидереп алды да, кисәк борылып, казармага таба йөгерде. Әмма бераздан командирның тавышын ишетеп кире туктады.
Колосков әкрен генә аның каршысына килде, күрәсең ул нишләргә икәнен үзе дә белми иде әле.
— Мин часть командиры белән сөйләшеп карармын. Бәлки, атна-ун

көннән өегезгә кайтып килергә рөхсәт бирерләр. Билгеле, тегенди-мондый көтелмәгән хәл килеп чыкмаса.

*

*   *

Менә Амангилде өендә — командир тәки үз сүзендә торды.

«Их, Айгөл, Айгөл! Нәрсә эшләдең син? Нигә болай мәрхәмәтсез кыландың? Нигә, Айгөл? Бәлки, син мине яратмыйсыңдыр?»

...Амангилде, уйларымны әни ишетмәде микән дип шикләнгәндәй, як-ягына каранып куйды. Әнкәсенең анда эше юк икән — ул бәләкәй оныгы белән мәш килә.

«Әлбәттә син мине яратмыйсың, Айгөл. Әгәр яратсаң, улыңны калдырып, бездән китмәс идең. Нигә дип киттең син? Бик беләсем килә, Айгөл. Нигә?»

Бәләкәчнең дөньяда гаме юк: кулларын селтәп, үзенчә нидер сөйләнә-сөйләнә, авызыннан күбекләр чыгара.

«Үс, бәләкәч, үс! Син әбиеңнән дә, миннән дә үз анаң турында бер генә начар сүз дә ишетмәссең. Нигә сиңа ул хакта белергә? Мин белгән дә җитәр. Бәлки, берәр вакыт, син зур үскәч, күңелемне чишәрмен әле. Ләкин бу әле тиз булмас. Син инде ул чакта минем кебек авырлык сизмәссең. Ә хәзергә йокла, бәләкәч, төшеңә бәхет керсен».

Амангилде йомшак кына итеп баласының борын очына тиеп алды.

— Кара, кара, сине таныды бит,— диде әнисе.

— Әйе,— диде Амангилде көрсенеп.— Үз каным.

Әбисе бәхетле елмаеп оныгының кулларын үбәргә, үзе генә аңлый торган телдә нидер сөйләргә тотынды.

Амангилде тәрәзәгә табарак китте, әнкәсенә яшертен генә күз салды һәм башын түбән иде.

«Ярый әле син бәхетле, әни. Бәхетле булыр өчен сиңа күп кирәкмени! Оныгыңны сакла, әнкәй. Көзен, мин армия хезмәтен тутырып кайткач, бөтенесен үз өстемә алырмын. Безнең болай булуга бала гаепле түгел».

Тәрәзәдән өйгә кояш нуры кереп тулды. Ул нурлар, тезендә бала йоклаткан ана йөзенә һәм гамьсез яткан балага төшеп, аларны сихри яктылык белән күмә иде.

**ФӘНИС ЯРУЛЛИН** тәрҗемәсе.

## Уразак Бекбаулов

# ЛЕГЕНДА

*«ТАРАС АРАЛДА» ИСЕМЛЕ ӘСӘРДӘН*



Ярар, алайса, мин сиңа менә бер легенда сөйлим. Азиягә дә, Россиягә дә аның тәэсире көчле булган,— дидем мин юлдашыма, ул бик үтенә торгач.

Ул:

— Әйдә, сөйлә әле,— дип шатланып креслосына җайлабрак утырды.

Моннан ике гасыр ярым элек Нефет-Даг тирәсендә утырган тыныч кына бер авылда шундый хәбәр тарала. Бер төрекмән сәүдәгәре үзе сату итеп йөргән җирләр турында сөйләп утырганда ике йөз еллар элек гарәп сәяхәтчеләренең Хазирда, ягъни Хорезм диңгезе ярларында булганнарын һәм

ул чорларда Оксус елгасының (Аму-Дәрьяны элек шулай атаганнар) Хазар диңгезенә, ягъни Каспийга коюын әйтә. Озын сакаллы сәүдәгәрне тыңлап утырган Хуҗа Непеска бу сүзләр шундый нык тәэсир итә ки, ул дулкынланудан чәй агызган кәса урынына кунагына тәмәке тартмасы суза.

— Оксус елгасы,— ди карт сәүдәгәр, сүзен дәвам итеп,— Һиндстандагы иң биек таулардан башлана. Ул таулар шундый биекләр, алар аша хәтта кошлар да очып үтә алмый. Елга суы, тау токымнарын ерып, аска ашкына һәм үзе белән ходайның иң зур байлыгын — катламнар арасында яткан алтыннарын да юа.

— Алтын дисеңме? — дип сискәнеп куя тыңлап утыручылардан берәү.

— Әйе, алтын. Су алтынны да агыза. Елга башындарак яшәүчеләр судан аны балык тоткан кебек тоталар,— ди карт ышандырырлык итеп. Тыңлаучылар, сәерсенеп, бер-берсенә карашып алалар, аннары шаулашып сөйләшә башлыйлар. Тавышлар бераз тынгач, карт дәвам итә.— Алтын турындагы хәбәр көнен дә, төнен дә Бохара белән Хива ханнарына тынгылык бирми. Алар руслар килер дә алтынны үз кулларына алырлар дип шикләнәләр. Бу мәсьәләдә зур саклык күрсәтсәләр дә, хәбәрнең русларга барып җитмәвенә ышанып бетмиләр. Хәбәрне ничек тә русларга ишеттермәү чараларын күрәләр. Оксус елгасының кайда икәнлеген чит кешегә әйтү катгый рәвештә тыела. Моның белән генә чикләнмичә, елганы буып та куялар.

— Елганы буып буламы соң? — ди тыңлаучыларның берсе гаҗәпләнеп.

— Ник булмасын. Халыкта — көч, бер тотынса, булдырмый калмый. Елганы хан бумаган, әлбәттә, халык буган, күмәкләшеп эшләнгән бу эш. Мәккә белән Мәдинәне, Петербургны төзегән халыкның Оксус кебек елгага гына көче җитмәсме? — ди сәүдәгәр игътибар белән тыңлап утырган Хуҗа Непеска карап.

— Әйе, халык тотынса булдыра...,— диешеп, тыңлаучылар баш кагалар.

Шушы көннән Хуҗа Непесны уй баса. Аз сөйләшә, уен-көлкегә кушылмый, ни турындадыр һаман уйлый да уйлый. Яшьрәк чагында ул рус сәяхәтчеләренә юл күрсәтүче булып йөри, алардан бик күп нәрсәгә өйрәнеп калган була. Әлеге рус кешеләренең сөйләвенә караганда, Петр I атлы патшалары Һиндстан, Әфганстан, Кытай белән яңа сәүдә юллары ачу хакында хыялланган, чөнки Бохара аша салынган кәрван юлы бик озын һәм кыен икән. Шушыны истә тотып, Хуҗа Непес: моны патшага ачсам, ул миңа теләгәнемне бирер, бигрәк тә чәчүлек җирсез итмәс, дип уйлый.

Шушы көннән ул гел баеп китү турында хыяллана, икенче төрле әйтсәк, «су күрмәс борын аяк чишенә башлый».

Һәм көннәрдән бер көнне, атына атланып, Хуҗа Непес Петербургка чыгып китә. Максаты — патшаны күреп сөйләшү. Ул киткәч, халыкта аның турында төрле сүзләр тарала. Берәүләр аны фәлән юлдан, икенчеләре төгән юлдан киткән, дип сөйлиләр. Очрашкан һәр ике кешенең телендә ул була.

Үзенең Тимеркүгенә атланып, өч ай да егерме көн дигәндә Хуҗа Непес Петербургка барып җитә.

Нефет-Дагтан чыккач, Петербургка җитү белән ул патша сараена туп-туры керермен дип уйлый. Әмма башкалада икеләнеп кала, кәефе кырыла. Шулай да ул патша сараена керү хакында кайгырта башлый.

Хуҗа Непес үзен бик кыю тота, моны күреп, сарай кешеләре аны ерактан килгән берәр илчедер дип уйлыйлар. Зур хөрмәт күрсәтәләр, атын үз карамагына алалар.

Хужа Непес тизрәк патша янына кермәкче була, ләкин вице-канцлер аның юлына каршы төшә:

— Бәлки йомышыгызны берәр министерствода хәл итеп булыр, нинди эш белән килгән идегез... һәр нәрсә белән императорны борчып йөрү уңайсыз,— дип ничек тә Хужа Непесны кертмәскә күндермәкче була.

— Миңа император үзе кирәк, аның белән генә сөйләшәм,— дип кабатлый Хужа Непес бернича тапкыр, күпме генә үгетләсәләр дә сүзендә нык тора.

Кунакны болай гына күндереп булмаячагын аңлап, сарай кешеләре аның хакында Петр I гә әйтәләр. Император кунакны кабул итә.

Хужа Непес сөйли, тылмач тәрҗемә итеп тора. Хужа Оксус елгасының бетмәс-төкәнмәс хәзинәләре, элекке заманнарда ул елганың Хазар диңгезенә коюын, хәзинәләрнең руслар кулына төшүеннән куркып, Хива ханының елганы будыртуын, Хорезм диңгезенә таба боруын сөйли.

Тыңлый торгач, императорның йөзе үзгәргәннән үзгәрә бара, күзләре тылмачка түгел, хужага төбәлгән. Императорның карашыннан Хужа курка кала, ләкин шул чак Петр I елмаеп куя һәм бу елмаю Хужага өмет өсти.

Менә Петр I аягына торып баса. Тылмач Хужа Непеска да урыныннан торырга ымлый.

— Дәвам итсен,— ди император һәм каушап калган Хужаны тынычландырыр өчен стенадагы географик картага борыла. Әмма Петр I күпме генә караса да, Оксус елгасының Хазар диңгезенә түгел, Хорезм диңгезенә койганын күрә. Бәлки элек чыннан да шулай булгандыр дип уйлый һәм килеп кунакның аркасыннан сөя.

Хужа Непес моны хуплау дип кабул итә.

— Сезгә, Һиндстан, Әфганстан, Кытай белән сәүдә ачу өчен су юлы булдыру әллә ни авыр булмаячак,— ди ул.— Хивалылар булдыргаңны сез булдырасыз да булдырасыз инде.

— Хәбәрегез дөрес булмаса да, ул миңа кадерле,— ди император.— Уйлашырбыз, әлегә сез ял итегез, соңыннан дәвам итәрбез.

Петр I кунакка затлы бүләкләр тапшырырга һәм Россиягә булган яхшы мөнәсәбәте өчен аның хөрмәтенә зур кичә үткәрергә куша.

Болай зурлау Хужа Непесның күңеленә бик хуш килсә дә, ул үзенең язмышын уйлап борчыла. Ул китергән хәбәр әгәр чыннан да дөрескә чыкмаса? Ни булыр ул чакта? Бу уй аңа тынгылык бирми. Ләкин император белән булган соңгы сөйләшү начар үтмәде кебек. Борчылырга нигез юк шикелле.

Бераз вакыттан соң Хужа Непесны зур хөрмәт күрсәтеп үз иленә озаталар.

Хужа Непес югалып торган арада аның турында авылда төрле сүзләр йөри. Берәүләр аны зур бүләкләр белән кайта имеш дип сөйләсәләр, икенчеләре исә ышанмасалар башын кисәчәкләр икән дип тараталар. Ә кайберәүләр Хужа күптән инде руслар белән элемтәдә булган, рус патшасы аны яшертен генә үз янына чакыртып алган дип гайбәт таратканнар. Патша кабул иткән кешегә кагылмыйлар икән, менә күрерсез, Хужа исән-имин кайтыр да керер, дип сөйләүчеләр дә булган. Үтеп баручы кәрван башларыннан да аны сораштырып торганнар, әмма Хужа Непес турында бернинди хәбәр ишетелмәгән. Бәйрәм табыннарында, туйларда да гел аны телгә алып сөйләгәннәр.

Җиде ай тулды дигәндә Хужа Непес өенә кайтып төшә. Халык аны котларга агыла. Элегрәк Хужа Непес яхшы сәүдәгәр һәм игенче буларак билгеле булса, хәзер аның даны тагын да арта. Хәзер ул Петербургка барып патшаның үз кулыннан бүләк алган кеше бит! Бәйрәмнәрдә һәм туй мәҗлесләрендә беренче сүз аңа бирелә. Аның белән киңәшмичә авылда бер эш тә башланмый.

Хужа Непесның хәбәре Петр I не тирән уйга сала. Ул көн-төн шул хакта уйлый, яңа сәүдә юлы ачу турында хыяллана. Һәм төпле бер фикергә килер өчен галимнәрне җыеп киңәшергә була.

Сарайга галимнәр җыела. Үзләренең нигә чакырылуларын уйлап баш ваталар.

Менә нык адымнар белән залга Петр I килеп керә. Җитди йөзендә сизелер-сизелмәс елмаю. Аны барысы да аягүрә басып каршылыйлар. Император аларга Хужа Непес алып килгән хәбәрне сөйләп бирә, фикер әйтүләрен сорый.

Россиянең киләчәгенә кагылышлы бу мәсьәлә барысын да дулкынландыра, чөнки моңа хәтле дә Һиндстан, Әфганстан, Кытай белән сәүдә мөнәсәбәтләре урнаштырырга күпләр тырышып карый. Галимнәр үз фикерләрен әйтәләр, әмма берәү дә Оксус елгасының борынгы заманда Хазар диңгезенә коюын раслый алмый. Шушы көннән башлап яңа сәүдә юлы ачу мәсьәләсе көн тәртибеннән төшми.

Петр I Фәннәр Академиясендә эшләүче атаклы галим, картограф Ж. Н. Делиль белән киңәшә, ләкин Делиль аңа ярдәм итә алмый. Бу хәбәр аның өчен дә яңалык була, анда бик нык кызыксыну уята.

Көнчыгыш белән яңа сәүдә юллары ачу идеясе Россиядә беркайчан да онытылмый һәм шуның нәтиҗәсендә күп санлы экспедицияләр оештырыла. Алар составында каракалпаклар җиренә рус, украин, поляк халыкларының атаклы вәкилләре килә. Каракалпак халкын агартуда, күзен ачуда, аны гасырлар караңгылыгыннан чыгаруда бу шәхесләрнең роле зур.

СОЛТАН ШӘМСИ тәрҗемәсе.

Лирон Хәмидуллин

# ЕРАК АРАЛАРНЫ ЯКЫН ИТЕП

Былтыр, җәй урталарында, республикабызның зур төркем әдәбият һәм сәнгать осталары Каракалпакстанда иҗат бәйрәме үткәреп кайттылар.

Менә быел инде каракалпак кардәшләребез безгә килә. Журналыбызда укучы хөкеменә тапшырылачак бу сәхифә әнә шул туй-бәйрәмгә дип хәзерләнгән кунак сыеның бер өлеше.

Әйе, бездән шактый еракта, ярыйсы ук читтә булганлыктан, Аму-Дәрья буйларына барып-кайтып Каракалпак дуслар белән күрешергә турыдан-туры бәйләнешергә бик еш туры килми әле безгә. Казагыстанның Мангышлак нефтен чыгарышырга барган татар нефтьчеләре дә әлегә Каракалпакстанның чик буена, Өстерт калкулыкларына гына үтеп керделәр.

Ә халыкларыбызның күңелләр бердәмлеге, дуслык тамырларының бергәләп тирәнгә сузылуы Бөек Октябрь революциясенә кадәрге еллардан ук килә. Мәдәният казанышларыбыз белән турыдан-туры уртаклашу исә гражданнар сугышы чорында туган-даш Урта Азия халкына бөек Ленин идеяләрен җиткезешүдә аеруча көчле чагылды. Моны без, мәсәлән, беренче Төркстан Совет хөкүмәте вәкиле якташыбыз Кәрим Хәкимов, язучы кызыл комиссарлар Афзал Таһиров, Шамил Усманов, Төркстан АССРның беренче мәгариф комиссарлары язучы Шәһит Әхмәдиевләр биографиясендә күрәбез.

Уку-укыту, китап тарату, сәнгать өлкәсендәге кайбер казанышларыбыз белән уртаклашу күпкә алданрак башланган. Революция алды елларында татар интеллигенциясенең суга сусап яткан сахра чүл кебек аң-белемгә мохтаҗ каракалпак халкына

мәгърифәт алып килүе хакында язма мисал китерәлек. Бу хакта, каракалпак халык шагыйре Ибраһим Юсупов 1980 елда Нөкистә чыккан «Татар шагыйрьләре» китабына кереш сүзендә менә ничек яза: «Татар халкының белем ияләре — интеллигенция вәкилләре соңыннан үз җирлегендә генә түгел, бәлки бөтен Урта Азия белән иркен Казагыстан өлкәләрендә дә яңача тормыш кору өчен үз-үзләрен аямый хезмәт иттеләр. Рус иле аша Европадан килгән мәгърифәт нурын Көнчыгыш халыклары арасына иңдерү буенча искелеккә каршы бик көчле көрәш алып бардылар» дип яза ул. Шундый ук фикерне «Аму-Дәрья» журналының 1980 елгы җиденче санында Каракалпак тел, әдәбият һәм тарих институтының директоры, профессор Кабул Мәкъсүтов та куәтли. Ул «Егерменче гасыр башында татар телендә елына өч йөздән артык китап басылып торды... аның йогынтысы каракалпак халкына да җитеште... Бөек Октябрь революциясенә кадәр Казанда, Уфада, Оренбурда һ. б. шәһәрләрдә татар телендә чыккан газета-журналларны Урта Азия җирлегендә дә алдыручылар, яратып укучылар булды... Г. Тукай ише олы әдипләр... барлык төрки телле халыкларның сөекле шагыйренә әверелделәр. Революциягә чаклы һәм революциядән соң иҗат иткән каракалпак язучылары, шагыйрьләре алардан үрнәк алды, алар йогынтысында яздылар» ди автор һәм аның аерым мисалларын теркәп китә.

Хәзерге Каракалпакстан Автономияле республикасы Үзбәкстан ССРга керә. Аның җир биләмәсе Үзбәкстан территориясенең кырык өч процентын тәшкил итә. Әмма ул җирнең күп өлеше яшәү өчен яраксыз — анда елга-сулар юк, яңгырлар бөтенләй диярлек ямый. Тормыш итү Аму-Дәрья үзәненә һәм Арал диңгезе буйларына гына җайлашкан. Җимеш бакчалары, иген кырлары арык, ерганаклар аша дәрья белән сугарылалар.

Республиканың төньягын Арал диңгезе чикли. Көнбатышта Арал белән Каспий диңгезе аралыгында, иксез-чиксез буш Өстерт такырлыгы. Еллар буе тамчы су күрмәгән шул калкулык янәшәсендә үк диярлек «Барса килмәс» баткаклыгы. Бу тирәләрдә булган сәяхәтчеләр Өстертнең кинәт умырылып, урыны-урыны белән ике йөз иллешәр метр тирәнлеккә җитеп, капыл гына баткаклыкка күчүенә хәйран калалар...

Ә көнчыгышта, Аму-Дәрья үзәненнән Сырдәрья үзәненә кадәрле мең чакрымлы бушлыкта Кызылком чүл-сахрасы. Анда инде бөтенләй берни дә үсми. Болай да тар оазис-үзәнне көньяктан кысрыклап Караком чүле килеп тоташа. Җирләрен көньяктан төньяк-көнбатышка таба сугыштан соңгы бишьеллыкларда салынган тимер юл кисеп үтте. Аңа кадәр илебез үзәгеннән булсын, Урта Азия республикаларыннан булсын Каракалпакстан белән экономик аралашу бик авыр иде.

Каракалпак халкының тарихи юлы бик катлаулы. Алар хакындагы беренче мәгълүматлар урта гасыр башларына, Киев кнәзлеге чорларына карый. Ул вакыт каракалпакларның бер өлеше Кара диңгезнең төньягында, Днепр буйларында яшәгән. Киев кнәзлегенең көньяк күршеләре буларак шул чор рус елъязмаларында алар хакында төрле истәлекләр шактый. Әйтик, шуларның берсендә каракалпакларның Юрий Долгорукийга биргән вәгъдәсе китерелә: «Без... рус җире өчен синең улларың белән бергә үләрбез, синең намусың дип башыбызны корбан итәрбез...»

Аннары кайбер шәҗәрә-истәлекләрдән каракалпакларны Идел, Идел-Җаек төбәгенә бәйле итеп күрәсең. Ул вакыт олы Идел белән Җаек (Урал) елгалары арасында яшәгән каракалпаклар: «Идел — илнең ишеге, Җаек — җирнең бишеге» дип... җырлаганнар. Шул чордан инде бу ике халык телендә дә:

Атам кияү булган җир,
Анам килен булган җир,
Кендегемне кискән җир,
Төмле суын эчкән җир,

— кебек уртак җыр, мәкальләр калган.

Бу күршелек, якынлык безнең кайбер истәлекләрдә дә чагылыш таба шикелле. Мәсәлән, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты хезмәткәре М. Әхмәтҗанов бер мәкаләсендә болай ди: «Урта гасырларда хәзерге каракалпак һәм татар халкының бабалары бер-берсе белән тыгыз этник, политик, экономик һәм культура элементларендә булганнар. Бу хәл... ике тугандаш халыкта яшәп килгән шәҗәрәләрдә сакланган. Әйтик, каракалпак шәҗәрәләрендә ыру-кабиләләренең башында борынгы заманнарда Майкы би булган дип тасвирлана. Татарстанның Баулы һәм Саба районнарыннан табылган шәҗәрәләрнең дә төп бабалары итеп Майкы би яки Байкы би күрсәтелгән». Бу очраклы гына түгел, билгеле. Каракалпакның «Ормамбәт би» янсә «Идел кайда, ил кайда» кебек тарихи җырауларында да ике халыкның уртак мөнәсәбәтләренә караган мисаллар бар диелә.

Алтын Урда бүленеп таркалганда каракалпаклар исеме бер ара Ак Урда, Ногай Урдалары биләмәсендә телгә алына. Аннары берничә буын буе алар әле шул казакъ (Ак Урда), әле Бохара хан-солтаннарына буйсынып көн күрәләр. Ә 1722 елда, Россиягә кушылырга теләк белдереп, Петр 1 патшага да мөрәҗәгать итәләр. Мәгәр бу тиз генә тормышка ашмый. Унтугызынчы гасыр башында каракалпак ыруларының өлкән биләре үзләрен кабул итүне үтенеп күрше Хива ханлыгына баралар. Шул буйсынудан Бөек Октябрь революциясе ирек алып килгәнчегә чаклы бүгенге каракалпак җирләренең күп өлеше Хива ханлыгының биләмәсе булып кала. Тик Аму-Дәрьяның уң як яры гына 1874 елда Россия дәүләтенә кушыла.

Ирек сөючән каракалпак халкы Хива ханлыгына каршы берничә мәртәбә баш күтәрә. Шулардан бер күтәрелеш-кузгалыш халык телендә «Коңгырат күтәрелеше» яки «Бүзатау (Бозатау) бәрелеше» булып хәтерләнә (1858—1859 еллар). Баш күтәрүчеләрнең башлыкларыннан берсе шагыйрь Әҗинияз (1811—1878) була. Алар Арал буендагы кечерәк атауга бикләнеп (Бүзатау) соңгы сулышка кадәр диярлек хан гаскәренә каршы сугышалар. Бик аз кеше генә исән кала. Шулар арасында Әҗинияз да була, һәм тиздән ул төньяк казакъ далаларына качып китә. Йөри-йөри Урал-Җаек буйларына — татар-башкорт араларына ук барып чыга. Шул елларда Коңгырат күтәрелешенә багышлап күп кенә шигырь чыгара. Каракалпакларның бер өлеше Россия дәүләтенә кушылгач кына ул иленә кайтып үлә.

Хива ханлыгына каршы халыкның баш күтәрү вакыйгалары чәчән шагыйрь Бердахның «Айдас би», «Айдас баба», «Ирназар би» кебек дастаннарында, Әҗиниязның Бүзатауга багышланган көчле рухлы, ялкынлы шигырь циклында сурәтләнә. Бердахның төрле ыру атамалары килеп чыгышын тасвирлаган бик зур «Шәҗәрә» дастанында да бу хәлләргә урын бирелә.

Каракалпакларның язма әдәбияты егерменче елларның икенче яртысында гына барлыкка килә. Аңа кадәр яшәгән барлык шагыйрьләр дә чәчәннәр — иҗат иткән әсәрләрен авылдан-авылга, илдән-илгә йөреп, сөйләп, халык күңеленә иңдергән шагыйрьләр.

Әйе, каракалпак әдәбияты, кайбер башка төрки әдәбиятлар кебек, чәчәнлек традицияләрен безнең гасыр урталарына кадәр китереп җиткергән әдәбият. Узган гасыр башларында ук иҗат иткән халык күңеленә «Уракчылар», «Куй көтүче» кебек әсәрләре белән уелып калган «шайыр» Көнхуҗа (1799—1880), динчеләр һәм байлар кысуын, халык арасындагы социаль тигезсезлекне язган, хезмәт сөючән, тапкыр телле халкына дан җырлаган Үтәш Алшынбай улы (1828—1902), иҗатлары белән халыкның намусы да вөҗданы да булган, бөтен тарихи язмышын чагылдыра алган Әҗинияз (1811—1878), Бердахлар (1827—1900) — әнә шул борынгыдан килгән традициядә иҗат иткән, шуның белән илгә, халыкка танылган шагыйрьләр.

Хәзер ул талантлы чәчән-шагыйрьләрнең әсәрләре җыелып тупланып, язма әдәбият казанышы булып китте, олы мираска әверелделәр. Соңгы елларда гына бөтен ил белән бергә Әҗинияз, Бердах юбилейлары уздырылды. Каракалпакстанның бүгенге башкаласы Нөкистә олы фикер иясе Бердахка һәйкәл куелды. Соңгы чирек гасырда бу сүз осталарының әсәрләре рус, үзбәк, казакъ, украин һ. б. телләргә тәрҗемә ителделәр. Бердах иҗаты белән татар укучысы да берникадәр таныша алды («Казан утлары», 1978 ел, 11 сан).

Шушы олы мирасны, борынгы традицияне инкарь итмәстән, яңа чорның яңа таләпләре нигезендә совет власте елларында Каракалпакстанда яңа, язма әдәбият барлыкка килде. Аның нигез ташларын салуда революция алды елларында ук иҗат юлына баскан якташыбыз Сәйфелгабит Мәҗитов (1869—1938), Аяпбиргән Мусаев (1880—1936) күп хезмәт куйдылар. Бу җәһәттән С. Мәҗитовның хезмәтләре аеруча зур. Туган теле татар теле булганлыктан ул татар әдәбияты һәм матбугатын укып, аның ирешкән уңышларын белеп яши. Каракалпакстанда яңа тормыш урнашу белән ул мәктәпләр ачуга, беренче каракалпак әлифбасын төзүгә алына. Халык авыз иҗаты үрнәкләрен, чәчән шагыйрьләренең халыкта йөргән әсәрләрен язып ала, аларны беренче уку әсбаплары — дәреслек-хрестоматия рәвешендә туплап чыгара. Бу китап-дәреслекләр егерменче ел урталарында дөнья күрәләр.

1924 елның ахырында каракалпакча беренче газета «Беренче адым» чыга.— Башта ул Хөҗәйлидә, соңрак республиканың яңа башкаласы Дүрткүлгә (инде «Иркен каракалпак» исеме белән) күчерелә. Анда 1927—1929 елларда бу газетаның җаваплы секретаре булып язучы С. Мәҗитов эшли. Шунда ук «Хезмәт әдәбияты» исемле беренче әдәби журнал 1931 елның ноябрендә чыга башлый. Аңа кадәр укытучылар, интеллигенция арасында «Кызыл мөгаллим» дип исемләнгән кульязма журнал (1927—1930) таратыла. Каракалпак телендә беренче хикәяләр шуның битләрендә күренә башлый.

Каракалпакта беренче проза әсәрләре иҗат итүчеләр Нәҗим Дәукараев белән Сәйфелгабит Мәҗитов була. Нәҗим Дәукараев хикәясе егерменче елларда Коңгырат төбәгендә басмачыларга каршы көрәшне сурәтләүгә багышланган. С. Мәҗитовның каракалпак фольклорыннан тыш үз чәчмә әсәрләре дә урнаштырылган «Уку китабы» 1925 елда Ташкентта басыла.

Партия өлкә комитеты һәм дәүләт оешмаларының әдәбиятка килүчеләргә даими ярдәме нәтиҗәсендә утызынчы еллар башында яңа каракалпак әдәбиятының нигезе формалаша. Сәнгатьнең башка төрләре һәм театр туа. Драматургия барлыкка килә.

Каракалпакча беренче пьесаны Касыйм Әүезов яза (1897—1938). Аны 1925 елда шагыйрь С. Мәҗитов һәм педтехникум укытучысы Зариф Касыймов оештырган «Таң нуры» һәвәскәр артистлары сәхнәләштерә. Соңыннан дәүләт театры булып үсәчәк бу коллектив өчен С. Мәҗитов үзе дә 1925 — 1928 еллар арасында «Сабак», «Ирназар батыр», «Егет булдык», «Соңгы киртә» пьесаларын, ә 1935 елда танылган «Багдагөл»ен яза. Әтисе үрнәгендә улы, язучы Рәхим Мәҗитов та (1903—1977) берничә драма әсәре иҗат итә, аның «Кара йөрәкләре» театрда уңышлы гына бара.

Егерменче, утызынчы еллар арасында Каракалпак әдәбиятына соңыннан халык шагыйре исемен казанган Җолморза Аймөрзаев (1910) һәм Аббаз Дабылов (1898—1970), шагыйрь Әсән Бегимов (1907—1958), шагыйрь һәм прозаик Мирзагали Дәрибаев (1909 — 1942), шагыйрь һәм әдәбият галиме Нәүрыз Җапаков (1914 — 1975), шагыйрь Дәли Нәзбиргәнов (1913 — 1942), халык шагыйре Садыйк Нурымбәтов (1900 — 1972), шагыйрь Избасар Фазылов (1909 — 1961), шагыйрь Артык (1915 — 1943), шагыйрь һәм прозаик Амәт Шаһморатовлар (1912—1953), калкып, күтәрелеп чыктылар. Бу әдипләрнең һәрберсе каракалпак әдәбиятында эз калдырды. Аның бүгенге көн дәрәҗәсенә үсеп җитүе, күтәрелеше өчен армый-талмый эшләделәр. Дөрес, утызынчы еллар каракалпак әдәбиятында әле күренешне озың итеп тасвирлап бирү, сөйләп чыгу алымнары үзен нык сиздерә. Сурәтләү чаралары бертөрлерәк була.

Сугыш алды елларында күләмле шигъри әсәрләрдән И. Фазыловның «Колхоз язы», Артык Шаймуратовның «Кавказ һәм Лермонтов», «Хезмәт мәйданында», М. Дәрибаевның «Аймҗамал», Җ. Аймөрзаевның «Көрәш», «Көрәштә җиңдек» һ. б. поэмалары иҗат ителде. Проза әсәрләреннән уңышлы хикәяләр, повестьлар туды. Шул елларда бүгенге каракалпак әдәбиятының үрнәгенә әверелгән, соңыннан каткат басылган повесть һәм хикәяләр дә иҗат ителә. Аларга мисал итеп М. Дәрибаевның «Меңнәрдән бере», Н. Дәукараевның «Партизаннар», «Балалар йортында», Ә. Бегимовның «Үлем тырнагында», Амәт Шаһморатовның «Иске мәктәптә», «Юлбарыс белән очрашу» әсәрләрен күрсәтеп була.

Сугыштан соңгы елларда бу беренче буын әдипләргә тагын бик күп талант ияләре, кызыклы шагыйрь һәм прозаиклар, әдәбият галимнәре өстәлде. Яңа әсәрләр иҗат ителде. Бу елларда инде шигъриятта аеруча уңышлы эшләүче, каракалпак совет

ерүгә лаеклы өлеш кертүчел
әдәбиятын үстерүгә лаеклы өлеш кертүчеләр арасында без халык шагыйрьләре Җолморза Аймырзаев, Ибраһим Йосыпов, Теләбирган Җумамуратов, Байнияз Каипназаров, Таҗетдин Сәетҗанов исемнәре дә, алардан соңрак килгән Бабаш Исмаилов, Галим Сәетназаров, Матен Сәетниязов, Халморат Сапаровлар исемен дә очратабыз.

Беренче хатын-кыз язучылар — шагыйрә Мәрьям Касыймова, Миһербангел Орҗанова, прозаиклар Базаргел Бекниязова, Гөләйша Есемуратовалар да әдәбиятка шул елларда килә.

Инде соңгы ун-унбиш елда иҗат юлына баскан һәм танылып өлгергән шагыйрь һәм прозаикларның исемлеге тагын да зуррак күләмлерәк. Шагыйрь һәм прозаик Шәүдербай Сәетов, Олмәмбәт Хуҗаназаров, шагыйрь һәм драматург Киңәшбай Рахманов, шагыйрьләр Теләпбиргән Матмуратов, Тулыбай Кабулов, Дәүләп Аетмуратов, Җолдашбай Дилмуратовлар инде милли әдәбият мәйданында җигелеп эшлиләр, аны үстерүгә зур өлеш кертәләр. Хатын-кызлардан Зәйтүнә Насруллаева, әдәбият галиме һәм прозаик Сарыгөл Баһадирова, шагыйрә Гөлстан Шаһмуратова, хикәяче Гөләем Торсыновалар да шул буынга бер төс бирeп тора. Саный калсаң алар иҗатыннан яхшы үрнәкләр исемлеге генә дә шактый озынга сузылыр иде.

Соңгы егерме елда проза өлкәсендә әйдәп баручыларның берсе — ул каракалпак халык язучысы, Үзбәкстан ССР һәм Каракалпакстан АССР Дәүләт премияләре лауреаты Түләпбиргән Каипбиргәнов булды дисәк ялгышмабыз. Ул бигрәк тә каракалпак халкының ике гасырлык язмышын, көнкүрешен чагылдырган, аның бәйсез, иркле тормышка омтылуын һәм шул юнәлештәге уй-хыялларын, гамәл-хәрәкәтләрен тасвирлауга багышланган тарихи романнары белән мәгълүм. Ул «Каракалпак дастаны» трилогиясен тәшкил иткән «Маман би хикәяте», «Бәхетсезләр», «Тәшенкесезләр» романнарын, шулай ук тарихи, ике китаптан торган «Каракалпак кызы» роман-дилогиясен каракалпак халкының коллективлашу-колхозлашу чорына багышланган «Соңгы һөҗүм» романын һәм берничә повесть, хикәяләр иҗат итте. Үзбәкстан фәннәр академиясендә 1960 елдан русча һәм каракалпакча «Хәбәрче» гыйльми журналы чыгып килә. Анда тел, әдәбият һәм тарих фәнни институтының галимнәре, тәнкыйтьчеләр актив язышып тора. Димәк, әдәбият галимнәренә көндәлек әдәби процесска даими йогынты ясау, әдәбиятны әйдәп барырдай уй-фикер туплау мөмкинлеге тудырылган.

Каракалпакстан язучылар оешмасы хәзер алтмыш СССР Язучылар союзы әгъзасын берләштерә. Унҗиде язучының гыйльми дәрәҗәсе бар. Республиканың промышленность, авыл хуҗалыгы, төзелеш, энергетика өлкәсендәге уңышлары зур. Биредә мамык басуларыннан елына биш йөз мең тоннага якын «Ак алтын» җыеп алына. Анда шулай ук җиләк-җимеш бакчалары мул уңыш бирә. Арал диңгезендә балык тотыла, Арал буе һәм Аму-Дәрья тамагы күл-ерганакларында затлы мехлы җәнлекләр үрчетелә, бик затлы каракүл бирүче куйлар асрала. Иксез-чиксез ком сахралары, Өстерт калкулыгы тирәнлегендә газ, нефть ятмалары бар.

Без — халыклар һәм әдәбиятлар үзара аралашып, ярдәмләшеп көн күргән чорда яшибез. Каракалпак һәм татар халыклары, аларның әдәбият һәм сәнгать вәкилләре дә соңгы вакытта үзара ныклы элемтә урнаштырдылар. Без бер-беребез ирешкән уңышлар белән чын күңелдән уртаклашабыз. Ерак араларны якын итеп аралашабыз.

## Гәрәй Рәхим

### Немец дустыма

Язлар килсә, апрель үтсә, майлар җитсә,
Яшь үләннәр күрсә, әнкәм сагышлана.
Әткәемнең истәлеге, төсе итеп,
Шушы хатны калдырган бит сугыш аңа:

«Җиңү көне якынлаша сәгать саен,
Безнең гаскәр алга кыю бара юлда.
Бүген Берлин шәһәреннән ерак түгел
Ял итәргә тукталдык без бер авылга.

Шунда күрдем, бер бай гына өйгә кергәч,
Үзебезнең малай кебек шук бер бала —
Безгә төзәп ул уенчык мылтыгыннан
«Русский капут!» — дип кычкырып сөрән сала.

Менә, иркәм, фашист нинди әшәке җан,
Менә ничек тәрбияли балаларын.
Юк! Күрмәбез шушы нәни балалардан
Фашизмның яңадан да яңарганын...»

Бу — әткәмнең соңгы сүзе, соңгы хаты...
(Соңгысы дип язмагандыр ул бу хатны).
Бер почмактан качып калган немец аткан,
Шул авылдан атакага киткән чакны.

Һәр көн саен яңа җиңү яулап ала,
Алга бара социалистик Германия,
Теге бала — миңа яшьтәш түгел микән —
Якыная бара һаман уйларыма.

Үсә төшкәч, немец дустым, син үзең дә
Кемнең «капут» икәнлеген сизгәнсеңдер.
Чәчәк куеп бүген әткәм каберенә:
«Рәхмәт, солдат, коткаргансың!» — диясеңдер.

# Әхмәт Гадел

## Хәтер

*1942 нче елның көзендә фашистлар, халыкны куркыту максаты белән, биш татар егетен Кара диңгездә үлем баржасында җәзалап үтерәләр*

Мәмдүдә апа сөйләгәннәрдән

Диңгез яры... Тауларда көз...
Җәйләүләрдән төшә шуышып үзәннәргә
Ахак, алтын төс.
Көз...
Яфраклардай уйлар ява хәтергә...

Кинәт күз явын алырлык диңгез рәшәсеннән
Калкып чыга кара кораб.
Ерак-ераклардан, хәтер диңгезеннән килә.
Ярга якынлаша ул кораб —
Кап-кара әҗәл көймәсе...
Палубада биш дар агачы...

Кардәшләрем минем —
Яшел күзле Ирек балалары,
Кайнар канлы, тимер рухлы толпарларым
Тирбәлделәр диңгез җилендә...
Биш кичә...
Биш сәхәр...
Җомгага кадәр...

...Тиздән кырык тула миңа...
Төннәрен сөер тойгыдан уянам сискәнеп:
Җанбуар фашист төшемә керә,
Җанурлар кораб каршыма килә,
Палубасында янган биш өмет
Диңгез җилендә моңлы тирбәлә...
Шуларның берсе мин түгелме?.. — дим —
Үткәнем минем һәм киләчәгем...

Уйлар, сагышлар...
Әй, тынгылык таба алмыйча, дөнья гизгән
Җанның сыкрануы!

Кара төшләрдә кара үлем корабы
Диңгезнең кара дулкыннарында чайкала...

.................

Шамил Бикчурин

# ТИРӘН КАТЛАМ

РОМАН

## УНИКЕНЧЕ БҮЛЕК

### I



Татьяна Макаровна белән телефон аппараты янында өч көн тоташтан каналларны өйрәнеп утыру Фәнүзәне тәмам туйдырып бетерде.

— Таня апа, бир инде үзем генә утырыйм,— дип ялына башлады ул.— Менә, әйтте диярсең, булдырам булгач булдырам!

— Ашыкма. Татарлар: «Ашыккан ашка пешкән», диләр бит.

— Билләһи, валлаһи түзәрлегем калмады...

Татьяна Макаровна гомерен телефончы булып уздырган, бу нечкә эштә аеруча сак, үтә таләпчән һәм бераз куркаграк та иде.

Ни элемтәдә булган объектларны, ни абонентларны, ни телефон аппаратын юньләп белмәгән яшь-яшь кызга, наушниклар кигезеп, бүгеннән бөтен бер нефть районының телефон каналын ышанып тапшыруны ул башына да сыйдыра алмый иде. Шулай ук тапшырмый да мөмкин түгел — сменага күптәннән инде бер кеше җитми, аның өчен ял да итмичә үзенә, бергә эшләгән иптәшенә торырга кала. Дәгъваңны конторага әйтсәң: «Син, Татьяна Макаровна, өлкән телефончы исәпләнәсең, тәҗрибәң зур, неужели шунда берәр кызны табып өйрәтә алмыйсың»,— дип кенә җибәрәләр. Ансат уйлыйлар да соң! Кыскасы, коммутаторга һич кичекмәстән, бүгеннән үк кулалмаш кирәк, шунсыз булмый, мөмкин түгел иде.

— Шутка эш түгел ул, телефонистка булу, дочка! — ди үз уена үзе нәтиҗә ясагандай Макаровна.— Хоть ышан, хоть ышанма, аппаратка тотынганчы мине алты ай ученик итеп йөрттеләр теге заманда...— Шулай әрли-үгетли, урындыгын үзе дә сизми Фәнүзәгә бирә, наушникларын кигерә.

Ә Фәнүзә — күптән коммутаторда утырган диярсең! — Шунда ук, үзенә бирелгән 33 ле санны әйтеп, тимер каләмнәргә охшаган штепселларны каналларга тоташтырырга керешә. Әкренрәк, сайланыбрак маташса да, чиста итеп, җиренә җиткереп эшли, каһәр!

---

Дәвамы. Башы 4 нче санда.

Татьяна Макаровна әйтә: нефтьчеләр коммутаторының эше башка телефон станцияләренә караганда бик тә үзгә, аеруча җаваплы, ди. Мондагы телефончы: «да», «нет», «занято» дип утыручы гына түгел, үзенә күрә диспетчер ролен дә үти, ди. Биредә телефончы җаваплылыгында йөзләгән скважиналар, дистәләгән насос станцияләре, нефть җыю пунктлары, зур-зур товар парклары бар икән. Шуларның бөтенесенең нормаль эшен күзәтеп, тәэмин итеп торырга кирәк.

Ул гына да түгел, бу коммутатор аша сәгать, минут саен диярлек нефть трестлары, идарәләр, конторалар элемтә тота. Фәнүзә фикеренчә, бу телефоннан башка вахта автобуслары, төрле агрегатлар һәм махсус машиналар нинди якка, кайсы скважинага юл тотарга белмәсләр иде.

Чыннан да нинди кызык, хикмәтле, серле бу телефон дигәннәре!

Фәнүзә бу минутларда үзен коммутатор белән түгел, бөтен дөнья белән идарә итә кебек тоя. Иөз чакрымнарга сузылган кырларда утыручы барлык скважиналар, буровойлар, вышкалар аның кулы астында, аңа гына буйсыналар, аны гына тыңлыйлар кебек һәм аңа гына бәйле булып тоелалар иде.

«Ялгышмаса гына ярар иде бу кызый»,— дип, аппарат тактасында бер кабынып, бер сүнеп торган яшелле-кызыллы лампочкаларга, өзек-өзек тырылдаган звонокларга карап торган Татьяна Макаровнаның да маңгаена бәреп чыккан тирләре бераз кибә башлады кебек.

— Молодец, Фанузушка, молодец! — дип көч биреп тора ул кызга. — Только номерыңны ачыграк әйт! Тотлыкмый гына җавап бир! Так! Менә шулай!

Телефонда утыру Фәнүзәгә рәхәт кенә түгел, хәтта кызык та. Башта җавап бирергә дә оялган кыз инде абонентлар белән аяк терәп сөйләшә, кешеләрнең: «җаным, фәлән контораны бирегез әле», «сөеклем, мине фәлән фәләнович белән тоташтырыгыз әле» кебек төче сорауларыннан, ялваруларыннан хәле бетеп көлә, кычкырыбрак, ачуланыбрак сорасалар бөтенләй каналны ябып куя иде. Фәнүзәнең, бигрәк тә үз кирәк-яраклары, шәхси эшләре белән шалтыратучыларны җене сөйми. «Хатының белән кайткач сөйләшерсең!», «Телефон кино турында сөйләшү өчен түгел!», «Кызлар кавыштыру өчен утырмыйм мин!» дип кенә җибәрә.

Боларны ишетеп торган Татьяна Макаровнаның коты оча:

— Телефонда утырганда син телеңне тый, доченька! — ди бармак янап.

Эшкә тиз төшенде Фәнүзә, ләкин бер кымшанмыйча диярлек смена буе һаман үзенең утыз өчлесен әйтеп аппарат алдында утыру туйдыра башлады аны. Телефоннан бигрәк, коммутаторның механизмнары, төрле-төрле лампочкалары һәм чуалчык чыбыклары кызыксындыра иде Фәнүзәне. Таң алдыннан, звоноклар чак кына тынып торган араларда, аппаратның артына чыгып, шунда казынырга, гайка-шөрепләрен тотып карарга, клеммаларны тикшерергә ярата иде ул. Сүтеп ала, контактларны чистарта һәм яңадан урынына куя. Тракторда әтисе контактларны шулай чистарта иде. Ток яхшы килсен өчен.

Бер көнне күбрәк сүтеп ташлаган икән кыз — клеммаларны бутады, кайсын кая куярга белми интекте. Куйды — звонок килми башлады, аппарат эшләүдән туктады. Ярый әле, смена алышыныр вакыт җиткән иде. Хәвефне күңеле сизепме, телефоннан шалтыратуга җавап бирмәгәнгәме — иртәләп Татьяна Макаровна килеп керде. Керде һәм сүтелгән аппаратны күргәч:

— Син что? — дип буылып кычкырып җибәрде.— Нәрсә була безгә хәзер! Ой, аталар! Асалар безне за это! — дия-дия аппаратка ташланды.

Бәхеткә каршы, чыбыклар артык саташмаганнар икән — Таня апасы аларны тиз генә үз урыннарына беркетте.

Шушы кыска гына вакыт эчендә дә әллә никадәр вакыйгалар булып алган: бер буровойда авария ясаганнар да, өеннән мастерны чакырта алмыйча гаҗиз булганнар. Икенче берәү авыру сәбәпле вахтага бара алмавын әйтмәкче икән — сөйләшә алмаган.

Боларның һәммәсе бергә җыелып, әле генә сменаны кабул иткән өлкән телефончы башына төште. Линияне өзгән өчен аны тиргиләр, аны ачуланалар. Чыдам һәм киң күңелле булса булыр икән Татьяна Макаровна, кызның бөтен гаебен үз өстенә ала бичара.

— Виновата, виновата,— дип кенә тора телефоннан. Башка бер сүз дә катмый. Кыскасы, уңмады ул Фәнүзәдән.

Коммутаторны ташлавын ташламады Фәнүзә, эшкә йөрде, әмма күңеле телефоннан тәмам суынган иде аның. Армиягә китәсе яшьләр өчен ДОСААФ оештырган механизаторлар курсына йөри башлады. Биредә кызларны алмыйлар иде — Фәнүзә курс башлыкларының борыннарына хәрби билетын китереп төрткәч, ризалаштылар. Кыз, элемтә эшчесе буларак, хәрби учетта тора икән.

Татьяна Макаровна гына, сәерсенеп, татарчалы-русчалы сөйләнеп бот чабып йөрде:

— Что за кыз бу, не понимаю. Я, зачем кирәк связисткага трактор? Чудак, нәрсә таскать итмәчке була ул трактор белән?

Болары чәчкәләре генә, җимешләре алдарак булган икән әле. Күпме борчулар кичермәде, шелтәләр алмады, нинди генә кыен хәлләргә калмады Татьяна Макаровна Фәнүзә дигән юньсез кыз белән!

«Таяк ике башлы» диясе урынга: «Телефон чыбыгы ике очлы» дип әйтергә ярата иде Татьяна Макаровна. Дөресе дә шулай булып чыкты. Бер башы аның монда коммутаторда булса, икенчесе промысел мастеры Курамшинга барып төртелде. Дежурда Татьяна Макаровна үзе иде. Декабрь башларында шул шалтырата:

— Татьяна Макаровна, сезме бу?

— 33 ле булгач, значит мин,— дип җавап бирә өлкән телефончы.

Курамшин һаман җитди:

— Сөйләшәсе бар иде. Кайчан күрергә мөмкин сезне?

— Свидание, значит,— дип янә шаярта Татьяна Макаровна.— Сезнең кебек яшь кеше белән мин с удовольствием!

— Свиданиеләрнең булганы да җитә инде, Татьяна Макаровна.

Өлкән телефончы төшенмәде һәм төшенерлек тә түгел иде.

— Ничек булганы? Кайчан булганы?

— Әнә, бер яшь кызыгыз бар бит, шуны әйтәм. Минем өлкән оператор Мәснәвинең башын әйләндерә башлаган бит.

— Фәнүзәне әйтәсезме? Сез нәрсә, Кәрам Ризванович, очумели?

— Фактлар бар, Татьяна Макаровна. Сез ул кызыгызга әйтегез: Мәснәвинең хатыны бар һәм нинди генә әле: бик тешләшә торганы! Шуның өчен шалтыратуым иде, гафу итегез.

Кәрам Ризванович трубканы куйды.

Татьяна Макаровна иренен тешләп уйга калды. Башын әйләндерә башлаган... Булмас, Фәнүзә андый түгел. Килеп скважинаны ваткан дисеннәр, барып берәрсенең яңагына суккан, берәр ирне кыйнаган дисеннәр — ышаныр иде Татьяна Макаровна. Ә инде Фәнүзәнең гыйшыкмыйшык тотуы, бигрәк тә ир кешегә, хатынлы иргә каравы белән килешә алмый. Дошман сүзедер ул...

— О, господи, үзең сакла андый гайбәттән!..

Әйе, чыбык ике очлы. Аның берсе дежурда торучы телефончы кыз Фәнүзәдә булса, икенчесе төнге вахтадагы өлкән оператор Мәснәвидә иде.

Күрәсең, төнге ялгызлыктан аның да эче поша, сүз юктан сүз булсын дипме, һич кирәкмәгәнгә телефончы кызларга шалтырата.

— Иптәш утыз өч, сәгать ничә әле ?

— Нәрсә, әллә хатыныңны сагындыңмы? — дип көлә Фәнүзә.— Булыр, булыр, без озак шалтыратмый торды шул бикәчең...

— Сез аны каян беләсез?

— Беләм. Сине дә яхшы беләм. Мәснәви. Утыз яшьтә. Зур гына квартирың. Сара исемле артык акыллы һәм чибәр генә хатының бар...

— Нәкъ эзенә бастың, сыер икәнсең! Әйе, биш балам да бар әле минем.

— Балагыз юк. Ә менә песиегез бар.

— Җитте, җитте! Каян беләсез сез боларның барысын да?

— Чөнки хатының: «песине ашатырга онытма!» дип телефонны ярып кычкыра!

Фәнүзә Мәснәви турындагы мәгълүматларны дежурда торганда телефоннан ишетеп җыйган иде. Кеше сүзен тыңлау килешми һәм ул ярамый да, ләкин колагыңда наушниклар булганда линиядәге сүзләр теләсәң-теләмәсәң дә килеп керә.

Коммутаторда каналлар болай да аз, эш тыгыз, ә Мәснәвинең хатыны көн саен иренә шалтыратып теңкәгә тия. Фәнүзәдән бригада йортын сорап ала да: «Мәснәвине чакырыгыз әле»,— ди. Бераздан телефонга Мәснәви килә, мышный-мышный хатынының чираттагы приказларын, командаларын тыңлый. Ә алар менә нинди: «Мин бүген соңрак кайтырмын, шулпа пешереп куй!.. Кайтышлый кибеттән май алырга онытма!»

Икенче көнне эш бетәр алдыннан тагын Мәснәви хатынының командалары ишетелә башлый: «Мин бүген соңрак кайтырмын, кичә калган ашны җылытып ашарсың. Идәннәрне юып куй әле мин кайтуга. Кибеттән ипи алып керергә онытма...»

Һәр көнне шулай. Фәнүзәнең җен ачулары чыга аларның сөйләшүенә. Башка урында булса, чукынып бетсеннәр иде нинди дә Мәснәвиләр һәм аларның иркә хатыннары. Эшнең иң тыгыз вакытында тоталар бит линияне. Кисәтми-нитми генә берничә мәртәбәләр өзеп тә куйган иде Фәнүзә аларның сүзләрен — Мәснәвинең хатыны кабат-кабат шалтыратып интектерде.

— Нинди хулиган шаяра телефонда? Иптәш утыз өч, сез нәрсә карыйсыз анда? Эшли белмәсәгез урын биләп утырмагыз! — дип кычкырына җитмәсә.

Тавышына һәм һавалылыгына карап, телефончы аны башта зур урында олы бер начальниктыр, дип уйлаган иде, соңыннан белде: судта секретарь булып утыра икән.

Мәснәви исемле бу яшь ир һәм аның Сара атлы усал хатыны белән кызыксыну әнә шул көннәрдән башланды.

Әвәл күңеленнән генә Мәснәвине тиргәде Фәнүзә: «Җебегән, мескен ирләр дә булыр икән дөньяда. Шул Сара-саранчасына колларча баш иеп тора бит! Эх, мин булсам! Күрсәтер идем аңа ничек аш пешерергә, ничек идән юарга кирәклеген!»

Тора-тора да, эченнән Мәснәвинең Сара-саранчасы белән әйткәләшә башлый: «Син кем, хан кызымы әллә шул кадәр? Ирең синең иртә таңнан эшкә китә, көн буе кырда, суыкта йөри, кайтуына җылы аш та пешереп ашата алмыйсыңмы? Идәнеңне чүпрәк белән сөртә белмисеңме? Кибеттән ипи алып кайтсаң, эчең төшәр дип куркасыңмы? Эх, син, аксөяк!..»

Беркөнне өйдә газеталар караштырып утырганда Мәснәви турында язылган мәкаләне күрде Фәнүзә. Скважина янында төшкән рәсемен дә биргәннәр. Фотода бер дә яшь кеше түгел — көр күңелле, батыр күренә. Төскә-биткә дә чибәр генә икән үзе: киңчә яңаклы, калынрак иренле, зур күзле. Мәкаләдә аны хезмәт алдынгысы, уңган оператор, уйлап табучы, рационализатор дип мактаганнар. Бер ел эчендә генә дә нефть чыгару эшендә дүрт яңалык керткән икән Мәснәви, берничә механизмны

камилләштергән. Мәкаләне бригаданың нефть чыгару мастеры К. Курамшин язган.

Телефон буенча Курамшинны да яхшы белә Фәнүзә. Кешеләр белән күп сөйләшми ул телефоннан — кырт кисеп бер-ике сүз әйтә дә трубканы куя. Менә ичмасам ир — ачык итеп, җиренә җиткереп әйтә.

Бер мәлне ниндидер йомыш белән Курамшинга хатыны шалтыраткан иде, ире озын-озак сөйләшеп тормады: «Миңа син моннан соң өч кенә очракта шалтырат: өйдә пожар чыкса, су басса һәм каты авырып китсәң»,— диде дә шуның белән трубканы куйды. Мәснәви уйлап табучы, рационализатор булса да шуны белми. Курамшиннан өйрәнәсе бар икән аңа, күпме өйрәнәсе...

Мәснәви белән Сара арасындагы элемтәгә ничаклы гына игътибар итмәскә тырышса да, колагына чикерткә булып керде аларның сүзләре.

Ир белән хатын мөнәсәбәте һаман саен киеренкерәк, тупасрак була бара иде. Мәснәви кайбер көннәрне өенә кайтмый, я бригада йортында, я үзе белән бергә эшләгән ялгыз иптәшләре янында тулай торакка барып куна башлаган. Бу турыда хатыны бер көнне Курамшинга шалтыратып әйтте: «Чара күрегез ул зимагорга!»

— Ярый, әйтербез без аңа,— диде кыска гына итеп Курамшин.

Атна-ун көннән Сара тарафларыннан мастерга тагын жалоба:

— Мәснәви бөтен акчасын эчеп бетереп кайтты. Нәрсә карый анда коллектив? Сез нәрсә карыйсыз?

— Ярый, тикшерербез,— дип җавап бирде Курамшин. Гадәтенчә, трубканы тыныч кына куйды.

Шул минутта ук Сара тагын Курамшинга шалтыратмакчы иде — «телефоннары эшләми» — дип ялганлады Фәнүзә, бирмәде сөйләшергә.

Нигәдер, ихлас күңел белән кызгана иде Мәснәвине Фәнүзә. Уңмаган хатыннан Мәснәви. Күреп тә, ишетеп тә белә: нефтьчеләрнең эшләре авыр, мәшакатьле, пычрак. Арып-талып кайтуларына аларга ял, тынычлык, семья җылысы кирәк. Һич югында ачык йөз, тәмле сүз кирәк. Ә Мәснәвигә берсе дә эләкми. Хәтта җылы аш та юк. Аннан: «Өйгә керәчин исе алып кайтасың. Кермә бүлмәгә, ятма яныма, башыма каба шул дегет исең!» — дип битәрли икән Сара Мәснәвине. Ирен салкын коридорда чишенеп керергә мәҗбүр итә икән. Мәснәви эшкә тышта калган салкын чалбарын, курткасын, итеген киеп китә, ди. Бу турыда борчылып бергә эшләгән дуслары телефон аша сөйләшәләр.

Ә бит Фәнүзә өчен машина исе ул «әти исе». Әтисе эштән кайтканын бала вакыттан бирле шул керосин, май исләреннән тоя иде кыз. Семья өчен күнегелгән һәм тәмле ис иде бу «әти исе!»

Фәнүзә үзен ир хатыны итеп күз алдына китерә. Сара урынына куеп карый. Дөресрәге, әнисе булып уйный Фәнүзә.

Имеш, Мәснәвинең эштән кайтуын көтеп, тәрәзәдән карап тора. Әнә, тыкрык башыннан аның ире Мәснәви күренә. (Фәнүзәнең әтисе шуннан кайта иде), Фәнүзә ирен каршы алырга, елмаеп капка төбенә чыга. Мәснәви арган, аякларын көчкә сөйрәп атлый. Шулай да ул шат, хатынына карап калын иреннәре белән елмая. Газетада баскан рәсемдәгечә.

Алар җитәкләшеп өйгә керәләр.

Тукта, өйгә кергәч нишли иде әле Фәнүзәнең әнисе? Әйе, йорт хәлләрен сөйли-сөйли әтисен чишендерә, итеген салдырыша, аннан аякларын юарга таз белән җылы су алып килә иде.

— Утыр әле, дегет чүлмәгем, тәпиләреңне ялтыратыйк!

Фәнүзә дә Мәснәвинең аякларын җылы су белән юа, сөлге белән сөртә, имеш...

— Тәпиләрең ап-ак инде, нефть чүлмәгем,— ди әнисенә охшатып. Аннан икесе табынга кара-каршы утыралар. Фәнүзә Мәснәвине кыстыйкыстый җылы шулпа, кайнар чәй белән сыйлый. «Тавыклар куначага менде, ятарга кирәк, карчык»,— ди ир тәмәке тарткач. Моны әтисе тү-

гел, Мәснәви әйтә, имеш. Фәнүзә сәкегә йомшак түшәк җәя, күпереп торган ястык-мендәрләр сала.

Хыялларны коммутатор зырылдаган звонок бүлдерде. Линиядә Мәснәви иде.

— Иптәш утыз өч, сезнең белән танышырга мөмкинме? — дип көлә.

— Без инде танышлар. Сез Мәснәви исемле. Утыз яшьтә. Өйләнгән. Зур гына квартирыгыз бар. Бик акыллы һәм чибәр генә хатыныгыз бар...

— Җитте инде, Фәнүзә, куй шул хатынны!

— Ә син мине ничек беләсең? — дип кызыксына Фәнүзә.

— «Занято» диюеңнән беләм. Нигәдер, син гел «занято». Аннан, чишмәгә ялан тәпи суга барганыңнан беләм. Хәтерлисеңме, минем өскә бер чиләк салкын су сипкән идең.

— Юк, өстеңә түгел, авызыңа сиптем! Авызыңны ачып миңа карап тора идең.

— Шулай да синең белән танышырга мөмкинме?

Әйе, алар очраштылар. Сүз куешканча, клуб каршында, кичкырын күрештеләр.

Ачуланырга дип барган иде Мәснәвине Фәнүзә. Хатынының капризларына буйсынып, гел шуның көен генә көйләп торганы өчен эт итеп тиргәргә дип барган иде. Ничектер килеп чыкмады. Мәснәви яңа фильмга ике билет алып куйган икән, сеанс башланыр вакыт иде — киногa кереп киттеләр. Ә залда исә читләр кайгысы бер кырыйга китеп торды — алар янәшә утырып караңгыга, музыка тавышына, сурәтләр дөньясына чумдылар. Мәснәви, сыена төшеп, көрәк кебек тупас, зур куллары белән кызның перчаткаларын салдыра. Фәнүзәнең кайнар бармаклары Мәснәвинең учында эреп киткәндәй була...

## II

Беренче мәхәббәт кешегә бәхет кошы булып, шатлык булып, наз булып килә диләр. Фәнүзәгә исә ул кайгы-хәсрәт булып, борчу булып, чир булып килде. Башкаларга килгән кебек бу мәхәббәт тә көтмәгәндә, кинәт килде, сиздермичә, яшеренеп килде. Килде дә кызның йөрәгенә ялкын булып капты...

Мәснәви белән Фәнүзәгә карата баштарак булган пышын-пышын сүзләр, киная ясаулар, мыек-танау астыннан елмаеп серле күз кысулар тора-бара үзләренә ачыктан-ачык төрттерүләргә, йөзләренә бәреп әйтүләргә кадәр барып җитте: яхшы түгел, диделәр, оят диделер, гөнаһ диделәр.

Бигрәк тә Татьяна Макаровна авыр кичерде бу хәлне! Аксаклыгы аркасында үзе кияүгә чыга алмый калган бу хатын оятыннан кызарып-бүртенеп тиргәп йөрде.

— Ой, безобразие! Ой, срамота! Ирләр белән гулять итмәсәң, беткәнме сиңа яшь егетләр! — дип тиргәде ул Фәнүзәне.

Ачуланды, сукте, әмма үз коммутаторыннан чүпне читкә чыгарасы килмәде. Ләкин аңа Мәснәвинең хатыныннан да, таныш булмаган ниндидер кешеләр тарафыннан да эш урынына әләк звоноклары килә торды.

Менә, телефонда янә Курамшин.

— Татьяна Макаровна, әйтер сүзләр бар. Бу турыда телефоннан сөйләшү дә уңайсыз инде... Сезнең теге кызыгыз һаман аздыра бит безнең егетне.

— Кызлар егетләрне аздырыр өчен яратылган инде ул!

— Яхшы түгел, Татьяна Макаровна. Мәснәвинең хатыны гариза китерде. Ире өенә кайтмый башлаган. Без, җыелыш җыеп, үзебезнекенә

каты гына әйттек. Аморальный җинаять бит. Сез дә тикшерми калмассыз дип уйлыйм. Кызартырга, мунча кертергә кирәк ул кызны.

— Мунча кертергә дип... Тотканмы соң Мәснәвинең хатыны? Юк.

— Утсыз төтен булмый, Макаровна!

— Зато төтенсез ут була!

Дежурда Фәнүзә үзе торганда да күп килде коммутаторга шомлы звоноклар. Кемнәрдер бер-ике сүз белән: «Эшеңне сизгәннәр, кызый, итәгеңне җыеп йөр!» — дип киңәш бирде. Кайсыларыдыр: «Молодец, шул кирәк Мәснәви хатынына!» — дип тантана итә, кайсыдыр тиздән коммутатор өстендә күк күкрәп яшен буласын белдерә.

Әлегә яшене булмаса да, күк күкрәп алды. Коммутаторда «утыз өч» тавышын ишетүгә бер хатын:

— Ә-ә, утыз өч,—дип сузды һәм күкле-яшелле тавышлар белән кычкырырга тотынды.— Син икәнсең, сөйрәлчек! Ирем белән өстерәлеп, тыныч кына анда утырырмын дисеңме? Иртәгә үк, кудырам, себерке!

Мәснәви саранчасы икәнне таныды Фәнүзә — башкасын тыңлап та тормыйча линияне өзеп куйды.

— Бер дә юкка бит...— дип әрнеште кыз.— Бер тапкыр кинога кергәнгә.— Аннан тәвәккәллек белән үз-үзенә ныгытып куйды.— Ярый. Юк икән — бар булсын! Бөтенесенә үч итеп йөрим!

Минуты белән Мәснәвигә шалтыратты:

— Мәснәви, бүген кич сине клубта көтәм! Ярыймы? Килештекме?

Алар тагын күрештеләр. Шуннан башлап кайда да булса көн саен, смена тәмамланган саен, җае чыкканда һаман очраштылар. «Кунак ашы кара-каршы» дигәндәй, Мәснәви хатыны тарафыннан да болар эзсез-җавапсыз калмады.

Кич иде. Гадәтенчә, эчтән ишекне бикләп телефонда утыра иде Фәнүзә, кемдер тәрәзәне шакыды. Борылып караса,— куркып китте: чәчләре тузгыган бер хатын, күзләрен зур акайтып, бөтен гәүдәсе белән тәрәзәгә капланган. Тышта яңгыр ява, хатынның борын, ияк очларыннан су ага. Нәкъ әкияттәге су анасы!

— Ач ишекне, ул монда! — дип кычкыра, тәрәзәне йодрыклары белән төя-төя.

Күргәне булмаса да таныды аны Фәнүзә. Көтә иде ул бу очрашуны. Кайчан да бер булачак, бүген булмаса иртәгә, иртәгә булмаса бүтән вакытта барыбер очрашачаклар иде алар.

— Ач ишекне, юкса ватам! — дип хәзер инде ишеккә тибә башлады хатын.

Эшнең дә тыгыз вакыты иде коммутаторда — игътибар итмәскә булды телефончы, аппаратка табан борылып утырды. Күрмәү әйбәтрәк.

Моңа ачу итеп коммутатор тәрәзәсен таш белән ватып китте Мәснәвинең хатыны.

Бу юлы җыелыш коммутаторныйда булды, бу юлы Фәнүзәнең тәртибен элемтәчеләр тикшерделәр. Тәрәзә ватуда һич гонаһы булмаса да, Фәнүзәне гаепләделәр. Җыелышның сүзе бер булды: «Фәнүзә ирләр белән йөрмәсә, коммутаторныйга хатыннары килмәс иде, хатыннары килмәсә, тәрәзә дә ватылмас иде». Аңа җыелыш алдында торып басарга куштылар — басты, өстәл янына «судьялар», «гаепләүчеләр» каршына килеп утырырга боердылар — утырды, бүтән мондый килешмәгән эшләрне эшләмәскә, тәүбә әйтергә мәҗбүр иттеләр — әйтте. Җыелыш аңа каты шелтә бирде.

Фәнүзәнең исә күңелендә бары бер генә теләге бар иде: «Түзәргә. Тракторчылар курсын тәмамлаганчы гына чыдарга». Аннан ул эштән җибәрүләрен сорап үзе үк гариза бирәчәк. Күп калмады инде: «Биш ае укылды, тагын бер генә ай...»

Фәнүзә белән Мәснәвинең яман эшләре турындагы хәбәр Ризатдин йортына да барып җиткән — Сәхибә апа, төн шактый авышкач, яңа ел кичәсеннән кайткан кызын тирги-тирги елый:

— И бала, бар икән күрәселәрем! Инде кеше күзләренә күренергә урын калдырмадың! Нинди бозык юлларга бастың, оятсыз? Нинди генә шайтаннар котыртты сине?!

— Шауламагыз әле, йокларга бирегез! — дип тынычландырмакчы иде Фәнүзәнең сеңелесе Фәния юрган астыннан, ләкин тиргәшү дәвам итте.

Ризатдинның да эче поша бугай — урын өстендә борсаланып ята һәм хатынын юатмакчы була:

— Җитәр, җитәр, анасы! Юк сүз ул. Фәнүзә начар юлга басмас. Ул андый кыз түгел...

Фәнүзә эндәшми, почмакка кереп поскан хәлдә, суыкта күшеккән кулларын мичкә терәп җылыта.

Аның колагыннан күңелле җыр, гармун тавышлары китмәгән. Мәснәви үпкән битләре, иреннәре әле һаман булса кызышып яна. Фәнүзә бүген һәммәсеннән канәгать, һәммәсе белән бәхил. Күңеле күктә. Ул һаман әле җиргә төшмәгән, ничектер, канатланып һавада очып йөри. Яңа елны тулай торакның кечкенә бер бүлмәсендә Мәснәви белән янәшә утырып, сыенышып бер табында уздырды алар.

Дуслары күп иде Мәснәвинең, өстәл тулы ризык, бихисап эчемлек иде. Яңа ел хөрмәтенә, һәркемгә яңа бәхетләр, зур шатлыклар теләп, матур тостлар әйтелде.

Соңыннан, Кремль сәгатьләре уникене сугып, илгә Яңа ел кергәч, Мәснәвинең бүлмәдәге иптәшләре, төрле сәбәпләр табып, кайсы кая — бал-маскарадка, танцыга, нииндидер мәҗлескә дип таралышып беттеләр. Мәснәви белән Фәнүзәгә беркая да барырга ярамый иде: «Күз тиюдән» курыктылар.

Бүлмәдә утны сүндереп, түр почмакта тумбочка өстендә торган ясалма чыршы лампочкалары яктысында калды алар. Бу чыршы икесенә дә әкияти чыршы булып күренде. Төрле төстәге вак лампочкалар, ботакта эленеп торган тиеннәр һәм аюлар, этәчләр һәм песиләр аларга карап җемелдәшәләр, нидер әйтергә теләп күз кысалар кебек. Кызның һичкайчан мондый күңелле кичәләрдә булганы юк, мондый матурлыкны күргәне юк, моңа кадәр һичкем тарафыннан бу кадәр ягымлы сүзләрне ишеткәне юк иде.

— Син минеке, Фәнүзә, син минеке,— ди Мәснәви, шашынып кызның иреннәрен, муеннарын, җилкәләрен үбә...

Бүген, Яңа елның беренче көненнән башлап әнисенең тиргәве, әтисенең «Минем кызым андый түгел», дип юатырга тырышулары да — бөтенесе дә соң иде. Кешеләр гайбәте дә хәзер аның эчен пошырмаячак, күңелен үртәмәячәк. Хәтта Мәснәви хатыны Сараның хурлау сүзләре дә колагына кермәячәк Фәнүзәнең. «Үч алынды,— дип тантана итте Фәнүзә бу төнне.— Инде миңа теләсә нәрсә әйтсәләр дә була, үкенмим...»

Күп нәрсәләрдән мәхрүм дә итте Фәнүзәне бу ялгыш адым. Борынгыдан йола булып килә торган кыз соратулардан, ярәшүләрдән, кыңгыраулы пар атларда гармуннар уйнап, купшы кияү егетләре арасында горур утырып килгән ыспай кияүдән, юлларына чуар паласлар җәелгән, тәңкә акчалар сибелгән егет йортына килен булып төшүләрдән, шаулап-гөрләп торган туйлардан, караңгы чыбылдык эчендә куенына керәчәк егетне ояла-тарсына көтеп ятулардан, беренче кайнар мунчалардан, иртәсен авылның үзе кебек яшь киленнәре, арчи кызлары белән чиләкләр җырлатып коега суга барулардан — гомумән, җиткән кызларның барысына да үз вакыты белән килә торган бөтен шатлык-куанычлардан мәхрүм булды Фәнүзә.

Бу көннәрдән соң озак та үтмәде, Сара белән урамда очрашты ул. Фәнүзә, Мәснәвинең киемнәрен юып-үтүкләп, култык астына кыстырып, сумкасына кибеттән тегене-моны алып тыккан һәм шуларны илтергә бара иде — хатын ничектер йорт почмагыннан килеп чыкты. Саранчаның тәрәзә ватып китү белән генә чикләнмәсен, көндәшенә карата тагын да яманрак нәрсәләр кыласын күңеле белән тоеп йөри иде Фәнүзә. Ниһаять, кышкы тар сукмакта күзгә-күз очраштылар.

Алга таба атларга да, кырыйга тайпылырга да бирмичә, тып итеп басты Сара. Йонтәс бүреге астында яшел күзләре зур булып ачылган, нәфрәт чаткысын сибә. Авызы бер якка кыегаеп, мәсхәрә белән елмая, тантана итә: асыл кош аягыннан элəкте, янәсе. Бер күз ташлау белән иренең күлмәкләрен танып, кызның кулыннан тартып алды. Икенче кулы белән сумканы йолкып читкә атты.

— Фәхишә! — дип кычкырды да Фәнүзәнең мамык шәл астыннан бөркелеп чыгып торган чәчләренә ябышты. Ул да булмады, каракошныкы кебек очлы, ләкин кызыл тырнаклары белән Фәнүзәнең битен тырнап алды, кысладай ябышып пальто якасын умырып төшерде.

Моңа кадәр теләсә нинди егеткә дә бирешми торган кызыбыз бу хатын алдында җебеде дә төште, үзен яклап кул күтәрү түгел, тырнаудан-сугудан битен-күзен дә яшерә алмады.

Көндәше аны, әшәке сүзләр белән акыра-бакыра, дөмбәсләде дә дөмбәсләде...

Бу тамашаны күреп халык җыелды. Көпә-көндез ике хатынның сугышуы алар өчен сәер дә, кызык та иде бугай — арадан берәве дә килеп боларны якламады, аермады. Киресенчә, кайберләре ирештереп, котыртып торды:

— Картын кара син, картырагын — бокс алымнарын ничек шәп белә! Менә шулай, вәт, вәт!

— Яше нәрсә карап тора? Әйдә, кыюрак бул!

— Әһә, әһә, хәзер кирәген бирә ул!..

Кашы җимерелеп, күз төбе күбеп чыккан Фәнүзә, Сараның каты кулыннан ычкынып китеп барган иде — тегесе тагын куып җитте — аның җилкәсенә үк менеп атланды. Бу юлы инде Фәнүзә түзмәде, бер селтәнүдә көндәшен карлы сукмактан читкә, көрт эченә чөйде.

Сараның:

— Коткарыгыз, үтерәләр! — дигән тавышы урамда Фәнүзә киткәч тә әле озак ишетелеп торды...

Икенче көнне үк Курамшин бригадасыннан коммутаторга тагын шомлы звонок килде:

— Татьяна Макаровна, бу сезме?

— Мин булсам нәрсә әйтерсез, Кәрам Ризванович?

Курамшин сүзне кайдан башларга белми тамак кыргалап торды. Мастер хәтәр борчылган иде булса кирәк.

— Кичәге вакыйганы ишеткәнсездер инде. Ничек юк? Яшерергә маташмагыз, Татьяна Макаровна. Бу турыда бөтен шәһәр белә. Менә минем алда зыян күрүченең гаризасы ята. Әйе, Сара ханымның. Коллективта тикшереп Фәнүзәгә кискен чара күрергә, судка бирергә кушкан.

— Аның үзен подсуд бирергә кирәк. Кызның карар урынын калдырмаган. Прямо безобразие!..

— Монда бит синең кыз гаепле!

— Нигә ул хатынга самосуд ясарга! Кем аңа право биргән? Вот нәрсә, товарищ Курамшин, алайга китсә, син инде үзеңнең операторыңны — мактаулы Мәснәвиеңне тикшер! Нигә ул яшь кызларны аздырып хатыны өстеннән йөри?

Күренә: Татьян Макаровна яхшы гына эшләп торган телефончысын, ә мастер үзенең бригадада менә дигән «башлы малаен» хөкемгә бирәсе

килми иде. Ике житәкче бер-берсе белән шактый тарткалашканнан соң, элемтәчеләр белән нефтьчеләрнең уртак җыелышын үткәрергә, иптәшләр судын җыеп өчесен — Мәснәвине, Сара ханымны һәм Фәнүзәне — күзгә-күз очраштырырга, тикшерергә, гаеплеләргә тиешле җәза бирергә, дип килештеләр.

Җыелышның житди һәм кискен булачагы алдан ук күренеп тора иде. Бригаданың кызыл почмагына нефтьчеләр ягыннан да, элемтәчеләрдән дә кешеләр күп килгән, бүлмәдә басып торыр урын юк.

Хөкемдарлар түрдән урын алды. Фәнүзә белән Мәснәвине янәшә, суд эскәмиясенә утырттылар. Сара ханым, зыян күрүче буларак, өстәл кырыена килеп басты.

Тәге көннәрдәге кебек, Фәнүзә инде бу юлы аска — идән ярыгына карап утырмый, туп-туры каршысындагы хөкемдарларга баккан. Курку түгел, хәтта оялу да юк сыман. Киресенчә, ул мондый зур тавыш-гауга чыгуы белән горурлана кебек. Теләсә нәрсә дисеннәр, теләсә нинди җәза бирелсен — Фәнүзә әһ тә итмәячәк. Ни генә әйтсәләр дә инде Мәснәви аныкы, ул — Мәснәвинеке.

Җыелышны нечкә муенлы, елак тавышлы кеше — бригаданың иптәшләр суды председателе ачты. Ул шактый озак һәм ялыктыргыч итеп әхлак мәсьәләләре Мәснәви белән Фәнүзәнең «үз-үзен тотышлары» «җәмгыятькә хас булмаган тәртипләре» турында нотык сөйләде. Сөйләгәндә ул әле Мәснәвигә, әле Фәнүзәгә озын, нечкә бармагы белән төртеп-төртеп күрсәтә иде.

Аның чыгышыннан соң бераү Сараның дүрт-биш биттән торган җалобасын укып чыкты. Ходаем ниләр генә язмаган ул анда, Фәнүзәгә нинди генә ялалар якмаган да ниләр генә әйтеп бетермәгән! Андагыга ышансаң, Фәнүзәне Сара түгел, ә Сараны Фәнүзә урамда очратып кыйнаган, әшәке сүзләр әйткән булып чыга. Кара инде, Сараның йөзендә бер генә тырналган эз дә юк, ә Фәнүзәнең янагында, күз төпләрендә әле дә булса кабарган, кара янган урыннар ярылып ята.

— Ялган! Дөрес түгел! — дип кычкырдылар арттан эшчеләр.— Монда ике яктан да шаһитлар булсын!

— Кул күтәргән өчен аның үзен судка бирергә кирәк!

— Икесенә дә штраф чәпәргә!

Иң кырыйдагы урыннан яше илле-илле биш чамасындагы бер эшче күтәрелде. Әюп абзый иде бу.

— Җәмәгать! — диде ул.— Ир дигән зат — ул бозау түгел, качса аны муенчаклап алып кайтып булмый. Инде өеннән чыгып качу хәленә житкергән икән, монда кем гаепле? Әлбәттә, хатын! Ирне ир иткән дә хатын, жир иткән дә хатын! Шулай булгач, ничу жалобалар язып йөрергә!

Бүгенге көндә Мәснәви белән торакта, бер бүлмәдә яшәүче Салих сүз сорап алды. Фәнүзәнең хәтерендә, Яңа ел кичәсендә ул башын чайкый-чайкый гел җырлап утырган иде.

— Мин сөйли белмим, җырлап кына күрсәтәм,— диде дә көйләп тә китте егет:

Минем хатын мәхәббәтен
Торган саен арттыра
Профкомга чакырта да
Җаныем, бәгърем,
Никахны яңарттыра.

Икенче куплетын җырларга да исәбе бар иде кәмит кирәкми диделәр, утырырга куштылар.

Мастер Курамшин торып басты. «Авыл кияве», Фәнүзәнең сабакташы Хәтимә ире. Ул Фәнүзәне таный торгандырмы, юкмы, ә Фәнүзә аны яхшы белә. Беренче тапкыр теге елны, чишмәдән кайтканда нефтьчеләр белән бергә су эчкән иде ул Фәнүзә чиләгеннән. «Оператор итеп

алыр идем дә, буең кыска, үсәсең бар», дип шаярткан булды, ә үзе «үсәсе бар», дип тормады, карт башы белән Фәнүзәнең яшьтәшенә, унсигез дә тулмаган ятимә кызга өйләнде.

Аска карап, кешеләрне маңгае белән сөзеп сөйли икән Курамшин.

— Килешмәгән, әдәпсез эшләре белән Мәснәви бригаданың йөзенә тап төшерде. Монда мин аны якларга теләмим. Ләкин бит, иптәшләр, үзегез уйлап карагыз, безнең алда, әгәр шулай әйтергә яраса, яп-яшь кыз утыра. Мәснәвинең хатыны бар икәнен белә ул. Белә, ә шулай да бу семьяның тормышын боза. Бу бернинди калыпка да сыймый, иптәшләр...

«Төптәнрәк уйлый башласаң үз хәлең дә алай мактанырлык түгел әле — дип утырды эченнән генә Фәнүзә.— Әнә, Хәтимәсен Шәфрун оныта алмый йөри. Шул әйле-шәйле Шәфрун Курамшинның күз алдында капка төбенә килеп төне буе гармун уйнап чыга, җитмәсә шунда, гармунын баш астына салып, утыннар өстендә кунып та китә, ди. Алай бик кычкырырлыгы юк әле «авыл кияве»нең кешеләр алдында...»

Җыелыш давыллы һәм гаугалы булды. Өстәл артында утырган хөкемдарлар урамда сугышуны, Фәнүзәнең күзе-башы җимерелүен, шулай тиеш кебек, бөтенләй исәпкә алмаска маташтылар. Сүзне бары тик Мәснәвинең хатынын ташлап, Фәнүзә белән буталуына гына кайтарып калдырдылар.

Фәнүзәнең бу кадәр тавыштан, хак һәм хаксыз сүзләрдән башы авырта башлады, колаклары томаланды. Утырган кешеләр томан аша күренгәндәй, аларның сүзләре стена аша ишетелгәндәй тоелды. Кемнәрдер сораулар бирделәр, кайсыларыдыр Мәснәвине, кайсыларыдыр Фәнүзәне яклап сөйләде. Тагын Курамшинның Мәснәвине бастырып әрләве, аны өенә, семьясы янына кайтырга үгетләве хәтердә. Мәснәви исә каты котырды: «Юк, кискән икмәк кире ябышмый!» — дип киреләнде.

Анысын булдырды, ә менә Фәнүзәне канат астына ала алмады.

«Без бергә, безне сез түгел, хәзер үлем дә аера алмый!» — диярга, хатыны алдында хәтта кочаклап алырга кирәк иде. Көткән иде, тилмереп көткән иде Фәнүзә Мәснәвинең бу адымын. Хәтере калды Фәнүзәнең: «Юк икән, егет түгел...»

Фәнүзәнең битендәге җәрәхәтләрен, күз астындагы күмгәкләрен күрсәтә-күрсәтә, чыгыш ясаган Татьяна Макаровнаның да, ирен шушы көнгә калдырган, үз өеннән бизәргә мәҗбүр иткән Сараны яманлап сөйләгән нефтьчеләрнең сүзләре дә үтмәде. Иптәшләр суды күпчелек тавыш белән Фәнүзәне дә, Мәснәвине дә «эштән азат итүне сорап администрациягә мөрәҗәгать итәргә», дигән карар чыгарды.

Чыпчык баласын таларга җыенган каргалар төсле күренгән кара ир-ат төркеменә һәм алар арасында чыркылдашкан берничә хатын-кызга борылып, нәрсә булса да яман итеп кычкырасы килгән иде Фәнүзәнең — тыелып калды. Әлеге шау-шу, тарткалаш эчендә калкып торган үз хәсрәте бар иде аның: «Эштән кумагайлары чукынып китсеннәр. Тырнак очы кадәр дә кайгырмыйм анысына. Менә курста укуларны бетерәсе иде. Бары ике атна калды бит... Аннан, тракторчы исеме бирелгән белешмәне алам да — дүрт ягым кыйбла!..»

### III

Җыелыш тавышы әле колактан да чыкмаган шушы март башларында кинәт кенә җылытып җибәрде дә яңгырлар явып алды. Аның артыннан ук күз ачкысыз бураннар башланды. Җепшек кар суынып, телефон чыбыкларына сарылды, беләк юанлыгы булып катты, чыңгылдап торган бозга әйләнде. Авыр йөк баганаларны басты, чыбыкларны шартлатып

өздә, күп урыннарда элемтәне сафтан чыгарды. Моның кыенлыгы техникларга һәм монтерларга гына төшсә бер хәл иде — ул нефтьчеләрнең эш графигына, режимнарына да китереп сукты.

Бу көнне дежурда Фәнүзә иде. Актык көнем булыр ахры дип, беркинди теләксез, кәефсез килеп утырган иде ул. Кичтән үк төрле урыннардан звонoклар яңгыры ява башлады. Кайдадыр нефть җыю пунктыннан нефть кудыралар, ә товар паркы продукция кабул итүне туктаткан. Кайсыдыр скважина электр линиясе өзелү сәбәпле эшләми — авария бригадасын чакыртырга кирәк. Ә ул бригада белән элемтә юк. Ярый әле, коммутатор белән товар паркы арасында бер линия эшли һәм тагын товар паркыннан шәһәргә киткән чыбык бар. Шуннан кычкыралар:

— Кая китеп дөмеккән бу нефтьчеләр?

— Утыз өч, ишетәсеңме, туктатсыннар нефть кудыруны!

— Анда линия өзелгән! — дип ансат кына котылмакчы булган иде Фәнүзә.

— Өзелсә, ялга! Теләсәң ничек хәбәр ит! — дип акырдылар. Әйтерсең, мондый четерекле эшләр коммутаторда утырган гап-гади телефончының кулыннан килә.

Татьяна Макаровна болай дип өйрәтә торган иде: берәр җирдә авария булып, нефтьчеләрдә кыен хәл килеп туган икән, син инде «линия занята», фәлән-төгән дип утырма, кем генә сөйләшсә дә аны өз һәм газап чигүләрне тизрәк коткару ягын кара. Ала алмасалар, хәбәр итү чарасына кереш. Шартла, ярыл, ә сораган кешеләрен тап! Шунсыз тынма, тоташтырып бир! Үзең генә булдыра алмыйсың икән — бүтән телефончыларны ярдәмгә чакыр, шәһәр коммутаторына шалтырат. Кирәк икән элемтә начальнигына, кирәк икән министрның үзенә җит, әмма эшне булдыр!

Зиһенен җыя алмыйча бер мәл уйланып торганнан соң, Фәнүзә ашыгып товар паркын ялгады, андагы коммутатордан шәһәрне сорап, әллә ничә буын аша Курамшиннар квартирасын алды.

Хатыны Хәтимә иде булса кирәк: — Ул китапханәгә китте,— диде дә трубканы куйды.

Шәһәрдә телефон автомат станциясендәге дежур кызлардан китапханәгә шалтыратуны сорарга кирәк.

Курамшинны анда да тапмадылар. «Нефть идарәсенең техник китапханәсе бар, бәлки шундадыр»,— диде мөдир.

Чыннан да, Курамшин анда утыра икән — телефонга килде. Фәнүзә, ашыга-кабалана, хәлне аңлатып бирде. Курамшиннан, ниһаять, беренче рәхмәт! Таштан юкә суелды.

Эш моның белән генә бетми әле. Чыбыкларның сафтан чыгуы турында элемтә начальнигына да, квартираларына шалтыратып буровой хуҗаларына, нефть идарәсе башлыкларына да хәбәр итәргә кирәк.

— Тукта, мин нишләп өзек линия саклап утырам әле? — дип сорады Фәнүзә үз-үзеннән.— Нәрсә эшли алам мин монда? Мәснәви дежурда, аның хәле ничек икән?

Колакларыннан наушникларын салып куйды да, урыныннан торып, җәһәт киенә башлады.

— Әйе, товар паркында чаннар нефть белән тулганны, бүтән кабул итмәячәкләрен белми, шалтыратмыйлар — хәбәр итмиләр дип, скважиналарын эшләтә, нефть кудыра торганнардыр. Чаннары тулып ташыячак, нефть торбалары ярылып бетәчәк бит... Барып әйтергә кирәк үзенә.

Тышта буран тагын да котырган, аяктан екмалы җил дулап, бөтереләп, карны өеме-өеме белән һавага күтәрә, әйләндерә, болгата да әллә кайларга алып китә. Юллар капланган, сукмаклар күмелгән. Мондыйда курыкмыйча кем юлга чыксын да нинди машина килә алсын? Буран басылмыйча монтерларны да, нефтьчеләрне дә көтмә хәзер. Фәнүзәне алыштырырга смена да булмаячак.

Киез итеге белән бот төбеннән карга бата-бата, бригада йортына таба китте Фәнүзә. Моннан нибары бер, күп дигәндә ике чакрымнар чамасы арададыр ул. Кичә генә зур җанҗаллар белән Фәнүзәгә һәм Мәснәвигә хөкем чыгарылган бер катлы таш йорт. Кичә буран юк, юл такыр иде. Килен төшергәндәй, ике ягына ниндидер ике купшы егетне утыртып, мастер Курамшинның яшел бөркәнчекле легковоенда гына алып килделәр Фәнүзәне бу таш йортка...

Ул, җилдән бигрәк, сырма кардан сакланып, гел яны белән барды, бияләйләре белән гел битен каплады. Ниһаять, сөт кебек куе кар пәрдәсе эченнән җемелдәп ут күренде. Тәрәзә каршына ук килеп туктаган икән Фәнүзә. Стена буйлап капшана торгач, ишекне тапты, шакымый гына ачып керде.

Мәснәви ниндидер сызымнар белән мәшгуль иде, өстәл артыннан чәчрәп торды.

— Фәнүзә? — диде ул гаҗәпләнеп. Төн пәрие булса да бу кадәр гаҗәпләнмәс иде. Хөзер Ильясны күрсә дә бу кадәр шаккатмас иде.

— Уф, ардым Мәснәви, телефоным эшләми...

Мәснәви агарынып китте:

— Телефон эшләми? Ник шалтыратмадың?

Мәснәви үз сүзеннән үзе көлеп җибәрде.— Әйе, телефон эшләми дисең бит... Алайса миңа хәзер үк скважиналарга йөгерергә кирәк.

— Мин Курамшинга да, идарә җитәкчеләренә дә шылтыраттым...

— Син нәрсә, Фәнүзә? Кая мондыйда килә алсыннар?

Мәснәви чаңгыларын алды.

— Мин хәзер. Син китә күрмә, адашырсың...

— Ә син адашсаң?

— Минме? Мин, Фәнүзә, бу тирәләрдә күземне бәйләп җибәрсәләр дә йөри алам!

## IV

Бураннар басылып бер-ике көн үткәч, коммутаторныйга Курамшинның звоногы килде. Сүзен ул гадәттәгечә башлады:

— Татьяна Макаровна, бу сезме?

— Мин булсам нәрсә әйтерсең, Кәрам Ризванович?

Курамшин трубкада бер мәл мышкылдап, борынын тартып торды.

— Гафу итегез, Татьяна Макаровна, суык тигән. Теге көнне машина белән бик озак буранда утырдым,— дип зарланып алды карлыккан тавыш белән мастер.

— Нәрсә, больницаны алып бирергәме?

— Кирәкми, болай да үтәр. Ни дип әйтмәкче идем...

— Ни дип?

— Синең кызың эшлиме әле? Фәнүзәне әйтәм.

— Синең егетең эшлиме соң?

— Менә шунда шул хикмәт... Әллә, мин әйтәм, эшләрендә калдырыргамы үзләрен?

— Ә җыелыш? Суд решениесе?

— Анда бит «администрациядән сорарга» диелгән. Без кем, администрация түгелмени? Хәл итә алмыйбызмы?

— Ә Сара ханым нәрсә дияр?

— Үзе судта утыра, кирәк булса үзе хәл итсен! Синең Фәнүзәңне әйтәм, молодец кыз булып чыкты бит. Уйламаган идем ул җилбәзәктән... Бик зур бәлаләрдән коткарды безне. Ул булмаса баш беткән иде... Нефтьчеләр исеменнән рәхмәт белдерергә кирәк аңа!

Мартның соңгы ачы бураны һәм нефтьчеләргә булган шундагы бәләкәй генә хезмәте Фәнүзәнең эштә калуын тагын күпмегәдер кичек-

терде, солдатка китәсе егетләр белән бергә ДОСААФ каршындагы курсын тәмамларга, алар кебек үк тракторчы, бульдозерчы, скреперчы һәм трактор краны машинисты хокукларын биргән таныклык алырга мөмкин итте. Ул гына да түгел, бу таныклык белән ничек, кайда һәм кайчан китәргә икәнен уйларга вакыт бирде.

— Себергә китәм! — дип карар кылды ахырда Фәнүзә.

Барыбер ул Мәснәви белән бергә була алмаячак. Тынгы бирмәячәк аның хатыны. Эш тирәнгә киткәнче өзәргә кирәк Мәснәви белән араны... Бетерергә кирәк бу яшерен очрашу-кавышуларны. Онытырга Мәснәвине, Себергә качарга кирәк. Авылдашларыннан, туганнарыннан, дусларыннан, әти-әнисеннән качарга. Мөмкин кадәр ераграк китеп...

Фәнүзәнең «качар» өчен жылы Ташкент якларын түгел, нәкъ менә салкын Себерне сайлавы тикмәгә түгел иде. Ул ишетеп тора: шушы бер-ике ел эчендә халык теленә кинәт кенә «Себер» дигән сүз килеп керде. Урал таулары артында — Төмән якларында гаять зур нефть һәм газ ятмалары тапканнар, бик күп эшче көчләр таләп ителә икән.

Кешеләр ялгыз-ялгыз да, семьялары белән дә Тубылга, Сургутка, Урайга китә башладылар. Кайсылары вакытлыча, договор белән, кайсылары йорт-җирләрен сатып, бөтенләйгә, гомергә...

Берсеннән-берсе чуалчык уйлар, хәтәр планнар белән азапланып йөри торгач, тагын айга якын вакыт сизелми дә узып китте. Һаман үз язмышын хәл итә алмый иде әле Фәнүзә.

Китү нияте нык булса да туган туфрактан аякны тиз генә кубарып булмый икән. Бер яклап, әти-әнисеннән, туганнарыннан аерылырга читенсенсә, икенче яклап, эшен ташларга җөрьәт итә алмый йөри. Вөҗдан газаплый. Юк, телефон кызганыч түгел, ә Фәнүзә өчен җанын ярып бирергә торган Татьяна Макаровна жәл. Кызны ул эшкә алды, һөнәргә өйрәтте, Фәнүзәнең башына өсте-өстенә бәлаләр явып торганда ул җил-давылдан саклап калды. Хәзер бу киң күңелле, игелекле хатын янә телефончысыз калачак, ике кеше өчен берүзе коммутаторда утырачак. Үзенең «Фәнүзушка»сына ихлас күңелдән ышана, аны самими бала итеп күрә иде бит Татьяна апасы...

Һәм шунда моңа кадәр һич хәл итә алмаган мәсьәләне чишкәндәй булды. Әйе, әйе, үзе урынына бер яшькә кече сеңелесе Фәнияне калдырачак Фәнүзә. Аны Татьяна Макаровнаның да күргәне бар. Фәния кайсы көннәрне дежурдагы апасына ашъяулыкка төреп жылы аш яки кайнар бәрәңге китерә иде. Телефон белән дә бик кызыксына. Фәнүзә тамак ялгап алган арада, наушникларны киеп, Фәнүзәнең «утыз өчле» шифрын әйтә-әйтә «да», «занято», «минутку» дигән булып утыра, ярыйсы гына житез итеп штеккерлар белән каналларны тоташтыра. Кулы ята аның бу эшкә — рәвешен китерә....

Кайчандыр, әле Мәснәви белән буталмаган чакларда, Татьяна Макаровна:

— Сестраң үзеңә похоже икән,— дия торган иде.— Мин пенсиягә китәм, сине үз урыныма, ә сестраңны синең урынга калдырам, согласныммы?

Ләкин эшне ташлап читкә китү мәсьәләсен ата-ана да, туганнар да, Татьяна Макаровна да түгел, көтелмәгән бүтән нәрсә хәл итте.

Дежурдан кайтып йокларга яткан иде Фәнүзә. Бүген башка көннәргә караганда да эш тыгызрак булды төсле— арытты. Төн урталарында кайсыдыр скважинада торба ярылган, нефть аккан — операторлар звонокны гел дырылдатып кына тордылар, авария командасын эзләттеләр, мастерларны таптырдылар. Алардан гына котылган иде Фәнүзә — бораулаучылар теңкәгә тиде. Буровойга энергия килү туктаган. Тагын өзлексез шалтыратулар, кеше эзләтүләр... Аларның тавышы йокларга яткач та һаман колак төбендә чыңлап торды.

Сулуын тирән алып, изелеп кенә бара иде Фәнүзә, кемдер шунда

дык итеп эчтән корсагына типте. Фәнүзәнең башын авыр йокы баскан, ул аны-моны уйларлык түгел, аңгы-миңгерәк шикелле иде — кабат йокыга китте. Һәм менә тагын дык итеп кемдер сул як касыгына төртеп куйды. Фәнүзә күзен ачты.

— Чү, нәрсә бу?

Тын алырга да куркып ятканда эчтә янә нәрсәдер селкенеп куйды. Фәнүзә, коты очып, торып утырды, ике кулы белән эчен басты.

— Бәби бит бу! Балам! Я ходаем!..

## V

Сеңелесе Фания кичтән жылы аш китергәндә дә әле Фәнүзә коммутаторда эшли, гадәтенчә, абонентларга кырыс-мырыс кына җаваплар биреп утыра иде.

Бер тыныч ара табып Фаниягә борылды.

— Бәрәңге китердеңме?

Шунда апасының күзләре кызарганын, күз кабаклары шешенгәнен күреп алды Фания: «җылаган бу».

— Үскәнем,— диде Фәнүзә, ничектер матур, моңлы итеп. — Миңа хәзер үк авылга кайтырга кирәк. Бик кирәк. Нигә икәнен сорама, соңыннан белерсең...

— Авырыйсыңмы әллә?

— Юк, авырмыйм. Сорашма, соңыннан белерсең. Син шуны әйт: дежур тора аласыңмы син минем урынга?

— Төнлә куркам бит мин...

— Берни дә юк монда! Менә ничә ел торам, ичмаса шушында бер шүрәле килеп чыксын! — Фәнүзә сеңелесен гайрәтләндерү өчен көлгән булды.— Тыңла инде, үскәнем. Бүген кешеләрнең ял көне, эш алай тыгыз түгел. Беразга гына булса да тор, соңыннан килеп чыгармын...

Фания бу төнне дежур торырга әллә риза булды, әллә юк — аппарат алдына утырып наушникларны кигәндә, коммутатор бүлмәсендә Фәнүзә юк иде инде... Апасының: «Бүген ял көнe, эш алай тыгыз түгел»,— дигәне дә дөрес булып чыкмады. Скважиналардан берөзлексез звоноклар килде, буровойлардан шәһәрне сорап тордылар, насос станцияләре, товар парклары, нефть җыю пунктлары белән дә элемтә өзелмәде. Аларын апасыннан яхшы гына өйрәнеп калган иде Фания, ә менә шәһәрне, андагы квартираларны алып бирә белми икән. «Фәләнфәләновның квартирасын бирегез әле» — диюгә:— Кайда соң ул квартира?— дип сорады. «Атаң башында!»—дип кычкырдылар аңа. Берәү: «Иптәш утыз өч, башың әйләнгәненә ышанмаган идем, хак икән»,— ди. Монысын ул, әлбәттә, Фәнүзәгә әйтәм, дип уйлый.

«Утыз өч», «утыз өч» дип нефтьчеләргә җавап бирә-бирә тавышы карлыгып беткән Фания апасын төн урталарына кадәр көтте — Фәнүзәнең эзе дә юк. Япа-ялгызы, яңгырлы кара төндә, әллә кайда җәһәннәм астында утыруы куркыныч иде. Җитмәсә, сәгать икеләр тирәсендә телефон да тынды, коммутатор бүлмәсендә тагын да шомлырак булып калды. Җил улаган, шыбырдап тәрәзәгә яңгыр бәргән саен, кыз сискәнеп аппаратка таба сыенды.

Идән астының нәкъ аяк турысында гына ике гөберле бака чырылдый, бер почмакта тычканмы, нәрсәдер кыштырдый. Тукта, кемдер тәрәзәне кага икән.

Бервакыт, пыяланы сызып алган кебек, яшен ялтырады, дөбердәп күк күкрәде. Быелгы бу беренче яңгыр, Фанияне куркытыр өчен, юри яшьнәп-күкрәп ява кебек иде. Яктыра башлагач, кешеләр төрле җирләрдән коммутаторга дәшә башлагач кына кот керде Фаниягә. Хәзер инде ул курыкмый, аңа иптәш бар, таныш булмаган кешеләргә, шатлана-шатлана, үзенең «утыз өчлесен» әйтеп утыра.

Телефоннан кайберәүләре аңа «Фәнүзә» дип эндәшәләр.— «Нигә тавышың зәгыйфь, әллә кәефең юкмы, әллә Мәснәвиең йокы бирмәдеме?— ди кайсыдыр бер мөртәте. Иртән смена бетәр алдыннан гына бер кызык сөйләшү булып алды.

— Хәерле иртә!— дип башлап җибәрде сүзен бу бәндә, «утыз өч» дигәнне ишетү белән.— Мин сиңа һаман шалтырата алмыйм, Фәнүзә. Син миңа бик каты ачуландың бугай. Гафу ит инде, җыелышта сине яклап бер катрә сүз әйтә алмадым... Үзең беләсең — андый чакта артык сүз — утка нефть салган кебек булыр иде. Үпкәләдеңме? Аңлыйм, аңлыйм. Дәшмәвеңнән үк күрәм. Я, Фәнүзә, бер генә сүз әйт инде. Хет мине тиргә, теләсә нинди әшәке сүзләр әйтеп бетер — миңа җиңелрәк булыр...

— Синең белән сөйләшергә вакытым юк!— диде дә, каналны ябып куйды Фәния. Кем икәнен чамалады кыз. Апасы белән Мәснәви арасында булган чуалчык хәлләрне кешеләрдән ишетеп тә, эти-әнисенең Фәнүзәгә әйткән сүзләреннән дә, көн саен диярлек аны тиргәүләреннән дә яхшы белә иде. Гомердә нәсел-нәсепкә кермәгән хурлык эшләде апа кеше. Хәзер ничек юар-йолыр инде ул «азгын», «сөйрәлчек» дигән исемнәрне?..

Кызның үтереп ашыйсы килә башлады. Ни хикмәттер, төнлә йокысы килмәде, ә ашыйсы килде. Ишек төбендә, чөйдә эленеп торган ашъяулык эчендә Фәнүзәгә дип алып килгән җылы коймаклар, кайнар бәрәңгеләр һәм сөт өсте бар иде — аларны барып алырга курыкты ул. Тышта яктыргач һәм телефонда кешеләр сөйләшә башлагач кына, батыраеп, аппарат алдына төенчекне күтәреп килде. Эшләргә дә, ашап утырырга да була икән.

Төенчекне чишү белән үк идәнгә язу килеп төште. Анда эре хәрефләр белән берничә сүз генә: «Мине ачуланмагыз, эзләп җәфаланмагыз. Мин авылдан бөтенләйгә китәм. Хушыгыз! Фәнүзә», дип язылган иде. Фәниянең күзеннән яшь атылып чыкты.

Нәкъ иртәнге җидедә сменаны алыштырырга «коммутатор анасы» Татьяна Макаровна килде. Фәнүзә урынында аның сеңелесе утыруын күргәч:

— Ба, монысы тагын нинди новость?— дип ишек төбендә үк туктап калды.

Татьяна Макаровнага нәрсәдер әйтмәкче, зарланмакчы иде Фәния— иреннәре калтырап китте, сүзен табалмады, аппарат өстәленә капланып еларга тотынды. Апасының алдап чыгып китүе, үзенең эшли алмыйча интегүе, төн буе куркып чыгуы өчен дә һәм, ниһаять, Фәнүзәнең беркем белән киңәшмичә туган җирен, өен, эшен ташлап каядыр китеп баруы өчен дә хәтере калып, ачынып елый иде ул.

## УНӨЧЕНЧЕ БҮЛЕК

### I

Бүген якшәмбе, Курамшинның ял көне. Ул моны, ничектер, онытып җибәргән иде — күзен ачу белән ялт итеп сәгатенә карап алды да, урыныннан сикереп торды. Гамьсез йоклап яткан бүлмәдәшләрен күргәч кенә иркен тын алып куйды — эшкә барасы түгел.

Килгәннән бирле һич кенә дә күнегә алмый шушы Себер вакытына Кәрам. Татарстандагыдан өч кенә сәгатьләп аерма — шуңа яраклаша алмый азаплана. Иртән йокыдан торалмый интегә: Мәскәү вакыты белән бик иртә бит әле — сәгать тик төнге өч. Черек күлдән кайткач кичне уздыра алмый гаҗиз була: бездә бишләр-алтылар тирәсе, ә биредә инде кичке сигез-тугыз, урамда, ишек алларында уйнаган бала-чагалар

таралып бетәләр, кешеләр йокларга әзерләнә башлый. Шәһәрдә төн уртасы житә, кинотеатрлар, танец мәйданнары тына, ресторан ябыла, ә Кәрамның һаман йокысы килми — я тәмәке тартып кунак йортының болдырында сөялеп тора, я борынгы картлар кебек капка төбенә чыгып утыра. Ничектер күңелсез, ямансу...

Житмәсә, монда җәй урталарында ак төннәр генә икән. Караңгы бөтенләй төшми диярлек — төнлә шәһәр өстендә ике-өч сәгать эңгер-меңгер асылынып тора да тагын яктыра башлый. Шул сөт кебек ак, тоныкъ яктылыкка сокланып, хозурланып утыра торгач, абайламый да каласың — Вах елгасы ярында үскән сирәк чыршы-нарат төпләреннән кып-кызыл шардай кояш чыгып килә. Бездәге кебек сызылып таң беленү, алсуланып таң ату дигән нәрсәләр юк икән монда, җәй көне көтмә икән аларны...

Болай да соңга калган иде Кәрам, бүлмәдә озын-озак юанмады. Тиз генә юынып керде, өстенә үзе яраткан сары күлмәген киеп зәңгәр галстугын буды, яхшыга дигән костюмын җилкәсенә элеп, урамга чыкты.

Бүген йөрисе урыннары да, күрәсе кешеләре дә байтак иде. Иң беренчесе — шәһәрара телефон станциясенә барып, Хәтимәсе белән сөйләшергә кирәк. Нигәдер, сагындыра, балалар юксындыра. Аннан, кызлар торагын табып, Фәнүзәне күреп чыгасы булыр. Очрашканнан бирле шул Фәнүзә гел күңел түрендә, җанны кимереп тора. Ял булмаган көннәрне, эштән соң да бара ала иде инде ул Фәнүзә янына — һаман читенсенеп йөрде. Ни әйтсәң дә егетләр торагы түгел бит.

Соңыннан, бәлки кичкә табарак, Кузьма янына сугылсаң да ярар иде. Ресторанда утырган теге көннән соң, идарәдә яки эш урыннарында очрашкалап, бер-ике сүз алышудан башка, юньләп күрешкәннәре дә юк бит әле аларның. Бәлки бүген, гәп сатып утыру өчен, үзен ресторанга чакырырга кирәктер? Алай дисәң, Пичуговның Таня белән «башка-баш» алышып алган яңа хатыны — Зоясы бер дә ошамый Кәрамга. Нинди уртак сүз табарга, нәрсәләр турында сөйләшеп утырырга белми алар янында. Аптыраш бит...

Алар турында уйланып бара торгач, телефон станциясенә килеп житкәнен дә сизми калды. Тагын бер нәрсә исенә төште: аның бит Хәтимәгә зур гына йомышы да бар иде. Өйдә, шкаф тартмасында кайбер сызымнар, схемалар саклана. Автомат җиһазлар урнаштыруның кайбер вариантлары, караламасы. Диспетчер бинасының күләменә һәм андагы шартларга яраклаштырып, ул аларны үзе сызган иде. Нәтиҗәдә аппаратлар залы, идарә пульты уңайлырак та, җыйнаграк та килеп чыкты. Аларны куеша алырмы-юкмы, әмма кайсын кая, ничек урнаштырырга кирәклеген күрсәтеп китү зарар итмәс.

Станциянең үзенә килеп заказ бирү яхшы булып чыкты: бередә тавыш ачык ишетелә. Кәрам, гүя, меңнәрчә чакрым ераклыктан түгел, ә өйдәгечә, Хәтимәнең янына утырып сөйләшә:

— Исәнме, Хәтимә аппагым, анда сезнең хәлләр ничек?

— Курамшин, бу синме? Исән-имин генәме?— ди Хәтимә, электәгечә каушап һәм тынына капланып.— Бу көннәрдә ник шалтыратмадың, әллә бөтенләй оныттыңмы безне?

— Вакыт тыгыз, Хәтимә аппагым, вакыт!

— Тавышың карлыккан дип әйтимме, әллә салкын тидердеңме?

— Телефонга суык тигән бугай.

— Син Курамшин, анда сак йөр! Себер булгач — суыктыр. Жылы киемнәреңне дә алып китмәдең ичмаса! Әллә пальтоларыңны, бүрекләреңне җибәримме?

— Монда киресенчә — эссе! Жәйге чиллә кебек. Ничек анда минем бәләкәчләрем, авырмыйлармы, тазалармы?

— Барысы да әйбәт, тик сагынабыз. Олысы бик тырышып мәктәпкә

әзерләнә, китап-дәфтәрләр җыя! Уртанчысы гел уенда, урамнан кергәне юк. Кечесен әйтәсеңме? Анысы бик матур сөйләшә башлады. Әти дә, әти, дип тоташтан такылдап тора.

— Китсәнә, мине юксынамы. Тәпили дә башладымы?

— Чабып йөри инде!...

Кәрамның күзләре нур белән балкый: бүгенге көндә мәктәпкә керергә торган, урам бетереп чаба торган, «әти» дип әйтә ала торган малайлары булу белән горурлана.

— Синең безнекеләрне күргәнең бармы, нишләп яталар икән анда?— дип икенче, үзен гел борчып торган темага күчмәкче була Кәрам. «Безнекеләр» дигәне билгеле инде: аның автоматлашкан участогындагы кешеләр.

— И-и, Курамшин,— дип сәерсенә хатыны,— бер нәрсә дә булмас кешеләреңә! Аларны сорашып вакытыңны алма, үзең турында сөйлә!

Кәрам, көлә-көлә, Аввакумов әйткән сүзләрне кабатлый:

— Миңа нәрсә: ашау — байдан, үлем — ходайдан. Солдат йоклый, хезмәт бара...

— Бик яхшы, бик яхшы! — дип куана Хәтимә. — Хәзер күп тә калмады бит инде, Курамшинкаем, бер ай гына!..

— Әйе, этеп-төртеп ярты айны уздырдым, калганын да мондагыларга булышып үткәрәм инде, боерган булса...

— Әллә чын-чынлап эшләргә җыенасыңмы?

— Килгәч ничек эшләмисең ди инде, карчык. Юкса, бездельник дип куып җибәрүләре бар.

— Әйе шул.

— Ярый, вакыт бетә, трубканы улларыма бир әле.

Моңа кадәр дә әниләре янында мышкылдап торган малайлар, телефон трубкасын алу өчен тарткалаша, кычкырыша башладылар. Аларның кайсы Тәлгать тә кайсы Фәргать икәнен һич тә аерырлык түгел:

— Әти, тизрәк кайт!

— Аю баласы апкайт, әти, үзең әйттең бит апкайтам дип!

— Мин әлифба алдым, әти, рәсемнәре шундый матур!

— Ә минем буяу карандашлары бар! Иртәгә кайт, әти!

Вакыт чыкты, малайларның тавышы «кайт!» та «кайт!» дип кычкырулар белән өзелде.

Урамда да хатыны, балалары белән сөйләшү тәэсирен кичереп йөрде Кәрим. Хәтимәнең ягымлы, шул ук вакытта үпкәләүле сүзләре, улларының ихлас самимилек белән аю баласы таләп итүләре һаман колагында яңгырап торды. Әйе, аларны Кәрам бик юксына, сагына башлаган иде инде.

Иртәнге якта берән-сәрән генә күренгән чебен-черкиләр дә куерды, талый башладылар. Мондагы черкиләр үзенә бер сорт — шундый әрсезләр, пуля урынына очып киләләр дә, шул килеп бәрелгән хутка тәнеңә кадалалар. Син учың белән сугып төшергәндә инде җитәрлек кадәр каныңны эчкән, кып-кызыл бөртенгән була.

Чебен-черкиләрдән качып, Фәнүзәләр торган җиргә күләгәдән, парк аша гына үтеп чыкмакчы булды Курамшин. Тик черкиләр монда да тынгы бирмәде аңа, ябырылып-ябырылып килделәр дә әрнетеп-әрнетеп талауларын белделәр.

Агачлар арасына качмакчы булып, асфальттан чак кына читкә атлаган иде — бот төбеннән сазга чумды Курамшин.

— Тфу, бәдбәхет! Парк түгел, тозак бу, декорация!— дия-дия сүгенеп, аягын көчкә тартып алды. Парк уртасындагы фонтан янына

барып чалбар балагын, туфлиләрен югач, сукмак буйлап кына урамга чыкты.

Шәһәрнең бу башы генераль планда һәм официаль кәгазьләрдә беренче микрорайон дип исемләнсә дә, халык аны нефтьчеләр поселогы дип, ә нефтьчеләр үзләре «Чукотка» дип йөртә. Тоташ тулай тораклардан гына төзелгән бу урын шәһәрнең бер читендә, ярымутрау булып чыгып тора, бәлки шуңа Чукоткадыр?

Нинди генә төр, нинди генә типтагы һәм конструкциядәге тораклар юк монда! Бер читтәрәк тоташ балконнары, биек тәрәзәләре белән җәлеп иткән унике катлы бина да төзелеп ята. Монысы да семьялылар өчен түгел, ялгызлар өчен булачак икән.

«Чукотка» — чыннан да тулай тораклар, ялгыз һәм ялгызаклар шәһәрчеге. Аның үзенә күрә кечкенә клубы да, мунчасы да, кибетләре дә, сакал-мыегың китсә, яшәреп чыгу өчен парикмахерские да бар.

Эш көннәрендә микрорайонда кешеләрне очрату кыен. Ял җитте исә — кеше күплегенә хәйран каласың. Кайдан җыелып беткәннәр диярсең: урамда халык белән юллар, тротуарлар тулы. Ишегалларында волейбол, баскетбол туплары сикерешә, тупас такталардан кагып куйган өстәлләрдә доминолар шыкылдый. Кибет, ларек тирәләре аеруча җанлы. Клуб, кинотеатр яннарында билетка озын-озын чиратлар төзелгән.

Урамга чыккан саен, Курамшин шулай тирә-юньне карап, кешеләрне күзәтеп йөрергә ярата. Себер белән үзенең Әлмәт якларын чагыштырып карый, «монда болай, тегендә тегеләй», дип бәя биреп ала. Бирәдәге төзелешләрне дә, тәртипләрне дә, хәтта кешеләрен дә ничектер ошатмый иде ул. Вахның бу микрорайонын да килештермәде Кәрам. Урамның ике ягына тезелеп киткән бараклары казармаларга охшап тора, ә тоташ ир-атлардан гына торган кешеләр солдатларны хәтерләтәләр. Хәрби гарнизон кебек. Кыз-кыркын тавышы, балалар чыр-чуы ишетелмәгәч, кошлары очып киткән көзге урманны искә төшерә шәһәр. Моңсу монда.

Уналтынчы йортны тиз тапты Курамшин. Кызыл кирпечтән салган дүрт катлы, бөтен квартал буена сузылган озын бина. «Шәһәрнең бөтен кызлары шушы торакта, башка җирдән эзләмәгез дә, тапмассыз да» дип, уены-чыны белән әйтеп кертеп җибәрделәр аны шул тирәдәге егетләр.

Ишек төбендә Курамшинны ниндидер кырыс йөзле, ирләр тавышлы усал апа каршылады:

— Сезгә кем кирәк?
— Ризатдинова.
— Нигә кирәк ул?
— Нигә дип... Күрергә иде.
— Йөрмә, йөрмә, бар, ишекне теге ягыннан яп!
— Йомышым бар иде минем аңарда.
— Бар, бар, чык! Беләбез нинди йомышың барын!..

Сүз әйтергә дә өлгерә алмый калды Кәрам, әлеге апа аны ишеккә таба борып урамга төртеп тә чыгарды.

— Кара нинди явыз! Бу хатын булганда овчаркаң да кирәкми, валлаһи!

Курамшин өстен какты, кыйшайган галстугын рәтләде дә, нинди дә булса язу тапмакчы булып кесәсенә тыгылды. Аннан кызыл тышлы кенәгә — техника куркынычсызлыгы таныклыгы килеп чыкты.

Бу мәсьәләдә Кәрамның студент еллардан ук килгән тәҗрибәсе бар. Кайда да булса тулай торакка керергә кирәк икән, вахтерларга студент билетын түгел — алар аны санга да сукмыйлар — я Кызыл Хач, я ДОСААФ тарафыннан бирелгән кенәгәне күрсәтәләр иде. Ниндидер

магик көче бар ул катыргы тышлы нәмәстәнең. Төсе дә кызыл булса, берсүзсез үтәсең инде ишектән... Вахтер хатын, ишектән тагын килеп кергән Кәрамга жикеренергә дип авызын киереп ачкан иде, кызыл тышлы кенәгәне күреп, шул хәлендә катып калды — авыз йомылды, елмаюга көчте. Кешеләрчә матур итеп сөйләшә дә белә икән үзе тагын:

— Башта ук шулай дип әйтәләр аны. Юкса монда кем керми? Ничәнче бүлмә кирәк дисез әле? Бишенче? Ничек әле фамилиясе? Ризатдинова бит. Фәнүзә. Шулай дидегез бит. Беләм мин ул хатынны...

— Хатын түгел ул, кыз! Кияүгә чыкмаган,— дип төзәтте Кәрам.

— Әйе шул, әнисенә кыздыр... Ул кызның инде ат кадәр малае бар...

— Сез бутыйсыз булса кирәк. Фәнүзә Ризатдинованың баласы юк,— дип тагын каршы төште Курамшин.

— Алайса, ялгыш кергәнсез. Сез эзләгән кыз — башка Ризатдиновадыр ул...

Вахтер хатын ишектән кереп баручы бер кызны туктатты.

— Рая, бишенчегә дәш әле, Ризатдинова монда төшсен. Әйе, әйе, Фаяга...

Бераздан, этаж баскычларын шапылдата-шапылдата йөгереп, Фәнүзә төшеп тә житте. Ул яланаякларына үкчәсез башмак элгән, ачык изүле зәңгәр халаттан иде. Төшеп тә житте, Курамшинны күреп, аның биленнән кочаклап та алды.

— О, Кәрам Ризванович! Хуш киләсез, әйдә, икенче катка минем бүлмәгә күтәрелик.

— Рөхсәт итәрләрме соң? — дип, вахтер хатынга карап алды Курамшин.— Монда сезнең тәртипләр кырыс икән! Нык саклыйлар сезне!..

— Саклый-саклый шушы көнгә калдырдылар инде...— Фәнүзә, вахтер хатынга борылып:— Евдокия Матвеевна, таныш булыгыз, бу Курамшин булыр,— диде.— Татарстанда гына түгел, бөтен илдә зур кеше ул, аңладыгызмы? Аңласагыз шул, Евдокия Матвеевна, аны бүтән тоткарлыйсы булмагыз!

Фәнүзә Курамшинны, үз кешедәй итеп култыклап, югары катка алып менеп китте.

Бүлмәдә Фәнүзәдән башка тагын ике кыз тора икән. Алар, Фәнүзә белән ят ир-ат кергәнне күреп, шунда ук аякка бастылар, ашыгып урын-жирләрен рәтләргә тотындылар.

— Курыкмагыз, кызлар, бу үз кеше, минем авылдашым,— дип таныштырды Курамшинны Фәнүзә.— Әйттем бит ул миңа киләчәк дип. Менә, шул үзе инде.

— Исәнмесез? — дип баш иде Курамшин, ишек төбеннән китмичә генә.

— Әйдә, түрдән уз, Кәрам Ризванович, әнә минем караватым янына утыр.— Фәнүзә урындык тәкъдим итте.— Менә шушында яшәп ятабыз инде...

— Бик яхшы, бик яхшы.

Фәнүзә, ни эшләргә белмичә, як-ягына каранып алды да, кызларга кычкырды.

— Ни эшләп катып калдыгыз әле, кызлар? Марина, бар әле, магазинга йөгер! Наташа, чәй куй, табын әзерлә!

— Кызылын алыргамы соң, агынмы?— дип сорады кибеткә жыенучы Марина дигәннәре.

— Инженер кешенең кайчан кызыл эчкәне бар? Минем якташ, беләсегез килсә, акны да капмый әле ул! Коньяк алып кайт! Аның да биш йолдызлысын! Шулай бит, Кәрам Ризванович, биш йолдызлы бит?..

— Я инде, Фәнүзә, кирәкми андый нәрсәләр. Булмаганны...

Фәнүзә, мәжбүри диярлек, Курамшинның пиджагын салдыра да чөйгә элә. Шул арада кухняда табак-савытлар шалтыратып йөргән Наташага әмер бирергә дә онытмый:

— Син анда, Наташа, колбаса белән бәрәңге кыздырырга онытма! Минем авылдаш бәрәңге ярата. Закускага тозлы кыяр бардыр, аны да тура!

«Һы, авылдаш бәрәңге ярата, имеш,— дип авызын кыйшайтып, үз алдына елмаеп куйды Кәрам.— Кайда күргән минем бәрәңге яратканны? Минем белән гомерендә бер утырып ашаса икән...»

Курамшин үз артындагы караватта нәрсәдер селкенүен тоеп, ыңгырашкан сыман аваз чыкканын ишетеп алды. Борылып караса, ятакта өстен ачып ташлаган нәни бала чалкан яткан килеш йоклый иде.

Фәнүзә, дәшмәскә кушып, имән бармагын иреннәренә аркылы куйды, аяк очларына гына басып бала янына килде. Беравык икәүләп балага тын гына карап тордылар.

Кәрам әле генә вахтер хатын әйткән сүзләрне исенә төшерде: «Ул кызның инде ат хәтле малае бар»...

— Синекеме?

— Я, кемгә охшаган соң?

— Мәснәвигә,— диде Курамшин туп-туры.

Чыннан да, үпкәләгән сыман турсаеп торган иреннәре белән Мәснәвине хәтерләтә иде сабый. Аның, хәтта, калкып торган «текә маңгаена» кадәр Мәснәвинеке.

— Ничә белән бара инде?

— Сентябрь азагында ике тула.

— Ах, гомерләр...

— Уза шул...

— Исеме ничек?

— Фәнил.

— Исемен үзеңнекенә якынлаштыргансың икән.

— Ничек булса да атасын онытыйм диюдән.

— Нигә онытырга? Бала атасын белергә тиеш.

— Кирәкми. Торсын Мәснәви хатыны белән тыныч кына.

— Хәзер эшендә дә күңеле юк инде Мәснәвинең. Йөри шунда иләсмиләс килеп.

— Ир түгел ул Мәснәви, җебегән арыш боламыгы, менә кем! Ни хатыны белән, ни минем белән очны очка ялгый алмады!

— Әкрен, баланы уятырсың,— дип кисәтте аны Кәрам.— Монда, Фәнүзә, гаеп миндә дә булды. Беләм, син җыелыштагы хәлләр өчен миңа ачуланасың. Я, әйт, мин нишли ала идем соң? Күреп тордым: Мәснәви хатынын яратмый. Белеп тордым: ул Сара белән бер вакытта да матур яши алмаячак. Шулай да, аның хатынын якларга, Мәснәвине, сине гаепләргә туры килде...— Курамшин, көрсенеп алды да, сүзләрен өзә-өзә булса да, дәвам итте: — Аңлыйсыңмы, шулай кирәк иде.

Фәнүзә йөзенә усаллык чыгарып көлде:

— Башкалар да хатыннары өстеннән йөрмәсеннәр дип инде, гыйбрәт өчен... Сугышып-талашып булса да яшәгез, яратышсагыз-яратышмасагыз да торыгыз, тик миңа гына тимәгез, минем авторитетка гына кагылмагыз, әйеме? Шулай бит?!

— Безнең бригада алдынгылар рәтендә иде шул. Эштә, тормышта үрнәк яшәргә, дип алган йөкләмәбез бар иде...

Фәнүзә нәрсәдер әйтергә дип авызын ачкан иде, исенә килеп, шул хәлендә туктап калды да көлә башлады.

— Ярый, Кәрам Ризванович, тәмсезләнеп утырмыйк әле, сез бит әле бүген минем кунагым!

— Мин дә һич ачуланышырга дип кермәгән идем. Синең Себердәге тормышыңны күрергә дип...

— Менә шулай яшәп ятабыз инде, Кәрам Ризванович,— дип Фәнүзә тирән сулап алды. — Минем сезгә бер генә үтенечем бар, Кәрам Ризванович...— Әйтергәме-юкмы дигән сыман, уйлап торды да.— Бер генә

үтенечем,— дип кабатлады.— Сез минем монда, Себердә яшәвемне һичкайчан, беркемгә дә белдермәсәгез иде.

— Ник инде алай, Фәнүзә?

Кәрам урыныннан кузгалды, ни өчендер, тәрәзәгә килеп карап торды.— Минемчә, бу һич дөрес түгел, Фәнүзә. Хәтта, җинаять! Анда, туган ягында, синең өчен ата-аналарың ут йотып ята, Мәснәви үз-үзен кая куярга белми йөри...

— Туганнарга минем кайда икәнем мәгълүм. Мин, алар борчылмасын дип, хәбәремне җибәрдем. Бары тик балам барын гына белмиләр. Мәснәви, гомумән, мине онытырга тиеш. Шулай кирәк.

Ул арада, «җәтмәсенә» коньяк, берничә балык консервасы, колбасалар, нииндидер яшелчәләр тутырып, Марина кайтып керде — сүз өзелде. Фәнүзә, аның кулыннан әйберләрен алып өскә күтәрде дә, ризасызлык белән:

— Өч кенә йолдызлысын алгансың икән. Тапмадың мени шунда әйбәтен?— диде. Бу сүздән Кәрамның авызы куырылып китте, гүя ул нииндидер зәһәр кислота капты. «Фәнүзәнең миннән уч алуыдыр инде,— дип уйлап куйды эченнән.— Баба шулпасы эчерә бит, каһәр...»

— Мин китим инде, Фәнүзә...

— Хәзер табын өлгерә, беркая да кузгалмыйсыз,— диде катгый итеп Фәнүзә. — Нәрсә сез, Кәрам Ризванович, аштан олы булдыгызмы? Әллә безне хөрмәт итмисезме?

Күп тә үтмәде, кызлар Курамшинны өстәл янына дәштеләр. Шунда Фәнүзәнең башына кинәт кенә: «Тукта, бу Курамшинны кызларымның берәрсе белән таныштырыйм әле, йөрмәсен үзен генә изгегә санап»,— дигән мәкерле фикер килде. Әйе, әйе, Марина белән кавыштырачак ул аны. Марина, чаткы бәбәк, аны үзенә карата да карата инде... Кирәк икән ташыңны эретер ул күз карашы белән.

— Кәрам Ризванович, менә монда, кызлар янына утыртыйм әле сезне,— дип Фәнүзә, Курамшинны җитәкләп килеп, Марина янына кысрыклады. Үзе һаман сөйләнә:— Син, Марина, минем якташны әйбәтләп сыйла!

Марина елтыр күзләре белән Кәрамга матур итеп карап алды.

— Тырышырбыз, кунагың рөхсәт итсә...

Курамшин, җавап урынына, алдындагы тәлинкәдән кыяр телеме алып чәйни. Ничек тә җитди булырга, хатын-кыз алдында йомшап китмәскә тырыша.

Өстәл кечкенә булса да, табын шактый бай, ямьле иде. Кыздырылган бәрәңге янында тәгәрмәчләп туралган яшел кыяры, суган, укроп сибеп әзерләнгән помидор салаты, хәтта телемләп кисеп сап-сары кавыны да бар.

— Суганы — Россиянең үзәгеннән, кыяры Урта Азиядән, кавыны — Әзербайҗан якларыннан,— дип санап китте Марина.— Алдыбызда бөтен ил винегреты! Ә үзебез! Беребез Украинадан, икенчебез Иваново шәһәреннән, өченчеләребез Татарстаннан! Могҗиза бит бу, кызлар, чын винегрет!

Фәнүзә касәләргә коньяк салды. Аларны һәркемнең алдына куеп чыкты.

— Ягез, нәрсә өчен эчәбез?— диде үз савытын күтәреп.

— Очрашу хөрмәтенә.

— Якташлар исәнлегенә.

— Танышу өчен!

Соңгысын хуплап Фәнүзә кул чапты:

— Дөрес әйттең, Марина! Нәкъ шулай, танышу өчен! Нәрсә ул якташлар очрашуы: бүген бар, иртәгә юк! Ә менә кавышу — мәңгелек!.. Бер кавышсаң, исәлеге мәңгегә кала...

— Әйдәгез, шуның өчен!— диделәр кызлар дәррәү килеп.

Фәнүзәнең тел төбен аңласа бер Курамшин гына аңлагандыр, ләкин тост әйтелгәч, күтәрми булдыра алмады.

Кызлар, өчесе өч яклап, Курамшинны кыстый башладылар.

— Моның нәрсә өчен эчәбез?— диде Марина, яшелле-зәңгәрле күзләрен мутландырып, Кәрамга сыена төште. Курамшин, аңардан читләшергә теләпме, торып басты.

— Моны мин Фәнүзәнең матур малае исәнлегенә күтәрәм!

— Дөрес әйттегез!

— Без дә кушылабыз!

Шуннан китте кечкенә Фәнилнең шуклыклары, наянлыклары, усаллыклары турында сөйләүләр, китте малай булып кыланып күрсәтүләр.

— Малай түгел, шайтан ул, тумас борын ук унынчыны бетергән!

— Күз генә тия күрмәсен, я зур артист, я очучы-космонавт булачак!— диеште кызлар.

Моннан шул мәгълүм иде; кызлар, малайдан бигрәк, аның әнисен яраталар, аны күбрәк хөрмәт итәләр. Бу — Кәрамны куандырды: «Күрәсең, яратырлыгы, хөрмәт итәрлеге бар Фәнүзәнең. Молодец, сер бирми икән якташ».

Тагын эчемлек күтәрергә чират җиткәч, моңа кадәр тыйнак кына утырган Наташа исемлесе дә урыныннан кузгалды.

— Туктагыз әле, дуслар, сабыр итегез! Танышлык өчен дә, танышлык өчен дип кычкырабыз, ә үзебез шушы вакытка кадәр Кәрам иптәшнең кем икәнен дә белми утырабыз. Нинди бөркет ул, ничек килеп чыккан ул чебен-черкиле якларга?

— Башыңа төшкәч киләсең инде,— дигән булды Кәрам, артык сүз куертырга теләмичә генә. Ул инде бу бүлмәдән ничек булса да чыгып китү җаен эзли иде. «Әйе, әйе, тизрәк китәргә кирәк биредән. Бүген барыбер Фәнүзә белән аңлашырга ирек бирмәсләр...»

— Кызкайларым, Кәрам Ризванович әле сездән тартына,— дип тезеп китте Фәнүзә. — Бераз ояла да булса кирәк. Ул ачылыр, сөйләр әле. Мин шуны гына әйтә алам. Кәрам Ризванович безнең авылның гына түгел, бөтен тирә-якның күрке, данлы кешесе. Атаклы нефть остасы, инженер — менә кем ул! Себергә тикмәгә генә җибәргәннәр дисезмени аны!

«Якыннан белгән кеше кебек сөйләп утыра бит, вәт син!»— дип гаҗәпләнде Курамшин.

Марина Кәрамга табан һаман саен якынлаша, сыена барды һәм инде, берничек борылырга да урын калдырмыйча, аны үзенең юан, кабартылган туп кебек тыгыз янбашлары белән почмакка ук китереп кысты. Ни эшләргә дә чама юк иде инде Курамшинга.

— Ярый-ярый, атаклы да, оста да, галим кеше дә булсын ди сезнең Кәрам Ризвановичыгыз...— Үзенең очкынлы күзләрен ялтыратып, Марина сөйли:— Ышанам, барысына да ышанам, дуслар. Ә менә ул хатын-кызлар ягына ничегрәк соң? Рыцарьмы...

Кызлар гөж килеп көлештеләр. Фәнүзә, авылдашын яклаган булып, монда да дилбегәне үз кулына алды:

— Син, Марина, авызыңны чамалап ач! Безнең Кәрам Ризванович хатын-кыз алдында югалып кала торганнардан түгел! Ул өйләнгәндә дә, беләсегез килсә, авылда бер дигән унҗиде яшьлек кызны каптырды. Үзеннән ун яшькә кечене.

— Я инде, Фәнүзә...

Курамшин үзен чын-чыннан тозакка эләккән итеп сизде һәм бу тозактан ничек итеп ычкынырга белми баш ватып утырды. Сәгатенә карады да:

— Миңа, Фәнүзә, кайтырга кирәк иде бит,— диде ялварулы тавыш белән.

— Курыкма, курыкма, Кәрам Ризванович, Хәтимәгә әйтмәм, һәм иптәшләр судына тикшерүгә дә куйдырмам...
Марина да үпкәләде.
— Әйттем бит, рыцарь түгел, дип...
Бу сүзләр Курамшинның мин-минлегенә кагылды. Аның инде, үзе дә сизмәстән, иягендәге чокыры тартыша башлаган иде.
— Ярый, сезнең исәнлеккә!— дип алдындагы эчемлекне авызына каплады.
— Во, браво!
— Менә булдырды!
— Егетлеген күрсәтте!— диештеләр кызлар бертавыштан.
Марина, хәтта, Курамшинның ияк чокырын да «пәп» итеп үбеп алды:
— Рыцарь булырга ярыйсың икән!
Өч хатын-кыз өчесе өч яклап Кәрамга чәнечке белән кыяр, кавын телеме, ипи кисәге, тагын әллә нәрсәләр суздылар, аны кыстый-кыстый, кабарга, чәйнәргә, йотарга мәҗбүр иттеләр.
Хәмер Кәрамның тәмам башына китте. Әле генә бар нәрсәгә дә битараф булып утырган кешебез инде кызларга туры итеп, елмаеп карый башлады. Йөзенә, хәмер кызыллыгы белән бергә, шәфкать, мәрхәмәт галәмәтләре чыкты.
Боларны күреп торган кызлар сөенделәр, кунакка карата тагын да игътибарлырак, ягымлырак булырга тырыштылар.
Марина исә янында утырган ирнең житәрлек кадәр хисе дә, мәхәббәте дә бар икәненә ышанды. Ул инде үзенең сыгылмалы симез беләкләрен Кәрамның иңбашына салырга да өлгергән иде.
Хәзер инде Курамшин чыгымчыламый, табындагыларның күңелен күрү өчен булса да карышмаска, буйсынырга тырыша. «Кагылмас кыз сыман кәнфитләнеп утыру килешмәс,— дип юата үзен.— Әйдә, бер көнгә генә укам коелмас әле...»
Кызларны да алай әдәпсез дип әйтергә урын юк иде. Үзләрен итәгатьле итеп тоталар, культуралы гына сөйләшәләр. Житмәсә, барысы да сайлап куйган кебек чибәрләр!
Курамшинның күз аллары яктыра төшкәндәй булды. Табындагы кызларның да йөзләре ачылды, нурга күмелде. Кәрам, башын күтәрә төшеп, янындагы Маринага карап куйды. Чыннан да чибәр, чукынчык! Аның тулы гәүдәсенә күрә түгәрәк битләре дә, ап-ак муены да, текә күтәрелеп киткән күкрәкләре дә килешле. Артык та түгел, ким дә. Ә инде күзләре! Маринаның күзләре аерым сурәтләүгә мохтаж. Алар, башка адәми затлардагы кебек, күрер өчен генә яратылмаганнар булса кирәк. Бу күзләр һичкем булдыра алмастай матур итеп карый да алыр, сине иркәли дә, шелтәли дә, чакыра да, куа да алыр...
— Курамшин! Кәрам Ризванович!
Фәнүзә эндәшә икән. Яңадан да эчемлек бүлеп салган, табындагыларны тагын авыз итәргә кыстый.
— Әй, алай түгел! — Курамшин алдындагы савытны этеп куйды. — Кызлар-йолдызлар,— дип башлап китте сүзен,— сез барыгыз да өстән-өстән генә булса да минем белән таныштыгыз, белдегез, күрдегез, ә мин сезнең белән — юк. Тәртип түгел бу!
— Дөрес!— дип хуплаган булды Фәнүзә.— Безнең Курамшин тәртип ярата. Ул инде танышса, бүгенге өчен генә түгел, ә озын-озакка дип таныша!
— Димәк, сиңа биография кирәк? Учет карточкасы тутырырга? — Марина йөзенә, күзенә үпкәләү галәмәтләре чыгарды.— Рәхим ит, иптәш Кәрам: мин Украина кызы. Ничә яшь дисезме? Күпме икәнен хатын-кызлардан сорамыйлар. Жиде класс белемле. Котельныйда «инженер-кочегар» булып эшлим. Хезмәт хакым — ике йөзнең өстендә. Ирем-

не ташладым, бала-чагам юк, егетем дә әлегә юк. Синнән башка, әлбәттә. Шул әйтелгәннәр җитәме? Син ризамы?

— Риза, иптәш инженер-кочегар.

— Ә син?— дип Наташага мөрәҗәгать итте Кәрам.— Күрәм, Наташа да бу якларда туып үсмәгән.

— Мин — Иваново шәһәреннән. «Хатыннар патшалыгы» диләр безнең каланы, Кәрам Ризванович. Турысын әйткәндә, Себергә егетләр эзләп килдем... Әнә бит Фәнүзә егетеннән качып, Марина дигән юләр ирен ташлап килгән. Кадерен белмиләр алар ир-атның, бәясен белмиләр шыр тилеләр! Ә мин менә, киресенчә, шушы урманлы ояга егетләр эзләп килдем. Көлмәгез, көлке түгел бу. Беләсегез килсә — трагедия! Шулай, шулай. Аны үз башына төшкән безнең кебек карт кызлар гына белә...

— Ә нигә, анда егетләр беткән иде мени?— дип сорау бирә Курамшин көләргә дә, көлмәскә дә белмичә.

— Һе, егетләр! Тот капчыгыңны! Кайдан килсен ул Ивановога егетләр? Шәһәрнең туксан проценты хатын-кыз!..

— Егетләр таптыңмы соң?— дип кызыксынды тагын Кәрам.

— Себердә кая гына барып төртелсәң дә — егетләр! Бәя ун мәртәбә күтәрелде. Егете түгел, кешесе булсын миңа, тормыш итәрдәй кешесе...

Аны Марина туктатты:

— Ташла әле шул тормыш турындагы фәлсәфәләреңне! Таптың сөйләр нәрсә, ир дә ир имеш! Күрмәгәннең күрәсе килә, күргәннең качасы килә.

— Әйе шул, бик тирәнгә кереп киттек бугай,— диде Фәнүзә, табындагыларга ашамлыклар куя-куя.— Марина дөрес әйтә. Мәхәббәт, сөю турында гына сөйләшергә кирәк бүген.

Фәнүзә үзенең мәкерле планнарын онытмый иде. Әйе, Курамшин гына бер гөнаһсыз, фәрештә булып утырмасын әле. Сынаганы бар инде ир-атны Фәнүзәнең. Алар хатыннары алдында гына әүлия булып кыланалар. Әнә, күр хәзер, Хәтимәсенә тугрылыклы Кәрам Ризвановичны: ничек мөкиббән китеп Маринаның чәчләрен сыйпап утыра...

«Шулай, Кәрам Ризванович,— дип эченнән тантана итә Фәнүзә.— Дөнья куласа, әйләнә дә бер баса»... Теге чакларда, Фәнүзә белән Мәснәви өстенә авырлык килгәндә, сиңа ансат иде. Хәтта бөтен җыелыш алдында кычкыруы да сиңа бернәрсә тормады. Чөнки син анда мулла идең. Әйе, әйе, мулла! Элек муллалар да бит, «Гөнаһ кылмагыз, шәригатьне бозмагыз»,— дип халыкка үгет-нәсихәт укыганнар да, үзләре өч-дүрт хатын белән торганнар, хыянәт белән яшәгәннәр.

Украина чибәре Маринаның матурлыгына сокланып, мөкиббән китеп, аны иркәләп утырса да, Кәрамның баш миендәге теге, медик-галимнәр әйткән контроль лампочкалары бөтенләй үк сүнмәгән, гоныккына булса да яна иде әле. Яна һәм сигнал бирә: «Тукта, Кәрам Ризванович, ди, саташма, нәфесеңә баш була бел»,— ди. Шунда ук бу сигналлар менә бу бик үткер, астан уя торган якташы Фәнүзәдән дә сак булырга куша — иртәгә үк тирә-якка яманатыңны таратыр...

Әгәр дә Фәнүзәнең улы кечкенә Фәнил уянмаса һәм сөт сорап, күзләрен уа-уа кухняга кермәсә, Курамшин белән Марина арасынданиләр булып бетәр иде икән?

Малай керде һәм мондагыларның барысын да дәррәү аякка бастырды.

— Һөт кирәк, әни! Һөт асыйсым килә!— дип тәкатьсезләнде ул.

— Хәзер, хәзер! Сиңа һөд-һөдне дә тотып бирәм, улым, тик тавышланма гына!— дип көлде әнисе.

Малай өстәлдәге кавыннарны күреп алды.

— Һөт кирәкми миңа, әнә теге тупны бир, сары тупны! — дип биергә тотынды. Кавынны беренче күрүе иде ахры.

Өч хатын-кыз, өчесе өч яклап малайны көйләргә, юатырга керештеләр: аңа теләсә нәрсә бирергә, теләсә нинди соравын үтәргә әзер иделәр — тик ул гына еламасын, ул гына тыныч булсын.

Кәрам чекрәеп, нәрсәдер табарга тырышып малайга карап торды. Бригадада, уенын-чынын бергә кушып, һәрвакыт ирештерәләр, үртиләр иде Мәснәвине: «Син, брат, хатыныңнан юкка бала даулыйсың. Синең үзеңнән булмый ул. Мондый корыган тал чыбыгыннан нинди бала көтмәк кирәк?» Һәм башкалар, һәм башкалар... Менә, уллы булган ич Мәснәви!

— Их, улы барын белсә, күрсә, Мәснәви ни эшләр иде икән!— дип, сокланып куйды.— Очып килер иде ул синең янга, Фәнүзә, атылып килер иде!

— Зинһар, кирәкмәс...

— Әйе син, Кәрам Ризванович, инженер, зур кеше икәнсең, Фәнүзәгә ярдәм ит,— дип бик житди сүз башлап жибәрде Наташа.— Күрмисеңмени, нинди шартларда яши синең хөрмәтле якташың? Бала белән торакта ничә ел бер караватта интегеп йоклый бит бичара. Ә безгә? Аның белән бергә, бер бүлмәдә торучыларга төн буе бала елаган тавышны тыңлап яту рәхәт дисеңме? Эштән соңга калган көннәре була. Баланы ясленнән кем алып кайта? Һаман да без! Зарланмыйбыз инде, түзәбез. Үзебез дә хатын-кыз бит, бер язмыш кешеләре, үзебезгә дә шундый кыенлык килүе бар... Син, зур кеше, Курамшин, инженер, ярдәм ит Фәнүзәгә квартир алуда. Синең сүзне тыңларлар алар, каршы килмәсләр.

— Мин моны истә тотармын.

— Юк, истә генә тотма, алып бир син аңа квартирны,— дип һаман бәйләнде Наташа.— Квартир артыннан күпме йөри бит инде мескенем, күпме иза чигә... Аңа бит зур кирәкми. Бер бүлмә булса житә. Ваннасызы да ярый, баш өстендә түбә кирәк, кыскасы.

— Әйе, эш түгел бу,— дип раслады аның сүзен Кәрам.— Обязательно мин бу хакта сөйләшермен. Юк, болай яшәү мөмкин түгел!..

Иркәләнеп, песи кебек Кәрамның куенына ук сыенып утырган чибәр Марина да сүзгә кушылган булды!

— Раз Кәрам Ризванович әйткән икән, эшли дә эшли инде ул аны!— Чын егет, рыцарь икән — сүзендә торырга тиеш ул.— Аннан, күзләрен майландырып, Кәрамга карады.— Дөрес әйтәм бит мин, шулай бит Карамушка?

— Кулдан килгәнчә тырышып карармын.

— Ә син, рыцарь булсаң, конкретрак итеп әйт!

— Әйе, сүземдә торачакмын!

— Менә молодец! Менә ичмасам, настоящий рыцарь дисәң дә урынында!— дип Марина Курамшинның битеннән чәбәкләде.— Ә хәзер — әйдә танцыга!

— Танцыга?

Фәнүзә Курамшинның икеләнеп торуын күреп, әйтте:

— Барыгыз, бар, Кәрам Ризванович. Танцы мәйданы моннан ерак түгел, паркта гына. Якташ икәнсең, сынатма инде!

Кич булган, кайтырга вакыт житкән иде. Кәрам Ризвановичка чыгып китү, очраклы гына эләккән әсирлектән котылу өчен моннан да уңайлы сәбәп юк иде. Мариннаның тәкъдименә шатланып риза булды. «Барган булыйк әле танцы дигәненә, аннан күз күрер»,—дип уйлады ул.

## II

Иртән күзен ачкач, бик озак тора алмый ятты Курамшин. Кичә хәмерне артыграк җибәреп, башы авыртудан түгел. Ул, кайбер кешеләр кебек, махмыр дигән нәрсәне белми. Аның чире һәрвакыттагыча, вөҗдан газабы — артык сөйләгән сүзләренә, кылган эшләренә үкенү. Чак кына эчемлек капса, гел шулай инде аның: егетләнә, батырая, үтәп булмас вәгъдәләр биреп ташлый...

Кәрам яктырганнан-яктыра барган тәрәзәгә караган килеш, кичәге көннең һәр минутын диярлек барлап, аңа нәтиҗәләр ясап, үзенчә бәя биреп ятты. Бик нык исереп китмәгән, барысы да хәтердә, тик менә яше кырыкка җиткән кеше, хатынлы ир өчен һич тә килешми торган эшләр эшләп ташланган...

Ярый, Фәнүзә бүлмәсендә, инде хатын-кызлар компаниясенә килеп эләккән икән, алар белән утырсын да ди. Үзеңне зурга куеп, якташыңны санга санамыйча табынны ташлап чыгып китү килешми. Анысы әдәп, культура дигән нәрсәгә керә. Кызлар янына утырып, аларны сыйлап-сыйланып утыру да гади бер тәрбия билгесе. Ә менә янында чекрәеп утырган ике хатын-кыз, бигрәк тә сине сынап утырган Фәнүзә алдында, Марина белән кочаклашу бернинди әхлак кагыйдәләренә дә сыймый.

Аннан, рәхмәтләрен әйтеп, кызлар белән матур гына саубуллашып үз бүлмәсенә кайтып китәсе урынга, нигә дип инде Марина белән танцыга барырга булган? Танцыга гына булса бер хәл, ресторанга да чакырды бит Маринаны. Үзенең егетлеген күрсәтәсе килеп, ул, Украина кызына кыйммәтле коньяк, кызыл балык, аю итләре китертте. Кемнән китертте бит әле: Пичуговның яңа хатыны Зоядан!.. Җитмәсә: «Менә минем Себер кошчыгым,— дип таныштырды,— чибәр түгел дип карагыз инде моны!» — дип мактанып та җибәрде.

— Тфу, җилкуар! — дип төкерде Кәрам. Оятыннан кичәге эшләре өчен бүген кызарып, уттай янып ята иде ул.

Ресторанда Курамшин тагын нинди хикмәтләр чыгарды соң әле? Әйе, ул Марина белән өч-дүрт тапкыр танцевать итеп алды. Күптән биегәне булмагангамы, Кәрамның бүген дә аяклары, җилкәләре авыртып ята.

Хатын-кызлар белән кичәләрдә бию анысы гаеп эшләрдән саналмый. Культуралы кеше андый чакта күзле бөкән булып утырмаска тиеш. Тик менә биегәндә чут-чут үбешү җәмәгать урыннарында һич кенә дә килешми инде. Кәрам үзе авыз күтәреп үпмәде үбүгә, әмма Маринаның тыелгысыз иреннәренә ирек бирде, карыша алмады...

— Уф, инде хәзер Пичугов хатынына, Кузьманың үзенә ничек күренергә, алар алдында нәрсә дип акланырга?

Ярар: «үпкән-кочкан җилгә очкан» дигәннәр, ә менә салметдин баштан биргән вәгъдәләре белән нишләргә? Кичә күпме буш вәгъдәләр биреп ташланган бит, каһәр: Марина белән көн саен очрашып-күрешеп торырга, бергә танцыларга, кино-театрларга йөрергә... Аннан, Фәнүзәгә квартира алуда ярдәм итәргә...

Эшкә барырга вакыт җитеп килә иде — Курамшин, сикереп торып, киенә башлады.

— Шулай, шулай, иптәш Курамшин,— дип танау астыннан үз-үзен битәрләп сөйләнә иде ул.— Эшне башлап җибәрә алмасаң да гулять итүне көйләп җибәрдең син!..

## I

Черек күлдән кайтып керүгә Курамшин аптырап калды. Бүлмәдәге тимер караватлар, иске өстәл һәм тумбочкалар алынган, алар урынына ялтырап торган агач караватт, аның ике ягына ике яңа тумбочка куелган иде. Тәбәнәк журнал өстәле янында йомшак креслолар. Ватык ишекле шифоньер да көзгеле кием шкафы белән алыштырылган. Идәнгә бизәкле келәм җәелгән, тәрәзәләрдә — калын пәрдәләр, чәчәкле юка челтәрләр. Кыйммәтле җәймәләр белән капланган урын-җир өстендә күперенке ап-ак ике мендәр тора. Стеналарда картиналар.

— Әллә ялгыш килеп кердемме?— дип чыгарга да уйлаган иде, өстәл өстендә үзенең китапларын, сызым кәгазьләрен күргәч туктады.— Бу ни булды әле? Әллә безне бүтән җиргә күчергәннәрме?

Тиз генә дежурный хатынны эзләп китте.

— Нишләттегез минем бүлмәне? Кайда башкалар?

Дежурный да, башка көннәрдәге кебек өч сорауга бер генә җавап бирми, Кәрам алдында өтәләнеп тора:

— Курамшин бит әле сез? Ялгыш әйтмәдемме? Сезнең өчен җиһазладылар бүлмәне. Кузьма Николаевич лично үзе кушты, үзе килеп тикшерде. Барыгыз, рәхим итеп, урнашыгыз.

— Кем сораган әле аңардан?..

Курамшин тиз генә юынып алды да, Кузьма янына барырга җыенды. «Бу нәрсә дигән сүз? Башкалар ни әйтер?» «Башкалар» дигәне, үзе белән бер бүлмәдә яшәгән иптәшләре иде Курамшинның. Алар да Кәрам кебек үк инженерлар, төрлесе төрле яктан командировкага килгән кешеләр иде. «Күзләренә ничек күренермен? Мин аксөяк, аерым зат, шуңа люкска күчерделәр диярменме?»

Кузьма Пичугов янына баруның тагын бер сәбәбе бар иде: Фәнүзә мәсьәләсе. Вәгъдә биргәч, сөйләшеп карарга кирәк Пичугов белән. Бик тә уңайсыз, авыр хәлдә яши бит Фәнүзә...

Чыгып китәргә генә торганда, тәрәзә чирткән тавыш ишетеп, туктап калды Курамшин. Икенче этаж, ә тәрәзә шык та шык килә! Барып караса, аста Марина! Шул албасты кызы үзе, башын югары күтәргән дә авыз ерып, тәрәзәгә вак таш атып тора!

— Каршы алырга чык, Карамушка, мине дежурный кертми!

— Бар икән күрәселәр!..

Кәрам коридорда утыручы дежур хатын янына барганда Марина шунда тора иде инде.

— Сезнең янга мени?— дип сорады дежур хатын.— Гафу итегез, белмәдем.— Һәм Маринаны, күзе белән баштанаяк капшап, үткәреп җибәрде.

Керү белән Марина, бүлмәгә сокланып, ишек төбендә туктап калды. Аның күкле-яшелле күзләре зур ачылып, мизгел эчендә биредәге бар нәрсәне күреп тә өлгерде.

— О-о, Карамушка ничек бай яшисез! Күренә, бу безнең торак түгел инде... Үзең генәме?

— Әйе бугай.

— Шәп! Димәк, күңелле яшәү өчен безнең инженерга бөтен шартлар тудырылган?

— Күңелле яшәү өчен түгел, эшләү өчен,—дип төзәтте аны Курамшин.

Марина биек үкчәле туфлиләрен ишек төбендә салып, аяк табаны белән идәндәге келәмне капшый-капшый түргә узды, көзге алдына килеп бөргәланып алды.

— Син мине утырырга кыстар идең.

— Рәхим ит.
— Нигәдер кәефең юк ахры?
— Ашыгам, Марина, барасы җирем бар.
— Ну, ну, Карамушка, кунак килгәч чыгып китмиләр... Ресторанга үзең чакырдың бит. Әллә хәтерләмисеңме?— Марина, урыныннан торып, балериналарча бөтерелеп алды.— Әллә сиңа бу күлмәгем ошамыймы? Әллә прическаларым килешмиме? Я, әйт...
— Барысы да әйбәт, тик мин бик ашыгам, барасы җирем бар.
— Танцыга да чыкмыйбызмы? Син бит анысына да сүз бирдең...
Курамшин, Маринадан тиз генә котылып булмасын сизеп, ялганлау юлына басты:
— Алайса, Марина, син анда бара тор, әйеме. Мин бер ярты сәгатьтән килеп җитәрмен.
— Рыцарь сүземе бу?
— Әлбәттә!— диде дә эченнән: «юләр, рыцарьларның ниндие булмый. Әллә алар бер дә алдый белмәгәннәрме?»— дип көлеп куйды.
Шулай да чыкканда Марина, муеныннан кочып, Курамшинның ияк очындагы чокырын үбәргә өлгерде.
Көйләп-җайлап Маринаны паркка таба озатып җибәргәч, Курамшин урам чатында аптырап басып торды.
— Кузьманың кайсы квартирасына барырга соң? Аны ничек эзләп табарга?
Пичуговның тормышына һаман төшенеп җитә алмый иде әле Кәрам. Сәер, буталчык нәрсә, Зоя белән тора, Танясын уйлый. Күп көннәрне Зоя янына да бармый, үзенең буш квартирасында кунып ята икән.
Хәер, Пичугов үзе дә тормышы турында кайгыртырга яратмый. Очрашкан араларда Кәрам аның кылларын тартып караган иде инде — сөйләшергә дә теләми ул хакта. Телендә, әлеге дә баягы булачак зур шәһәр, аның перспективалары һәм планнары, нефтьчеләрнең тормыш-көнкүрешен яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар һәм башка шуның кебекләр генә. Бер тапкыр, Черек күлгә китешли, Кузьма Николаевичның эш бүлмәсенә кереп чыккан иде Кәрам, анда да ишекле-түрле йөренә-йөренә: «Ресторанга менә дигән җырчы китерттем. Саф меццо-сопрано тавыш! Ей-богу менә! Хәзер ресторан концерт залы мени! Кирәк андыйлар Кәрам туган, безнең шәһәр өчен бик кирәк!»— дип, үзенең җилбәзәклеге белән Курамшинны гаҗәпләндергән иде. Икенче тапкыр күргәндә: «Черек күл мәйданына көнкүреш комбинатын җибәртәм. Парикмахерларны, итек төпләүчеләрне, тегүчеләрне куам. Ятмасыннар шәһәрдә пыскып, нефтьчеләргә хезмәт итсеннәр!»— дип сөйләнде.
Кулына китап тоткан хәлдә ишек ачты Кузьма.
— Әйдә дустым, әйдә, рәхим ит.— Китабын култык астына кыстырып, ике куллап күреште.— Түргә уз! Колагыңны борасым бар, бу арада күренмисең. Узган ялда да килмәдең! Нәрсә, эш күбәеп киттеме?
— Әллә нәрсә майтарган юк әле...
— Күңелеңне генә киң тот, дустым, Себердә эш җитәрлек.
Кәрам Кузьманың кара янып, күбеп чыккан маңгаена күрешкәндә үк игътибар иткән иде, сорамыйча түзмәде:
— Ни булды башыңа, Кузьма?
Пичугов тотлыгып калды:
— П-п... пүчтәк!— дип маңгаен сыпырып алды.— К-к... караңгыда ялгыш шифоньерга килеп орындым. Ничего, т-т... туйга кадәр төзәлер.
Кузьма елмайган булды, ләкин бу елмаю елауга охшаганрак иде.
— Синең кебек солидный начальник кешегә шишка белән йөрү килешеп бетми бетүен, нишлисең инде... Шулай да, ул «шифоньер» тирәсеннән ераграк йөрергә тырыш әле...
Кузьма Николаевич шаркылдап көлде. Кәрамның үзенә төрттерергә дә җае чыкты бугай:

— Анда, командировкага килгән изге Курамшин галиҗанәпләре тирәсендә дә тутый кошлар биеп йөри диләр, дөрес булса...

Ресторандагы кичә турында Зояның Кузьмага сөйлисенә шик тотмаган иде ул.

— Булды андый гаебем.

— Юкка, брат, юкка андый юлга басасың.

— «Ертык тишектән көлә», дигәннәр...

— Мәнә шуңа кисәтеп куям да. Үз тәҗрибәмнән чыгып әйтәм: сак бул, дустым, ул хатын-кыздан! У-у, хатын-кызмы! Ул зат фәрештәңне юлдан яздыра!

— Маңгаеңа да алар бәрдеме?

— Әйе, Зоя печате. Өченче көн, йоклаганда саташып, «Таня» дип кочаклап алганмын икән үзен...

Курамшин, диванга авып, бөгелә-бөгелә көләргә керешге:

— Нык тамызган! Ой, Кузьма! Кызганам мин сине, билләһи кызганам!..

— Шуннан бирле барганым да юк янына. Чукыңып бетсен!.. Мәнә рәхәтләнеп үз квартирамда китап укып ята идем әле.

— Яхшы китапмы? Күз алдыңа китер, Кузя, командировкага килгәннән бирле кулга китап тоткан юк! Вакыт та тими, кәеф тә начар.

Пичугов, шактый иске китапны байрак сыман югары күтәреп, Курамшин янына килеп утырды.

— О, о, беләсеңме нинди яхшы китап бу! Китап түгел, ә хәзинә! «Язмалар» дип атала. Авторы кем диген: Николай Васильевич Басаргин!

— Ишеткәнем юк.

— Ишеткәнең юк?!— Кузьма, дулкынлануыннанмы, ачуы килепме, тагын тотлыга башлады.— Д-д... декабрист Б-б... Басаргинны б-б.... белмисең?

— Чын мәнә, белмим.

— К-к... күпне югалткансың! Бу китап Себер турында, төшенәсеңме?

Курамшин кызыксынып үрелгән иде, Кузьма кулындагы китабын өскә күтәрде.

— Мин бу китапны, дустым, ничә еллар эзләдем!.. Ниһаять, бүген базардан, иске китаплар сатучы бер карттан алдым. Ниндидер надан бабай. Бер сум сорый бит, аңлыйсыңмы, бары бер сум! Ә мин аңа ун сум сузам. Алмый. Мәнә юләр түгел диген инде. Йөз сум сораса да бирә идем. Моннан йөз ел элек чыккан китап бит бу, Басаргин үзе үлгәннән соң күп вакытлар үткәч, 1872 елны басылган!

Тышлыгы тузып, катыргысы кубып беткән китапны әле баш очында, әле Кәрамның борын төбенә китереп селки-селки сайрады бу сүзләрне Пичугов. Ахырда тынып, фал китабын ачкандай, аерым бер игътибар, саклык белән генә ачты китапны. Күзенә беренче бәрелгән юлларын укып китте:

«...Әгәр кешеләр һәм хөкүмәт мондагы табигый байлыкларны файдалана белсә, Себерне гүзәл киләчәк көтә».

— Мәнә бит, Кәрам туган, нинди баш булган кешедә! Себернең киләчәген сөргендә, каторгада яшәп тә йөз илле ел алдан күргән!

— Яхшы,— диде Курамшин артык исе китми генә.

Пичугов тиз-тиз генә тагын берничә битне актарып алды.

— Молодец кеше булган ул Басаргин. Себердә югары уку йорты ачу идеясен дә беренчеләрдән булып ул күтәрә. Биредә, нинди дә булса зур шәһәрләрнең берсендә ачылган мәктәп бу якларга нифрат зур файда китерер иде, ди. Тирән демократик идеяләр болар, дустым! Илнең чын патриотлары булганнар алар декабристлар, Себер хуҗалыгын үстерү буенча заман таләпләре белән атлаганнар. Мәнә, син тыңла әле, нәрсә

ди Басаргин: «Шик тә юк, монда табигый байлыклар бар чагында, җитәрлек капитал һәм мәгълүматлы кешеләр булганда, тиздән бөтен Себер хисапсыз күп промышленность предприятиеләре белән капланыр иде». Шәп әйткән бит?

— Әйе, нәкъ бүгенгечә әйткән.— Курамшин китапны үз кулына алды, саргаеп, таушалып беткән бер-ике битен ачып үзалдына гына укыды да:

— Кара син аны!— дип баш чайкап куйды.— Әле бүген дә үтә авырткан урыннарга кагылган бит.

Кузьма Николаевич, үзенең табышына сөенеп, ишекле-түрле йөри һәм китап белән мавыгып киткән Курамшинга астан гына күз төшереп ала. Ул хәзер дәрес бирүче укытучыга охшап киткән иде.

— Әйе, Басаргин Себернең капиталистик үсеше өчен нәрсәләр мөһим, нинди шартлар кирәк икәнен яхшы аңлаган. Тик боларны ничек тормышка ашырырга мөмкин икәнен генә төшенмәгән. Либераль позицияләрдә торган декабрист Басаргин тигезсезлекне, хаксызлыкны мәгърифәтчелек, гуманистик юллар белән төзәтмәкче була, хөкүмәткә акыл сату, үгет-нәсихәт белән тәэсир итәргә тырыша. Тот капчыгыңны!..

— Син моны миңа укып торырга бирерсең бит?

— Алырсың. Менә шулай, дустым... Себер элек-электән теш үтмәс җир булып килгән һәм әле бүген дә без аны тулысынча аңлап бетерә алганыбыз юк бугай.

— Син, Себер кешесе дә аңламагач, кем аңлар соң,— дип шаяртып, Курамшин китапны Кузьмага сузды. Себер турында зур проблемалар күтәреп бәхәсләшәсе килеп кермәгән иде шул әле Кәрам, бераз кечкенәрәк, җанга якынрак, йөрәкне бүген тырнап торган нәрсәләр хакында сөйләргә килгән иде.

Ләкин ерак тарих, иске китаплар белән җенләнгән Пичугов һаман үзенекен сукалады:

— Уйланып йөри торгач, мин үзем өчен бик кызыклы ачыш ясадым бит әле,— дип башлап китте ул яңа фикерен.— Күреп торасың, бүгенге Себер — Басаргин Себере түгел. Хәзер биредә техника — буа буарлык. Хәзер бөтен мөмкинлекләр бар, шулай да Себергә нәрсәдер җитми әле. Нәрсәдер юк, сизәсеңме, Кәрам?

— Кешеләр, кадрлар җитми димәкче буласың инде.

— Түгел!— диде Пичугов кычкыра төшебрәк.— Түгел! Белмәдең! Кешеләрне Себергә теләсә күпме җыярга була. Беләсең килсә, кешене китерү түгел, аларны калдыру проблема! Ни өчен китәләр? Ямь җитми Себергә, матурлык, бизәк җитми! Менә кешеләр нәрсәдән канәгать түгел.

Пичугов сөйләгәннәргә Курамшинның ачуы кабара башлаган иде:

— Бу бәладән котылу өчен син нәрсәләр тәкъдим итәсең, ягъни?..

— Тәкъдим итү түгел, ә шәһәрне төзекләндерү, бизәү, культуралы итү өчен көрәшергә кирәк. Мәсәлән, урамнарга агачлар, чәчәкләр утыртырга, бакчалар, парклар булдырырга, стадион, футбол, хоккей мәйданнары төзергә, су керә торган бассейннар ясарга, концерт заллары, никах йортлары, модалар ательесы өчен биналар салырга кирәк безгә.— Тәмле хыялларын шул урында кинәт өзеп дәвам итте.— Модалар ательесы димәктән, бүген мин тегү мастерское белән сөйләшкән идем. Клубта яңа модалар күрсәтүне оештырмакчы булабыз. Тик тоткарлык шунда: костюм кидереп сәхнәдә күрсәтергә ир-ат табып булмый. Нигәдер, оялалар. Сездә, нефтьчеләр арасында, баһадир гәүдәле чибәррәк егетләр юкмы? Мәһабәтрәк кеше кирәк...

Курамшин бөтенләй өнсез калды. Ачуланышып китүдән үзен тыеп булса да:

— Сине, Кузьма Николаевич, җирдән аерылган дип әйтимме, әллә вакланып киткәнсеңме,— төшенмим әле мин,— диде.— Кешеләргә

торыр, йоклар урын юк, эшкә йөрергә юл юк, машина житми... Черек күлдә һаман нефтьне тиешенчә кузгатып булмый, ә син «мода» дип ачу китереп утырасың.

Кәефе бозылып, Кәрам урыныннан торды. Пичугов аның җилкәсеннән тотты:

— Син алай димә, дустым. Кирәк мондый нәрсәләр, кирәк! Кеше нефть белән генә яшәми!..

— Нефть белән генә яшәми шул менә... Әнә, анда Фәнүзә исемле хатын баласы белән тулай торакта яшәп ята. Бер бүлмәдә өчәү, дүртенчегә шул бала.

— Ризатдинованы әйтәсеңме? Беләм мин аны.

— Белгәч? Әллә нинди модалар кайгыртып йөргәнче, башта син аңа квартира юллар идең.

— Ах, дустым Кәрам! Квартирага мохтаҗ кешеләрнең исемлеген күрсәтимме? Күп алар, бик күп бездә — йөзләгән!

— Фәнүзә кебекләре юк анда, мөмкин дә түгел!

— Андыйлар да буа буарлык! Аннан да мохтаҗраклары дөнья! Күрә торгансыңдыр: күпләр вагоннарда, иске баракларда яшәп ята. Берәүләрнең, хәтта, бүген баш очына түбә саламы да юк!..

— Анысын арттырасың...

— Арттырмыйм. Мәсәлән, үзебезнең Ишәй абзыйны гына алыйк, Черек күлдә каравылчы булып эшли торган Ишбулдинны. Гомер буе аучы йортында яшәгән. Үзе разведчиклар белән киткәч, урманны киськәннәр, өен җимергәннәр, юл сала башлаганнар. Бүген, әнә күрәсең, сукбай кебек вагонда, тимер мич янында йоклап ята. Ул бит Бөек Ватан сугышы ветераны, заманында данлыклы аучы, ударник булган кеше...

Пичугов, үзенең разведкада эшләгән елларынмы, Татьянасы белән булган чакларынмы исенә төшереп, моңсуланып калды да:

— Ишәй абзыйны геологларга юл күрсәтергә дип мин алып киткән идем,— дип дәвам итте аннары.— Мин аңа зур бурычлы. Әйбәт, эшчән карт ул. Әле, әнә, сандыгы да миндә ята. Әнә мылтыгы эленеп тора... Кая куйсын ул аларны? Үзенә бер бүлмәле булса да квартира алып бирергә күптән тырышып йөрим...

Кәрам каршыга да, уңайга да ләм-мим дәшмәде, торып китте дә стенада эленгән сары каешлы мылтык янына килеп басты.

Бу калын көпшәле оптик прицеллы мылтык гадәти ау мылтыкларыннан аерылып тора иде.

— Бу бит винтовка,— диде Курамшин, коралның сызылып, киртләнеп беткән түтәсен капшый-капшый.

— Үзенең әйтүенә караганда, Ишбулдин, имеш, сугышта снайпер булган. Төз аткан өчен, бу мылтыкны Ишәй абзыйга генерал үзе бүләк итеп биргән.

— Кем белә,— дип җилкәләрен җыерды Кәрам.— Минемчә, солдаттан кайтканда корал бүләк итеп бирелми. Юк сүздер ул?..

— Алайса, бу гаскәри корал Ишбулдинга ничек килеп эләккән? Әнә, күрәсеңме мылтык түтәсендәге сырларны? Ишбулдин киртләгән тамгалар. Бер фрицның башына житкән саен бер кирт сала бардым, дип сөйли Ишәй абзый...

Курамшинның күзләре шар булды.

— Болармы? Кит, булмаганны! Монда киртләрнең санына чыкмалы түгел ич!

— Ике йөз егерме!

— Алайса Ишәй абый герой булырга тиеш!

— Героен герой түгел дә, ниндидер орденнары, медальләре бар.

Пичугов квартира мәсьәләсендәге сүзне түгәрәкләргә ашыкты:

— Менә шулай, Кәрам дус. Әйтик, Ишбулдин батыр да, снайпер да булмасын ди. Ләкин бит Ватан сугышы ветераны буларак та, Черек күл нефть мәйданын ачуда катнашкан кеше буларак та һәм йортсызжирсез карт буларак та беренче чиратта квартирага лаек кеше.

— Бир син, кем аңа каршы? Тик, хөрмәтле Кузьма Николаевич, Фәнүзә турында да онытма. Бик тә авыр аның хәле...

— Әлегә бер сүз белән дә юата алмыйм... Карарбыз. Бәлки «үтә мохтаҗлар» исемлегенә кертеп булыр.

— Анда күпме кеше?

— Ике йөздән артыграк.

— Уһу!..

Курамшин китәргә җыенды. «Бер бүген генә һич ни кырып булмый. Тамчы булып тамарга кирәк Пичуговның башына. Көн саен, сәгать саен, минут саен, бертоташтан» — дип ныгытты үзен. Чыгарга ишек ачкач кына кунак йортындагы купшы бүлмәсе турында исенә төшерде:

— Син, Кузьма Николаевич, нигә дип әле бүлмәдә мине ялгызымны калдырдың? Нинди гаепләрем өчен бу җәза?— диган булды.

— Гостиницаны әйтәсең инде син. Себергә бердәнбер дустың килсен дә...

— Мин моңа каршы, Кузьма. Яратмыйм мин андый купшылыкны. Өйрәнмәгән...

— Я, я, чыгымчылама, кешенең яхшыдан туйганы буламы?

— Башкалардан уңайсыз. Килешми.

— Турысын әйткәндә, идарә начальнигы үзе кушты. Аның фәрманы. «Күңеле утырып эшләрлек шартлар тудырырга кирәк Курамшинга», диде. Ышанмасаң, үзеннән сора!

— Нәрсә, ул мине мәңгегә килгән дип уйлыймы әллә?

— Дөнья хәлен белмәссең. Әнә теге, ресторанда утырган ялтыравыклы күзләр башыңны әйләндерсә...

Кузьма Николаевич, башын артка ташлап, ләззәтләнеп хихылдагач:— Ярый, ярый, мин болай гына,— дип тынычландырмакчы булды.— Тик, Кәрам дус, кабатлап әйтәм: сак бул андый чәчбикәләрдән, зинһар юк белән мавыкма.

## II

Курамшин урамга чыкканда сәгать унберләр җитеп килә, сыек сөт кебек ак төн, томанны хәтерләтеп, һавада асылынып тора иде. Ничектер, эңгер-меңгере дә, кояш тотылгандагы кебек, хәвефле һәм күңелсез.

Сирәк-мирәк узып киткән машиналардан башка урамда бернинди хәрәкәт калмаган, тик елга порты белән иске пристань якларында гына катер һәм баржа сигналлары, теплоходларның авыр ухылдавы ишетелеп киткәли иде. Себер йокламый, Себер эшли, Себер иртәгесе мәшәкатьле көнгә әзерләнә. Себер киләчәккә көч, гайрәт җыя.

Шәһәрнең һәр хәрәкәтен, чак кына ишетелеп торган чыңнарын һәм гөрелтеләрен дә үзенә сеңдерә-сеңдерә, Курамшин кунак йортына таба атлады. Шәһәрнең колакка бәреп кергән ят тавышлары белән бергә, Фәнүзәнең «менә шулай яшибез инде», дип бүлмәсен күрсәтеп көрсенүе дә, Мариньның урамда аерылып киткәндә «Рыцарь сүземе бу?» дип чытлыкланып вәгъдә алып калуы да, барысы да Кәрамның артыннан ияреп барды. Шушы күп санлы, төрле-төрле тавышлар арасында балаларының еракта, телефоннан ишетелгән авазлары аеруча яңгырап тора: «Әти, безгә тере аю баласы алып кайт!»— диләр алар.

Курамшин белән янәшә Пичугов ияреп килә сыман һәм: «Кеше нефть белән генә яшәми» — дия кебек.

— Ярый,— ди Кәрам, Пичугов белән сөйләшкәндәй.— Нефть белән генә яшәми, әмма нефтьсез дә яши алмый бит. Бу нефть дигән нәрсә безне, дустым, менә кайларга кадәр илтеп ташлады...

Килгән мәлне Кәрам, сабакташының биредә үскәненә, дәрәҗәгә күтәрелгәненә, могтәбәр кеше булып житешкәнлегенә сөенгән һәм эченнән бераз гына көнләшкән дә иде. Ни әйтсәң дә, идарә кадәр идарә житәкчесенең урынбасары булу — теләсә кемнең кулыннан килми. Моның өчен баш та, булдыклылык та, ниндидер сәләт тә кирәктер. Кәрам, үзе зур кеше булып карамагач, начальник урынбасарының рәвешен дә китерә алмас иде әле бәлки. Ә ул Кәрамның башына да килмәгән планнар, проектлар белән эш йөртә.

Соңыннан, аның эшләрен күзәткәләп, сөйләгән сүзләрен тыңлап, уй-фикерләре, киләчәк планнары белән ныклабрак таныша торгач, ничектер, шиккә калды Курамшин: үз урынындамы соң бу Кузьма Николаевич? Начальникның көнкүреш буенча урынбасары булгач, барысын да — ресторанга меццо-сопрано тавышлы җырчылар, модалар ательесына манекенчылар табудан башлап, урам-йорт проектлары төзүләргә, квартиралар өләшүгә кадәр бер Пичугов кайгыртырга тиеш микәнни?

Әлмәттә, Курамшин эшләгән нефть идарәсендә дә бар начальник урынбасары — Аркадий Аркадьевич Кривопольский. Дусты юк, дошманы юк аның, туган-тумачасы юк. Биредә Пичугов бөтен камытны үзенә генә кияргә тырышса, Кривопольский исә киресенчә, бер эшне дә үз өстенә алмас, башкаларга гына аударырга тырышыр. Нинди генә йомыш белән килсәләр дә: «Мин зам. гына. Минем акчам да, материалым да, кәгазьгә басарга печатем дә юк»,— дип кенә чыгарып җибәрә кешеләрне. Рәхәт аңарга — юкның башы авыртмый.

Курамшин кунак йортына кайтып житкән, ишек яңагындагы кнопкага гына басасы калган иде. Кинәт артында әкрен һәм сузынкы гына:
— Карамушка!—дигән тавыш ишетте. Борылып караса, Марина.
— Марина, нишләп торасың монда?
— Рыцарымның егетлеген сынар өчен торам.
— Нинди рыцарь инде мин, Марина.
— Син танцыга килергә вәгъдә биргән идең.
— Әйе, әйе... Соңга калынды... Эш бит. Гафу ит. Мин хәзер сине озатып куям.
— Номерыңа чакырмыйсың?
— Ни бит, Марина, дежур хатын бик усал. Шундый явыз!..
— Да, сине Фая болай куркак дип сөйләмәгән иде.
— Фәнүзәме? Нәрсә белә ул Фәнүзә!..
— Белә, бик белә! Не скромничай, Карамушка, анда ничек гулять иткәннәреңне дә, яратмыйча хатыныңнан ничек командировкага качып киткәннәреңне дә яхшы беләбез!..

Кәрамның өстенә пычрак, бозлы су сиптеләр мени — ул, җилкәләрен җыерып, кулларын җәйгән хәлдә катып калды. Менә бит эшләр кая таба киткән. Ах бу явыз Фәнүзәне! Күр син аны ничек итеп үч ала...

— Менә авыртмас башка тимер тарак,— дип зарланды Кәрам эченнән. Аның бердәнбер чарасы — хәйлә, Маринаны юату, аны ничек булса да торагына илтеп кую иде.

— Бүген соң инде, Марина,— дип аның шактый юан биленнән кочаклап сүз башлады Кәрам.— Көн бүген генә түгел. Иртәгә кич очрашырбыз, яме?
— Кайда?
— Үзем барып алырмын.
— Рыцарь сүземе бу?
— Әйе.

Алар, култыклашкан хәлдә, Маринаның торагына таба киттеләр. Шунда Курамшин, Хуҗа Насретдин турындагы бер мәзәкне исенә төшереп, елмаеп барды.

Имеш, ят бер шәһәрдә Хуҗа Насретдинның бик нык ашыйсы килгән. Базарга барган да бер сатучының хәлвәсен, сораусыз-нисез ашарга керешкән бу. Теге сатучы Хуҗа Насретдинны кыйный, ә бу аның саен ашый икән. Соңыннан, тамагы туйгач, хәлвә сатучыга рәхмәт әйткән дә китеп барган Хуҗа Насретдин. Очраган кешеләргә: «Шәһәрегез әйбәт икән, кыйный-кыйный хәлвә ашаттылар»,— дип, мактап сөйли икән Хуҗа.

— Мине дә монда кыйный-кыйный хәлвә ашаталар бит, вәт син!

Юлда аларга ыспай гына киенгән бер ир очрады һәм ул, ун-унбиш метрлар узып киткәч, Маринаны үз янына чакырып алды. Алар кызыпкызып сөйләшә, тарткалаша калдылар. Кәрам туктамады. Сөйләшептарткалашып калганнарга игътибар итмәскә тырышса да, кисәк кенә адымын әкренәйтте. Юлы аның шушы урында өзелеп калгандай булды. Әлеге ир кеше, кайсы ягы беләндер, Кәрамга бик тә таныш кебек иде.

— Кем булды бу?

Арттан, мышный-мышный, Марина куып җитте.

— Менә монысы рыцарьлык түгел инде, Карамушка!— дип, авызын бөреп, үпкәләп шелтә белдерде.— Дамаларны шулай ташлап китәләрме?

— Калдың дип уйладым. Танышың иде булса кирәк?

— Дрянь ул! — диде Марина. — Безне эшкә яллап алып килгән кеше, вербовщик кисәге. Общежитиега килеп, башта Фаяга бәйләнеп йөрде, аннан Наташага, хәзер инде миңа... Андый сукыр чебеннәрне яратмыйм мин.

«Кара, Маринаның да үз принциплары бар икән!»—Кәрам үзе өчен ачыш ясады.

— Жан, дип йөртәләр ул кешене,— Кәрамне бик тә пошаманга төшергән сүзләр сөйләп китте Марина.— Синең дә күргәнең бар аны. Хәтерләмисеңмени, теге көнне рестoранда ике өстәл аша гына безгә карап утырды? Башыңа киткәнрәк иде шул синең. Ә мин аны үртәп, юри көнләштереп утырдым, синең белән алдына барып-барып биедем. Ачуыннан шартлый язды!

— Димәк, аны көнләштерү өчен генә яратасың?— Марина беләнараны өзү өчен, ниһаять, Курамшинга сәбәп табылды. Хәзер ул үзе дә көнләшүгә салыначак, үпкәләгән, ачуланган булып, Марина яныннан китеп барачак. Шунсыз котылу юк моңардан.

— Мин сине чынлап яратам, Карамушка, ышанмасаң, әнә, Фаядан сора...

— Сорап торасы түгел, күренә! Хуш, мин киттем!

— Тукта әле, Карамушка, җаным, аңлашыйк!..

Кәрам, артына да борылып карамыйча, җил-җил килеп, кайтып китте. Уенда аның бөтенләй дә Марина түгел, ә теге Жан дигән бәндә иде.

— Юк, бүген генә дә түгел, ресторанда гына да түгел, күптән күренгәнгә охшый бу кеше. Тагын кайда гына очраттым соң әле аны?

Кәрам, кинәт туктап, маңгаена сугып куйды:

— Җәмил ич бу! Әйе, әйе, Җәмил! Муенын кырын салып йөрүе дә, авызына папирос кабып, ике кулын кесәсенә тыгып баруы да — аның гадәте.

Якташы белән тагын бер күңелсез очрашу. Курамшин алты-җиде ел элек бригадада мастер булып эшләгән көннәрен, кыр тулып утырган скважиналарны, шуларның Зәй елгасы янындагыларын караган оператор Җәмилне исенә төшерде. «Җаен Җәмил» дип йөртәләр иде аны. Юк, эшчеләр такмаган, нәселеннән килгән кушамат. Гәүдәсе дә бик җыйнак, авызы да алай зур түгел — җаенга бер дә охшамаган. Ә менә начар гадәтләре белән теләсә нинди кушаматка да лаек.

Иптәшләре дә, Курамшин да аны ялкау һәм вөҗдансыз булганы өчен яратмадылар. Скважинасына барасың, карыйсың — торбага парафин тыгылган, нефть килми. «Кыргыч төшердеңме, нефть юлын чистарттыңмы?» — дип сорыйсың. Ә ул күзен дә йоммыйча алдый. «Хәзер генә чыгыр төшердем, билләһи, чукынып китим менә!» Скважинага киләсең, кыргыч будкасына керәсең — Җәмил, башын тезенә куеп, йоклап утыра. «Юк, йокламадым, чукынып китим менә, установканың эшен карап утыра идем». Ә үзенең күзләре шешенеп чыккан, битендә шадраланып калган бияләй эзләре...

Бер мәртәбә, скважинада йоклап, нефть чаннарын ташыткач, бригада җыелышы карары белән эштән куганнар иде аны, Җәмил өч ай тик йөрде дә Курамшинны судка бирде. Суд, моңа кадәр приказ белән шелтәләр бирелмәгән, гаепләре документ белән оформить ителмәгән дип, Җәмилне яңадан эшенә кайтарды һәм, аның эшләми йөргән көннәре өчен, мастер кесәсеннән түләтте. Курамшинның идарә приказы белән каты шелтә алуы да Җаен Җәмил аркасында. Эшчеләренә күпме әйтә килде: газ факелы янына якын бармагыз, газ линиясенә нефть үтеп, өстегезгә ут атылуы мөмкин, диде. Шуңа да карамастан, операторлар яңгырлы көннәрдә факел янында өсләрен киптерәләр иде. Моңа кадәр, ничектер, нефть атылу очраклары булмады, барысы да хәвеф-хәтәрсез узды. Ә менә, кемгә диген, эзләгән кешесенә килеп юлыккан бит бәла: чак кына янып үлә язмады Җәмил. Салкын көз көне өшеп, скважина янындагы факел төбенә килеп утырган да йоклап киткән. Бервакыт скважина каты гына төчкереп җибәргән һәм моның өстенә факелдан ут тамчылары коелган. Ярый әле, тиз генә торып киемнәрен салып өлгергән, шуның белән янып үлүдән котылып калган. Тәннәре ялкында пешеп, ике айлар больницада ятты егет. Аның яралары төзәлде, ә менә «куркынычсызлык техникасы кагыйдәләрен үтәмәгән, эшчеләрен өйрәтмәгән өчен» дип бирелгән шелтә җәрәхәте Кәрамның әле дә булса йөрәгендә...

Җәмилнең эштән куылуы ул елны да түгел, соңыннанрак, иптәшләрен дә, бригаданы да берничә мәртәбәләр төп башына утырткач булды. Ул, график буенча, яңа елга каршы төнне вахтада торырга тиеш иде. Килде, бергә эшләгән иптәшеннән скважиналарны кабул итеп алды. Мондый җаваплы көндә җитәкчеләр сизгерлекне күтәрү максатында, таләпне аеруча каты куялар — дежур калып, скважиналарны тикшереп кенә торалар. Идарәдән төн уртасында килеп, шундый обход ясарга Курамшинны да алып киттеләр. Операторлар барысы да скважиналарда, тик Җәмил генә үз урынында юк иде: скважиналардагы нефть юлларын япкан да Яңа ел кичәсенә кайтып киткән. Иртән Курамшин белмәмешкә салышып кына сорый моңардан: «Вахтада булдыңмы?» Җәмил, оятыннан кызара да белми ичмасам, үзенең нефтьле кулларын күрсәтә: «Күрмисеңмени, скважиналар белән төне буе иза чигеп чыктым, чукынып китим менә!» — ди. Бу юлы инде аны суд та, Кәрам өстеннән бирелгән төрле жалобалар да коткарып кала алмады...

— Ярый, узган тузган, җилгә очкан! — диде Кәрам, авызына тәмсез нәрсә капкандагыча, җиргә төкерде. — Ә хәзер нигә ачу саклап йөри икән соң әле ул? Ник танымаска салыша, нигә исәнләшеп китми? Әйе, вак җанлы кеше гомере буена шулай кала торгандыр инде ул.

## I

Баш инженер Бибиковта иртәнге планерка бара. Ул «биш минутлык» дип йөртелсә дә, биш минут эчендә генә беткәне һич юк, кайвакытта унбиш-егерме минутка сузыла, ә кайчакларда ярты сәгатькә дә сыймый иде. Шуңа күрә «биш минутлыкларны» иртәрәк, вахта машиналары китәргә бер сәгать алдан башлыйлар.

Шунда утыра-утыра, мунча кергәндәгедәй тирләде Курамшин. Бүлмә эсселектән түгел, тоташ сүз боткасыннан, зарлану һәм тиргәштән кызган иде ул. Тавышның асылы нәрсәдә? Әлеге дә баягы. Черек күл мәйданында эшнең ифрат сүлпән баруында, нефть объектларының срогында өлгермәвендә.

Бүген Пасарби Пшимаховичның кәефе аеруча начар, ул урынында утырып тора алмый, ишекле-түрле йөри, туктап, һәр бүлек мөдирен бастыра да акыртып җавап ала.

Эш графигы чамадан тыш бозылган: скважиналарны җиһазлау буенча сызымнарны өлгертмәгәннәр. Кирәкле кадәр металл конструкцияләр китертә алмаганнар, квалификацияле эшчеләр туплау планы өзелгән...

Баш инженер, бөркет кыяга кунган кебек, ике кулы белән өстәл почмагына таяна. Күзләре белән стена буенда тезелеп утырган кешеләрне сөзеп чыга.

— Ну, инде нишлибез?

Кыскача информация ясау өчен чират Аввакумовка җитә.

— Ә син нәрсә диярсең, Виталий Иванович?

Аввакумов үз бәясен белә, урыныннан чәчрәп тормый, баш инженер бастыргач, башкалар кебек каушап-куркып калмый:

— Ике көтүче очрашканнар да икән, зарланалар, ди: ике кулыма бер эш булыр дип көтү алган идем. Ике кулга бер эш тә юк, әмма аякларга чыдап булмый, дип әйтәләр, ди...

— Син миңа әкият сөйләмә, Виталий Иванович!

— Менә шул турыда әйтәм шул. Көн буена күл буйлап чабышып йөрибез, ә кулга тотарга эш юк! Кайда безгә китереләсе торбалар, кайда табаклы калайлар, электродлар? Нигә бүгенге көнгә кадәр сызымнар әзер түгел? Нигә һаман слесарьлар, монтажчылар бригадасы җибәрелми? Фактта навигация бетте, елга юлы ябылды — кышын нәрсә эшләрбез? Безгә хәзер йөкләрне самолетлар, вертолетлар белән китертү мәсьәләсен куярга кирәк, Пасарби Пшимахович.

— Ә синең, Кәрам Ризванович, автоматларың, телемеханикаларың ни хәлдә?

Кәрам Ризванович тора, ни әйтергә белми аптырап кала. Нигә дисәң, Курамшинның командировка срогы бары ике айга иде — аны тагын бер айга озайттылар. Монысы да ике-өч көннән тула, өйгә китәр вакыт: ә бу Пшимахович дигәннәре һаман өскә атланып куа, көннән-көн ныграк җигә бара. Срок дигән нәрсәне әллә онытып җибәргәнме ул?

Шул турыда Бибиковның исенә төшермәкче булып торган иде, ләкин теле әйләнмәде, башкалар кебек үк зарланып китте:

— Мин үзем аңлый алмый интегәм. Безнең промыселларда, иптәш Бибиков, болай эшләмиләр... Бездә башта китерәсен китереп, җиткерәсен җиткереп бетерәләр, аннан соң — «давай, давай!» — Кәрам Ризванович үзенең кычкырыбрак җибәргәнен тоеп, тавышына азрак «тормоз» бирде.— Миңа нәрсә! Үзегез әйтмешли, мин командированный кеше, килмешәк. Срогым тулгач «сау-бәхил бул», китәрмен дә барырмын. Ә бит анда Черек күлдә телемеханика системасының яртысы да комплект-

ланмаган! Блоклар кайткан, кабельләре юк, диспетчер пульты бар, язу җайланмалары юк...

Баш инженер, кулын күтәреп, Курамшинның сүзен кисте:

— «Моя хата с краю» димәкче буласыз. Алай түгел! Без монда барыбыз да бер арбага җигелгән. «Мин командированный» дип, туарылып китә алмыйсың. Ботканы бергә пешердек, ашавын да бергә ашыйбыз, менә шул!

Курамшин, башына суккандай, миңгерәп китте кебек. Авызын бер ачты, бер япты, тел очына килеп торган сүзен әйтә алмый интекте. Өч көн генә элек «тиздән кайтып житәм» дип хат язган иде, кичә генә хатыны белән «якшәмбе-дүшәмбе тирәләрендә юлга чыгам», дип телефоннан сөйләште. Тагын да килеп, өч «ташбашына» күчтәнәчкә фотоаппарат белән диафильмнар сатып алынган. Бүген эштән кайткач Хәтимәсе өчен дә кызыклырак берәр нәрсә эзләп карамакчы иде. Болар турында биредә сөйләп булмый шул.

Баш инженер Бибиковның планеркалар үткәрү стиле гаҗәп кызык: кешеләрне чират белән берәм-берәм бастыра да, башкарылган эшләр өчен җавап бирүне сорый. Ләкин сөйләргә, акланырга, зарланырга да бирмичә, эшкә куып чыгара. Аны «тупас кеше» дип тә, «принципиаль кеше» дип тә «конкрет кеше» дип тә йөртәләр.

Ләкин Курамшин аны үзенә карата тупас дип әйтә алмас иде. Ни өчен дисәң, баш инженер аңа һәрвакыт игътибарлы булды, иплән сөйләште, киңәшен кызганмады. Әлбәттә, ул да Аввакумов кебек, Курамшинга вакытлы кеше итеп кенә карый иде. Бүген планеркада шунысы гаҗәпләндерде: баш инженер башкалар белән беррәттән инде аны да бастырып тирги. Моңа сөенеп тә куйды, хәтта Курамшин. Димәк, баш инженер аны идарә кешеләре белән тигез күрә, үз итә. Димәк, аңа ышана башлаган Пшимахович. «Соң түгелме икән кайтып китәргә вакыт җиткәч?» — дип Бибиков өчен борчылып та алды Кәрам Ризванович.

Бибиков өчен генә түгел, ул бүгенгечә заводтан килеп җитмәгән автоматлар, телемеханик аппаратлар өчен, анда эшлисе кешеләр, бөтен Черек күл язмышы өчен борчыла иде.

Планерка беткәч, кешеләр тарала башлагач та уйланды ул Черек күл язмышы турында. Әйе, ордым-бәрдем генә түгел ул ерактан идарә итү системасын кору. Идарә ялгышкан монда Курамшинны китертеп. Булгач булсын иде: бу өлкәдә яхшы гына мәгълүматлы бер инженерны — калып яши торган кешене чакыртырга кирәк иде. Ул үзенә укымышлы-белдекле егетләр җыяр иде, бригада яки цех кебек бер нәрсә оештырыр иде, укытыр, өйрәтер, шунда мәж килеп үзе дә эшләп йөрер иде. Ничек тә язга кадәр тырышырлар, ничек тә төзеп бетерерләр, сафка бастырырлар иде яңа системаны. Кирәк иде аларга даими бер кеше.

— Беләм, Кәрам Ризванович, синдә инде «чемодан настроениесе»,— дип, Бибиков бүлмәдә ялгызы утырып калган Курамшин янына килде.

— Сиңа бер генә үтенечем: кал тагын берәр айга!

Кәрам Ризванович җавап бирмичә идәнгә карап утыра иде.

— Нәрсә ул бер ай! — дип күтәрелеп кычкырды аннан.— Бер ай белән ни кырып була?

— Системаны комплектовать иткәнче генә. Үтенәм. Мин сезнең идарә начальнигы белән дә, баш инженерың белән дә сөйләштем. Каршы килмиләр. Эш бары синнән тора. Без рәсми язу да язарбыз. Бәлки өеңә кайтып кына килерсең, Кәрам Ризванович? — дип көтелмәгән тәкъдим ясады баш инженер.

Кәрам елмайды.

— Бер кайтсам, килер дисеңме?

Аннары, Кәрам Ризвановичның юлын бүлеп, каршыга басты.

— Шулай да ун-унбиш көнгә кал әле. Кубенә түзгәнне азына гына чыдарсың!

— Аннан соң ни була?

— Җиһазлар алырга самолет җибәрербез. Заводның үзенә. Мондагы эшләрне башлау өчен кемнәрне булса да табарбыз.

— Тагын читтән теләнепме? Ташлагыз шул гадәтегезне, табыгыз даими кешеләр!

— Менә син калмыйсың бит — башкалар да шулай. Проблема! Бу мәсьәлә министрлыкка да билгеле.

Кыстауга бирелүдән куркып, Курамшин тиз генә чыгып китте. Себернең үтенечләренә берәү дә каршы килергә батырчылык итми.

Тыңламасаң — барыбер кушарлар. Риза булмасаң — мәҗбүр итәрләр.

Кирәк икән — бөтенләйгә җибәрергә дә күп сорамаслар. Көч — алар ягында. Дөреслек — алар кулында... Пшимахович бит юри генә ризалык сорап маташкан була. Курамшинның калу-калмау мәсьәләсе, бәлки, әллә кайчан хәл ителгәндер инде?!.

Шуларны белешмәкче булып, кадрлар бүлегенә кереп чыкмакчы иде Курамшин. Ләкин, коридор буенча тезелеп шап-шоп атлап килүче солдатларны күргәч, туктап калды. «Болар нишләп йөри монда?» Килделәр дә, кадрлар бүлеге ишеге төбендә шып итеп туктап калдылар. Алдагысы, фуражка кигән сержант, сафтан чыгып команда бирде:

— Вольно! Таралмаска!

Үзе, ишек тә шакып тормыйча, эчкә узды.

Солдатлар барысы да озын шинельдән, бүректән, кара погоннардан иде. Погоннарында Кәрамга таныш булган элемтәче билгеләре — аркылы-торкылы киткән яшен чаткылары. Ул хезмәт иткән частьта да бар иде андый солдатлар.

Ишек төбендә алар белән бергә ике-өч минутлар торгач, ни өчендер, кызыксынмакчы булды Кәрам:

— Солдатларга нинди хәсрәт төшкән нефть идарәсендә? — диде.

Җавап бирүче булмады. Бәлки, сөйләшү өчен дә аларга команда кирәктер? Бәлки хәрби сердер?

Курамшин, кесәсеннән папирос чыгаргач, берсе кыюсыз гына:

— Рөхсәт итегез? — дип, тартырга сорады.

— Рәхим итегез.

Бернichә кул берьюлы папироска үрелде.

Менә шунда ачыла инде ир-атның теле, шунда китә танышу.

— Без монда эшкә килдек,— диде беренче булып папироска үрелгәне.— Ничек уйлыйсыз, алырлар микән?

— Срокны тутырыпмы?

— Әйе. Күрәсез, бөтен отделениебез, командирыбыз белән. Үзебез теләп.

— Ниндирәк эшкә дисез?

— Ниндигә дә риза.

— Димәк, романтика китерде Себергә?

— Теләсә ничек дип белегез...

Сержант чыкты.

— Бетон эшенә китәбез! — диде.— Бүгеннән үк барыбызга да военкомантка учетка керергә, паспортлар алырга, торакка урнашырга һәм башкалар. Сораулар бармы?

— Юк!

Шунда Курамшинның күкрәге актарылып чыккандай булды. Тынына капланып, кул күтәреп сержантка таба килде. Бер секунд соңга калса да эш узар, югаласы югалыр кебек иде аңа.

— Туктагыз әле, егетләр, сабыр итегез. Сез элемтәчеләр түгелме соң?

— Элемтәчеләр! — дигән дәррәү җавап ишетте.

— Нәрсә, сез башка эш тапмыйсызмы? Әллә бирмиләрме?
— Безгә барыбер. Ил кая кушса — шунда!
Курамшин ачу белән кулын селтәде.
— Ташлагыз әле романтикагызны! Сездәй асыл егетләрне кара эшкә кушу — җинаять! Кадрлар бүлеге ахмаклык эшли!
Кырт итеп борылды да, баш инженер бүлмәсенә таба китте.
Бүлмәсеннән Пасарби Пшимаховичны ияртеп чыкканда солдат-егетләр арасында Аввакумов тора, кызыл сакалын селкә-селкә, аларга нәрсәләрдер сөйли, аңлата иде.
Аввакумов, баш инженерны күрү белән кулын-кулына сугып:
— Менә дигән егетләр таптым үземә, Пасарби Пшимахович! — дип кычкырып әйтте.— Бетон эшенә җибәрмәкче булалар икән үзләрен. Әмин монда монтажниклар көтеп утырам!
— Юк инде, Виталий Иванович, соңга калгансың. Егетләрне син түгел, мин таптым. Алар миңа киләчәкләр,— диде Курамшин, егетләрне аралап, урталарына кереп басты.
— Күр син аны,— дип, Курамшинга төртә-төртә көлә башлады Аввакумов.— Моны гына кара, Пасарби Пшимахович! «Миңа» дип сөйләнә бит! Син кем? Кайсы оешмадан? Кем булып эшлисең?
— Кемме-түгелме, егетләр — минеке!
Курамшин, кулларын җәеп, солдатларны каплап басты. Аввакумов шулай ук колачын җәеп, күкрәге белән Курамшинны артка таба кыса башлады. Баш инженер, ике читәсен тотып, бу күренештән рәхәтләнеп көлә иде. Коридорга кешеләр чыкты.
— Виталий Иванович,— дип, сүзен юри сузып, боларны тынычландыру өчен әйтте Бибиков.— Без бит үз кешеләр, Виталий Иванович. Без синең белән ничек тә килешербез... Алсын Курамшин егетләрне үзенә. Кирәктер алар...
Курамшин кулына яшь, таза, белемле егетләр эләкте, бирелә беренче мәртәбә, кечкенә генә булса да, коллективка ия булды ул. Әйдә, вакытлыча гына булсын, әмма хәзер аның үз кешеләре бар. Курамшин егетләрне, аз булса да, яңа система белән таныштырып, кулыннан килгән кадәр өйрәтеп калдырачак. Алардан, белмәссең, киләчәктә телемеханик системасының менә дигән осталары, Черек күл нефть мәйданының чын хуҗалары чыгар!
— Ну, бөркетләр, нигә аптырап калдыгыз әле? — диде Курамшин елмая төшеп. Ул үзенең дә, егетләрнең дә кәефен күтәрергә тырыша иде: — Я, әйтегез, кайсыгыз белә: ни өчен мин сезне тартыша-тартыша алдым?
— Үзеңә кирәк булганга,— диде арадан берсе.
— Ни өчен кирәк?
— Эшләтер өчен!
— Дөрес сукалыйсыз.— Курамшин янындагы сержантка борылды.— Димәк, элемтәчеләр сез. Димәк, электр, радио, телефонны нәрсә белән ашаганны беләсез?
— Бераз сукалыйбыз,— дигән булды сержант тыйнаклык күрсәтергә тырышып.
— Телемеханика, электроника дигән нәрсәләрне дә ишеткәнегез булды инде?
— Күз алдына китерәбез.
Курамшин, институттагы профессор Кабулов сүзләрен исенә төшереп елмайды да, алдындагы бер кечкенәрәк солдатка төртеп:
— Тараканның мыеклары нәрсәгә кирәк? — дип сорады.
— Солдат та югалып кала торганнардан түгел икән, мәзәккә шулай ук шаяру белән җавап бирде:
— Ана тракан алдында көязләнү өчен.
— Алайса ана тараканның мыеклары ни өчен кирәк?

— Ата тараканга ярар өчен.

Егетләр гөр килеп көлештеләр.

— Тагын нәрсә өчен кирәк?

— Бер-берсен эзләп табу өчен.

— Иснәшер өчен! Қапшашыр өчен!

— Молодцы! — дигән булды Қурамшин көлә-көлә.— Болай булгач мин сезне эшкә алам да алам! Таныш булыйк: фамилиям Қурамшин Кәрам Ризванович. Әйтергә авырмы? Өйрәнгәч кыен булмас. Әле мин Пасарби Пшимахович дип әйтергә дә өйрәндем. Ә сезнең барыгыз белән дә соңыннан танышырбыз. Мин Черек күл телемеханика системасы буенча эшлим. Миңа килүегезгә бер дә үкенмәссез. Бик кызык нәрсә ул телемеханика.

Қурамшин сержантның җиңеннән тотты.

— Исемең ничек синең?

— Владимир. Фамилиям — Леванов.

— Әйдә әле, Володя, яңадан керик бирегә,— дип егетне кадрлар бүлегенә алып кереп китте.

## Укучының күңел дәфтәренә

**Украин мәкальләре һәм әйтемнәре**

*Әшәке эт борчага, яман кеше сүзгә бай.*
*Бияне куян ашаса, бүрене гаеплиләр.*
*Тимерне тутык ашый, йөрәкне сагыш телә.*
*Үзе итектән атлый, эзе — яланаяктан.*
*Күзләр еракка карый, акыл арыракны күрә.*
*Дусты кем икәнен әйткәч, үзе кемлеген белдем.*
*Кунагына күрә хөрмәте.*
*Карлыгач башлаган көнне сандугачлар тәмамлый.*
*Син аңа аш белән, ул сиңа таш белән.*
*Һәр шелди үз сазын мактый.*
*Бүредән курыксаң — урманга барма.*
*Гапка белен пешергән — капкасы да камырлы.*
*Күпмегә алсам, шул хакка сатам.*
*Куян эзеннән барып та кайчак аю тоталар.*
*Дөньяның бөтен яктысы бер тәрәзәдән керми.*
*Безнең бусага — биек, дошман атлап үтәлми.*
*Россия һәм Украина — бер төптә ике куак.*
*Кеше умарталыгында бал корты үрчетмәкче.*
*Күлмәксез туып, ыштансыз үлгән.*
*Чүлмәге булса, капкачы табылыр.*
*Һөнәр ризык сорамый, үзе сине ашата.*
*Йөз кешенең кәвешен бер калып белән тегә.*
*Ат кемнеке — олау шуныкы.*
*Урлыйсы әйберен карак алладан сорый, имеш.*
*Дөнья сукыр эт шикелле: күрмәсә дә өрми торалмый.*
*Үзеңдә юк дөреслекне бүтәннәрдән эзләмә.*
*Бердәм көтү бүредән курыкмый.*
*Барча кошны томшык туендыра.*
*Агачларның җимешенә, кешенең эшенә кара.*
*Чишмәдән су эчәр өчен җиргә иелү кирәк.*
*Кошлар каурый белән матур, кеше белеме белән.*
*Бер кашык суга — бер чиләк пычрак.*

## Гамил Афзал

# АГА СУЛАР

## Ленинча

Озын еллар уйлый-уйлый, үз-үземә әмер бирәм:
— Ленинча яшәргә тырыш, Ленинча эшләргә өйрән!

Яхшылык битлеге кигән һәр төрле алдаудан җирән,
Ленинча күрергә тырыш, Ленинча уйларга өйрән!

Талау фәлсәфәсен җиңгән, ирекле яшәргә килгән
Ленинча уйларга тырыш, Ленинча күрергә өйрән!

Тыңла улым, тыңла, кызым, изге теләк — васыять дигән:
Ленинча яшәргә тырыш, Ленинча эшләргә өйрән!

Еллар арты еллар үтәр, заман барыр шушы эздән.
Илдән — акыл, куәт сезгә, ә хәер-фатиха — бездән.

## Идел башы

*И су ташый, су ташый ла,*
*Кайда микән су башы.*

Халык җыры

Борынгылар казан аскан
Чишмәләр чыккан җирдә.
Нәсел-ыру тәпи баскан
Чишмәләр чыккан җирдә...

Калкулыкта яшел уҗым,
Иңкүлекләрдә — болын.
Изге булган борын-борын
Чишмәләр чыккан урын.

Кәрлә каеннар төбендә
Бер инеш тибеп тора.
Сабый инешне күрергә
Буыннар килеп тора.

Табигатьтән килгән өлеш, —
Байлыгың белән бүлеш.
Шушы хәтле нәни инеш
Иделләр булсын имеш!

Челтер-челтер нәни инеш,
Елтер-елтер нәни инеш,
Агып ята нәни килеш,
Сулары кара көмеш.

Ышыкланып талларына
Ул һаман ага тора,
Данлы Идел ярларында
Дөнья яңара тора.

Гасырлар белән сөйләшә
Йолдызлы кичләрендә,
Аккош кебек пароходлар
Керәләр төшләренә.

## Йокысыз үтә айлы төн

Тудым да үстем болында үләндәй,
Җилләр кагылды битемә.
Дөньяда торуның мәгънәсен эзләп
Бармадым илләр читенә.

Кояшлы кырларда каерылып эшләдем,
Кызларны үптем кичләрен.
Дөньяда торуның мәгънәсен эзләп
Уй дәрьясына төшмәдем.

Биш улым, биш кызым каера дөньяны,
Айкыйлар җир астын, җир өстен.
Дөньяда торуның мәгънәсен уйлап,
Йокысыз үтә айлы төн.

## Килер әле...

Чырай сытып, әйдә ярар, диеп тордык,
Ялыктырды чиле-пешле уртакуллык,
Фикерсезлек, ялагайлык, өйрәнчеклек,
Коры сүздән, фразадан җәфа чиктек.

Шигырь диеп исемләнгән көйле чүп-чар
Йөрми торган акча кебек йөреп туктар.
Җиң сызганып яшь даһилар килер әле,
Саф талантлар ак кул белән йолдыз тотар.

Акчага һәм дәрәҗәгә кызыкмаган,
Йөзгә бәреп сүз әйтергә курыкмаган,
Яшь Тукайлар килер әле җырлашырга
Тимер ялын чәеп чапкан бу гасырда.

●

Җәйге кичләр әкият кебек кызык,
Сандугачлар сайрап юанган кебек.
Елга аръягында сузып-сузып
Бер моңлы җыр җырланган кебек.

Бу дөньяда гашыйк җаннар гаме
Гомерләрне моңлы, мәгънәле итә.
Кыяр-кыймас ай калыккан мәлне
Кәккүк моңнарына ни җитә!

## Өф-өф итеп...

*Киресенчә киңәшләр*

Матур киңәшләр укыма
Календарь артларыннан,
Хәйләле киңәшләр тыңла
Акыллы картларыңнан:

— Сиңа кагылмыйлар икән,
Посып кына ят, энем,
Хәйләсез дөнья файдасыз,
Һәркем дипломат, энем.

Юкка-барга талаш кызса,
Читтә калырга тырыш;
Сиңа да файдалы булса —
Дәреслек өчен ызгыш!

Өлкән әтәчләр сугышсын,
Мамык-каурыйлар очсын,
Җитәкчеңнең җиңелгәнен
Күрмәскә тырыш, дустым.

Синсез дә планнар тула,
Басуда уңа иген.
Сөяркәң яныннан кайткач,
Дусларда кундым, диген.

Җитәкчеләр әрләгәндә,
(Булгалар сирәк-мирәк)
Дәрес белмәгән малай күк,
Дәшми торырга кирәк.

Оратор пәйгамбәр түгел,
Тиешкә ярма яра.
Ни әйткәненә карама,
Кем әйткәненә кара.

Зур түрә булып китәрсең
Танышлык бара-бара,
Коры портфельдән файда юк,
Сәүдә тирәсен кара.

Пөхтә булсын итәк-җиңең,
Дошманнар телле-тешле.
Халык өчен алдым диген,
Сизсәләр теге эшне...

●

Елан тоткан кебек, бик җирәнеп,
Әрем йоткан кебек сытып йөзне,
Мин сүзлектән сызып ташлар идем
Блат белән Ришвәт дигән сүзне.

## Бар әле...

Барчабыз тук. Һәм хокуклар тигез,
Тормыш ысуллары төрлечә:
Берәү ябык, ә берәүләр симез,
Һәм автомобиле... берничә.

Чорлар үтә һәм үзгәрә еллар,
Нәфес җайлашмыйча торамы?—
Шәһәрендә заман мещаны бар,
Авылында — заман кулагы...

## Иске зиратта

Йөз кешегә озын гомер биргән
Врач кабере белән берләттән,
Йөз кешенең башын чабып өзгән
Палач кабере килеп эләккән.

Гомер юлын алар бергә үткән,
Берсе — үлем, берсе — тереклек...
Хәтта монда бергә булыр икән
Кабәхәтлек белән бөеклек.

## Эпитафия

Матбугат йортына ул еш керде,
Битараф йөз, салкын караш күрде,
Гомер буе үзен эзләп йөрде...
Җаны пьедесталга кунсын.
Каләм әһелләрен бик тиргәде,
Тәнкыйть сүзен колакка элмәде,
Шагыйрь түгел икәнен белмәде...
Авыр туфрагы җиңел булсын!

●

Күпме чабата туздырдың
Бу чорга килә-килә,
Йокысыз төннәр уздырдың, —
Кирәген генә сөйлә.

Бик тирән уйлар уйладың
Бу көнгә килә-килә,
Гасырлар буйлап урадың, —
Кирәген генә сөйлә!

●

Һәр бөҗәкнең дусы, дошманы бар,
Горур, гамьсез түгел беркем дә.
Көнчел көндәш тулы мәйданы тар,
Авыз ачып йөрмә бер көн дә!

## Гаиләдә

...Синең хакың, минем хакым...
Синең эшең, минем эшем...
Көн-таң атса, ир дә хатын
Ызгышалар власть өчен.

Гаиләдә ир баш булсын,
Хатын булсын урынбасар,
Акыллы һәм тырыш хатын
Өй эчендә оҗмах ясар.

Ирнең дә кәефе булыр,
Үтәлә һәр кушканым дип,
Алдына бәрәңге куйсаң,
Боер, ханым-солтаным, дип.

## Нәни шаяру

Кайгыларга кайгы һич ошамый,
Кайгы савытлары бушамый.
Мактау белән бүләк көткән чакта
Каты шелтә алды Хисамый.

Бәхетләргә бәхет, һәй, ошамый,
Бәхет савытлары бушамый,
Башын иеп кайтып барган чакта
Бер сум акча тапты Хисамый.

# РАДИК ФӘИЗОВКА 50 ЯШЬ

Радик Фәизов

## ҖИНАЯТЬ

хикәя



Суд бара.

Безне авыл Культура йорты залында хөкем итәләр. Судьяларның һәр соравы, һәр сүзе бу иркен залда аеруча җитди, ә безнең өчен — хөкемдәгеләр өчен, аеруча рәхимсез булып яңгырый.

Язмыш дигәнең — менә ул! Моннан унбиш еллар элек Лашман авылында мәдәният үзәге булып калыккан бу мәһабәт бинаны мин үз кулларым белән салыштым. Аның һәр кирпечендә минем дә күңелем җылысы, һәр тәрәзәсендә минем дә күңелем яктысы бар. Өйләнмәгән егет идем әле ул чакта. Шушы Лашмандагы авыл хуҗалыгы техникумының механика бүлегендә укыйм, алай-болай гына түгел, башкалардан уздырып укыйм, киләчәктә авыл агаеның эшен җиңеләйтүдә революция ясап ташлаячагыма шигем юк. И егетләр дә идек инде үзебез! Укуын, гөрләтеп комсомол җыелышлары үткәрүен, туган авылларыбызның алдагы көне турында нинди кыю фикерләр, планнар иҗат ителүен әйтмим дә инде. Җәйге каникулларда да без ял итүнең ни икәнен белмәдек. Сыер абзарлары, мастерскойлар, клублар салдык. Мин— вожак, мин — анда сикерәм, монда өлгерәм, бер урында эш беткәнче икенчесен табып куям. Егетләрне нык кулда, бөтен бригаданы тимер кыршауда тотам кебек. Сәүбән генә түгел, Хәтәр Сәүбән идем мин.

Күңелем ни теләгәнен үзем дә төшенеп бетерми идем. Әле дә хәтердә, менә шушы бинаны салганда төзелеш мастеры Сибгать абый бер тәрәзә турысында үскән, кеше буеннан аз гына калку яшь бер каенны кисеп ташларга кушты.

— Кисмибез! — дип каршы төштем мин.

— Соң, тиешсез урында үсә бит ул.

— Агачка нинди тиешсез урын ул. Үсә бирсен. Ул безнең истәлек булып калыр. Киләчәк буыннарга бу сарайны кем салганын сөйләп торыр.

— Сафсата... кисәргә! — дип кызды мастер.

— Кулымны кисегез, ә каен калсын!

Әнә ул каенкаем, әле дә исән, хәзер инде очлары түбәдән ашкан. Тышта искән көзге җилдән салмак кына чайкалып, ботакларын тибрәтә. Әйтерсең лә, тәрәзә аша мине сәламли, мине юата. «Изге күңелле кеше син. Теге чакта мине балтадан саклап калдың. Синең ниндидер гаебең булуына мин ышанмыйм»,— ди сыман. Син, каенкай, кайгырма.

Мин бернинди җинаятьче түгел, усал ният белән берни дә кылмадым. Дөрес, мин гамьсезлек, судьялар теле белән әйтсәк, хезмәт вазифаларына салкын мөнәсәбәт күрсәткәнмен. Бу бит — җинаять түгел. Миңа, күп дигәндә, бер-ике ел мәҗбүри хезмәт бирерләр.

Әйе, мине иректән мәхрүм итүләре мөмкин түгел, һич тә мөмкин түгел! Яраткан эшемнән, әле нибары алты ел бергә торган, бер-березгә авыр сүзләр дә әйтешмәгән Гөлнарымнан, матур кызчыкларым Эльмира белән Лилиядән аерып... Өметем зур әле минем, каенкай!

Суд өстәле янында утырган хөкем итүчеләрне дә мин күреп беләм. Әнә, судья Хәлил ага Насретдинов. Аның аксыл чырайлы түгәрәк йөзендә, күз карашларында безгә, гаепләнүчеләргә карата, бернинди ачу да, дошманлык галәмәте дә күренми. Ул сорауларны да бик җай белән генә бирә, җавапны да ашыктырмый, ак керфекләрен йомып, сабыр гына көтеп утыра. Ул, яше пенсиягә якынлашкан агай, мондый эшләрдән тәмам туеп беткәндер, без ўйлап торган арада аз гына ял итеп, черем итеп аладыр кебек тоела миңа. Дөрес, аны законның һәр хәрефенә чатябыша торган вакчыл, җинаятьчеләргә карата аяусыз диләр. Әмма гаебе булмаганнарга карата шулай ук бик тә гадел диләр. Димәк, монысы минем файдага. Халык утырышчысы Вәкил Хәбибрахманов, урта яшьләрендәге бик чандыр, пеләш агай — журналист. Аның олы гуманист икәнен, төрле кыерсытылганнарны яклап, зур-зур мәкаләләр язганын, кирәк урында низагларга кереп йөргәнен бөтен район белә. Икенче халык утырышчысын — гел аска гына карап, мыштым гына утырган яшь ханымны мин әйбәт белмим. Больницада эшли кебек. Ул битараф төстә утыра, әледән-әле, авызын кулы белән каплап, иснәп ала.

Хөкемне алып баручыларның гадел буласына, мине аклаячакларына шигем юк.

Менә икенче көнен инде залда суд бара. Судьялар, прокурор һәм адвокатлар хөкемдә булучыларга, шаһитларга сораулар бирәләр. Мин ул сорауларның үземә кагылмаганнарын юньләп тыңламыйм да. Тәрәзә аша үземә кул изәгән каенкаема караштыргалап, боек кына утырам. Минем хәзер үк, хәзер үк өйгә кайтып китәсем килә. Өйгә кайтмаганыма инде бишбылтыр. Озакка сузылган тикшерүдән соң, судка кадәр дип, безне инде ике айдан артык ялгыз камераларга ябып тоттылар. Аһ, анда утырулары, аһ, сагынуларым! Бу суд дигәннәре тизрәк бетсен иде дә, Гөлнарым янына, нәни кызларым янына кайтып китәсе иде. Үземнең эш урынына, авыл профессиональ-техник училищесының баскычыннан йөгереп менәсе иде. Анда инде эш өелгәндер, эш өелгәндер... Мине монда ник алып килделәр, суд эскәмиясендә ник утырам соң әле мин?

Былтыр көзлектә, ниндидер киңәшмәдән соң, училище директоры Әһлиулла Хисматович миңа кабинетта калырга кушты.

— Ә беләсеңме, Сәүбән Зарипович, эшләр менә болай, җайсызрак дип әйтиммe, тора бит әле безнең,— дип башлады ул сүзен гадәтенчә бик озын һәм томанлы итеп.— Син минем урынбасар, филиаллар буенча дим. Ә безнең исә тиешле филиаллар саны җитми. Ягъни, әйтик, урынбасар штаты саклау өчен җитми.

— Ник, мин яңадан укыта башлармын!— дидем мин бу хәлгә бер дә хафаланмыйча. Әле урынбасар булганыма нибары бер ел, аңарчы дәресләр бирә идем бит!

— Нигә инде алай итәсең, әллә кая борма әле! Безгә яңадан бер филиал ачарга кирәк. Шуның белән вәссәлам!

— Кайда?

— Хәтәбе Лашманда.

— Нәрсә буенча?

— Сыер савучыларның белемен күтәрү буенча.

Лашман — элек район үзәге булган зур авыл. Анда моңарчы филиал ача алмавыбызга мин үзем дә борчылып йөри идем.

— Идея бу, Хисматович! Кайчан китәргә,— дидем.

— Эшләрең бик тыгыз булмаса, иртәгә үк. Приказ язармын.

Иртәгесен училищега иртүк менеп хәстәрен күрдем дә, юлга чыктым. Лашманда мин техникумда укыдым, кызлар белән йөрдем, Культура йорты салыштым, анда барырга күңел дә, аяк та тартып тора иде. Колхоз идарәсендә дә мине ачык йөз белән каршы алдылар.

— Безнең җиңгәчәйләргә гакыл өстисегез килә инде сезнең алайса. Барысын да алай бик югары классլы итеп бетермәгез тагын. Миннән акчаны күп даулап йөдәтерләр,— дип шаяртып алды колхоз председателе Фазылҗан абый һәм уйга калды.

— Укыту бик кирәк, бик хуш эш анысы. Тик менә аны кем өстенә йөкләргә әле бездә?

— Терлекчелектә механик бардыр бит?

— Барын бар да, белем ягы минем баш түбәседәй тап-такыр аның. Дипломлы белгеч булмаганга гына йөреп тора.

Сүзгә партком секретаре Һидият Галәвиев кушылды.

— Булдыра торган кеше ул безнең Хәмит абый. Нык куллы. Аңа бу эшне ышанып тапшырырга мөмкин дип уйлыйм.

— Аның нык кулы астына ике яшь белгечне дә куйсак? Диплом күтәреп әле быел килгән яшьләрне әйтүем. Мәсьәлә дигәнебез шушының белән чишелеп тә бетә,— диде Фазылҗан абый.

Хәмит Дәүлиевне чакыртып китерделәр. Механик Хәмит Дәүлиев тәбәнәк буйлы, туптай түгәрәк гәүдәле, төксе генә чырайлы кырык бишләр тирәсендәге кеше — миңа беренче караштa ук ошады. Аның куе кашлары астындагы елтыр күз карашында зирәк акыл сизелә.

— Мин риза,— диде ул бераздан.— Укыткан өчен түләү тәртибе нинди була?

Монысы да урынлы иде. Бәс, эшкә алынгансың икән, аның хакы белән дә кызыксына белергә кирәк.

— Бирелгән дәресләр, аларның темалары, сәгатьләре, укучыларның йөреше турында ай саен училищега белешмә җибәрәсез. Шуның нигезендә училище бухгалтериясе эш хакы җибәрә,— дидем мин.

— Монысы белән дә килешеп була икән,— диде Дәүлиев.

— Калган вак-төяген үзегез хәл итегез. Хәерле сәгатьтә, егетләр!— диде Фазылҗан абый.

Әгәр дә мин моның нинди сәгатьтә икәнен белгән булсам кана!..

Идарәдән без Дәүлиев белән бергә чыктык. Көзге кыска көн инде тәмам сүнгән, аязып, салкынайтып җибәргән, күктә эре-эре йолдызлар кабынып килә, каяндыр эт өргән авазлар ишетелә иде. Миңа ничектер бик шыксыз, уңайсыз булып китте.

— Безгә кузгалырга да вакыт. Сез курсларны ачып җибәрүгә тагын бер сугылырмын әле,— дидем мин.

Идарә болдырыннан төшкән якта Дәүлиев калын кашлары астыннан көлемсерәгән күзләре белән миңа туры карап алды.

— Сез инде, Сәүбән Зарипович, мине болай гына калдырып китмәгез. Бәс, шундый зур эш йөкләнгән икән, миңа аның тәртипләрен дә белергә кирәктер шәт. Бергәләп терлекчеләр йортына бармыйча булмый әле,— диде ул.

Моның эш кешесе икәне әллә каян күренеп тора иде.

Һәм без пычрак ерып, машина газаплап, авылның аргы башындагы, җәһәннәм астындагы фермага киттек. Ферма йортының боздай салкын бер бүлмәсендә мин Дәүлиевне терлекчеләрне укытуның тәртипләренә төшендердем. Амбар кенәгәсенә махсус журнал ачып, дәресләрнең те-

маларына кадәр үз кулым белән язып бирдем. Без төнге сәгать унберләргә кадәр утырдык. Колхозларга барып мондый эшләрне хәл иткәч, гадәттә, хуҗа кешенең сиңа карата җылы сүзе, кайнар чәе табыла. Мин дә Хәмит Дәүлиевнең дә безне үзенә чакыруын, кайнар чәй эчертеп чыгаруын көттем. Ләкин ул:

— Рәхмәт сезгә, Сәүбән Зарипович. Инде кайтырга да вакыттыр. Шофер егетегез дә көтә-көтә күчән булгандыр,— диде дә, башка берни әйтмәсен белдереп, тынып калды.

Шулай итеп без төнге сәгать унбердә алтмыш чакырымдагы училищега, чәй дә эчмичә, ката-туңа кайтып киттек.

Нәкъ тиешле көне җиткәч, эзенә генә таба бастырып, Лашман филиалыннан училищега дәресләрнең барышы турында бик пөхтә, төгәл итеп тутырылган белешмәләр килеп төште. Алар нигезендә Хәмит Дәүлиевкә һәм аның кул астында укыткан өч белгечкә — барысы дүрт кешегә хезмәт хакы җибәрелде. Филиал эшли башлаган, ул яктан тыныч булырга мөмкин дигән сүз иде бу.

Ә филиалларда укуларның барышына, программаларның төгәл үтәлешенә күз-колак булу — минем төп вазифам. Яңа ел алдыннан мин тагын Лашманга барып чыктым. Безнең якларда моңарчы күрелмәгән бик зәһәр, хәтәр салкыннар торган вакыт иде бу. Хәмит Дәүлиев мине артык куану да, әллә ни хафалану да күрсәтмичә каршы алды. Аның салынкы кашлары астыннан елтыраган күзләре генә һаман да күңелнең түренә үтеп керә торган итеп карыйлар иде.

— Дәресләр барамы, иптәш Дәүлиев?

— Дәресләр бара, Сәүбән Зарипович.

— Кайда әле журналыгыз?

Журналда дәрескә йөрүче терлекчеләрнең фамилияләре язылган, билгеләр куелган, барысы да тәртиптә иде. Мондый пөхтә журналны филиалларда сирәк очратасың.

— Сез киләсе айларга да дәресләрнең темаларын язып китсәгез икән, Сәүбән Зарипович,— дип үтенде Дәүлиев.— Зерә дә шәп булыр иде. Сез язып киткән безгә дөресрәк юнәлеш була инде ул.

Ни эшлисең, тагын бер сәгатьтән артык мәшәкатьләнергә туры килде миңа.

— Мин бүген дәресләрегезгә дә керәм әле. Карап карыйк, ниләр майтарып ятасыз икән сез монда! — дидем мин.

— Нәкъ менә бүген сез дәресләргә керә алмыйсыз әле,— диде Дәүлиев тыныч кына.

— Нишләп тагын? Ник алай ул? — дидем мин бик аптырап.

— Дәресләр үткәрә торган залның җылыту батареялары шартлаган. Төнге кочегар салмыш булган. Ә салкынны — үзегез дә күрәсез. Икс көнсез дә булмый әле.

— Ә Фазылҗан абый белән Һидият моны беләме? Алар дәресләрдә булдымы? Азрак кызыксыналармы?

— Аларның... кайда ул! Үз мәшәкатьләре муеннан ашкан,— дип кул селтәде Дәүлиев.— Аннары, алар миңа иман да китергән бит инде.

Шунда минем күңел түрендә бер шикләнү корты яралып, кыймылдап куйды. Әллә юкса бу агай минем күзгә төтен җибәрәме? Юк, алай булмаска тиеш. Үз сүзенең хуҗасы, намуслы кеше басып тора минем каршымда. Әнә бит, әле генә һәр теманы ничек бәйнә-бәйнә яздырды.

Әгәр мин шул чакта шикләнү кортының авазына колак салган булсам, кана!

Инде кайтырга җыенгач кына келт итеп искә төште: Гөлнар миңа ничек тә булса ике капчык фураж оны табып кайтырга кушкан иде. Безнең училище урман куенындагы аулак кына поселокта, укытучыларның күбесе үз йортлары белән тора, мал-туарын да асрый. Минем дә үз йортым. Абзардагы бура чаклы сыерыбыз соңгы көннәрдә тагарак

кимерә башлаган, бу салкында аны башаксыз калдырырга һич тә мөмкин түгел иде.

— Иптәш Дәүлиев, миңа бер-ике капчык фураж кирәк иде. Аны кемнән табарга булыр икән?— дидем мин.

— Минем үземдә юк ул. Ә менә Садыйковта артык ашлык бар иде шикелле,— диде ул.

Садыйков Айдар ферманың ветеринария технигы, филиалда дәрес бирүчеләрнең берсе иде.

— Ә аннан сорау... уңайсыз булмасмы соң? — дидем мин.

— Ул ягын үзегез чамалыйсыз инде, Сәүбән Зарипович. Бу вакытта эзләп тә кемнән генә табасың инде аны,— диде Дәүлиев.

Машинага утырдык та, Садыйковларга киттек.

Садыйков Айдар, кып-кызыл чырайлы, базык гәүдәле, кеше, безне бик кунакчыл йөз белән каршылады.

— Өйгә рәхим итәсез, Сәүбән Зарипович! Хәмит абый, син дә әйдә. Бу суыкта... Җылынып та чыкмыйча һич килешми,— дип тезеп китте ул.

— Сәүбән Зариповичның вакыты тар. Аңа ике капчык фураж оны кирәк,— диде Дәүлиев, әмер биргәндәй, коры гына.

— Ә, фураж... Бар ул. Кирәк икән — биш капчык.

Садыйков келәтеннән ике капчык онны машинага чыгарып та салдылар.

— Ничә сум тиеш соң миннән? — дидем.

— Куйсана, Сәүбән Зарипович! Сездән ниткән сум ди ул. Күпме ярдәмегез... — диде Садыйков һәм шунда капылт тукталып калды. Дәүлиев каш астыннан гына аңа бик сәер итеп карап тора иде.

Шунда, нидер сизенгәндәй, минем күңел түрендәге шикләнү корты тагын бер кыймылдап куйды. Ләкин күп уйланып, нәрсә дә булса төпченеп торырга вакыт юк, кич җитеп килә, буран да күтәрелергә чамалый иде.

Мин ашыгып кулымны кесәгә тыктым һәм... менә шайтан алгыры! Янчык өйдә онытылып калган, кесәдә сукыр бер тиен дә акча юк иде.

— Акча да юк икән әле монда, егетләр,— дидем мин бик уңайсызланып.

— Икенче килгәндә булыр,— диде Дәүлиев.

Мин Лашманга икенче кат тиз генә барып чыга алмадым. Китте котып салкыннары, китте бураннар... Алма, чия агачлары өшеп бетте ул елны. Садыйковка бирәчәк турындагы уй да тора-бара искерде, аңа атап кесәгә тыгып чыккан акчалар да тотылып бетә барды. Акрынлап минем күңелдә икенче бер уй урнашты. «Ә дөресе дә мин аларга күпме булыштым. Салкын бүлмәләрдә алар өчен журналлар тутырып утырдым. Соңыннан сырхаулап та йөрдем бугай әле. Шул ике капчык фураждан торырга алар...» — дип тынычландым мин.

Сазламыкка, акрынлап гел тирән тарта торган баткаклыкка адәм баласы әнә шулай ансат кына, үз аягы белән барып керә. Аның өчен туры сукмактан аз гына читкә тайпылып аласы бар.

Инде кыш урталары үткәч, Хәмит Дәүлиев училищега үзе килде. Нәүбәттәге белешмәләрен дә алган. Бухгалтериядә эшләрен бетергәч, ул миннән үзен озата чыгуын үтенде. Без аулак бер өйгә кердек. Өстәлгә шешә дә килде. Дәүлиев бүген нигәдер бик тартына, мескенләнеп кенә утыра иде.

— Нәрсә? Ни булды тагын? — дидем мин.

— Ничек дип әйтергә дә белмим әле, Сәүбән Зарипович. Эшләр бик начар бит безнең... — диде ул ихлас күңелдән борчылган төстә.

— Соң, нәрсәсе начар тагын?
— Дәресләрне һаман да башлап җибәрә алганыбыз юк бит.
— Ничек? Теге батареялар шартлаганнан соңмы?
Дәүлиев каядыр, читкә карап, авыр итеп көрсенде.
— Алай гына булса иде ул... Гомумән дәресләр биргәнебез юк безнең,— диде ул.
Бу сүзләрдән мин, башыма күсәк белән китереп органдай, миңгерәүләнеп калдым шикелле. Гәрчә моңа кадәр нидер сизенеп йөрсәм дә. Бу... җинаять иде! Чын мәгънәсендә һәм зур җинаять. Мин хәтта куркып, шомланып калдым, ышанасым килмәде.
— Әкият сатма, иптәш Дәүлиев. Ниҹек инде алай була алсын?!
— Шулай менә. Башта без вакытында оештырып җибәрә алмадык. Аннан... батареялар, нинди салкыннар китте. Шулай итеп калды да калды инде,— диде ул.
— Тукта әле, ни сөйлисең син? Колагың ишетәме? Син бит укулар башланды, укулар бара дип, күпме белешмәләр җибәрдең. Күпме акчалар алдың. Монысын ничек итеп аңларга кушасың? — дидем мин, аның күзләренә керердәй булып.
— Килергә тиешле акчалар булгач, алдым инде...
— Ничек тиешле булсын?! Бу бит, агайнем, уен эш түгел. Моннан бит нәрсә исе килә?! Син шуны беләсеңме?
— Анысы шулай инде. Ул акча дигән тәреләреннән үзем дә куркам хәзер.
— Беләсеңме, мин сине ни эшләтәм хәзер? Беләсеңме, тиз көннәрдә син кайда утырачаксың?
— Утыруга китсә, без анда бергә булмагаек әле?
— Юк инде, агайне! Син мине бутама!
— Мин сезне бутамыйм анысы, Сәүбән Зарипович. Ул-бу була калса, мин сезне акларга да тырышырмын. Тик менә вәкаләтле агайлар, директор урынбасары бу көнгә тикле моны ник белмәгән, ник чарасын күрмәгән, дип җибәрсәләр? Монысына ни чара? Хәзер безгә сүзләрне бердәм тотып эш итәргә генә кала инде, Сәүбән Зарипович! — диде Дәүлиев.
Минем башка тагын берне китереп органдай булды. Кулларым салынып төште.
— Соң, ни эшлибез хәзер?..— дидем мин, тәмам вайран калып.
— Артыгын борчылырга да урын күрмим әле мин, Сәүбән Зарипович,— диде Дәүлиев.— Ә бит, беләсезме, укуларны аны киләсе көзгә дә оештырып була. Нәкъ шушы программа белән. Иманым камил, киләсе көзгә гөл кебек итеп оештырып җибәрәм, гөл кебек итеп алып барам мин аны! Бушлай укытабыз. Шулай булгач, безнең алган акчалар да хәрамга булмый. Бер тиене дә... һәм моны гөнаһка да алмаслар, дип уйлыйм мин. Эшлибез аны, Сәүбән Зарипович, бер дә хафаланмагыз. Хәмит сүзе нык булыр!
— Ә колхоз җитәкчеләре, партком ни әйтер?
— Алар барысын да белә инде. Тик менә эш хакын гына... Анысын инде мин аларга әйтеп тормадым. Башка берәүләр генә сүз сала күрмәсен...
Без, акбашлыны бушатып, байтак сөйләшеп утырдык. Хәмит Дәүлиев киләсе көзгә филиал эшен ничек башлап җибәрәсе, инде терлекчеләрнең һәркайсы белән ничек сөйләшеп, вәгъдәләшеп куелганы, алар да моны хуплаганы турында миңа бәйнә-бәйнә сөйләп бирде.
Мин дә бераз тынычлана төштем. Хәзер инде, дөрестән дә, уку елы үтеп бара, тавыш күтәрүнең файдага караганда зыяны күбрәк булуы бик ихтимал иде.
— Сүзләр бердәм булсын инде безнең. Сәүбән Зарипович. Егетләр сүзе булсын! — диде Дәүлиев нык итеп.

— Бердәм булыр. Егет сүзе...— дип җөпләдем мин. Ә үземнең күңел түрендә: «Ниткән сүз ул? Кемгә вәгъдә биреп утырасың әле син? Иртәгә үк, юк, бүген үк барысын да фаш итәргә! Ни булса да булыр. Намусың чиста калыр...» — дигән авазлар яңгырый иде.

Кеше үзенең күңел авазына гына буйсынып яшәсә, кана!

Инде саубуллаша башлагач, Дәүлиев куен кесәсеннән алып миңа кыштырдап торган өр яңа йөз сумлык акча сузды.

— Бу ни өчен миңа? Юк, юк, кирәкми! — дидем мин.

— Ә бу ихлас күңелдән генә, Сәүбән Зарипович, башка берни дә түгел,— диде Дәүлиев.— Безгә күрсәткән булышлыкларыгыз өчен. Миндә дә намус дигән нәрсә бар... Киләсе көзгә бушка эшләячәкбез. Сез анысын да исәпкә алыгыз,— дип өстәде ул томанлы итеп.

Их! Аягы белән сазлыкка бер адым ясагач, инде икенче адымны ясаудан тартынып торамы соң адәм баласы?

— Сез безгә тагын бер килеп китәрсез инде, Сәүбән Зарипович,— диде Дәүлиев китәр алдыннан.

— Анысы нигә тагын?

— Соң, аның имтихан дигән нәрсәләрен дә, ничектер, рәсмиләштерми булмас инде.

— Ә... әйе шул.

Шулай да өйгә бик борчылып, кәефем кырылып кайтып кердем. Теге йөз сумлыкны да ничек алай ансат кына алып кесәгә тыкканымны хәзер үзем дә төшенә алмыйм, ул акча кием аша минем күкрәгемне кыздыра, йөрәгемне пешерә сыман иде. Өйгә кайтып керүемә, аны сервантның иң аскы тартмасына салып куйдым. Гөлнарны да кисәттем.

— Бу акчаны... Моны тота күрмә. Кешенеке. Саклап торырга гына бирде,— дидем. Ул минем шәхси эшләремә артыгын тыкшынмый иде. Төпченеп тә тормады.

Чишенеп диванга утыруыма кызларым Эльмира белән Лилия миңа килеп сарылдылар. Алар белән кайнашып авыр уйларым да онытылды.

Шулай бит ул: тора-бара тән сырхаулары да, җан җәрәхәтләре дә үтә, кайгы-хәсрәт, борчулар да басыла. Адәм баласы шулай яратылган инде. Көндәлек мәшәкать белән мин дә шактый тынычлана төштем.

Инде Лашманга яңадан барырга, колхоз җитәкчеләре белән дә хәлне ачыктан-ачык сөйләшеп, анда эшләрне җайга салып кайтырга җыенып йөри идем, мине район үзәгенә, прокуратурага чакыртып алдылар.

Шунысы гаҗәп, бу мине тамчы да куркытмады. Тикшерүче дә бик таныш кешем, мин әле күптән түгел генә аның җиңел машинасын төзәтеп биргән идем. Теләсәм, мин аннан күп нәрсәләрне, теге ике капчык фураж белән йөз сум акчаны, хәтта укулар бармаганын белгәнемне дә яшереп кала ала идем. Ә нигә? Бернинди хәрам кертмичә, барысын да бәйнә-бәйнә сөйләдем дә бирдем. Ахыр чиктә мин бит җинаятьче түгел, усал ният белән берни дә кылмадым. Ник тел яшереп маташырга миңа?

— Моны җинаятькә санамаслар, шәт. Мине төрмәгә үк җибәрмәсләр? — дидем мин өмет белән.

Тикшерүче, калын күзлеге астыннан искиткеч дәү булып күренгән күзләрен миннән каядыр читкә текәп, ни әйтергә белми байтак торды.

— Ай-һай, Сәүбән, дус кеше. Кечкенәдән түгел бу эш. Хәмит Дәүлиев берүзе мең ярымга якын акча үзләштергән. Хәтта терлекчеләргә дип җибәрелгән стипендия акчаларын да үз кесәсенә салу җаен тапкан. Мәсьәлә авыл хуҗалыгын күтәрүгә аяк чалу төсен ала... Синең ул йөз сум акчаң белән ике капчык фуражың да бик начар нәрсә. Ришвәт алу бит бу! — диде ул йомшак кына.

— Нинди ришвәт? Ниткән ришвәт булсын ул?!

— Һе, ә ришвәт тагын нинди була дисең?

Тикшерүдән соң мине өйгә кайтармадылар. Район эчке эшләр бүлегендәге камерада ике ай утырдым. Янәшәдәге камерада — Хәмит Дәүлиев.

Бу ике ай эчендә мин барысын да кат-кат уйладым, һәр адымны күз алдыма китереп барладым. Ясаган нәтиҗәм шундый: гаебем зур түгел минем. Гамьсезлек, йомшаклык күрсәтү, кемнеңдер усал ниятенә юлыгу. Бу — үзең дә җинаятьче дигән сүз булмаска тиештер әле. Мин бит бер нинди явыз ният тотмадым.

Менә инде судның икенче көне кичкә авышты. Хәзер инде эшләр тәмамланып та килә.

Менә судьялар аерым бүлмәгә, киңәшкә кереп киттеләр. Безнең язмышны хәл итәргә. Түз, йөрәгем! Мине аклarлар. Мин ышанам.

Судьялар бик озак — бер сәгатьтән артык киңәштеләр. Һәм, ниһаять:

— Суд килә!

Бөтен зал — шаһитлар, болай тыңларга кергән кешеләр аякка басты. Бөтен халык тирән итеп, әллә нинди дәһшәтле итеп бер сулап куйды. Барчасының карашы судьяларга түгел, ә безгә — хөкемдәгеләргә текәлде. Һәм безгә төбәлгән бу карашларда гаҗәпләнү, кызгану, җирәнү аермачык күренеп тора иде. «Менә нинди кешеләр үзләре, ә нәрсә эшләгәннәр бит. Җәза аларга! Аяусыз хөкем!»— дигән теләкне күрдем мин бу карашларда.

Судья Хәлил Насретдинов ак тимер кысалы күзлеген киде. Залда дәһшәтле тынлык урнашты.

— ...Эшләгән барлык җинаятьләре өчен Хәмит Дәүлиевне алты елга ирегеннән мәхрүм итәргә һәм хөкем карарын каты режимлы колониядә үтәтергә! — дип укыды судья. Бөтен зал, теләктәшлек белдереп, гөрләп куйды. Мин җәзаның катылыгына таң калып, янәшәмдә басып торган Хәмит Дәүлиевкә карадым. Аның йөзенә мәет сарылары йөгергән, үзе бер туктаусыз башын чайкый иде.

Кинәт миңа залның иләмсез киң түшәме түбәнәя, иңнәремә төшә, ә стеналары як-яктан китереп кысарга җыена кебек тоелды. Судья миңа карата чыгарылган хөкем карарын укый иде:

— Сәүбән Зариповны дүрт елга ирегеннән мәхрүм итәргә һәм җәза срогын каты режимлы...

Залда басып торган Гөлнарым, яшь тулган күзләрен мөлдерәтеп, кулларын миңа таба сузды. Ара якын, тик мин еракта, бик еракта идем шул.

Каенкаем да тәрәзә аша мине сәламли, әйтерсең янына чакырып, тармакларын тибрәтә, тик мин анда да чыга алмый идем инде.

# АРЫШ ТАМЫРЫННАН ҖЫР ДА ШЫТА

*Рәшит Гәрәй иҗаты — асылда үзенчәлекле, матур иҗат һәм шигъриятебез мәйданында аның кабатланмас урыны бар.*

*Әлеге үзенчәлекләр хакында сүз башлаганга кадәр, «телеграф теле» белән генә булса да, шагыйрьнең тәрҗемәи хәленә тукталып үтик, чөнки иҗат чишмәсенең башы шунда.*



*Бөек Ватан сугышы башланган елны Рәшит Гәрәйгә ун яшь тула. Олы афәтнең беренче көннәрендә үк ул әтисенең яу кырында батырларча һәлак булганын ишетә. Колхоз атларын көтү... Сабан сөрү... Почта йөртү — өйдән өйгә хәбәр ташу, ә хәбәрләр төрле-төрле... Туган авылы Малтабар һәм урта мәктәпле Күзкәй авылы арасындагы уку еллары озынлыгындагы юллар... Аннары — Иске Мәлкән һәм Тойгузино мәктәпләрендә укытучы булып эшләү. Экстерн тәртибендә Минзәлә педагогия училищесын тәмамлау. Республика яшьләр газетасының әдәби хезмәткәре. Совет Армиясе сафларында хезмәт итү. Мәскәүдә М. Горький исемендәге әдәбият институтында уку еллары. Ә йөрәктә һаман Минзәлә яклары, авыл манзаралары...*

*Боларның барысы да Рәшит Гәрәй иҗатының үзенчәлеген күрергә ярдәм итә торган баскычлар. Иң беренче булып күзгә ташлана торган үзенчәлек — бу шигырьләрнең аркау җебе халык иҗаты булуында. Шагыйрь, халык җырларының тышкы формасыннан файдалану белән бергә, традицион булып киткән образлар һәм детальләр белән дә эш итә. Шулар нигезендә ул җырлап тора торган ягымлы, моңлы, чын мәгънәсендә халыкчан шигырьләр иҗат итүгә ирешә.*

*Рәшит Гәрәй бөтен кальбе белән «авыл» шагыйре. Дөрес, шагыйрьләрне «шәһәрнеке»нә, «авылныкы»на бүлү үтә дә шартлы. Әмма «авыл» шагыйре дигән билгеләмә, башка шагыйрьләргә караганда, Рәшит Гәрәйгә күбрәк туры килә, аның иҗат үзенчәлеген тулырак, төгәлрәк ачарга ярдәм итә. Ни турында гына язмасын, бу шагыйрь дөньяны уҗымнарга төшкән чык бөртекләре призмасы аша, арыш серкәсе томаны аша күрә. Рәшит Гәрәйнең сурәтләү чаралары нигезендә фәкать авыл күренешләре, авыл буяулары, әсәрләренең геройлары — авыл кешеләре. Хәтта самолетны да ул без күргәнчә зәңгәр күк фонында түгел, ә басулар, авыл кырларындагы уҗым җирлегендә күрә. Диңгез турында язганда да, шахтаны сурәтләгәндә дә, Казан урамнары шавын җырлаганда да ул авылда гына була торган буяулар, тавышлар, әйберләрдән файдалана. Авыл аның өчен тема гына түгел, ә уй-фикерләренең, иҗатының, мәхәббәтенең табигый халәте. Шушы халәттән читкә тайпылмаганда шагыйрь һәрвакыт диярлек иҗади уңышка ирешә, гади шигырь юлларына киеренке хисләр, олы мәгънә, барлык хакыйкате белән чынбарлык керен тула.*

*Кырык бернең җәе искә төшә*
*Тугайлардан атлар кайтканда.*
*Кешеләр генә түгел, ул елны бит*
*Армиягә китте атлар да.*
*Аларга да җиңел булмагандыр*
*Соң кат күрү туган җирләрне.*
*Кемдер шунда: «Атлар елый...» — диде*
*Һәм үзе дә үксеп җибәрде.*

*Йөрәккә кан сауган ул көннәрне*
*Оныта алмыйм менә бүген дә.*
*Яу кырында калган байталларның*
*Кешнәүләре колак төбендә.*

*Гасырлар дәвамында кешегә тугры хезмәт иткән ат турында шигырьләр бик күп. Татар әдәбиятында да алар дистәләгән. Ләкин менә мондый, ат моңын кеше моңы дәрәҗәсенә күтәреп, шул моңга ил моңын куша алган шигырьләр, дөресен әйтергә кирәк, әллә ни күп түгел.*

*Рәшит Гәрәй шигырьләре гаҗәеп җылылык, кече күңеллелек белән өртелгәннәр. Аның «Мендәр», «Васыятен дә әйтеп калдырмаган», «Каен кистем», «Җырлы вагоннар», әнисенә, дусларына багышланган шигырьләрендә дөньяны, тормышны, кешеләрне өзелеп ярату хисләре сәнгатьнең олы казанышлары дәрәҗәсендә, шул ук вакытта үзенчә — Рәшит Гәрәйчә чагылыш тапканнар. Чын сөюне белдерү өчен «яратам» сүзе генә көчсез. Шуңа күрә шагыйрь «яратам»ны чамасын белеп кенә куллана. Ә иленә, халкына, туган авылына булган олы хисен «буразна җене кагылган» шигырьләре, арыш тамырына береге үскән уйлары, тургай, бытбылдык, киек каз авазларыннан төзелгән сүзләре белән җиткерә.*

*Табигате белән йомшак күңелле Рәшит Гәрәйнең иҗатына да йомшак күңеллелек, сабырлык, тыйнаклык хас. Аның тормыш һәм иҗат, иҗат һәм шагыйрь, шагыйрь һәм тормыш турындагы уйлары-борчылулары «Сабантуйда шигырь укыттылар» дигән әсәрендә иң киеренке ноктага җитә:*

*...Егылганны кем соң күккә чөйсен?!*
*Башым минем түбән иелгән.*
*Сөялләнгән куллы аксакаллар*
*Килеп кага шунда иңемнән.*
*Якын итеп биргән киңәшләрен*
*Гомер буе юлдаш итәрлек:*
*— Җырларыңны өйрәт көрәшергә,*
*Сабантуйлар алда җитәрлек!*

*Ә безгә калса, Рәшит Гәрәйнең күпчелек шигырьләре — оста, көчле көрәшчеләр. Һәм алар мәйдан тоткан урын — кеше күңеле. Шагыйрьнең югары сәнгатьлелеккә ирешкән бик күп әсәрләре укучы күңелендә кешелеклелек гөлләре чәчәк атсын өчен мәйдан әзерлиләр, укучының күз карашына, сүзенә, җанына җылылык өрәләр, атаанага, дусларга, бала-чагага мәрхәмәтле булырга өндиләр. Рәшит Гәрәйнең иң яхшы шигырьләрен укыганнан соң күңелеңнең бәхеткә дә, кайгыга да сизгеррәк була төшүен тоясың.*

**Ренат ХАРИС.**

## Рәшит Гәрәй

### Ветераннар җырлый

Ветераннар җырлый, ветераннар...—
Бергә туры килгән чакларда.
Сагыш-моңнар тулы җырларын мин
Ишеттермәс идем ятларга.

Дуслар өчен генә җырлый алар,
Күңелләре киткәч нечкәреп:
— Нинди генә утка кермәдек без,
Нинди генә сулар кичмәдек!

Йорт-җирләрдән бергә чыгып киткән
Илдәшләрнең истә сүзләре...
Эзләшегез, дуслар, табышыгыз,
Кайда икән алар үзләре.

Европаның кайсы үрләреннән
Аваз сала алар таңнарда?!
Юк, сүнәргә тиеш түгел алар,
Тиеш алар мәңге янарга.

Учак дөрләткәндә, бер урынына
Дөрләтәбез һәрчак икене.
...Үзебез генә исән калуыбызга
Гаебебез бардыр шикелле.

### Якты маяк булып

Хәтта хыял кочагына сыймый
Киң колачлы илем.
Бер-берсеннән матур калаларын
Күргәнем бар минем.

Кояш юмарт балкый һәркайсының
Якты карашында.
Тик син, Казан, миңа иң якыны
Алар арасында.

Тыныч төннәреңдә сабыйларың
Рәхәт изрәп йоклый...
Мәйдан уртасына басып, сине
Ильич үзе котлый.

Таңнарыңның көлеп туачагын
Ул бит алдан белгән.
Күкрәп чәчәк аткан гөлләреңә
Сәйдәш моңы сеңгән.

Көр авазлы җырың ишетелә
Бөтен җир шарына.
Күгең нинди иркен — канат җилпеп
Очар кошларыңа!

Гүзәллегең таң калдырмый икән
Бүген кемне генә?!
Бөек Мусаң горур карап тора
Идел киңлегенә.

Якты маяк булып янгансың син
Аның тормышында.
Ул сине дә уйлап елмайгандыр
Соңгы сулышында.

Сер сынатмас улларыңның сиңа
Мәхәббәте тирән.
Бәхет сиңа кунак булып түгел,
Гомерлеккә килгән.

## Кадер-хөрмәткә ия син

Кичкырын авыл юлыннан
Бер көйгә атлап кайтам.
Башакларның серле шавын
Җыр итеп ятлап кайтам.

Кояш инде батып бара,
Эңгер дә төшәр тиздән.
Шактый җир җәяү узылды,
Арганлыгымны сизәм.

Туган җир бит үзе мендәр
Без — авыл баласына.
Керәп йокларгамы әллә
Арышлар арасына.

Башаклары битләремнән
Сыйпап уятыр иртән.
Бу күңел ник игеннәргә
Шул кадәр гашыйк икән?!

Кайгыларым бетә, алар
Сарылсалар иңнәргә.
Кадер-хөрмәткә ия син
Бары туган илләрдә.

## Гомерем инеше

Кұр, нинди саф чишмә,
Төпләре — күзгедер?!
Картларга ышанам:
Бу чишмә изгедер.

Үзенә юл ярып
Ага ул тын гына.
Әйтерсең дәшә ул:
— Колак сал моңыма.

Суым эч... дулкыным
Битеңә кагылсын.
Еракта йөргәндә
Бер искә алырсың.

Бүлдерми тыңладым
Авазын чишмәнең.
Йөрәкне дөрләтеп
Кабынды хисләрем.

Уйланып бик озак
Юандым кырыңда.
Никадәр аһәңне
Сыйдырган җырына!

Бу җырга әнкәмнең
Моңы да кушылган.
...Гомерем инеше
Башланган шушыннан.

## Йолдызлар ява икән

Урләргә менгән чакта да
Атларны ардырмадык.
Яшьли сөйгән ярларны без
Ятларга калдырмадык.

Тормыш юлдашы иттек тә
Кердек кочакларына.
Таяныч булдык аларга
Иң кыен чакларында.

Пар учакларда утлар да
Яктырак яна икән.
Яшьлектә җиргә кар түгел,
Йолдызлар ява икән.

## Сулар үргә акса да...

Сез бит әле бик-бик яшь идегез,
Мин хушлашып моннан киткәндә.
Сөзәк ярлар буйлап сулар түгел,
Еллар шулай ага икән лә.

Күрче инде ничек үзгәргәнсез,
И талларым минем, талларым!
Гомерем буе, ахры, үкендерер
Сезне назлап яши алмавым.

Күңелем белән ләкин мин һаман да
Янычызда сезнең калырмын.
Хәтта сулар үргә аксалар да
Мин барыбер сезне танырмын.

## Тургайларга сөенеп сәлам бирәм

Әйтерсең мин шушы басуларга
Каравылчы итеп куелган!
Кәтү әле кырга чыкмас борын
Урап кайтам авыл буеннан.

Тургайларга сөенеп сәлам бирәм —
Тавышлары көр дә, матур да.
Моңнарын, әй, түкми-чәчми җыеп,
Казаннарга алып кайтырга!

Яңгырасын иде сәхнәләрдән,
Сыялмыйча иркен залларга...
Шул да җитәр иде җырга гашыйк
Игенченең җанын аңларга.

## Якты бул син, җырым

Авыр юллар хәлдән тайдырдымы,
Чәчләремне ак кар сардымы?
Көтмәгәндә тавышым көчсезләнеп,
Ирексездән тынып калдыммы?

Үземә дә әллә сиздермичә
Хисләремме бара сүрелеп?
Дусларыма җырлыйм дигән җырым
Ярты юлда кала бүленеп.

Ялкынланмый, очкын чәчрәтми ул
Һәм ашыкмый алга узарга:
Әйтерсең лә каршы тора алмый
Юлын кискән силгә, бозларга.

Кырыс заман, әйе, җырларны да
Кыл иләкләр аша үткәрә.
Сынатасың икән бу сынауда,
Чорга түгел, үзеңә үпкәлә.

Эчтән ятлап йөргән сүзләремнең
Тигез рәткә тезәм һәммәсен.
Ихлас сүздә генә һәр нәрсәнең
Тоя йөрәк тулы мәгънәсен.

Арыма, җырым, көчле һәм якты бул,
Ахыргача бул син янымда.
Гади кешеләрне сөю хисе
Сүрелмәсен берүк канымда.

## Тәүфикъ Камалиев

# КЫРЫК ЯШЬТӘ

●

*Айратка*

Кырык яшьтә кеше кырык төрле,
Уйга батып ярыла кырыкка.
Бу тормышта йөзгә ярылсаң да
Юк, курыкма икән, курыкма!

Кырык яшьтә инде ир-затларның
Куна чәченә тәүге кыраулар.
Бик еракта калган кыңгыраулар,
Сиңа бәхет, ак юл юраулар.

Әниләрнең бәхет юраулары
Юш килсә, һәм хәтта килмәсә,
Кыңгыраулар моңы барыбер татлы,
Төшләреңә кереп эндәшә.

Кырык яшьтә кешенең юлларында
Кырыкмаса кырык бусага.
Бусагалар... ләкин узу кирәк
Адым саен егылып булса да.

Кырык яшьтә кеше бу тормышның
Бик күп татый ачысын, төчесен,
Тик кырыкта әле язмыш түгел,
Син көчлесең, кылыч төслесең.

Әйе, әйе, әле син кыныдан
Алган гына кылыч кебексең,
Язмыш үзе үтә киселерлек,
Ә кисәргә тиеш егет — син!

*Январь, 1980*

---

Шигырьләр арабыздан яшьли киткән шагыйрьнең архивыннан — үзе исән чакта төзеп өлгерә алмаган яңа китап кульязмасыннан — сайлап алынды. Редакция.

## Яңа елда

Яңа елда һәркем теләк тели,
Яңа елда эшләр уңачак,
Ел буена ашмый йөргән уйлар
Яңа елда кабул булачак.

Яңа елда насыйп булсын әйдә
Яңа хисләр белән янарга!
Яңа елда инде онытылган
Хатирәләр кабат яңара:

Халык әйтә: «Яңа елда кардан
Икмәк тәме килә, ди, бездә!»
Ахры, хактыр — ак калачка охшап
Ай тәгәри зәңгәр диңгездә.

Яңа елы яңа бишьеллыкның
Капкасы күк яңа дәвернең.
Дәвер безгә дәү-дәү эшләр йөкли,
Дәү кешеләр итеп, кадерлем.

Галиҗанәп эшче сыйныфының
Миссиясе безгә бик изге.
Миссиясе аның бишьеллыкка
Биек итеп салу нигезне.

Теләкләрне шуңа зурдан телик
Зурдан кубып — килер замана
Магелланнар диеп белсен безне...
Магелланга тиңләр чамада!

Берәүгә дә гомер ике килми,
Ике кабат кайчан яшьнәргә?
Теләк телик: шушы бер гомерне
Ике гомер итеп яшәргә.

*Январь, 1980*

●

Ашыкмый башта ачы җил,
Көч, куәт җыя-җыя,
Берәмләп ул алмагачның
Чәчәген генә коя.

Берәмләп йолкый яфрагын,
Берәмләп җиңмәк була...
Ак күлмәк кигән алмагач
Кызлардан иртә сула.

Ачы җил ачы сызгырып,
Зилзилә, давыл булып,
Ботарлый һәрбер ботакны
Бөрегә хәтле буып.

Тартыша бары тамырлар —
Тирәнгә киткән алар.
Ачы җил белән, яңгырлар
Яуса да читкә явар...

Ачы җил, давыл, зилзилә...
Кайсысы кайсын җәлләр!
Бүтәнчә димсең тарихта?
Анда да шул ук хәлләр...

*21 январь, 1980*

●

Бу дөньяда һәркем үзенең хакын сорар:
Мал кортлары — уч тутырып алтын сорар,
Акыллылар тагын бир дип, акыл сорар,
Юләр — гүзәл вә сылу бер хатын сорар.

Шуларны син диваналар димә инде...
Бай кешегә уч-уч алтын нигә инде?
Акыллыга тагын акыл нигә инде?
Шыр тилегә матур хатын нигә инде?

Чү, ашыкма! Байның нәфсе юк дисеңме,
Акыллыга хәким булу чүп дисеңме,
Тилеләрнең эчтә җаны юк дисеңме,
Ә матурлар әллә шулай күп дисеңме?

Тик калачак... алтын-көмеш — бүтәннәргә,
Хәким өлеше — бер хөкемсез — бүтәннәргә,
Син яраткан сылулар да калачак бит
Иң сөймәгән дошманыңа — бүтәннәргә...

*16 январь, 1980*

## Эзлим, эзлим

Календарьлар... рәттән актарамын,
Көндәлекне читкә куям да,
Үз урынында икән барлык көннәр,
Мин эзләгән көн тик юк анда.

...Әллә сизгән, килеп сарылды да,
Җибәрмәскә теләгән шикелле,
Үксеп куйды,— нелеп юлларына
Гөлләреңне учлап сип инде!

Барлык көннәр, төннәр арасыннан
Ул көнне мин таныр идем дә,
Аңа ничек урап кайтырга да,
Кай юллардан, кайчан килергә?!

Язмышыма шулай язылгандыр,
Соңладым шул... күпме яшь түктем:
Календарьдан ертып алганнар ич
Без кавышасы көнен яшьлекнең.

Җил очырткан аны кай якларга?
Кайчан да бер табылыр кебек лә!
Эзлим-эзлим... Кире үз урынына
Кайтмаслыгын үзем белеп тә.

*9 сентябрь, 1965*

●

Су төбендә йолдыз җемелди —
Соңгы өмет кебек... Төптә үк.

Ә камышлар, тынып калганнар,
Камышларның тыны беткән күк.

Су төбендә йолдыз җемелди,
Нәни маяк кебек — ерактан.
Я охшый ул ятим кызларга,
Гүя аны берсе елаткан.

Су төбендә йолдыз җемелди —
Соңгы өмет кебек... Төптә үк:
Юк, яңадан күккә ашарга
Кодрәт көче кимегән, беткән күк.

...Җемелдәми инде йолдыз да.
Сулкылдар да йөрәк сулкылдар.
...Агып китте якты йолдызым,—
Алып китте зәңгәр дулкыннар.

*26 январь, 1980*

Фәтхулла Абдуллин

# ЧАКЫРУЛАР

Казан авыл хуҗалыгы институты ректоры Николай Семенович Катков белән өлкән укытучы Мөбәрәкҗан Гатинович Гатинны КПСС өлкә комитетына чакырганнар икән. Институтка бу хәбәр килеп төшкәндә аларның икесе дә совхозда иделәр. Инде менә алар шәһәргә кайтып баралар. Җиңел машина түбән төшкәндә дә, тауга менгәндә дә тизлеген киметми — бердәй чаба. Юл читендәге куаклар, әйтерсең шыта башлаган бөреләрен саклап читкә тайпылып калалар шикелле. Ә юл кырыендагы баганалар, гүя кемнедер эзләгәндәй, каршыга килеп чыгалар да, машина үтеп киткәч кирегә, бүтән юлаучыларга таба йөгерешә...

Суы кайнап чыкты ахры, радиатордан пар бөркелә башлады. Шофер егет машинасын тиз генә юл кырыена барып туктатты да чиләк күтәреп үзәнлеккә төшеп китте. Мөбәрәкҗан Гатинович та машинадан чыкты. Тирә-якта кая карама — яз галәмәте. Әйе, яз-язлыгын итә. Әле кайчан гына адым саен гөрләвекләр ага, тез тиңентен пычрак иде. Ә хәзер, кара, ничек җилләткән. Күктә сабан тургайлары. Кулларыңны маңгаеңа куеп, башыңны югары күтәреп карасаң, зәңгәр күк йөзендә нокта булып кына күренәләр.

— Мине Чаллы МТСында баш инженер булып эшләгәндә дә шушылый җәһәтләп өлкә комитетына чакыртып алганнар иде,— диде ул юлдашы Николай Семеновичка.— Ул чагында да нәрсәгә чакырттылар икән юл өзегендә, нинди ашыгыч эш килеп чыкты икән дип баш ватып барган идем...

«Борчыла,— дип уйлады Николай Семенович.— ...Тыштан тыныч күренсә дә. Ә Гатин чая һәм гаярь егет булган диләр ләбаса! Очучы. Бусы инде сугыш еллары, фронт».

Шулай бер чакны өйрәнүләр вакытында Гатин утырган самолетның бомба ташлагычы сафтан чыга. Самолетта килеш аста ни барын күреп булмый. Бәлки ул бомбаның бер башы ычкынып, икенче башы эләгеп калгандыр? Җиргә төшкәч кенә самолет астында шартлавы ихтимал. Ул чагында хуш, кара кашым, Гильмиямал! Ә аста болыннар, урман-күлләр, иксез-чиксез иген кырлары җәйрәп ята. Юк, болай борын салындырып утырудан эш чыкмас. Штурман линеткасын алып, Мөбәрәкҗан урыныннан күтәрелә. Аның битенә куәтле һава агымы килеп бәрелә, шлемы читеннән чыгып торган бөдрә чәчен йолкып алырдай көч белән җилфердәтә. Очучы егет, иптәшенең гадәттән тыш тәвәккәллек эшләргә җыенганын сизеп, артка борылып карый. Самолет чак кына чайкалып куя.

— Артка карама!— дип кычкыра Мөбәрәкҗан.— Самолетны авыштырма! Күзең тигезлектә булсын!

Һәм үзе самолетның канатына чыгып баса! Бер кулы белән ике канатны тоташтырган тимерләргә тотынып, икенче кулындагы линеткасы белән канат астына беркетелгән бомбага үрелеп карый. Юк, берничек тә буй җитми! Аскы канатка ятып карарга кирәк. Аннан буй җитәргә тиеш. Иптәше генә сынатмасын. Мөбәрәкҗан сакланып кына түше белән самолет канатына ята. Мондый хәл белән килешергә теләмәгәндәй, көчле һава агымы аны канат өстеннән бик җиңел генә

очырып төшерергә тырыша. Күзлек пыялаларына бәрелеп, җил яна. Ике арада алыш башлана. Кем кемне? Ниһаять, тырыша торгач, Мөбәрәкҗан бомбаны түбән төртеп төшереп җибәрде. Мондый хәлгә исе киткәндәй, җил булып җил дә, сызгырып куя. Бераздан аста, күл буенда көчле шартлау тавышы яңгырый. Штурвалда утырган очучы егет тә маңгай тирен сөртеп ала, җиңел сулап куя. Соңгы чигенә җитеп киерелгән нервлар беразга гына булса да бушый төшә: ниһаять! Шулай да борылып карарга ярамый әле. Хәтәр үткән булса, штурман үзе күренер. Күп тә үтми, Мөбәрәкҗанның шатлыклы йөзе күренә.

— Их, бөркет! Сөякләрең шытырдаганчы кысып кочар идем мин сине!

Түзми, чын йөрәктән дустының кулын кысмакчы булып үрелә... Һәм шундук сузган кулын кире ала.

— Иптәш лейтенант, сезнең кулыгыз...

Мөбәрәкҗан фәкать шунда гына бармак битләреннән кан саркыганны шәйләп ала. Һава агымы очырып төшермәсен өчен тырышып кысылган бармак итләре сытылган икән.

— Әллә биленңә бау бәйләргә дә оныткансың инде?!

— Әйе икән шул. Кызулык белән онытылган.

Мөбәрәкҗан аннан соң тагын ничаклы кыю хәрби бурычлар үти! Дошманның тылына үтеп, корал складларын шартлату дисеңме, штабларын бомбага тотумы... Кышкы зәмһәрирләрдә һәм җәйге чилләләрдә дә Мөбәрәкҗанның ПО-2 самолеты һәрчак һавада — Шамазов Мәгъсүм кебек батыр якташлары белән дошман карчыгаларын кыйратып йөри. Совет солдатларының фидакарь батырлыгы нәтиҗәсендә бер-бер артлы безнең шәһәрләр, авыллар азат ителә. Дошманны куакуа алар тугандаш Польша җиренә керәләр. Познань шәһәре тирәсендә каты бәрелешләр бара. Һава сугышларының берсендә алар немецларның ике «юнкерс»ын бәреп төшерәләр. Дошман карчыгасының да күзләре үткер. Ул арада каяндыр өченчесе килеп чыга һәм... Мөбәрәкҗаннарга ут ача. Моңа кадәр бер карусыз очкан самолет кинәт кенә тыңлаусызга әйләнә — йөгәнсез ат кебек тыелгысыз көч белән түбәнгә суырыла... Бу инде идарә итү аппаратлары сафтан чыкты дигән сүз. Менә алар җиргә якынайганнан-якыная баралар. Җитмәсә, каяндыр ут капкан бугай, көек исе борынны ярып керә. Мөбәрәкҗан, самолеты җиргә барып бәрелгәч очкын чыгып шартлатмасын өчен, моторны сүндерә һәм... госпитальдә генә аңына килә. Ул чагында моторны сүндерү сәбәпле генә самолетның шартламый калуын да, агач башларына эләгүе аркасында гына исән калуларын да, аяклары сынган Мөбәрәкҗанны үлемнән коткарган кешенең штурман егет Булгаков икәнен дә ул белми әле. Гипста тоташтан өч ай ята. Култык таяклары белән йөри башлагач, аны госпиталь начальнигына чакыралар.

— Я, бөркет, очасың килмиме әле? — ди аңа хирург.

— Бик килә! — ди Мөбәрәкҗан.— Берлинга җитмәдем ич әле.

— Җир шарын да әйләнеп чыгарга теләмисеңме соң?

— Дустым өчен үч алырга телим,— ди ул, батырларча һәлак булган Шамазов Мәгъсүмне күз алдына китереп.

— Синең үчеңне башкалар алыр. Синең пардашың өчен генә түгел, яуда ятып калган барча батырлар өчен дә, тол калган хатыннар, ятим калган балалар өчен дә үч алырлар, кайгырма! Менә документларың! Менә сиңа Чистайга кадәр кайтырга билет! Кул куеп ал.

— Юк, мин фронтка китәм!

— Шушы килешме! — ди хирург култык таягына ишарәләп.— Аяксызларны авиациягә алсалар, бөтен кеше очучы булып бетәр иде...

— Барыбер җибәрегез!

— Кая?

— Үзебезнең полкка! Иптәш майор, үтенәм сездән!

— Миңа хәзер 60 яшь, күгәрченем. Мин инде могҗизаларга ышанмыйм.

Шулай, хәрби хезмәткә яраксыз дип туган илгә кайтырга әзерләп биргән документларны Мөбәрәкҗанга тоттыралар. Кәгазьләрне кулына алганда ничаклы гына тыелырга тырышмасын, бугазына төер килеп тыгыла һәм бите буйлап күз

яшьләре тәгәри. Шулай итеп, аңа яңадан самолет штурвалы тотарга язмаган микәнни? Берлинга кадәр җитәргә хыялланган иде ләбаса ул. Иптәше өчен дә үч алырга ант иткән иде. Нишләргә соң хәзер? Нишләргә? Бәлки тәвәккәлләргәдер? Әнә бит, безнең полк командиры иптәш Милютинның да бер аягы юк. Барыбер оча бит! Оча! Бәлки ул аңлар? Чистайга кайтасы урынга, ул үзе хезмәт иткән полкны эзләп китә һәм таба.

Менә зарыгып көткән көннәр: ул яңадан самолет штурвалында! Ниһаять, ул һавада! Иптәшләре арасында! Ул көнне Мөбәрәкҗаннан да бәхетлерәк кеше булмагандыр бу дөньяда! «...Болай булгач, Берлинны алмый кайту юк инде, карлыгачым...» дип яза ул үзенең сәлам хатларын. Һәм чыннан да 1945 елның язында Берлинны штурмлаган лачыннар арасында Мөбәрәкҗан самолеты да оча. Берлинны алганда күрсәткән батырлыклары өчен аны Кызыл Йолдыз ордены белән бүләклиләр. Беренче танк Армиясенең командующие генерал-полковник М. Катуков аңа үз кулы белән Мактау грамотасы тапшыра. Бүген аның күкрәген сугыштагы каһарманлыклары өчен алган дистәгә якын орден-медальләр бизи. Арада Польша Республикасының бүләге дә бар.

Теге чакны Тымытык районының Чалпы МТСында баш инженер булып эшләгән Мөбәрәкҗанны Зирекле МТСына (элекке Ямаш районы) директор итеп расларга дәшкәннәр булып чыкты. Моңарчы артта сөйрәлгән коллектив бер ел эчендә алдынгылар рәтенә чыга. Аннары үзен булдыклы итеп таныткан җитәкчене икенче МТСка җибәрәләр. Анысын аякка бастыруга, тагын чакыру кәгазе килеп төшә. Тагын кайсыдыр МТСка сәләтле директор кирәк була. Егерме биш меңче, партия солдаты Мөбәрәкҗан Гатинович, кирәк булгач, карышып тормый. Бу берөзлексез күченүләргә тормыш иптәше Гыйльмиямалның гына кәефе кырыла. Сугыштан соң илдә хуҗалыкны торгызу кирәклеген ул да аңлый. Тик менә балаларны нинди телдә укытырга?! Бер ел татар авылында торсалар, икенче елны рус авылында. Тагын күпмедер вакыттан карыйсың, алар инде чуваш авылында яши башлый.

«МТСтан МТСка, авылдан-авылга күчеп йөргәндә кемнәр белән генә очрашырга туры килмәде дә, нинди генә авырлыклар кичерелмәде. Теркәп бармагач, аларның барысын да каян хәтерлисең? Ә шулай да, Иске Адам авылында Шамазов Мәгъсүмнең әнисен очратуымны мәңге онытасым юк. Бөтенләй очраклы рәвештә килеп чыкты ул очрашу. Ничектер, шулай агайлар белән сугыш хәлләре турында сөйләшеп утырабыз. Аларга кушылып, мин дә үземнең иптәшләрем турында сөйлим. Самолеты белән бергә шартлаган полкташым турында сүз чыккач, арадан берсе:

— Безнең Мәгъсүм кебек булган икән алайса,— дип әйтеп салмасынмы.

— Фамилиясе Шамазов түгелме? — дигәнемне үзем дә сизми калдым.

— Әйе, Шамазов.

— Соң, алай булгач, сезнең авыл егете минем дустым булып чыга ләбаса!

Җыйнаулашып шундук батыр егетнең әнисен күрергә киттек. Улы турында ишеткәч, ана кешенең беренче соравы шул булды:

— Чит-ят җирләрдә йөреп, улым бозылмаган идеме?

Әйтерсең, аның улын вакытлыча урман кисәргә генә җибәргәннәр.

— Юк, апаем, улыгыз бик тәүфикълы иде. Тәмәке дә тартмады...

— Ярый инде, сүземнән чыкмаган,— ди ана күз яшьләре аша сөенеп.— Мин аңа тәмәке тартмаска кушкан идем шул».

Караңгы төшә. Утлар кабызалар. Җиделе лампа яктысында стенадагы рамнан батыр очучы, җан дусты Шамазов Мәгъсүмнең рәсеме карап тора. Ана бер рәсемгә, бер аңа күз сала да:

— Бигрәк тә охшашкансыз инде. Минем улым гына булып калсана. Бердәнберем иде бит ул минем, Мәгъсүмҗаным,— дип Мөбәрәкҗанны кочаклап елый. Чал чәчле анага карап ул да түзеп тора алмый. Ананы кочаклап ала. Икәүләп елыйлар.

...Һәм менә тагын бер чакыру... Тәгәллисе эшләр ничаклы. Эшли башлыйсылары тагын да күбрәк. Дөрес, аның Союз күләмендә танылган дистәдән артык

уйлап табулары бар инде. Аларның барысы да терлекче хезмәтен җиңеләйтү, сыер саву аппаратын камилләштерү, фермадагы эшләрне механизацияләүгә юнәлтелгәннәр. СССР Министрлар Советындагы уйлап табулар һәм рационализаторлык эшләре комитеты биргән авторлык таныклыклары шул хакта сөйли. Тынгысыз холыклы галим һаман эзләнә. Фермаларга барган саен ул савымчыларның һаман авыр аппаратлар белән интегүләрен күреп кайта. Аларны сүтеп җыю өчен генә дә ничаклы вакыт сарыф ителә. Ә менә ул уйлап тапкан аппарат җиңеллеге белән аерылып тора. Чагыштыру өчен ике сан китерик: хәзергеләре 4,9 килограмм, ә Мөбәрәкҗан Гатинович уйлап тапкан аппаратныкы 1,89 килограмм гына. Аны сүтеп-җыярга 25—30 секунд вакыт җитә. Мәскәүдә аларны ул үзе җиде секундта сүтеп, унбер секундта җыеп та бирде. Мәртәбәле комиссия алдында саудырып та күрсәтте. Тагын шунысы да игътибарга лаек, яңа аппарат белән саудырганда сыер җиленендә сөт калмый.

Алай гына да түгел, ул уйлап тапкан аппаратны кулланганда сыерларның сөте артуы да беленде. Казан галиме үзе боларны яхшы белә иде билгеле. Чөнки еллар буе тәҗрибәләр ясады. Кайберәүләр моңа шикләнеп караганнар иде. Үзенең сүзен исбатларга галим тагын Мәскәүгә юл тотты. Барысы да хакыйкать алдында баш игән иде, югыйсә. Гафу үтенеп, актка кул да куйганнар иде. Тик сөенергә иртәрәк булган икән әле. Бөтенесе хәл ителде дип йөргәндә генә Мәскәүдән тагын күңелсез хәбәр килеп төшмәсенме? Комиссия членнарына нишләптер тагын шик төшкән. Институттагы лекцияләрен калдырып, тагын башкалага юл тотарга туры килә галимгә. Ничә еллар куйган хезмәт шулай бик тиз җиңел генә югалыр микәнни? Комиссия җыялар. Бу юлы инде ачыктан-ачык көнләшеп караучылар да табыла. Мыек астыннан көлеп, юри, саудырмый торган кырагай сыерны күрсәтәләр: әйдә, тыңлатып күрсәт әле, янәсе. Ул сыерны башта сыйпап-иркәләп тынычландыра да, җилен-имчәкләренә тиз генә үз аппаратын урнаштырып куя. Бәхеткә каршы, нәтиҗәсе көткәнгә караганда да уңышлырак булып чыга.

Мөбәрәкҗан Гатинович үзенә теләктәш башкала галимнәреннән, бигрәк тә ВАСХНИЛ профессоры Дәүләт премиясе лауреаты В. Ф. Королевны хөрмәт белән искә ала. Аның фатихасы белән Мөбәрәкҗан Гатинович уйлап тапкан саву аппараты ВДНХ залларына куела.

Менә шуннан соң күпме вакыт үтте инде, ә Мәскәүдән бернинди дә хәбәрхәтер юк иде әле. Ул кул кушырып утырмады. Диссертациясен төгәлләп, техник фәннәр кандидаты дигән исем алды. Аппаратының язмышын беләсе килә. Ничек икән? Сынауны уңышлы үтте микән? Газиз баласын сагыну хисе кешене ничек ямансулатса, аны да аппаратының язмышы шулай кызыксындыра иде.

КПСС өлкә комитетында аларны бик җылы каршыладылар.

— Тәбрик итәбез сезне, иптәшләр! — диделәр анда Мөбәрәкҗан Гатиновичның кулын кысып. — Әле генә Мәскәүдән телеграмма килеп төште. Сез уйлап тапкан саудыру аппараты Союз күләмендә танылу алган. Уңышлар телибез!

...Чакырулар, чакырулар... Аны хәзер кайларга гына чакырмыйлар. Әле күптән түгел генә Саратовта фәнни конференциядә катнашып, бик яхшы отзыв алып кайткан иде. Менә шушы арада гына аны тагын Ригага сыерларны машина белән саудыруга караган Бөтенсоюз симпозиумына чакыралар. Доклад белән чыгыш ясавын үтенәләр.

— Саудыру аппаратын тизрәк производствога кертәсе, серияләп җитештерәсе иде,— ди галим. — Аны үзләренә җибәрүләрен сорап, илнең төрле районнарыннан миңа хатлар килә.

— Мөбәрәкҗан абый, әйтегез әле, сез чыннан да самолет канатына чыктыгызмы? Сезгә беркем дә боермаган лабаса.

Мөбәрәкҗан Гатиновичның кашлары җыерылып килә.

— Николай Гастеллога үз самолетын фашистларның танк колоннасына юнәлтергә, Газинур Гафиятуллинга күкрәге белән амбразура капларга кем боерган?

Ялгыш сүз ычкындырганыма уңайсызланып киттем. Алар моны Ватан-ана хакына эшләгәннәр. Чын мәгънәсендә батырлык!

Чакырулар, чакрымнар, күңел чакырулары, гомер чакрымнары.

Шәмси Хамматов,

доцент, тарих фәннәре кандидаты

# МУСА ҖӘЛИЛ — ЖУРНАЛИСТ, ТӘНКЫЙТЬЧЕ

*Аның иҗаты матбугат өлкәсендәге актив, оештыручанлык хезмәте белән бергә бәйләнеп үсте. Шуңлыктан аның художество әсәрләре дә хәрәкәтчел булдылар.*

М. Җәлил[1].

**Матбугат көне уңае белән «Коммунист» газетасында 1934 ел, 5 майда «Хәбәрчелек хәрәкәте үстергән каләм осталары» дигән мәкаләсендә Муса Җәлилнең каләмдәш дуслары хөрмәтенә әйтелгән бу сүзләре аның үзенә дә тулысынча кагыла.**

**Ул сугышка кадәр үк газета-журнал редакцияләрендә хәбәрче, журналист, әдәби тәнкыйтьче буларак тормыш тәҗрибәсе туплый, каләмен шомарта, матбугат аша поэзия, әдәбият дөньясына керә. Бу чыгышта шул эшчәнлекне күрсәтү максат итеп куела.**

Үзе язганча, М. Җәлил 1922 елның көзендә Казанга килә. «Анда,— дип яза ул,— язучылар белән күрештем... «Татарстан» (хәзерге «Социалистик Татарстан») газетасы редакциясенә күчереп язучы булып кердем» (3 том, 540 бит). (Чыганаклар алда да шулай астөшермәсез, җәя эчендә күрсәтеләчәк.)

1923—1925 елларда татар рабфагында укыган чорда «Татарстан» битләрендә аның дистәләгән хәбәре басыла. Газетаның кайбер саннарында хәтта өчәр-дүртәр хәбәре чыга.

«Рабфак еллары минем иҗатымда борылыш тудырдылар» (3 том, 451 бит). Үз хәбәрләрен ул башта «Хәбәрче-укучы М.» «Муса», «М. Җәлил» дип имзалый.

Республикабызда хәбәрчелек хәрәкәте нәкъ шул елларда киң колач җәя башлый. 1923 елның башында, мәсәлән, «Татарстан» газетасына даими язучы берничә эшче-хәбәрче генә булса, ә инде 1924 елны аның тирәсенә 46 актив эшче-хәбәрче туплана. Газета каршында эшче-хәбәрчеләргә җитәкчелек итү өчен махсус үзәк бюро оештырыла, аларның киңәшмәләре үткәрелә, иң яхшыларының тәҗрибәсе гомумиләштерелә. Шуларның берсе — Муса Җәлил. Ул шунда һәм башка матбугат органнарында эшләгән яки актив язышып торган Г. Ибраһимов, Г. Камал, Ш. Камал, К. Тинчурин,

[1] Муса Җәлил. Әсәрләр. 4 том, 99 бит. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1976.

Ш. Усманов, Ф. Бурнаш, Ф. Сәйфи-Казанлы, Г. Нигъмәти, Һ. Такташ, К. Нәҗми, К. Әмири, Ш. Рәмзи һәм башка әдип-публицистлар белән аралаша башлый. Бу очрашулар, аларның басылып чыккан мәкаләләрен һәм әдәби әсәрләрен өйрәнү М. Җәлилнең иҗат үсешенә уңай йогынты ясый. Мәсәлән, 1923 елгы 12 июль санында «Эшчеләр бистәсе» дигән сәхифәдә хәтта биш хәбәр була: бер хәбәрдә «Кызыл күнче» заводында икмәк займының начар таралуын, икенчесендә «Волгарь» ширкәте заводында җыелышларның ана телендә алып барылмавын, өченчесендә вокзал янындагы пар тегермәнендә эшчеләр өчен татарча газета-журналларның алдырылмавын яза. Рабфак укучылары тормышына ул аеруча зур игътибар бирә. Әйтик, «Татар эшче факультетында» исемле хәбәрендә мәктәп янындагы РКСМ һәм РКП(б) ячейкаларының һәм аң-белем тарату оешмаларының укучыларга программадан тыш гомуми һәм сәяси белемнәр бирүе, ике-өч мәртәбә аерым һәм катнаш кичә уздырылуы, «Яшь йөрәк» дигән кулъязма журналның 2, 3, 4 саннары, «Яшь коммунист» стена газетасының 1, 2, 3 саннары чыгарылуы бәян кылына. Әйтеп үтик, М. Җәлил аларны чыгаруда үзе иң актив катнаша.

«Балалар әдәбиятына ярдәмгә» дигән хәбәрдә исә М. Җәлил Мәскәүдә, РКСМ Үзәк Комитеты янындагы татар-башкорт бюросы «татар телендә яңа бер балалар журналы чыгарырга әзерлекләр күрә башлады»,— дип яза, ул «Кечкенә иптәшләр» исемендә булып, 9—14 яшь арасындагы балалар һәм яшүсмерләргә аталуын белдерә. Автор журналга язып торырга, аны укып барырга, таратышырга чакыра. «...Яшүсмерләр, беренче баскыч эш мәктәпләрендә укучы эшче-крестьян балалары бу журналны күтәп алырлар дип ышанабыз. Балалар бакчасы, балалар йорты һәм балалар клубларында да моның хакында тавыш-тынсыз калынмасын иде» [1],— ди.

Рабфакта укыган елларда М. Җәлил яшьләр матбугаты белән тыгыз элемтәгә керә. Аңа 1925 елның гыйнварь аенда «Кызыл яшьләр», «Клич юного коммунара», «Яшь ленинчы», «За Ильичем» газеталарының һәм «Октябрь яшьләре» журналының «хәбәрчесе булып исәпләнә» дип комсомол өлкә комитеты һәм редакцияләр 162 номерлы таныклык бирәләр.


БИЛЕТ №162

Джалилов Муса

№162

*М. Җәлил исеменә бирелгән таныклыкның фотокүчермәсе*

М. Җәлил яшьтән үк ленинчыл комсомол рухында тәрбияләнә, үз әсәрләренә, аларның идея эчтәлегенә карата таләпчән була. «Кызыл Татарстан» газетасының 1925 ел, 13 гыйнварь санында Татар дәүләт театры сәхнәсендә М. Җәлилнең «Бибкәй кыз» драмасы куелу уңаеннан «Алтынчы урындык» псевдонимы белән әсәрнең идео-

[1] «Татарстан», 1924, 11 февраль, № 27.

логик кимчелекләре өчен тәнкыйтьләгән рецензия басылып чыга. Моңа җавап итеп М. Җәлил редакциягә язган хат газетаның 1925 ел, 15 январь санында басылып чыга. Яшь автор тәнкыйть белән килешә, әчтәлеге, идеясе белән укучыга, тамашачыга дөрес тәрбия бирмәгән әсәрләр «һичбер җирдә, һичбер сәхнәдә уйналырга, укылырга, тәзәтелергә, йөртелергә тиеш түгелләр»,— дип белдерә.

М. Җәлил Мәскәүгә күчеп киткәч тә Татарстан матбугаты, бигрәк тә «Кызыл Татарстан» газетасы редакциясе белән даими элемтәдә тора. Башкалада комсомол эшендә эшләгән, дәүләт университетында укыган елларда ул «Кечкенә иптәшләр», «Октябрь баласы» исемле балалар журналларында җаваплы редактор, «Коммунист» газетасында әдәбият-сәнгать бүлегенең җитәкчесе була (Әсәрләр, 3 том, 451 бит).

ВЛКСМ Үзәк Комитетының Үзәк архивында Җәлилнең 1927 ел, 6 август карары белән «Кечкенә иптәшләр» журналында эшләү өчен ВЛКСМ Үзәк Комитеты карамагына чакырылуын раслаучы документ саклана [1]. ВЛКСМ Үзәк Комитетының 1927 ел, 27 август карарында исә Г. Динмөхәммәтов, С. Садыйков, А. Ильясов, Г. Әхтәмов, А. Поздняков, Хәйретдинов, М. Җәлиловның татар-башкорт секциясе члennары итеп раслануы әйтелә [2]. Искәртеп үтик, ул елларда ВКП(б) Үзәк Комитетының татар-башкорт бюросы секретаре булып эшләгән Г. Динмөхәммәтов соңыннан Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе була. 1927—1930 елларда М. Җәлил дә ВЛКСМ Үзәк Комитетының татар-башкорт секциясенең секретарь урынбасары булып эшли. Бөек Ватан сугышы елларында М. Җәлилнең Г. Динмөхәммәтовка якын итеп хатлар язуына әнә шул элемтә сәбәп булган икән.

1927—1928 елларда ВЛКСМ Үзәк Комитеты органнары «Кечкенә иптәшләр», «Октябрь баласы»нда (1929-VIII—1933-III) җаваплы редактор, «Яшь эшче» (соңыннан «Ударниклар») журналында редколлегия члены булып эшли. Редактор М. Җәлил яшь хәбәрчеләр, әдәбият сөюче яшүсмерләр белән элемтәне ныгыта, аларга хатлар язып тора, киңәшләр бирә. Мәсәлән, Башкортстан АССРның Яңа авыл районында яшәүче хәбәрче М. Атнагулов-Буйский́га «Кечкенә иптәшләр» журналыннан 1927 елның декабрендә мондый хат килә: «Шигырь язганда һәртөрле яңа темаларга, тормыштагы күренешләргә тукталырга кара. Шигырьне бик бирелеп, аерым дикъкать белән, тырышып эшлә. Биш кат, ун кат төзәт. Чибәрлә» [3]. «Октябрь баласы» журналында эшләгәндә язган икенче хатында М. Җәлил аңа: «Син тормыштан бер сюжет сайлап алып, шуны картина, «шигъри хикәя» итеп бирергә тырыш... Журналны тарат. «Октябрь баласы» дуслары түгәрәге төзе. Үз районыгызда «Октябрь баласы»ның йолдызы бул» [4],— ди.

«Коммунист» газетасында М. Зәйнинең «Боз һәм кар өстендә» исемле очеркы басыла. Очерк авторы М. Зәйнигә — ятим, тәрбиясез балага Муса Җәлил зур ярдәм итә,— диелә керештә.

М. Җәлил шулай ук Г. Әпсәләмов, Н. Дәүли, М. Садри кебек яшь язучыларның иҗаты белән кызыксынып тора, яшь көчләрне үстерүгә өзлексез игътибар бирә. Бу хакта Мингали Зәйни соңыннан үзе дә яза: «Октябрь баласы» журналында очерк, хикәяләр язып өйрәнгәннән соң, үзәк газета «Коммунист»ка да очерклар яза башладым. Мин урам балалары тормышыннан озын хикәя язган идем, ләкин ул хикәяне Муса Җәлил һәм Ибрай Гази иптәшләр нык тәнкыйть иттеләр, күп җитешсез якларын күрсәттеләр. Тел өстендә эшләргә киңәш бирделәр. Хәзер мин ул хикәяне яңадан язарга керештем» [5].

Мәгълүм ки, 1932 елның январь аеннан «Эшче» һәм «Игенчеләр» газеталары (аларда М. Җәлилнең публицистик чыгышлары байтак) бергә кушылып «Коммунист» исемендә көндәлек яңа үзәк газета чыга башлый [6]. СССР Үзәк Башкарма Комитетының Милләтләр Советы органы була ул. Аңа җәмәгать эшлеклесе, публицист Идрис Агишев редакторлык итә. «Коммунист» газетасы, Татарстан белән Башкортстаннан тыш, Ерак Көнчыгыш, Үзбәкстан, Урал, Себер, Идел, Кыргызстан, Белоруссия, Мәскәү,

[1] ВЛКСМ Үзәк Комитеты архивы, 1 ф., 4 тасвирлама, 31 эш, 5 бит.
[2] ВЛКСМ Үзәк Комитеты архивы, 1 ф., 4 тасвирлама, 31 эш, 6 бит.
[3] «Социалистик Татарстан», 1960, 13 ноябрь.
[4] Шунда ук.
[5] «Коммунист», 1934, 12 июнь.
[6] Шунда ук, 1932, 15 январь, № 6.

Ленинград, Иваново өлкәләрендә һәм илебезнең башка якларында да тарала. М. Җәлил бу газетада 1933 елның февраленнән 1935 елның мартына хәтле әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире булып эшли.

Газета беренче белдерүләренең берсендә әдәбият-сәнгать мәсьәләләренә үзенең мөнәсәбәтен билгеләп, «Матур әдәбият, сәнгать өлкәсендә партиянең генераль юлын үткәрү, большевизмның бөек сәнгатен тудыру, киң катлау татар эшче-колхозчылар арасыннан язучылар җитештерү, аларны диалектик материализм белән коралландыруда, танылган пролетариат совет татар язучыларының әсәрләрен марксизм-ленинизм тәнкыйте аша үткәрү, матур әдәбият өлкәсендәге һәртөрле контрреволюцион, черек либеральлек, вак буржуачылык, мещанлык чыгышларга большевикларча кискен отпор бирер өчен көрәшәчәк»[1] дип искәртә. М. Җәлил әнә шул көрәшнең башында тора. Гомумән дә аның журналист, тәнкыйтьче, шагыйрь буларак зур мәйданга чыгуы «Коммунист» газетасында эшләгән елларга туры килә, дип әйтсәк, хакыйкатькә хилафлык килмәс. Бу дәвердә газетаның редколлегия члены, танылган журналист Муса — Мәскәү пролетар язучылары ассоциациясенең (МАПП) татар секциясендә өченче секретарь да була. Ул Мәскәү стена газеталары редколлегия члennары, эшчеләр белән очрашулар үткәрә, әдәби сәхифәләр оештыра, тәнкыйть-библиография, әдәбият мәсьәләләренә карата мәкаләләр, өлкә, край, республика газеталарына күзәтүләр яза. Мәскәү язучылары ассоциациясе татар секциясе исә Татарстан, Башкортстан, Урал, Себер пролетар язучылары берләшмәләре, Украинадагы язучылар оешмасы «Молодняк»ның Харьковтагы татар секциясе һәм башка әдәби түгәрәкләр эшчәнлегенә актив йогынты ясый. 1932 елда М. Җәлил Язучылар союзының оештыру комитетына язган «Докладная записка»сында татар пролетар язучыларының Мәскәү оешмасы октябрьдан соңгы татар әдәбияты үсешендә зур роль уйнады, эшчеләр арасыннан чыккан беренче татар язучыларын тәрбияләде, татар совет пролетар әдәбияты хәрәкәтенең башында торды, аның үсешенә нык тәэсир ясады,— дип язган (Әсәрләр, 4 том.) Ә матбугат көне уңае белән язылган мәкаләсендә ул производстводан — завод, фабрикалардан, авыллардан эшче-журналист, әдип булып күтәрелгән Шиһаб Шәһәретдинов, Салих Баттал, Мансур Крымов, Мөхәммәт Садри турында куанып белдерә[2].

«Коммунист» газетасы гомумән дә илебез хәбәрчеләрен, өлкән һәм яшь журналистларын, әдипләрен үз тирәсенә туплауда зур эш башкара, аларның иҗатына урынны кызганмый. Иҗади хезмәттәшлекне ныгытуда М. Җәлил башлап йөри. Нәтиҗәдә газетада М. Максуд, Ф. Кәрим, К. Нәҗми, Ш. Маннур, Р. Ильяс, Г. Мөхәммәтшин, Ә. Ерикәй, М. Әмир, А. Шамов, Т. Госман, А. Таһиров, Д. Юлтый, Г. Толымбай, Ә. Фәйзи, Т. Янәби, М. Крымов, Х. Әминев, С. Баттал, Ә. Гәрәй, М. Садри, К. Төхфәтуллин, Г. Минский, А. Әхмәт, Г. Иделле, М. Давыдов, Х. Хәйри, Г. Төхфәт, Г. Беляев, Г. Әхтәмов, Б. Корбан, З. Курмаш, Г. Баязитов, Г. Миңнул һәм башка авторларның әсәрләре бик еш күренә. Ә Җәлил үзе биредә күбрәк журналист, тәнкыйтьче буларак танылa, мәкаләләрен «Муса Җәлил», «М. Җәлил», «Муса», «М. Мостафин», «Җәлил Табын», «М. З.», «М» имзалары белән бастыра. Оештыручы буларак та чыгыш ясый. Газета өчен әледән-әле әдәбият сәхифәләре төзи. Мәсәлән, «Әдәбият магнитстройларын тудыруда Донбасс ударник язучылары алдынгы сафта булырга тиеш» дигән баш астында «Молодняк» татар секциясенең бер еллык эшчәнлеге күрсәтелә. Сәхифәдә Донбассның яшь әдипләре, эшче-хәбәрчеләре Ә. Әхметшин, Х. Маннапов, И. Курмай, С. Хәй, Н. Дәүли әсәрләре, ударник М. Вәлиев шигыре басыла[3].

М. Җәлил театр сәнгате үсешен игътибар үзәгендә тота. Ул Казан татар эшче театры турында «Яшь театрның үсү юлы» дигән мәкаләсендә театр эшчәнлегенә бәя бирә, дустанә тәнкыйть сүзе дә әйтә, «...җанлы газетчылык», «курчак уены» методыннан арынып, психологик образлар бирүгә күчәргә, сәхнәдә җанлы образлар тудырырга кирәк»[4],— дип киңәш бирә.

---

[1] «Коммунист», 1932, 15 январь, № 6.
[2] «Коммунист», 1934, 5 май.
[3] Шунда ук, 20 март.
[4] «Коммунист», 1934, 30 декабрь.

Җәлил МАПП членнары А. Әмин, М. Мостафин-Бәйрәкә белән берлектә язылган әч подвалга якын мәкаләдә татар эшчеләренең Мәскәүдәге үзәк театры репертуары мәсьәләләрен чагылдыра. Мәкаләдә үзәк театрның зур эш башкаруы басым ясап күрсәтелә. «Эшче районнарын, эшче тамашачыларын тәэмин итүне» төп бурыч итеп куюы, СССРның татар эшчеләре күп булган төп промышленность районнарына — Урал, Донбасс, Ленинградка гастрольләр белән чыгып, һәр гастрольдә 50—60 ка якын спектакль бирүе әйтелә. Театр алдында торган бурычларга тукталып: «...пролетариат театрының төп бурычы — партиянең генеральный сызыгын тормышка үткәрү, партиячелекне иң төп сыйфат итеп үзләштерү. Пролетариат театрының репертуары да һәм уйнау, күрсәтү методы да менә шушы төп юнәлеш белән билгеләнергә тиеш» [1] диелә. Аннары мәкаләдә «театрны яңа көчләр белән ныгыту, эшчеләр арасыннан кадрлар күтәрү, артистларны ленинизм теориясе һәм системалы пролетариат сәхнәсе белеме белән коралландыру мәсьәләләре» һ. б. куела.

Авторлар газета алдына бурыч куеп кына калмыйлар, аны тормышка ашыру җәһәтеннән реаль адымнар да ясыйлар. Аерым алганда совет язучыларының Бөтенсоюз съездына әзерлек уңае белән, «Коммунист» газетасы клуб сәхнәләре өчен язылган массовый пьесаларга смотр үткәрергә була. «Бу смотрда басылып чыккан яңа пьесаларга тәнкыйть-библиография, драматурглар арасында фикер алышу, драмтүгәрәкләр һәм театрлардан, шулай ук укучылардан хатлар, массовый драматургия буенча дискуссия һ. б. басылачак. Бу смотрдагы язучы, режиссер, артист, драмколлективчы, тамашачы-укучы һ. б. иптәшләрнең актив катнашуын сорыйбыз» [2],— диелә «Редакциядән» исемле искәрмәдә. Газетаның шул ук санында М. Җәлилнең ике тәнкыйть мәкаләсе басыла. Ул рецензиянең берсе — «Күршеләр» (А. Алиш һәм А. Әхмәт әсәре. Пьеса 4 пәрдәдә. Татгосиздат, 1934), ә икенчесе — «Житеш тормышка» (колхоз сәхнәләре өчен инсценировка һәм декламацияләр җыентыгы, төзүче Баян Гәрәй. Урал нәшрияты, 1934) дип атала. М. Җәлил сәхнә әсәрләренә җитди таләпләр куя, язучылардан «әсәр өстендә нык эшләүне һәм аерым кампаниягә карап лозунглар кычкырудан, җанлы сурәтләр, җанлы күренешләр, вакыйгалар бирүгә күчүне сорарга тиешбез»,— ди.

Әдип Афзал Таһирның хезмәтенә 15 ел тулу уңае белән газетада «Карт большевик язучы Афзал Таһировка сәлам!» диган баш астында аның тормышы һәм иҗаты турында сәхифә бирелә. Бер төркем язучылар исеменнән, шул исәптән М. Җәлил, тәбрик телеграммасы бирә. Мәхмүт Максудның «Большевик язучының иҗат юлы», шулай ук М. Җәлилнең «Җәлил Табын» имзасы белән шигыре һәм мәкаләләре басыла.

> «Сиңа сүнмәс гайрәт, дәрт телибез,
> Өйрәнәбез каләм эзләрең.
> Машиналы илгә тагын туар
> Бөек төзелеш чоры сүзләре... [3],

— диелә шигырьдә.

М. Җәлил оештырган «Башкортстан язучылары съездга яңа әсәрләр белән киләләр» диган сәхифәдә Башкорт әдипләренең әсәрләре, истәлекләре басылган. «Коммунист» редакциясе Афзал ага Таһировның юбилеена катнашу уңае белән Уфада Башкортстанның совет язучылары киңәшмәсен оештырды» — диелә анда.

Париж коммунасы көне һәм МОПРның 15 еллыгы уңае белән «Пролетар интернационализмын ныгыту өчен» дип аталган сәхифә дә бирелә. Париж Коммунасы вакытында коммунаның органы булган «Дүшән ата» («Пере Дөшене») газетасында эшчеләрнең, түбән катлау хезмәткәрләрнең басылган 13 хатына М. Җәлилнең публицистик күзәтүе басыла. Бу хатларның кульязмалары Маркс-Энгельс-Ленин институты архивында саклана, алар моңарчы бер җирдә дә басылмаган була. «Без коммуна сабакларын өйрәнгәндә,— дип яза М. Җәлил,— бу хатлар аркылы Париж пролетариа-

[1] «Коммунист», 1932, 26 апрель.
[2] «Коммунист», 1934, 22 июль.
[3] «Коммунист», 1934, 6 июнь.

тының йөрәген күрә алабыз. Без аңардан пролетариат массасы белән һәрвакыт тыгыз бәйләнү һәм аларның киң иҗат, инициатива көчен бөек эшләргә туплау кирәклеген аңлыйбыз» [1].

Газетада балалар әдәбиятына да зур игътибар бирелә.

«Балаларга тотнаклы, кызыклы, матур китап бирү — язучының намус эше» дигән сәхифәдә М. Җәлилнең «Совет балалар әдәбиятына иң нык игътибар!» дигән мәкаләсе һәм А. Алишның «Дулкыннар» дигән хикәяләре җыентыгына рецензия урнаштырыла.

«Татарстан Совет язучыларының булачак I съездында,— диелә мәкаләдә,— хәзерге әдәбиятыбызда кичектерми чишелергә тиешле үзәк мәсьәләләрнең берсе булып, һичшиксез идея һәм художество ягыннан югары сыйфатлы балалар әдәбиятын җитәрлек булдыру тора». Рецензиясендә исә ул: «Түбәндә Алиш балалар өчен матур гына хикәяләр язган. Бу китапны балалар әдәбияты китепханәсендә файдалы китапларның берсе дип тәкъдим итәргә була» [2]. Бу сәхифәдә Мәскәүнең 17 нче мәктәбендә укучы бер төркем укучылар балалар өчен матур әдәбиятның аз булуына борчылуларын белдереп «Язучыларга ачык хат» язалар.

СССР язучыларының 1 Бөтенсоюз съезды барышын яктырту өчен «Коммунист» зур урын бирә. Анда А. Жданов речь, М. Горький доклады, рус, татар, башкорт, әзербайҗан, үзбәк, төрекмән, таҗик, абхаз һәм башка милли әдәбият вәкилләренең чыгышлары басыла, съезд делегатларының Мәскәү хезмәт ияләре белән очрашулары турында отчетлар, репортажлар бирелә. 26 августта Максим Горький исемендәге культура һәм ял паркында съезд делегатларының бер группасы Мәскәү ударниклары белән очраша. Анда Демьян Бедный, Вера Инбер, Самуил Маршак, Корней Чуковский һ. б. чыгыш ясый. «...Бу тарихи кичәдә,— дип яза М. Җәлил,— эшнең югары сыйфаты өчен, югары класс метрополитен һәм роман, автомобиль һәм повесть, станок һәм поэма өчен ныклы договорга кул куелды!» [3].

Бер очрашу 3 сентябрьдә рус телендә чыга торган «Метрострой ударнигы» һәм татар телендәге «Коммунист метростройда» газеталары инициативасы белән «Коммунист» редакциясендә үткәрелә. Җыелышны «Коммунист метростройда» газетасы редакторы Г. Әхтәмов ача: «Безнең татар һәм башкорт язучыларының,— диелә отчетта,— социалистик гигантлар, анда эшләүче эшчеләр — ударниклар белән бәйләнешы әлегә начар, без аларның гигантларга, шул җөмләдән метростройга һәм андагы ударникларга якынрак килүләрен, аларның түзелештә күрсәткән геройлыкларын, фидакарьлекләрен матур әдәбиятта чагылдыруларын таләп итәбез» [4].

«Коммунист» газетасында делегатларның әсәрләре, чыгышлары, уй-фикерләре «Бөтенсоюз совет язучыларының беренче съездында», «Язучылар съездыннан соң», «Язучылар трибунасы» дигән рубрикалар белән басылып килә. Әдәбият-сәнгать бүлеге мөдиреннән һәм хезмәткәрләреннән бу зур оештыру эше таләп иткән әлбәттә.

Урал язучыларының татар-башкорт секциясе җитәкчесе, Свердловскида чыга торган «Социализм юлы» өлкә газетасы битләрендә әдәбият сәхифәләрен оештыруда иң актив катнашкан, хәбәрчеләр, яшь иҗат көчләрен үстерүгә күп көч салган СССР Язучылар союзы члены, съезд делегаты шагыйрь Хөсәен Әминевне М. Җәлил съезд барган көннәрдә редакциягә чакырып ала. Х. Әминев әлеге очрашу хакында миңа ниләр сөйли: «Алексей Максимович Горький докладын тыңлап, гаҗәп дулкынланып йөргән көннәр иде. Бервакыт, шулай безнең делегация җитәкчесе килде дә «Коммунист» газетасы редакциясеннән Муса Җәлилнең мине редакциягә чакыруын әйтте. Аптырабрак калдым. Үзем редакциягә атлыйм, үзем дулкынланып уйланам. «Нигә чакырды икән?..» [5].

Аннары бу мәкалә авторына 1981 елның январь аенда язган хатында Х. Әминев болай дип хәбәр итә: «Без Муса Җәлил белән танышып, сөйләшеп киттек. Ул Уралның татар-башкорт язучылары турында сорашканнан соң миңа шундый сорау бирде:

---

[1] «Коммунист», 1934, 18 март.
[2] «Коммунист», 1934, 12 июнь.
[3] «Коммунист», 1934, 28 август.
[4] «Коммунист», 1934, 12 сентябрь.
[5] «Социалистик Татарстан», 1965, 10 декабрь.

— Иптәш Әминев, Сез шушы көннәрдә съезд турында берәр кыскача шигырь язып, Мәскәү татар газетасы «Коммунист»ка бирә алмассызмы?

Мин бераз уйлап алдым да, «Ярый, Муса ага, мин бүген кичен бер шигырь язып, иртәгә иртә белән редакциягә китереп Сезгә бирермен», дидем. Ул елмаеп минем җилкәмә кулын салды да: «Шундый кыска вакытта язып өлгертсәгез бик шәп булыр иде» диде. Мин биргән вәгъдәмне үтәдем — кич һәм төн буена утырып «Съезд сәйләни» исемле шигырь язып, иртә белән редакциягә килдем. Муса Җәлил бу шигыремне укып карады да, рәхмәтләр әйтеп, мине фотография бүлмәсенә чакырып рәсемгә төшертте. Озак та үтмәде, бу шигырь минем рәсмем белән... «Коммунист»та басылып чыкты»[1].

Автор анда:

Съезд ачыла... Бөек сыйныфыбызның
«Давыл хәбәрчесе» кузгала,
Искелеккә үлем карарларын
Уку өчен башлап сүз ала[2],

— дип Максим Горькийга дан җырлый.

Газетаның әдәбият хроникасында «Критика-библиография институты эштә» дигән хәбәр басылган. Анда мондый белешмә бирелә: «Мәскәү критика-библиография институты, язучылар съезды җыйналу белән, татар телендә соңгы елларда чыккан бөтен матур әдәбиятны тулы тәнкыйть аша үткәрү эшен өстенә алды. Бигрәк тә балалар әдәбияты, клуб сәхнәләре өчен басылган театр әсәрләре һәм яшь язучыларның иҗатлары буенча булган китапларны күзәтеп чыгу уңышлы рәвештә бара. Бу эшкә Мәскәүдәге тәнкыйтьче, язучы һәм гыйльми көчләр тартылганнар. Бу көнгә кадәр институт 10 нан артык яңа әсәргә күзәтү үткәрде һәм аларның байтагын «Коммунист» газетасында бастырып чыгарды. Болардан тыш институт, И. Агиш, Муса Җәлил, Мәхмүт Максуд торган бригада ярдәме белән, «Совет әдәбияты» журналының 1933—34 елгы тулы саннарына обзор үткәрү эшен оештырды. Обзорга якын көннәрдә йомгак ясалачак»[3]. Йомгак 1934 елның 27 июль санында басыла.

Күзәтүчеләр журналның прозасы һәм поэзиясен тикшерәләр. Анда Татарстан предприятиеләрендәге эшчеләр тормышына, аларның көнкүрешенә багышланган хикәяләр, очеркларның булмавын, оештыру эшенең йомшак куелуы белән аңлаталар. Тәрҗемә мәсьәләсенә дә игътибар юнәлтеп исә тәрҗемәләрнең сыйфаты түбән булуын тәнкыйтьлиләр, кардәш республикаларның әдәбиятларыннан (Украина, Әзербайҗан, Белоруссия һ. б.) бер генә тәрҗемә дә бирелмәвен әйтәләр.

«Коммунист» газетасында бергәләп язылган берничә рецензиягә М. Җәлил имзасыннан соң «Мәскәү, критика-библиография институты» дип кул куелган.

Тәрҗемә мәсьәләләренә исә М. Җәлил соңрак та игътибар итә. Ул аны гадәттән тыш җитди эш, халыклар дуслыгын ныгыту, культураларның аралашу һәм баетышу чарасы итеп карый. Аның «Классиклар белән танышу болай булмый» исемле үткен мәкаләсе — моңа ачык мисал. Эш болай була. «Пионер каләме» журналының 1934 елгы 7 нче санында «Әдәбият классиклары белән танышабыз» дигән сүз башы белән А. Пушкинның «В Сибирь» һәм «Узник» исемле ике шигыре тәрҗемә итеп бастырыла. Тәрҗемәләрнең сыйфаты М. Җәлилдә ризасызлык тудыра. Әлеге мәкалә авторның тәрҗемә принципларын бәян кылуы җәһәтеннән игътибарга лаеклы. М. Җәлил тәрҗемә сыйфатын түбәндәге шартлар белән билгели:

«1 — Тәрҗемәдә шагыйрьнең үз әсәрендәге төп фикере бозылмый һәм арттырылмый-киметелми, тулысынча әйтеп бирелгән булырга тиеш.


2 — оригиналда булган төп охшатулар һәм метафоралар сакланган булырга тиешләр.

3 — тәрҗемәдә тәрҗемә ителә торган шагыйрь өчен характерлы булган форма... мөмкин булган кадәр сакланырга тиешләр. һәм тәрҗемәнең татар әдәби теле кагыйдәләренә җавап бирерлек шома һәм нәфис эшләнүе күзәтелергә тиеш»[4].

[1] Хат «Социалистик Татарстан» газетасы архивында саклана.
[2] «Коммунист», 1934, 6 сентябрь.
[3] «Коммунист», 1934, 14 июнь.
[4] «Коммунист», 1934, 27 октябрь

Шуны да искәртик, М. Җәлил «Коммунист» газетасында рус һәм башка милләт әдәбиятлары классикларының тормышы, иҗат юлы белән таныштыруны әдәбиятыбыз үсешенең бер чарасы итеп карый. Бөтендөнья пролетариатының сугышчан көрәш гимны булган «Интернационал» авторы Эжен Потьеның иҗаты турындагы «Коммунар һәм шагыйрь», Владимир Маяковский хакындагы «Революциянең бөек шагыйре», «Шевченкодан өйрәнергә кирәк» кебек мәкаләләре әнә шундый максатны күз алдында тотып язылган.

Муса Җәлил Татарстан дәүләт опера театрын оештыруда һәм аңа милли кадрлар әзерләүдә актив катнаша. Ул театрның әдәби бүлеге мөдире булып эшли, либреттолар яза, классик һәм совет опера либреттоларын тәрҗемә итә. «Фигароның туе», «Севилья чәч алучысы», «Ана» (Горький буенча) һәм башка операларның сүзләре аның тәрҗемәсендә яңгырыйлар. В. А. Моцартның «Фигароның туе» дигән әсәренең титул битенә 1936 ел, май аенда тәрҗемә ителде, дип язып куя.


Переведен с итальянского
языка через русского на татарский
язык и подтекстован —
II акт
1936 г. - Май
М. Джалил

*В. А. Моцартның «Фигароның туе» әсәренең титул битенә язылган текст.*

Муса Җәлил либретто язучы эдипләр әсәрләренә эчке рецензияләр, бәяләмәләр яза, аларның иҗат эшчәнлегенә дөрес юнәлеш, төпле киңәш бирә. Ул Әхмәт Фәйзинең «Качкын», «Сафа», Таҗи Гыйззәтнең «Наемщик», Гадел Кутуйның «Бәхет», Әнәс Камалның —«Туй», Мәхмүт Максудның «Кара йөзләр», Әхмәт Ерикәйнең «Бибисара» дигән либреттоларына һәм башка әсәрләренә тирән эчтәлекле, ышандыргыч итеп бәя бирә.

Җәлил татар әдәбияты классикларының иҗатын пропагандалауга күп көч куя. «Мәҗит Гафуриның иҗат юлы (кыскача обзор урынында)» исемле күләмле мәкаләдә бу эдипнең иҗатына югары бәя бирә. «Әдәбият мәйданына аяк баскан көннән алып, ярлылар моңын җырлаган, хезмәт ияләренең иң якын дусты булган, үзенең зур талантын алар тормышына багышлаган һәм эксплуатациянең килешүсез дошманы булган Мәҗит ага социалистик культура төзелеше тарихында якты йолдыз булып янар» [1].

Шәриф Камалга 50 яшь, иҗат хезмәтенә 25 ел тулу уңае белән «Коммунист» газетасында махсус сәхифә бирелгән. Анда М. Җәлилнең «Карт революцион язучының хезмәт бәйрәме» исемле мәкаләсе урнаштырыла. «Революциягә хәтле,— дип яза М. Җәлил,— татар эшчеләре тормышын чагылдырган бердәнбер татар язучысы Шәриф Камал булды. Эшчеләр тематикасы — Ш. Камалның төп тематикасы иде. Ш. Камал юлы,— ди ул аннары,— капиталистик системаны фаш итү, революциягә килү һәм социализм төзү өчен көрәш юлы» [2].

[1] «Коммунист», 1934, 3 ноябрь.
[2] Шунда ук, 27 декабрь.

*
* *

30 нчы елларда, «Правда» газетасы үрнәгендә, үзәк, республика, край, өлкә газеталары урыннарда күчмә редакцияләр, журналистлар, ударниклар, хәбәрчеләр бригадалары оештыралар. Бу башлангычтан «Коммунист» газетасы редакциясе дә читтә калмый. Газета «Матбугат хроникасы» дигән бүлегендә редакция «бу ел язгы чәчү вакытында Урта Иделнең Саранск районына, Уралның Ялан-Катай районына, Мәскәү өлкәсенең Касим районына, Түбән Иделнең Дергач районына дүрт күчмә редакция оештырды» [1],— дип хәбәр итә. Күчмә редакция һәм бригадалар махсус газеталар листовка-яшеннәр чыгаралар, төп газетага материаллар җибәреп торалар. Бу урыннардагы партия-совет оешмаларына, МТС һәм совхоз политбүлекләренә политик-хуҗалык кампанияләре үткәрүгә ярдәм иткән.

«Коммунист» газетасының күчмә редакциясе һәм аның махсус заданиесе белән М. Җәлил Урал (Серов заводы), Тула металл комбинаты эшчеләре, түбән Идел хезмәт ияләре, Каспий диңгезе балыкчылары арасында, Казан шәһәрендә, Татарстан АССРның Әлки районы Чирмешән совхозында һәм башка төбәкләрдә була. Ул җирләрдән очерклар, юлъязмалар, фельетоннар, шигырьләр яза, колхоз, совхоз, завод, район эшләре турында сәхифәләр оештыра. Әлки районының Чирмешән совхозында исә ул 1934 елның җәйге-көзге айларында була. Политбүлеккә телеграммада аның белән бергә эшләү өчен Шиһабетдинов та җибәрелә дип хәбәр бирелә [2]. М. Җәлил таныклыгына «Татарстанның Чирмешән май совхозы политбүлек күчмә газетасының урып-җыю кампаниясе чорына җаваплы редактор итеп җибәрелә»,— дип язылган.

М. Җәлил 1934 елның 17 октябрендә «Коммунист» газетасында Чирмешән май совхозына багышлап «Ялгышлардан большевикларча сабак алырга» дигән баш мәкалә, авыл хуҗалыгының алдынгы кешеләре турында өченче биттә сәхифә бастыра. Ул «Чирмешән совхозында конкрет оператив җитәкчелек өчен көрәшкә!» дигән исем белән чыга. Һәм М. Җәлилнең «Чирмешән совхозының имтиханы» дип аталган кереш сүзе белән ачыла. Анда мондый юллар бар: «...май совхозы урып-җыю һәм дәүләткә икмәк тапшыру планнарын зур өзеклекләр белән срогыннан кичегеп үтәде. Моның сәбәбе — совхоз җитәкчелегенең урып-җыюга большевистик әзерлекне тәэмин итмәвендә... оперативлык һәм конкретлык булмауда иде. Совхоз бу өзеклектән бары шул серьез хатасын төзәтү аркасында гына чыга алды...

Алдынгы аңлы ударниклары икмәк тапшыру планының 20 сентябрьгә үтәлүен тәэмин иттеләр...».

«Коммунист»ның 1934 ел, 20 октябрь санында «Чирмешән сабаклары (күчмә редакциясе материаллары)» исемле юлъязмасында М. Җәлил совхозның дәүләткә ашлык тапшыру чорындагы уңай якларга, эштәге кимчелекләргә анализ ясый.

М. Җәлил Чирмешән политбүлегенә газета редакциясе оештыруга, аның редакторын табышуга, типографияне шрифт һәм газета басу машинасы белән тәэмин итүгә актив булыша. Бу мәсьәләләрне үзәк оешмалар, Татполиграф алдына куя. Мәскәү журналисты, «Коммунист» газетасы хезмәткәре каләмдәш дусты Г. Әхтәмовны Әлки районына редактор итеп билгеләү өчен тиешле оешмалар алдында мәсьәлә кузата. Боларны Чирмешән совхозы политбүлеге начальнигы Г. В. Ломоносовка М. Җәлилнең «Коммунист» редакциясе бланкасына үз кулы белән язган (1934 ел, 15 октябрь, рус телендә) хаттан кайбер юллар ачык раслый:

«Мәскәүгә 13 ендә килдем. Исән-сау. Совхозда эшләвем вакытында сезнең тарафтан күрсәтелгән ярдәм өчен, игътибар һәм ихтирам өчен хосусан һәм аеруча сезгә чын күңелдән рәхмәт... Мәскәүгә килү белән совхозда редакция оештыру эшен ахырына кадәр җиткерүгә алындым. Совхоз редакциясе өчен шрифтка заказ биргәннәр. ...Татполиграф эшләргә тиеш.

...«Американка» [3] хакындагы мәсьәлә шулай ук уңай хәл ителгән.

---

[1] «Коммунист», 1933, 16 апрель.
[2] КПССның Татарстан өлкә комитеты партия архивы, 4103 ф., 6, 10 тасвирлама, 19, 75 битләр.
[3] «Американка» — газета басу машинасы.

...Димәк, редакция — сезнең үзегезнең редакция — булачак. ...Мин Әхтәмов белән сөйләшеп килештем. Ул сезгә редактор булып барырга риза. ...Соңыннан инде наборщик мәсьәләсе генә кала. ...Мин совхоз турында тулы сәхифә һәм «Коммунист» өчен баш мәкалә дә әзерлим. 17 октябрьда чыга. ...Хат яз. ...Мин отпуск алам һәм совхоз турындагы романга материаллар туплый башлыйм. Хәзергә. М. Җәлилев»[1].

Хаттан күренгәнчә, М. Җәлил Әлкидә бөтенләй үз кеше булып өлгерә. Ул совхоз политбүлеге мәшәкатьләре белән яши башлый, редакцияне ныгыту турында кайгырта. Әлкидә чагында исә кучмә газетаның 8 санын чыгара, хәбәрчеләр киңәшмәсен үткәрә.

*
* *

Мәгълүм булганча, М. Җәлил 1939 ел башында Казанга күчеп кайта һәм тулаем иҗат эшенә, җәмәгать эшенә чума. Ул Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе, Казан шәһәр Советы депутаты, Татарстан АССР Халык Комиссариаты Советы каршындагы художество советы члены, әдәбият буенча хөкүмәт комиссиясе члены, Татарстан китап нәшрияты редакция советы члены, күп газета һәм журналларда редколлегия члены. Көндәлек матбугатта даими катнашуны гражданлык бурычы дип санаучы иң актив автор...

Бу язмада М. Җәлилнең журналист һәм тәнкыйтьчелек хезмәтенең кайбер яклары күзәтелде. Әлбәттә, бу эшчәнлек киләчәктә җентекләп тикшеренүне көтә. Ләкин инде билгеле булган фактлар да М. Җәлилнең бу гаять мөһим иҗади өлкәдә дә зур эш башкарып, тирән эз калдырганын раслыйлар.

Коммунистлар партиясенә керү өчен 1929 елда М. Җәлилгә рекомендация биргән иҗат дусты Мәхмүт Максуд (аңа шулай ук партия һәм комсомол активистлары Н. Сәйфи һәм А. Дәүләтшин иптәшләр рекомендация бирәләр)[2] аның «тумыштан ук шагыйрь булуы белән бергә, журналист та иде, журналистлык хезмәтен ул чын күңеленнән яратып башкарды»[3],— дип яза.

Шагыйрь үзен һәрчак журналист дип саный. Инде фронттан язган бер хатында ул «Язучы, журналист-пропагандист буларак» командировкага баруын хәбәр итә. Икенче бер хатында да ул үзенең журналист булуына басым ясый.

Матбугат белән элемтәдә яшәү, анда эшләү, редакция «казанында кайнау», газета мандаты белән авыл, шәһәр, предприятие, колхоз-совхозларга бару, аларның эше белән танышу һәм, ниһаять, үзе әйткәнчә, фронтта, «көне-төне ут астында йөрергә туры килү» М. Җәлилгә иҗат өчен материал, дәрт, илһам биргән, әдәби һәм журналистика әсәрләре тудыру өчен чыганак булган.

---

[1] КПССның Татарстан өлкә комитеты партия архивы, 4103 ф., 10 эш.
[2] «Социалистик Татарстан», 1965, 22 декабрь.
[3] Мәхмүт Максуд. Сагынган минутларда. Казан, 1963, 26—27 битләр.
[4] Шунда ук.

## Зәки Зәйнуллин

# КАРБЫЗ СУГЫШЫННАН ЧЫН СУГЫШКА

**1919** елның язгы сулары китеп, таулар, кырлар яшелләнеп килгән чагында Стәрле буйларында каты сугышлар булып үтте. Кызылларның алдынгы кавалерия отряды Хәлекәй ягыннан капыл килеп чыга да, туктамастан өермә кубарып, Стәрле авылына һөҗүмгә ташлана. Акларның авыл өстендәге тауга урнаштырылган алты туплы артиллериясе исә аларны, шрапнель белән атып, кирегә чигендерә.

Тагын бер-бер артлы кабатланган өч атака кызылларга уңыш китермәде. Бары тик тагын өч туп һәм снаряд тутырылган әрҗәле олаулар килеп җиткәч кенә, Стәрле тау башларында давыл уйнатып җир актарган көчле ут астында калгач кына акларның әле исәннәре артларын-алларын карамыйча чигенеп котылалар...

Алар ташлап киткән окопларда ватык туплар, пулеметлар, бик күп мылтык, снаряд-патрон әрҗәләре аунап калды. Күренеп торганнарын гына тиз-тиз җыеп киткән кызыллардан соң окопларда Стәрле малайларының җәйләре патрон эзләп, «кызыллы-аклы» уйнап үтә башлады. Авыл урамнарында битләрендә дары уты чәчрәгәннән калган зәңгәр сипкелле яланаяклы әрсез ташбашлар көннән-көн ешрак күренә. Окоп төбендә казынганда мылтык тапсалар алар өерләре белән авыл советына йөгерәләр иде. Тәмәке төтененнән ысланып, саргаеп беткән мыек очын бөтергәләп, солдат чакларын исенә төшерә-төшерә, секретарь шунда ук акт төзи, малайлардан кул куйдыра. Үзенең һәр хәрәкәтен күзләре белән йотып торган малайлар алдында мылтыкны сүтә дә башлый. Тутыккан мылтык аның кулындагы керосинлы чүпрәктән күзгә күренеп ялтырап китә. Мылтык — дәүләт коралы. Шуңа күрә аның табылган берсе, сары мыек кулы аша шулай үтеп, милиция йортына барып җитте.

Еллар үтә, малайлар үсеп буйга җитәләр. Берәм-берәм кайсы-кая тарала да башлый. Алар урынына, җирдән калыккан үлән кебек, бүтәннәре үсеп җитә. Болары да патрон эзли, ура кычкырып «һөҗүмгә» йөгерәләр...

Тагын еллар үтә, окоплар җимерелә, аларны үлән баса, патрон табулары кыенлаша. Тик Бөек Ватан сугышы башланыр алдыннан булып үткән кайбер шаян вакыйгалар гына Стәрле картларына тагын Гражданнар сугышы елларын хәтерләтеп алалар. Ул шаян вакыйгаларга әчерәк телләләре «Төрек сугышы» дип, ә күпчелек исә, «Карбыз сугышы» дип исем кушалар. «Сугыш» оештыручылар — унлап үсмер малай, ә аларга каршы як колхозның яшелчә бригадасы бригадиры Төрек Кәриме, ике каравылчы карт һәм бакчада эшләүче яшь кызлар була.

Төрек Кәриме басмачыларга каршы сугыштан яраланып кайткан. Кәримне карт әтисеннән калган ләкәб исем белән шулай йөртәләр. Сугышка чаклы Кәрим колхозда кыяр-кәбестә, кавын-карбыз үстерә. Башта үзенең тау буендагы бакчасында Урта Азиядән алып кайткан орлыклардан кавын-карбыз үстерә башлый. Аның кайтканын зарыгып көтеп алган Гарифәсе дә үзе кебек уңган булып, алар ике-өч ел эчендә бәрәңге белән суганнан бүтән нәрсә үстерә белмәгән авыл халкына ка-

вын-карбыз тəмен татыталар. Колхозлар оеша башлау белəн, Кəрим тəрле орлык тутырган əлеге эреле-ваклы капчыкларын тотып колхозга керə. Керə дə, Стəрле елгасы буендагы Шакир ташы диеп йөртелгəн урында яшелчə бакчасы үстерə башлый. Баштарак моңа бик игътибар итеп җиткермəгəн председатель Габсаттар колхозга карбыз-кавын сатудан килгəн файданы сизгəч, бу эшне хуплап, яшелчə җирлəрен киңəйтергə ризалык бирə.

Тик, йөзлəре ак булгыры, бакчачыларга малайлар гына тынгылык бирми. Карбыз дигəне тавык күкəе хəтле булыр-булмастан ук, алар Шакир ташы янында урала башлыйлар. Кайсысы кичкырын бозау эзлəгəн булып йөри, кайсысы балык тоткандай итеп бакчасы янында бутала. Тик Кəрим дə бик сизгер уяу эш итə белə шул. Бакча каравылларга ел саен аның ике карты бар, шулар өстенə бакчачы кызлар. Элəктерсəлəр, малайларга каты тимилəр тиюен, бабайлар колак бора, ə кызлар... Ай-ай, каян табалардыр ул кызлар шул тикле дə зəһəр кычыткаwarнарын. Карбыз «эзлəп» шул тирəдə чуалган малайлар ике-өч көн артларына утыра алмый йөрилəр. Җитмəсə тагын өйдəгелəр кəлə: — «Нишлəп гел басып торасың, карбыз ашадыңмы əллə?»

Мең тугыз йөз утыз тугыз — кырыгынчы елларның җəйлəре каравылчы картлар өчен дə, Кəрим өчен дə бик авыр килде. Яшь чакларында чибəр Гарифə артыннан Барый тимерче белəн Кəрим икəү йөргəннəр иде. Урта буйлы, киң күкрəкле, бертуктаусыз елмаеп торучан кара күзле егет иде Барый. Нəрсəсе белəн кызыктыргандыр Кəрим, Барый аны аңламады,— Гарифə Кəримгə чыкты. Дошман булуын булмадылар. Тик яшьтəн килгəн дуслыклары көл астында калган учак кебек акрын-акрын сүнə барды. Гарифəгə хəтере калып йөрде-йөрде дə, Барый, бер ел үтəр-үтмəстəн, Түбəн оч Нəфисəне иярсеп алды. Озакламый Барый белəн Нəфисəнең Фəрит исемле малайлары туды... Алда сүз күбрəк менə шул малай хакында. Фəрит ниндирəк малай дисезме? Ай-һай, тел белəн сөйлəп кенə аңлатып булыр микəн? Нинди генə айгыр-аргамакларга атланып җир-буран уйнатканы юк аның! Кулы белəн ялыннан элəктерсə, өстенə менмичə калмый. Җырга да, биюгə дə бик оста. Сабан туйлары вакытында Габсаттар председатель аны чабышкы сыртына үзе күтəреп атландыра, чабыштан килгəч үзе күтəреп ала да авыл картлары янына илтеп бастыра... Бераздан инде Фəрит дигəнең дə мəйдан уртасында сөлге тотып көрəшкə чыга. Көрəшүе дə гел үзеннəн зур малайлар белəн. Ул да булмый, Фəритне колга башында күрəсең. Капчык киеп йөгерешүдə янə аны узалган малай юк.

...Авыл ягыннан колхоз бакчасына таба пар ат җиккəн бричка узып бара. Аңа Кəрим белəн янəшə илле яшьлəр чамасындагы ревкомиссия члены Лотфрахман утырган. Стəрле елгасы буйлап сузылган сазлыкны үткəч, Кəрим сөйли торган сүзен кинəт кенə икенчегə борды:

— Лотфрахман абзый! Син бит артиллерист булган кеше. Күптəн күргəнең юктыр, сугыш күрсəтимме үзеңə?

— Нинди сугыш ул тагын?

— Əнə, Кəҗə тавына кара əле!

Кəҗə тавы юлдан ерак түгел, йөз-йөз илле метрлар чамасы күтəрелеп тора. Тау башындагы иске окоп эченнəн такыя кигəн һəм такыясыз башлар күренə. Шул яктан искəн җил аларның акрын гына медер-медер килеп нидер сөйлəшкəн авазларын җиткерə. Ара-тирə шул малайлар болар ягына окоптан нəрсəдер ыргыталар.

— Карбызга нəфеслəре бик зур шайтаннарның. Өч көн рəттəн инде бакчаны басалар. Аптыраш əле, ничек кенə туктатырга шуларны? Син, Лотфрахман абзый, атларның башыннан тотып тор, өрекмəсеннəр, ə мин сиңа тегелəрнең кəсебен күрсəтим.

Кəрим олаудан җитез генə сикереп төште. Шул чагында окоп эченнəн боерык тавышы ишетелде. Такыялы-такыясыз башлар окоп эченнəн үрелеп, колакларына кадəр ерык авызларын күрсəттелəр дə юк булдылар. Окоптан зəңгəр күлмəкле малай чыгып басты.

— Шушы инде Барый малае Фəрит,— диде Кəрим көлемсерəп, үзе, чыбыркысын кулына алып, тауга таба атлады.

Фәрит азрак болайга таба карап торды да шаян тавыш белән тау буен яңгыратты:

— Бүген дә сугыш мыни, Кәрим абзый?

— Сугыш, сугыш! Бүген дә сугыш! Юкса, күп шаяра башладыгыз!

— Лутчы килмә, Кәрим абзый, барыбер без җиңәрбез! Лутчы килмә!

Кәрим җавап урынына кизәнеп торып каеш чыбыркысын шартлатты да инде томырылып үргә таба йөгерде. Фәрит урыныннан кузгалмый гына боерык бирде:

— Артиллеристлар, алга!

Өч малай окоптан көпшәсе юлга каратылган, бәләкәй кул арбасы сыман ике тәгәрмәчле бер нәмәрсә тәгәрәтеп чыгардылар. Фәрит кул селтәде. Гражданнар сугышы беткәннән бирле тынып аккан Стәрле елгасы буйларын яңгыратып туп атты. Гөрселдәгән тавышы тугайларга таралып, каршы тауларга барып бәрелде дә, кире әйләнеп кайтты. Ул да түгел, куе төтен арасыннан Фәрит янә кычкырып өлгерде:

— Пехота, алга!

Куаклар артыннан берничә малай йөгерәп чыктылар да кәлә-кәлә җирдән торып килгән Кәримгә поджиглардан пох-пох китереп атарга тотындылар. Тау башындагы артиллеристлар исә шул арада кабалана-кабалана янә тупларын кордылар. Азаккы поджигларга кушылып, янә туп атты. Кәрим чигенә-чигенә килеп җиткәндә, бричка янында Тури белән Өмәт карт басып торалар иде. Алар, Кәрим ишетсен диптерме, юри кычкырыбрак сөйләшә башлады:

— Ну чукынчыклар, чистый бәла булды болар безнең башка. Ярый, Кәрим энем, синең аяклар озын, тиз тая алдың, без плин эләгә инде бу дип торабыз. Шәп йөгерәсең дә икән әле. Булышма юк белән, аларны хәзер хәйләсез алдырып булмый инде. Хәйлә кирәк, хәйлә! Әнә чигенәләр шикелле.

Тау сырты буйлап яланаяклы малайлар атлый. Дүртесе туп тарткан, калганнары, кыр казлары кебек тезелеп, арттан баралар.

Картлар ике җәй буена җыйналган зарларын Лотфрахманга сөйләргә тотындылар:

— Аткан нәрсәләрен кара син аларның, Лотфрахман абзый, — диде берсе тирләгән маңгаен сөртә-сөртә, — чын шрапнель бит, чын шрапнель, кызыл балчыктан яндырып ясаганнар. Тимерче алачыгында Барый янында булыша торгач, тупларын да шунда эмәлләгән алар. Барыйдан сораган идем, күргәнем дә юк, ди. Ә үзе белә иблис. Белгәнен күзләре үк әйтеп тора. Син аны яшь чактагы дус диген инде, я? Фәрит сиңа Гарифә түгел, аны карбыз күрсәтеп алдый алмассың, ди. Чыннан да, чакырып карбыз белән сыйларга теләгән идек без ул малайны. Кая, якын да килми...

Өмәт карт, ниһаять, Кәримгә карап сөйләргә кереш**ә**.

— Син аларны үзең аздырдың, Кәрим энем, үзең. Мин тоз белән йомшак җирләренә аткач, басыла башлаганнар иде. Син миннән патроннарны сапсим канфискация ясадың. Ярамый имеш. Гапкадир мәгъзүм бер тавыгын урлаганга, урам йөретеп кыйнатыр ие элек заманда кешеләрне. Көне буе тоз әретеп елгада утырса, нибуч туктарие, юк бит атарга хут юк, права юк. Тупларына кофискация ясарга иде һич югы.

— Әйткәч әйтим инде, күрдем, карадым мин аларның тубын да, алачык артындагы тимер-томыр янында яшереп торалар икән. Барыйдан кәтмәннәр ясатып йөргәндә күрдем. Шәп ясаганнар, имансызлар. Баш та бар икән үзләрендә. Корыч көпшәне болтлар белән ныгытып тоташтырганнар. Алып китим, дип уйлаган идем, бер, нигәдер кул күтәрелмәде. Әйдә, мин әйтәм, уйнасыннар. Дөнья шулар җилкәсенә күчә. Әнә япун нәрсәләр кыланмый анда, Хәсән күле янында, ә бу якта финнәр. Пүлшене әнә ай тулыр-тулмаста герман кабып йотты. Котырган эт өере кебек төрле яклап ташланырга чамалыйлар. Онытырга ярамый безгә... Төннәрен басмачтан алган яралар сызлаганга һаман әле йоклый алмый азапланам. Эш карбызда түгел, картлар, әйдә аз булса да атырга өйрәнсеннәр. Өч-дүрт карбыз нәрсә ул?! Иң мөһиме куркак булып үсмәсеннәр...

Кәрим сөйләүдән туктагач, аны-моны дәшми торган Тури бабай, барысына да берьюлы мөрәҗәгать иткән кебек салмак кына ялгап китте:

— Фәрит кебек малайлар һәрчак беренче булып йөриләр. Шундыйлардан чыга инде, җәмәгать ил солтаны да чабата олтаны да. Дөрес эшлисең, Кәрим энем, карабрак торырга кирәк малайларны, бик ирәеп китеп, ат караклары кебек бозылып китмәсеннәр. Кавын-карбыз җәл түгел, бүтәнчә булмасын, менә нәрсә турында уйларга кирәк. Син дә, энем Кәрим, колга буе гәүдәң белән шуларга каршы сугышып йөрисең. Арбаңа еш кына улың Назим да утырып йөри бит әле. Шул гәүдәң белән таудан йөгереп төшкәнеңне ул да күреп тора. Бала һичкайчан да атаның андый чагын күрергә тиеш түгел. Ата кеше аңа әкияттәге батырдан да гайрәтле булып күренсен.

Гадәттә аз сөйләүче Тури бабайның бу сүзләре барысына да нык тәэсир итте. Ә карбызга... Үзләренә дип үзләреннән махсус өздерсәң, алар, минемчә кул сузмаслар иде... Озак кына сүзсез утыргач, тәмәке төпчекләрен сүндереп, бричкага карбыз төяргә тотынды картлар.

Ике көн үткәч тау башындагы окоп эчендә Кәрим белән малайлар арасында «солых договоры» төзелде. Нәрсә турында сөйләшеп, ничек килешкәннәрдер — аны белүче булмады. Шул килешүдән соң Стәрле елгасы аркылы салынган Ясаклы күпере астыннан бер ат йөгенә якын патрон казып алдылар. Баксалар, Фәрит командасы патроннарны тау башыннан түгел, Стәрле елгасыннан җыеп йөргән икән... «Карбыз сугышы» тынды, бетте.

Ә бер ел үткәч, чын сугыш башланды...

Әллә кайдагы Герман белән сугышта башларын салган ирләрен көтеп, яшьлекләрен ялгызлыкта үткәреп, кеше бусагасын таптап зур авырлыклар белән балаларын үстергән әбиләр, картаеп килгән хатыннар зар елап яшь түктеләр. Авыллардан ирләрнең арслан кебекләрен җыйдылар. Бричка-бричка төялгән карбыз-кавын кебек төяләп китте ир-атлар сугышка. Шакир ташы яныннан үткәндә аларны елый-елый бакчачы кызлар озатты. Юл кырына дерелдәп торган ак сакаллы Тури бабай, эчтән нәрсәдер укына-укына, китүчеләрнең сугыштан исәнимин кайтуларын теләп калды. Бричка эченнән берәүнең ярым исерек тавыш белән мактанып кычкырганы ишетелде:

— «Карбыз пешүгә, бәлки немецның да арт ягын пешереп кайтып җитәрбез әле менә...»

Авыллар бушап, урамнар тынып, мәет чыккан йорт кебек булып калды. Шар сугып, чебенле уйнап, урамга сыя алмыйча чабышкан малай-шалай да тынды. Авыл очындагы таш зыярат мөешендә, кичкә кадәр кайта алмыйча, әтиләре кайтканны көтеп кала юлына карап утыручы бәләкәчләр күбәя башлады. Тик әтиләре кайтмады. Юеш салкын яңгырлары белән көз үтте, һәм ул елны зәһәр салкын килгән кыш җитте. Стәрле буенда үскән арслан йөрәкле егетләрнең дә күбесе Смоленск янында һәм Мәскәү юнәлешендәге сугышларда башларын салдылар. Иң беренчеләр белән киткән тимерче Барыйның да үлгән хәбәре ноябрь азакларында килде. Бу хәбәр аның әнкәсе Зөбәйдә әбине түшәккә екты. Шул ятуыннан тора алмыйча, язгы сулар кузгалыр-кызгалмаста тыныч кына итеп дөньядан китте ул. Әтисенең хәтәр хәбәре килгәч, Фәрит укуын ташлады. Өйләренә укытучы Сания апаның ике-өч тапкыр килүенә карамастан, мәктәпкә бармады. Соңгы килүендә хәтта алачыктан да чыкмады. «Язгы чәчүгә сабаннар әзерлисе бар. Сугышлар беткәч, әтиләр кайткач укырбыз» дип кырт кисте. Фәриткә ияреп тагын берничә малай укудан туктадылар. Сугышка киткән Абсаттар урынына калган Чалыш Кәли колхозда аталары урынын алган малайларга үзенең төп терәге итеп карый баашлады.

1942 елның июнь айларында Тәрек Кәриме дә сугышка китте. Озатырга диеп килгән Фәриткә елмаю аша үтенечле тавыш белән эндәште ул:

— Каладагы каралудан үтсәм, китәм инде мин. Дөнья хәлен белеп булмый. туган, син шулай минекеләргә дә баргалап йөр инде. Гарифә апаңның хәлен үзең беләсең бит... Дүрт бала, әни карчык. Бик яман килә бит бу хәшәрәт фашист. Карбыз сугышы гына түгел бит, танк бик күп диләр аңарда. Хуш, энем. Күрешергә язмаса, бәхил бул!..

Шакир ташы янында юлга бакчачы кызлары Кәримне үзе үстергән мәк чәчәкләренә күмеп озаттылар. Шул китүдән гаип булды Кәрим. «Идел кичеп, Ста-

линградка барып кердек»,— дип язган кыска хаты гына килде дә сугыш беткәнче хәбәре булмады.

1943 елның январь башларында Фәритне дә сугышка озаттылар. Алачык ачкычын ул ун яшьләр чамасындагы энесенә тоттырды, энисен, межелдәп елаган ике сеңелесен берәм-берәм кочаклап үпте дә, хуш исле печән белән күмелгән чанага утырып китте Фәрит. Аның белән бергә киткән егермеләп үсмер егетләрдән ел тулар-тулмаста хатлар килүдән тукталды. Әйләрсең, упкынга төштеләр дә баттылар...

1944 елның сентябрь башларында Шакир Ташы янындагы юлда бер җәяүле солдат күренде. Пилотка астындагы акка уралган башы, обмоткалы солдат ботинкасы, күпне күргән шинеле юл тузанына буялган. Күзләре тоньк, йөзе саргылт бу кешенең үлем белән бик озак көрәшкәнлеген күрсәтеп тора. Кәҗә тавы янына җиткәч, тукталып, тау битендәге иске окоплар ягына бераз карап торды да ул, авыр гына кузгалып, тау буендагы сукмактан авылга юнәлде. Авылга көтү төшәр вакыт иде, кәҗә-сарыкларын көтеп моңаешып торган малайлар аны бик тиз танып алды: Түбән оч Сәхи бабайның улы Хәйдәр иде бу солдат. Фәритләр белән бер көнне киткәч елдан артык хәбәрсез югалып торган Хәйдәрнең шулай көтмәгәндә кайтып керү хәбәре авыл урамнары буйлап яшен тизлеге белән таралды. Атнадан артык Сәхи бабайның капкасы ябылмады. Хәйдәр белән киткән уллары турында берәр генә авыз булса да җылы сүз ишетергә өмет иткән аналар аларга көн саен килделәр. Тик Хәйдәр аларның өметләрен акларлык хәбәрләр сөйләмәде. Кайтканнан соң күп вакыт ул көзге кояшлы көннәрдә ишек алдында, нигездә утырып, көннәр кояшсыз булса, сәкедә ятып үткәрде. Кайтканның икенче көнендә үк ул больницага барды. Татар авылларында күп эшләп татарча чатнатып сөйләшә белгән фельдшер хатын, Хәйдәрнең башындагы марляны чишкәч, сүз таба алмый шактый торды һәм елады. Хәйдәр дәшмичә генә утыра бирде. Аның баш түбәсеннән алып җилкәсенә табан сөяксез яра җәелеп ята. Юка гына кызыл тире тартылып ябылган ярада кан тибеше күренеп тора... Яралы башны чалма кебек итеп ак марля белән бәйләп куйды да фельдшер тагын елап алды. Ә Хәйдәр торып өстендәге гимнастеркасын саклык белән генә сала башлады. Аның күкрәге дә, аркасы да ак бинт белән урап бәйләнгән иде. Маруся апаның сораулы күз карашына Хәйдәр кыска җавап бирде:

— Танклар белән сугышканда...

Аркасын бәйләп бетереп чыгып китәр алдыннан исә ул, тәрәзә аша ерактагы тауларга карап, дәвам итте:

— Син, Маруся апа, минем яралар турында бик сөйләнмә инде. Тән яралары төзәләр, тик менә йөрәкнеке генә...

Бу көннәрдә фронттан яхшы хәбәрләр килә башлаган иде инде. Октябрь азакларында, госпитальдән кайтып баручы Заикин авылы рус танышы Мөеш Хәйригә:

— Язга сугыш бетәчәк, кияүләреңне көтеп, исән-имин калуларын теләп тор,— диеп, ярым чынлап, ярым шаяртып әйтеп узган.

1945 елның язында, сугыш беткән чамаларда Хәйдәр Тури бабай янына бакча каравыллларга урнашты. Әмәт карт үлгәч, ялгыз калган Тури бабайга Хәйдәр яхшы иптәш булды. Карбыз сугышы вакытындагы халыктан икәү генә калгангамы, әллә бүтән нәрсә сәбәп булгандырмы, алар бик нык дуслаштылар.

Бер көнне Хәйдәр унике-унөч яшьләр тирәсендәге яланаяклы бер малайны кыяр түтәлләре арасында үрмәләп йөргән чагында тотып ала. Куыш янына алып килгәч, сораша башлыйлар:

— Нишләп йөрүең бу, малай актыгы? Кем малае син?

— Әти сугышта минем.

— Әниең кем?

— Гарифә.

— Кайсы Гарифә ул тагын?

— Тау буе Гарифәсе.

Хәйдәр нәрсәдер хәтерләргә тырышкан тавыш белән:

— Тукталь, Тури бабай, тукта! Кәрим абый улы түгелме соң бу үсмер?

— Кайсы Кәрим?

— Соң үзебезнең Кәрим абзый инде, Тәрек Кәриме. Шуның улы Назыйм бит син?

— Шул...

Өчесе дә бераз дәшми тордылар.

Тури бабай калтыранган тавыш белән:

— Нигә бернәрсә дә әэмәдең? — диеп сорады.

— Мин карбыз эзләгән идем, табып булмый.

— Тәмле тамак икәнсең үзең.

— Түгел. Әни авырый. Кичә әйтә: ай атаң өйдә булса, карбыз ашатыр иде дә, шуннан терелеп тә китәр идем әллә, ди.

— Әй, улым, улым. Нигә сорамаска инде туры үземә килеп: шулай-шулай, Тури бабай, мин Кәрим малае, әни авырый, шуңа дарулык кына кирәк, дип.

Тури бабай, куыштан сөйләнә-сөйләнә капчык алып чыкты да су буена төшеп, түтәлләр арасына кереп китте.

Назыйм Хәйдәрнең кояшта янып, кутырлары төшеп тәзәлеп бетә язган алалы-колалы аркасына балаларча кызгану белән карап торды да капыл гына сорап куйды:

— Фәрит абый кая булды, Хәйдәр абзый?

Хәйдәр, күкрәген йомшак кына итеп ышкудан туктады, агарынып китте, зәгыйфь тавыш белән җавап бирде:

— Фәрит Курск дугасында һәлак булды...

— Әнисе Нәфисә апа Барый абзыйны да, Фәрит абзыйны да көтә. Атна саен безгә килми калмый. Барый абзыйның 1941 нче елны ук килде үлгән хәбәре. Ә Фәрит абый билгесез... Тередер әле, бәлки, ди бер хәбәр дә булмагач...

— Янып үлде ул, Назыйм, танкка ташланып... Капчыгын куярга онытып каушап калган Тури бабайга Хәйдәр яшь баскан күзләрен күтәреп карады.

— Әнисенә ник сөйләмәдең?

— Ничек сөйлисең инде, бабай. Менә сугыш бетте, хәзер сөйләсәм сөйләрмен инде, тик аны ничек әйтәсең янып үлде дип.

Куыш янында алар озак утырдылар. Хәйдәр боларга ике елдан артык эчендә йөрткән сызлануын сөйләп бирде.

— Егермедән артык чыгып киткән идек бит без, әлеге көнгә менә бер мин кайттым. Барыбыз да бергә эләгергә тырышып караган идек, булмады. Фәрит үзе сорагач, артиллериягә алынды. Бергә киткәннәрдән Фәрит янына без алтау эләктек. Бер атна-ун көн автоматтан, мылтыктан атып йөрдек тә, калган ай ярымын — гел туптан. Шуннан фронтка. И-и-и, ни генә күрми икән адәм башлары! Харьков өчен барган сугышларның азагына барып эләктек. Барып та кердек, сугыша да башладык. Бирсә бирә икән бер кешегә башны да, йөрәкне дә, Фәрит полкта иң оста төбәүчеләрнең берсе булып китте. Гел карт солдатлар тирәсендә йөрде. Ул бит безнең кебек җебек түгел, баскан җирендә ут чыгарып атлый иде. Сугыш барганда бүреген кырын салып ала да үз эшен белә. Әллә бар аңа немецлар ачкан ут, әллә юк. Аның өчен әллә немец танкы килә, әллә утын арбасы. Бик еш искә ала иде ул синең әтиеңне, Назыйм, теге карбыз сугышларын, үзебезнең тупны. Кәрим абзый безне юри шулай үртәп тупка өйрәнә торсыннар болар дигәндер инде, дип кәлә иде. Егетләр, без Туган илне, Сәрле буйларын, үзебезнең карбыз бакчасын саклыйбыз бу сасы фашист хәшәрәтләрдән ди иде.

Җитмеш алты миллиметрлы тупта йөрдек. Ат белән тарттыра торган идек. Безгә авыр, ә ул хайваннарга бездән дә авыр. Ашамас-эчмәс иде үзе, иллә иң әүвәле атларны карар иде Фәрит. Начаррак караганнарның өстенә менеп китә торган иде инде. Берәр тыл обозы очраса, шул атларга азык эзләр... Хайваннарның теле генә юк бит ул, Фәрит күренде исә, пошкырып, әкрен генә кешнәп каршы ала торганнар иде. Атларыбыз да безне бер тапкыр да кыен хәлдә калдырмадылар. Безнең атлар елкылдап, бөтен полкта аерылып тора иделәр... Апрель башлары иде бугай. Украинада Синельниково дигән зур станция бар икән. Шуның өчен сугышканда без бер Потебня дигән бәләкәй генә хуторны алдык та шул хутор янында камалышка эләктек. Әллә ничек буталчык булды ул һөҗүм. Һавасы юеш, җире кап-кара сазлык иде. Кичә генә һөҗүм итә идек, бүген өйлә-

гә бар да чигенә. Пехота пычракта да чапыр-чопыр атлый бирә, ә бездә туплар. Ашарга юк, әйләнә-тирәдә немец, снаряд бетте дияргә ярый. Бик каты сугыш булды шул хутор янында. Бөтен батареядан биш кеше калдык. Туплар немец снарядларыннан ватылып, атмас хәлдә калды. Берсен немец танкы бөтен расчеты белән таптап-сытып юк итте... Караңгы төшүгә, немец туктады. Төнге сугышны яратмый алар. Бишәү калдык. Кем, кая — белгән юк, беребезнең боты яралы. Төнлә атларга атландык та үзебезнекеләрне эзләп киттек. Төн буе бардык, көндез бер чокырда куе агачлыкта качып яттык. Кичкә авыша башлагач, юлсызнисез тагын сыпырттык. Ашарга-эчәргә юк. Шул кичне бер бәләкәй генә хуторга җиттек. Сугыш тавышы көнчыгыштан ишетелә, ә без монда. Бу хуторда биш кенә йорт. Немецлар юк. Без кергән хуҗа Зайдун фамилияле. Ул кеше немецлар вакытында кем булгандыр, белмим, тик ул безне сатты. Өенә кердек — ашатты, эчерде, йокларга урын әзерләде. Фәрит миңа әйтә, син, Хәйдәр, сакка чык, күңел тыныч түгел, бу хуҗаның нигәдер күзләре ошамый миңа, ди. Чыктым да куак астына постым. Ярты сәгатьләп вакыт үткәч, Фәрит чыккан. Аның белән хуҗа кеше, аннан үзебезнең Чиләбе ягыннан Пәдер дигән чуаш иптәш бар иде. Ул да чыккан. Җәрәхәтле иптәшнең боты пеште. Фәрит боларны күрше хуторга йод алырга җибәрә икән. Пәдергә гел татарча гына сөйли Фәрит. Чуашның татарча белмәгәне бик сирәк бит аның. Болар хуҗаның атын җигеп китте. Фәрит тә керәп ятты. Ике сәгать үтмәгәндер, яңадан торып чыккан бу. Нигәдер эч поша, йоклап булмый, ди. Мине кертеп җибәрде дә үзе калды сакта. Мин кереп тә яттым, йокыга киттем. Бер заманны Фәрит өйгә кергән дә акрын гына тавыш белән боерык бирә:

— Паникасыз гына, иптәшләр! Немецлар килә, жигүле ат белән, — ди.

Сикерешеп тордык.

— Син, син! Тиз генә тәрәзәдән чыгыгыз, каралтылар артыннан бәрерсез! Без икәү моннан сугарбыз!

Фәрит яралы иптәш белән калды, ә без тиз генә сыз тәрәзәдән. Минут үтмәгәндер — әзер булдык. Зайдун безнең Пәдерне туп-туры немецларга алып барган да тоттырган. Азактан сөйли Пәдер, сизеп калып автоматка тотынган идем, этәп екты да акырырга тотынды ди. Сталинград өчен үч алырга тырышты фашист ул көннәрдә. Бик нахал кылана иде. Капка төбенә үк килеп туктадылар болар. Пәдернең коралы юк, немецлар, аны алдан җибәреп, үзләре арттан йортка якынлаша башладылар. Шуннан кычкыралар: «Русс сдавайсь!» — диләр. Пәдерне алдан җибәргәч, күрәсең безнең атмавыбызга нык ышанганнар иде. Болар өй янына килеп җитәргә дүрт-биш адым кала, ишек ачылып та китте, Фәрит автоматтан тырылдатырга да тотынды, без икәү арттан. Бер яралыдан икәү булды. Фәрит атканда Пәдернең сул кул башына ике пуля эләккән. Икесен дә тегеләр килгән арбага утырттык та, мин кучер урынына, Фәрит белән бер иптәш ат менеп, чыгып җилдерттек. Зайдун ат янында калган иде. Атыш башлангач, юк булды. Эзләп торырга вакыт юк, шул көйгә чыгып киттек. Пәдер ыңгыраша, Фәрит аның ярасын ачып карады да көлә:

— Бәхетеңә каршы, әз эләккән, фашист ияртеп йөрмә икенче, — ди.

Икенче көнне генә үзебезнең частьларны куып җиттек. Зур газап белән үз полкыбызны таптык. Полк командиры безне берәм-берәм үбеп чыкты. Яралыларны медсанбатка озаттык. Пәдер ике атнадан савыгып кайтты. Шәп егет иде ул. Фәрит аны көлеп «Чиремпиллек» дип йөртә иде. Нәрсә дигән сүз булгандыр инде, белмим. Шуннан соң немецне туктаткач, безне пополнениега чыгардылар. Аннан инде Курск сугышы башланды. Бу чакта Фәритнең Кызыл Йолдыз ордены белән ике медале бар иде инде. Аның белән полк командиры сөйләшеп карады. Хәрби училищега җибәрергә теләгән иде ул Фәритне, тик Фәрит риза булмады. Көлкегә бора да куя сүзне: «Мин укып йөргән арада я сугыш бетеп куяр... Сугыш беткәч, мин хәрби хезмәттән китәм, кавын-карбыз үстерәм колхозда», — ди. Солдатлар карбыз сугышын аңардан кат-кат сөйләтеп көлешә торганнар иде... Безне Курск тирәсенә андагы сугыш башланганчы бер ай элек илтеп куйдылар. Көне-төне диярлек бертуктаусыз җир казыдык. Җәй матур килде, ул тургайлар сайрый, ул бөтен кош-кортлар... сугыш беткән дип уйларсың. Барыбыз да таза-

рып, кояшта янып эшли-эшли кызынып ял иттек. Курск яклары бик матур, җире кап-кара, кулда кыссаң мае чыгып тора. Соңыннан урынын үзем күрдем, фашистлар Курск җире туфрагын хәтта вагон-вагон тутырып Германиягә ташыганнар... Ә сугышлар башлангач беренче көнне үк Пәдерны югалттык. Снаряд алырга дип үрелгән җиреннән ых кына итте дә тәгәрәпләр генә китте. Кай җиренә тигәнен карарга вакыт та булмады. Кара саранча кебек килә иде фашист. Китте сугыш, китте кырылыш. Ашарга, юынып торырга вакыт юк, көне-төне атыш та, бомбежка, бомбежка да атыш. Һөҗүмнең өченче көнендә фашистларның унлап танкы безнең оборонаны өзеп, окопларны теткәләргә тотынды. Снаряд шартлап, безнең тупны әллә кая алып очырды. Адәм баласы чыдаса чыдый икән ул. Китте халык кызып, мин сиңа әйтим. Кулга нәрсә эләгә шуның белән сугыша. Туп булмагач, тотындык гранаталарга, автоматларга. Кая безнекеләр, тирә-якта тагын бармы-юкмы, аны күргән юк, уйларга вакыт та юк. Тик башта бер генә уй: фашистны күбрәк юк итәргә! Үзебезнең исән калуга өмет беткән иде инде. Сугышкан җиребез — азрак калку урын иде. Белеп булмый, тик немец безне уратып үтте бугай. Өйлә вакытларында бер сәгать тирәсе булыр, немец азрак туктап торды. Шунда Фәрит миңа:

— Хәйдәр дус! Әгәр исән калсак, Стәрлегә кайткач, йортларны күрше итеп салыйк та авылдан беркая да китми шунда картайыйк. Әгәр инде кайтырга язмаган икән, ничек һәлак булганны әнигә сөйләмә, ярармы? Күп сорап-сөйләп булмый, туры килгәндә кайткач ярдәм иткәлә. Тере калсам, синекеләрне мин дә ташламам.

Без аның белән шулай сүз куештык. Шул көнне кич кырын Фәрит дусым минем күз алдымда янып үлде... Безнең окопка ук килеп менгән ике танкның берсен гранаталар, шешәләр белән бергәләп яндырып туктаткан идек, икенчесенә тотынырга торганда әллә кайдан, уйламаган яктан, кара төтен эченнән өченчесе килеп чыкты. Фәрит кулындагы яндыра торган сыеклык тутырылган шешәгә пуля тиде ахры — ыргытырга дип кизәнгәндә бөтен өстенә ут кабынды, ә икенче кулында тагын бер шешә иде. Ул шуннан соң үзен урап узып барган «Тигр»га ташланды, утлы тере чүмәлә кебек йөгереп барып, артыннан менеп китте. Шундук икенче шешәсе шартлады. Шул танк өстендә янып көлгә әйләнде, энем, безнең Фәрит.

...Ә үземә икенче көнне арттан башка таяк белән суккан кебек кенә булган иде, соңын хәтерләмим. Арка кайда янган — анысын да белмим. Ноябрь бәйрәме үткәч, Новосибирск госпиталендә аңыма килдем. Врачлар сорап-сорап карыйлар кем икәнемне, барысына да «Фәрит!» дип җавап бирәм икән. Башта шул бер сүз калган, башкалары онытылып беткән... Азрак терелә башлагач, Кыргызстанга җибәрделәр. Анда кымыз эчеп, ит ашап азрак рәтләндем... Менә шул инде, энем, сугыш дигән нәрсә. Карбыз урлап, үзебез ясаган туптан атып йөргәндә кызык иде, чыны бик яман була икән...

Көн кичкелеккә авыша башлаганда, Назыймны юату сүзләре сөйли-сөйли авылга озаттылар бакчачылар:

— Кайтыр улым, кайтыр алла кушкан булса, әтиең, кайтыр. Андый егетләр дә ятып калса, дөньяны кем күтәрер, кем? Әнкәңә әйт, терелсен тизрәк. Кавыннарыңны онытма. Капчыгын китерерсең. Бакчага шулай килгәләп йөр. Син бит, улым, бакчачы Кәрим малае.

Малай капчыкны аркасына күтәрде дә тауга карап юл алды. Тури бабай дымлы күзен кул сырты белән сөрткәли-сөрткәли кипшегән иреннәрен кыймылдатты...

Ә көзен җиңүчеләр кайта башлады. Тик тимерче Барый да, бакчачы Кәрим дә, әле бер кем дә булып өлгермичә унсигез яшендә ут эченә кереп киткән Фәрит тә кайтмады.

## ГАФУР КОЛӘХМЕТОВНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

### Диас Вәлиев

# АШКЫНУ

Ул күктә балкыган якты йолдыз кебек иде. Тиз, бик тиз сүнде. Бары тик 37 яшендә... Ә яктысын күрми калмадылар. Зурлыгын да белмиләр түгел: үзен татар әдәбиятының классигы дип атыйлар. Әмма аның күңеленнән чәчелгән нурларны күреп бетерә алдыкмы? Балкышы һәр тарафка да барып җиттеме икән?



Дөнья әдәбияты күгендә яктырырга лаек булган бу драматург һаман да ачылып җитмәгән хәзинә булып калмыймы?

Аның йөрәк җимеше — «Ике фикер» исемле фантастик драмасының төп герое Давыт өч юл чатында басып тора. Беренчесе — көндәлек яшәеш кысаларыннан ары китмичә, үз тамагыңны гына кайгыртып, вак мәшәкатьләр белән гомер үткәрү. Фикерсез-аңсыз, хайвани яшәеш. Давытның тирә-юнендәгеләр, аның мохиты әнә шулай яши, элекке дуслары шулай көн күрә. Икенче юл — юкка чыгу, бетүгә алып бара торган юл. Кара фикер Давытны нәкъ әнә шул юлга этәрергә омтыла. Өченче юл бар: шушы искиткеч гүзәл һәм гаять кырыс дөньяда кеше булып яшәү өчен көрәш юлы, ул дөнья чыннан да гүзәл булсын өчен даулашу юлы. Кызыл фикер Давытны әнә шушы юлга чакыра. Ә Давыт исә шушы өч юлның тормышта гына түгел, ә үз җанындагы реаль яшәешен — кеше рухының өч төрле халәте, өч яссылыгы рәвешендә яшәвен аңлый. Әйтерсең, аның күңеленә өч җан иясе кереп урнашкан да, һәрберсе үз ягына барырга теләп тартыша. Давытның үзен шуларның берсенә генә кайтарып калдырып та булмый: Кызыл да, Кара гына да, Соры да түгел ул. Ул үзендә чынбарлык төрлелеген чагылдыра. Ә тормыш ул һәрчак төрле-төрле, аңарда юллар, мөмкинлекләр, төрле тенденцияләр бергә укмашкан. Төсләр спектрының кайсы да булса бер канаты гына түгел, ә спектрның тулаем нәкъ үзе. Һәм менә кеше табигатенең барлык олы һәм вак, югары һәм түбән сыйфат-гаудәләнешләрен үзенә җыйган Давытка шул юлларның берсен сайлап алырга, бердәнбер хак юнәлешне табарга кирәк. Үз табигатенә каршы күтәрелеп, аңа хилафлык китерү бәрабәренә түгел, ә тормышның иң олуг мәгънәсенә, чын гүзәллегенә ирешү өчен кирәк ул аңа. Һәм Давыт ул иң олы мәгънәне таба да: тормышта юллар ни чаклы булмасын, кеше булып калу юлы бирәү генә — Кызыл фикер ачкан юл.

«Ике фикер»— символик эчтәлекле әсәр. Давыт образында (библия хикәятләрендә — кечүче Давид, ул бары тик таяк һәм пращ белән коралланган килеш тимер киемле, иләмсез зур кылычлы дөнья хәшәрәте явыз Голиаф белән алышка чыга һәм җиңә). Гафур Коләхметов тилмереп һәм газапланып үзенә хак юл эзләүче кешелекне гәүдәләндерә. Голиаф кабат терелеп кешелек юлына аркылы баскан һәм Давыт — борынгы хикәятләрдәге түгел, ә егерменче гасыр башында яшәгән хәзерге заман кешесе — дәһшәтле, явыз көчкә каршы аяусыз көрәшкә чыгарга үз-үзендә рухи көч таба.

Бер якта — абсолютизм һәм җәмгыять тормышының һәр тармагына, һәр күзәнәгенә үтеп керергә омтылучы шымчы чиновниклык аппараты, яшерен полиция һәм жандармерия челтәре, гасырлар буе үзгәрмичә катып калган тормыш тәртипләре, икенче якта — гади бер адәм баласы, аның кешелек намусы,— бу көрәштә кемдер җиңәргә, кемдер җиңелергә тиеш.

«Без барыбыз да җан иятәре бит. Җан ияләре булгач, без ничек яшәргә тиешбез?..» «...без дә дөньяда үзебезнең кыйммәтне аңламый яшибез...»

Коләхметов героена үз-үзен аңларга, үзе яшәгән мохитны, бар дөньяны танып белергә кирәк. Бу — аның өчен яшәеш ихтыяҗы.

«Шул хәлебезне аңлау тиешме безгә? Шуны аңларлык дәрәҗәгәчә, ичмасам, без уяныргә тиешме?..» «Хәтта хайваннарның акыллысы дип саналабыз бит.»

Һәм менә ул җаны-тәне, вөҗданы белән ничәдер кисәккә ярылган-бүлгәләнгәнлеген тойган, аңында берничә «мин» яшәгәнлеген сизүдән эчке газап кичереп бәргәләнгән хәлдә, ярсып һәм үчләнеп, үзендә бер бөтен шәхесне табарга омтыла. Хакыйкатькә бер ялгызың ирешү кыен нәрсә икәнлеген, хакыйкать юлын бергәләп эзләү тиешлеген Давыт тиз генә аңламый әле. Ул моңа соңрак төшенә. Һәм менә шушы авыр, газаплы юлда чын иптәш, таяныч булырлык беренче кешене очрата.

Монысы шулай ук бик сәер персонаж. Галия үзе болай реаль тормыштан алынган образ. Әмма аларны баглый торган җепләр җирдәгечә, көндәлек яшәештәгечә түгел. Аларны илаһи бер көч бер-берсенә якынайта.

«Мин сине сөям! — ди Галия.— Хатын-кыз сөюе белән түгел! Хатыны ирен яраткан кебек түгел! Менә бу серле урманны сөйгән кебек, Давыт, мин сине сөям!..»

Алар караңгы дөнья эчендә бер-берсен табып алалар, алдагы юлларын бергә дәвам иттерәләр. Кая баралар, нәрсә эзлиләр? XX гасырның Адәм белән Һавасы кая барып ирешерләр, нәрсә табарлар?

Гафур Коләхметов драмаларын укыганда (алдарак күрербез, аның «Яшь гомер» пьесасында да шуңа охшашлы моментлар җитәрлек) борынгы миф геройларына бәйле күзалланышлар тууы очраклы түгел. Чын сәнгать — резонатр кебек, үткән заманнар, башка эпохалар белән уртак яңгырашлар тудыра, аларны бер җепкә тоташтыра. Реалистик фикер агышы — ә көндәлек тормыш-көнкүрештәге акыл күзлегеннән карaганда, Давытның рухи эзләнүләре тарихы әнә шул көндәлек акыл чикләреннән чыгып, «исәрләнеп» йөргән кеше турындагы хикәят кенә бит — яшәеш, аның мәгънәсе хакындагы фәлсәфи фикер спирале булып әверелә. Гафур Коләхметов драмалары — тирән фәлсәфи драмалар.

Аның фикерләвендәге яңалык искитәрлек. «Ике фикер» пьесасын драматург 1905 елда иҗат итә. Гасыр башында. Ә хәзер исә, гасырның соңгы чирегендә алдан күрүчәнлегенә, фикри әүлиялегенә, киләчәктә шаулаячак дәһшәтле вакыйгаларны сиземләвенә гаҗәпләнми мөмкин түгел. Менә әсәрдән алынган кечкенә бер күренеш.

Давыт төшләр күрә. Нинди төшләр? Без һәркөнне газета битләрендә укыган, дөньяның төрле төбәкләреннән һәр сәгатьтә телетайплар, телевизион камералар алып килгән вакыйгалар түгелме соң болар?

Кызыл фикер. Адәм йокыга китте... Ул төш күрә... (Сәхнәнең арт ягыннан пәрдә күтәрелә, анда сыйныфлар көрәше тасвир кылына. Давыт гавам белән бергә... богаулар чылтырый, гавам ыңгыраша.. кулларында таяклар, мылтыклар, ташлар... Каршы яктан монтазам гаскәр, гавам... алга бара, күбесе егыла...)

Гасыр башында язылган шушы берничә юлда XX гасырның йөзен билгели торган сыйнфый көрәш вакыйгаларын сиземләү ята. Октябрь революциясенә кадәр әле ун-

ике ел вакыт бар, ә әсәр 1917 елның Октябре, Куба, Вьетнам, башка илләрдә булып узган канлы вакыйгалар, фашизмны юк итү турында сөйли кебек. Безнең гасыр дәвамында үзенең кара язмышын тамырдан үзгәртеп, яңача яшәеш юлларын ачкан кешелек дөньясы күз алдына килә.



*Г. Колахметов әнисе белән. 1915 ел.*



Кинематограф әле яңа туып, беренче адымнарын атлаган чорда драматург нәкъ менә киногa хас сурәтләү чаралары белән шактый иркен эш итә, гүя монтаж методы белән масса күренешен, андагы аерым детальләрне сурәтли. Биредә тормыш реалияләренә нигезләнгән сюжет һәм, шуның белән бергә, ассоциатив фикер, ирреальлекне файдалану күзгә ташлана.

Художникларның, менә шушы рәвешчә, үз чорыннан киләчәккә атлап, моңарчы күрелмәгән сурәт һәм стиль чараларына мөрәҗәгать итүе үзе зур мәгънәгә ия. Бүген хөкем сөргән караш күп элгәрерәк туган, сиздермичә генә куәт җыеп, өлгереп килгән икән. Бу яктан алганда, сәнгать — бүгенгедәге киләчәк, әлегә тормышның бер яссылыгында, хыял рәвешендә чагылган киләчәк.

Һәм тагын бер нәрсәгә игътибар итми калмыйк. Бу — фикер сөрешендәге яңалык, дияргә мөмкин.

«Гаҗәп!.. фикерем икегә аерылды... минем башымда сугышалар... төшенеп җитә алмыйм... ник мин болай булдым соң?»

Давыт әнә шулай өзгәләнә. Бүгенге укучы шушы авазларда кешелек эшчәнлегенең күп тармагында соңрак чорда аеруча ачык яңгырый башлаган мотивларны ишетмиме?

Кешелекнең фикерләү рәвешендә туган тирән үзгәрешләр, дөнья һәм кеше табигате хакындагы метафизик карашларның җимерелә башлавы язучы Г. Колахметов иҗатында да тирән чагылыш таба. Кызыл, кара, соры фикерләргә тәрләнеп, өч төрле яссылыкта яшәүче Давыт образы белән Г. Колахметов кеше җанының чиксезлеге, күп төрле хасиятләргә керә алуы хакында сөйли кебек. Аны дөрес тасвирлау өчен бер-берсе белән сыеша алмый торган сыйфатларны бергә туры китерергә, аларның аяусыз бәрелеш-көрәшләрен күрсәтергә кирәк. Пьесаның финалында Давыт белән Галия Кызыл фикергә ияреп китәләр. Шул ук вакытта алар инде Кара һәм Соры фикер тәҗрибәсен дә үзләштерә бара. Киләчәк көрәшләр өчен бу тәҗрибәнең дә файдасы булачак.

Реализмның элгәрге формалары инде искереп барган, тормыштагы яңа күренешләрне сурәтләү өчен аның мөмкинлекләре җитенкерәми башлаган чорда автор

«югары мәгънәсендәге реализм» чараларын ярдәмгә чакыра. Шундый реализм хакында әле Достоевский ук язып чыккан һәм аны үз иҗатында үстергән иде. Аның геройлары үз шәүләләре белән сүзгә керәләр, җеннәр белән аралашалар һәм, язучы иҗатын тикшерүчеләрнең берсе М. Бахтин әйткәнчә, «үз карикатуралары» белән әңгәмә алып баралар.

Гафур Коләхметов драмалары гаҗәеп бер хасияткә ия: символик характерда булсалар да, алар анык бер заман, мәгълүм бер җирлеккә нигезләнгән, көндәлек яшәеш эченә утыртып куелганнар. Ике реальлек — көндәлек тормыш реальлеге, гадәти дөнья һәм шуның эчендә — символик реальлек, шуларның бәрелеше, бер-берсе белән үреп баруы язучы эстетикасының асылын тәшкил итә.

Көндәлек акыл дәрәҗәсеннән караганда, «Ике фикер» әсәре — акылдан язган кеше тарихы. Давытның элекке иптәшләре нәкъ әнә шундый акыл яссылыгында яшиләр, алар күзендә Давыт — акылдан шашкан кеше. Әмма, югары мәгънәсендә алганда, пьеса адәми затның киеренке рухи эзләнүләре тарихын бәян итә. Акыл кысасыннан читкә чыгуга килсәк — анысы бар, ләкин нәкъ менә көндәлек яшәешкә корылган кыска һәм түбән акыл чигеннән чыгу ул.

Г. Коләхметовның 1908 елда язылган «Яшь гомер» драмасын алып карасак та шундый ук нәтиҗәләргә киләбез. Бер яктан, ул бик тә реалистик, беркадәр дәрәҗәдә фаҗигале хикәят, революционер Гали белән Зөләйха исемле яшь кенә бер туташның мәхәббәт тарихы. Зөләйханың бәхетен кисүче искергән тәртипләр, иске йола, гореф-гадәтләр һәм Гали кебекләрнең рухын, аңын изүче абсолют монархиянең тупас хакимлеге — бу ике көч аларны җиңелүгә дучар итә. Галине төрмәгә ябалар. Зөләйхага явыз ир йортында күз яше сыгып гомер кичерергә кала.

Ләкин бусы әле әсәрнең бер ягы гына. Икенче яктан драматург, үз геройларын көнкүреш сюжетыннан аермаган хәлдә, шул гадәти яшәеш эчендә шигъри нурланыш таба, аның фәлсәфи мәгънәсен ача, ә бу яссылыкта инде пьеса Россия яшьләренең тормышы турында сага булып яңгырый башлый. Тормыш-яшәеш гаять тә каршылыклы, ә финалдагы фаҗигале ноталар символик мәгънә ала, алар кисәтә, чакыра, яный...

Менә алар, тормышны үзгәртеп корырга омтылучы яшьләр — Гали, Йосыф, Вәли. Дөньяны явызлыктан, гаделсезлектән чистартырга килгәннәр. Әнә дүртенче зат — йола һәм гореф-гадәт тырнагыннан ычкына алмаган, залимлек корбаны булып яшәүгә дучар ителгән Зөләйха. Аңа кем ярдәм итәр, аны кем коткара алыр?

Вәли өчен дөньяда иң кыйммәтлесе, иң мөһиме — үз максаты. Ул гомуми категорияләр белән эш итә. Аерым бер кешенең язмышы белән шөгыльләнергә аның вакыты юк, ул Зөләйханы да корбан итәргә риза. Россиядә бәхеттән мәхрүм ителгән кешеләр бик күп, барысын да аерым-аерым коткару мөмкин түгел, моның өчен революция ясарга кирәк, дип саный ул.

Галинең Зөләйхага мәхәббәте — кызганулы мәхәббәт. Гали революцияне аерым кеше язмышыннан аерып карамый. Әмма ул үзенә күрә бер «уйга талу» чире белән авырый, уй-фикер туплавы аны анык бер гамәлне, конкрет эшне тормышка ашыруга этәрми дә кебек. Болар арасыннан бары тик Йосыф кына (биредә без тагын дини риваятьләрдәге Йосыф образының үзенчәлекле интерпретациясе белән очрашабыз) олы максат өчен дә, аерым бер кешенең язмышы өчен дә көрәшергә әзер, һәм көтелмәгән бер очраклылык аркасында гына ул Зөләйханы бәладән коткара алмый кала.

Монда да төрле караш һәм фикерләр бәрелеше. «Ике фикер» пьесасындагы кебек, «Яшь гомер» драмасында да авторны яңа кеше, чынбарлыкны тамырыннан үзгәртеп корырга сәләтле герой образы кызыксындыра. Давыт һәм Гали кебек укымышлы яшьләр образлары белән беррәттән әсәрдә Вәли, Йосыф кебек эшче образлары да бар. Иске җәмгыятьтә хөкем сөргән тәртипләрне юкка чыгаруны максат итеп куйган партия зарури рәвештә аны нинди җәмгыять белән алыштыру хакында да уйларга тиеш. Нинди җәмгыять һәм нинди кешеләр белән...

«Ике фикер» пьесасында Г. Коләхметов Давытның буш һәм мәгънәсез тормыш алып баручы дуслары портретларын бирә. «Яшь гомер»дә дә андый персонажлар

аз түгел. Әсәрнең ирекле композициясе революция алды җәмгыятенең төрле катламнары тормышын, күп төрле типларны күрсәтергә мөмкинлек ача. Күбесе тискәре типлар: рухи ялчылар, вак хәйлә белән яшәүче мещаннар, үзенең кысан дөньясыннан башка берни белергә теләмәүче битарафлар. Гали, Йосыф һәм Вәлиләрне урап алган мохит әнә шундый. Революциягә киртә коручы көчләр самодержавие һәм аның золым аппараты гына түгел. Киртәнең, мөгаен, иң хәтәре — самодержавие тарафыннан гасырлар буе изелеп килгән вак һәм буш җанлы, эгоистик адәм заты. Революция җиңгәннән соң икенче көнне үк аның яңа һәм иң катлаулы этабы башлана: әнә шул кечкенә эгоистик бәндәне рухи яктан яңадан тудыру өчен көрәш этабы. Бары тик бөтен рухы белән янарган, сыйнфый эгоизмнан тулысынча азат булган кешене тәрбияли алганда гына чын җиңү турында сөйләргә мөмкин.

Революция кешенең аңы, йөрәге аша үтә, монысы да — гаять әһәмиятле көрәш мәйданы. Гафур Коләхметов үзенең әсәрләрендә иске заман вәкилләрен сурәтләү белән бергә, яңа кеше, киләчәк заман кешесенә төбәлә, төп игътибарны революцион аңы уянган яисә уяна башлаган кешеләргә юнәлтә.

Шунысы аеруча кызыклы, драматург һич тә ул кешеләрнең портретларын идеаллаштыру, күпертеп күрсәтү юлына басмый. Үзе партияле кеше, профессиональ революционер буларак, яшертен революцион эш алып баручы иптәшләрен ул якыннан белә һәм чынбарлыкта нинди булсалар, аларны шулай гәүдәләндерә дә.

XIX йөзнең ахыры, XX йөз башы сәнгатендә символик башлангыч киң җәелә. Берьюлы ачылган чәчәкләр кебек символизм үсентеләре төрле җирлектә калка. Бу елларда Бельгиядә, Франциядә Морис Метерлинк иҗат итә. Россия әдипләре дә (мәсәлән, Леонид Андреев) бу юнәлештә шактый күп эш күрсәтәләр. Символик характердагы әсәрләр шушы ук чорда татар милли культурасы җирлегендә дә пәйда була. Әмма символизм һәркайда да бер үк төрле түгел. Коләхметов персонажлары— һәркайчан конкрет характерлар. Алар үзләре яшәгән тираләк белән тыгыз бәйләнгән. Шул ук вакытта алар бөек борылышлар алдында торган кешелекне символлаштыралар. М. Метерлинк персонажлары, киресенчә, җир кешеләре түгел диярлек, алар шартлы мохиттә хәрәкәт итүче символлар, изеп, таптап китәчәк билгесез хәтәр көчне көтеп, өнсез калганнар. Метерлинк сурәтләгән кеше — билгесезлек корбаны. Аның «Сукырлар» исемле әсәрендә кешелекне гәүдәләндерүче уникe персонаж төн караңгылыгыннан башка нәрсәне белми, Леонид Андреевның символик драмалары геройлары да әнә шундыйрак халәттә сурәтләнә.

Бу талантлы язучыларның драматургиясен караңгылык драматургиясе дип атарга мөмкин.

Г. Коләхметов исә әсәрләре белән якты көнгә омтыла. Аларда кеше үз сукырлыгына каршы чыга, күзләрен каплап торган пәрдәне куркусыз рәвештә ертып ташлый. һәм шул чак аның күзләре дөньяны күрә, аны яңартуның зарури бер нәрсә булуын аңлый башлый.

Үзенең икенче әсәрен М. Горькийны телгә алып башлап китүе Г. Коләхметов өчен һич тә очраклы хәл түгел иде. Аның драмаларындагы персонажлар нәкъ менә бөек пролетар язучысы тудырган пьесалар геройлары белән авазлаш.

Хосусый милеккә нигезләнгән иске системаның җимерeләчәген хәбәр иткән бөек эпоха рухи сукырларны да, ерактан күрүче гали затларны да тудырды. Берәүләр анда төн караңгылыгы иңүен күрсә, икенчеләр исә бу эпоханың моңарчы күрелмәгән яктылык алып килүен аңлады. Гафур Коләхметов, бөек замандашы М. Горький кебек үк, шушы яңа эпоха көрәшчесе һәм җырчысы булды.

Менә ничәнче көн инде мин Татарстан Үзәк архивында утырам. Өстәлдәге папкалар әле кат-кат булып югары өелә, аннары тагын кими. Номер сугылган йөзләрчә, меңнәрчә кәгазь битләре. Күз алдында сүзләр, аерым юллар бии, сюжетлар ачыла... Донослар, яшертен күзәтү мәгълүматлары, Казан губернаторы, полиция департаментының циркулярлары, прокламацияләр, тентү вакытында алынган кульъязмалар... Гасыр башында бөтен Россияне тетрәткән вакыйгалар җанлана. һәм шушы кәгазьләр диңгезендә әледән-әле бер кешенең исеме чагылып китә. Болар аның яшертен тормышы хакында сөйләүче аерым пунктирлар...

Менә әлеге документларның берсе;

«1902 ел, 27 сентябрь. Казан губерниясенең халык училищелары директоры әфәнделәренә.

Шушы язу белән миңа тапшырылган мәктәп курсын тәмамлап чыккан һәм Пороховой бистәсе башлангыч татар училищесына укытучы итеп беркетелгән Габделгафур Коләхметовның документларын җибәрәм...

Казан татар учительская школасы инспекторы». (Үзәк Дәүләт архивы, 1477 фонд. 1 нче тасвирлама, 62 бит).

Шушында ук учительская школаны тәмамлап чыгу турындагы таныклык та беркетелгән. Дин сабагы буенча мәгълүматы уртача дип бәяләнгән, башка фәннәрдән — «яхшы» һәм «бик яхшы» билгеләре.

Гафур Коләхметовның аңлы тормыш юлы әнә шуннан башлана. Бу мәктәптә ул ун елдан артык укыта һәм шушыннан аның башкалар өчен яшертен булган тормыш юлы сузылып китә...

«30 март, 1906 ел. Казан губерниясе жандармерия идарәсе начальнигы полковник Калининга.

Миңа тапшырылган полиция идарәсенә Пороховой бистәсенең Мещаннар урамындагы үз өендә торучы запастагы фейерверкер... Сәмигулла Хәбибуллин килеп хәбәр итте: үткән кыш татарларның ураза бәйрәме уңае белән Пороховой бистәсе Каравай урамында үз өендә торучы Т. Нигъмәтуллинга кунаклар җыелган. Алар арасында... беренче мәчет каршындагы татар мәктәбе мөгаллиме, октябрьдагы чуалышлар вакытында Казан Шәһәр Управасы бинасында кулга алынган Гафур Коләхметов та булган. Сүз арасында, ни өчен сине кулга алдылар, дип сорагач, Коләхметов Шәһәр Управасындагы студентлар янына корал алу һәм восстание ясау өчен баруын әйткән... Төрмәдән ул, унбер көн утырганнан соң, халык мәктәпләре инспекторының таныклыгы буенча чыгарылган. Россиядәге хәлләр, киләчәктә анда ни булачагы турында сүз киткәч, Коләхметов: «Бары да безнеңчә булачак! Государь-императорны якасыннан эләктерәчәкбез, студентлар эшне җайга салачаклар...»— дигән». (ТАССР Үзәк Дәүләт архивы, 199 фонд. 1 тасвирлама, 61 бит).

Менә 1907 елның 5 апрелендә язылган тагын бер документ. Пороховой бистәсенең полиция надзирателе жандармерия идарәсе начальнигы полковник Калининга татар мәктәбе укытучысы Гыймагулла Фәхретдиновның хөкүмәткә каршы агитация алып барганлыгын хәбәр итә. «Фәхретдинов Пороховой бистәсе училищесында укыта торган Габделгафур Коләхметов белән бик дус... һәр җомга көн алдыннан алар бергәләшеп Казанга китәләр һәм шимбә көн иртә белән әйләнеп кайталар,— дип яза полиция надзирателе.— Кая барулары билгеле түгел...» (Шунда ук, 300 бит.)

Жандармерия идарәсе әлеге фактларны тәфсилләп тикшерергә кушып Казан өязе исправнигына күрсәтмә бирә. Яшерен мәгълүматлар туплау, тикшерү актлары, хәбәрләр алышу дәвам итә, кәгазьләр бер инстанциядән икенчесенә йөреп кенә тора. Аларның барысын да биредә күрсәтү мөмкин түгел. Монысы махсус тикшерену өчен үзенә аерым бер мәсьәлә.

Матбугат эшләре буенча Казандагы Вакытлы Комитет члены, шәрык телләренең танылган белгече, Казан университеты һәм Духовная академия профессоры Н. Ф. Катанов 1908 ел, 13 февраль көнне цензура комитеты председателе М. Н. Пинегинга язган хатында «Яшь гомер» исемле 5 пәрдәлек, 77 битлек драманың кульъязмасын карап чыгуы һәм анда эшче союзлары, социализм турындагы кайбер урыннарны кыскартуы турында хәбәр итә (Шунда ук, 420 фонд, 1 тасвирлама, 7 бит).

Г. Коләхметов пьесалары белән татар социал-демократлары тараткан прокламацияләр арасында гаять зур рухи якынлык, аваздашлык бар.

Архив материаллары Г. Коләхметовның тормыш һәм көрәш юлы турында гына түгел, аның әсәрләренең автобиографик характерда булуы хакында да сөйлиләр. Бу яктан караганда, «Ике фикер»дәге Давыт та, «Яшь гомер»дәге Гали дә мәгълүм дәрәҗәдә Гафур Коләхметовның үз портреты итеп каралырга хаклы.

Гафур Коләхметов кебек язучыларның фаҗигасе аларның берьюлы ике фронт-

та көрәш алып барырга мәҗбүр булуларында иде. Полиция һәм жандармерия һәр адымыңны күзәтә.

Г. Коләхметов әсәрләре гасырлар буе хезмәт нияләрен изеп, хөр фикерне буып килгән иске тәртипләргә каршы да, татар вак буржуаз милләтчеләре психологиясенә, җәмгыятьтәге торгынлык һәм наданлыкка каршы да бер үк дәрәҗәдә юнәлдерелгән. Шушы юлда аңа нинди генә кыерсытулар, әзәрлекләүләр кичерергә туры килми. Казан жандармерия идарәсе полковнигы алдында гына түгел, татар байлары һәм руханилары алдында да ул җинаятьче, явыз җан санала. Шуңа күрә дә Г. Коләхметов пьесаларыннан берсенең дә сәхнәгә куелмавы табигый хәл булды. (Шунысын да әйтеп китик, драматургның «Әбуҗәһил» дип исемләнгән тарихи драмасы муллаларның доносы буенча полиция тарафыннан конфискацияләнә. Ә «Ник уйгандым» исемле үткен сатирик хикәясенең басылып чыгуы барлык кадимче муллаларны ярсуга сала. Беренче татар театры, гәрчә аны оештыруда Г. Коләхметов якыннан торып катнашкан булса да, аның әсәрләрен сәхнәгә чыгара алмый, көнкүреш темасына язылган башка әсәрләр белән чикләнергә мәҗбүр була.

1904 елда ук туберкулез белән авырый башлый. Вакыт үткән саен яңакларында кызыл таплар ешрак кабына, хәлсезлек баса... Ләкин алда әле ничаклы эш. Россиянең буеннан-буена революция ялкыны дөрләп кабынырга торганда ничек авырып ятмак кирәк?! Г. Коләхметов прокламацияләр яза, легаль матбугатта хезмәттәшлек итә, төннәрен революцион әдәбиятны татар теленә тәрҗемә итә. Шуның өстәвенә, митинглар, демонстрацияләр, яшертен очрашулар... Язарына ничек вакыт тисен?.. Әмма ул яза, уй-хисләрен кәгазьгә төшерергә ашыга. Ә төзәтергә, шомартырга аннары да соң булмас. Бастыру мөмкинлеге тугач төзәтәчәк ул аларны! Хәзергә каралама хәлендә ятып торсын...

Ә аяусыз әҗәл көннән-көн якынрак елыша бара...

Бер-бер артлы дүрт ир туганы вафат була... 1912 елда Г. Коләхметовның яшертен эшләре буенча хезмәттәше, эшче-революционер, «Яшь гомер»дәге Вәли образының прототибы булган Зариф Садыйков та үпкә авыруыннан үлә.

РСДРПның Казан комитеты члены, күптәнге дус, партия сафында бергә көрәшкән якын иптәше Хөсәен Ямашевның гомере киселә...

Аннары иң кадерле һәм газиз зат булган Тукайга да чират килеп җитә...

Тормышка ачык күз, аек акыл белән карый белүче, сабыр холыклы Г. Коләхметов, замандашларының искә алуынча, ачы язмыш авырлыгын зар-сыктаусыз күтәрә. Һәрвакыттагыча, сүзгә саран, хис-тойгылары кайдадыр ерак яшерелгән. (Ф. Агиев. «Гафур Коләхметов» җыентыгына сүз башы. Мәскәү, 1925 ел.)

Аның гомере 1918 елның 1 апрелендә чикләнә. Үлем үзе белән күп нәрсәне алып китә, әйтеләсе күп сүзләр әйтелмичә кала.

Язучының иҗат мирасы һич тә зур түгел. Гаять көчле, характеры белән бөтенләй яңа булган «Ник уйгандым» новелласы, «Ялган мол» хикәясе һәм алда әйтелгән кечә күләмле ике пьеса. Тикшеренүчеләр «Азат халык» газетасыннан табып алган берничә публицистик мәкалә, арифметика буенча мәктәп дәреслеге. Мисыр тарихы һәм культурасы, тарихка кадәрге җәмгыять турындагы язмалары — болары дөнья тарихы буенча язылачак хезмәтнең бер өлеше. Ә менә «Әбуҗәһил» һәм «Кем гаепле» исемле пьесаларының кулъязмалары полиция тарафыннан конфискацияләнә.

Г. Коләхметов беркайчан да көнкүреш сурәтен тергезүне максат итеп куймады. Зур художник өчен көнкүреш сурәте кешелекнең мәңгелек яшәешен тасвирлау чарасы гына. Аның драматургиясе арзан юмор эзләүче кайбер тамашачыларны бик мавыктырмаска мөмкин, чөнки ул әсәрләрдә алар җиңел танылa торган, кабатланып килүе белән «типик» ситуацияләрне таба алмаячак. Әмма художникның чыноарлыкны тирән гомумиләштерә белүе әһәмиятле. Һәм шундый әсәр тамашачының төрлесендә кызыксыну тудыра ала. Төрле чорлар өчен дә бу шулай. Ышанырга кирәк ки, Г. Коләхметов пьесалары татар телендә генә түгел, башка күп телләрдә дә яңгырар әле. Үз чоры өчен гаять зур яңалык алып килгән бу әсәрләр әле хәзер дә гомум кешелеккә хас мәгънәләрен югалтмаган, бүген дә яшь һәм гайрәтле.

# ГАФУР КОЛӘХМЕТОВ ХАТЛАРЫ

## «Хәзер сәламәтлегем...яхшы»

Гафур Коләхметовның әдәби мирасы катлаулы язмышка дучар була. Киң укучылар массасына аның «Яшь гомер», «Ике фикер» драмалары һәм бары тик «Уалган мол» нәсер тәрҗемәсе билгеле. Ә ул «Әбүҗәһил» исемле 4 пәрдәлек тарихи драма, «Кем гаепле?» исемле 5 пәрдәлек драма, русча «Талак» хикәясе, шигырьләр, балалар өчен хикәя-әкиятләр, бик күп мәкалә-рецензияләр иҗат иткән әдип. Әмма бер яктан патша цензурасы, икенче яктан реакцион дин әһелләре пролетариат язучысының бу әсәрләре дөнья күрүгә юл бирмиләр. Авыру әдипнең кульязма мирасы өлешчә Казанда, купчелеге шагыйрь Ф. Агиев кәгазьләре белән эссез югала...

Соңгы елларга кадәр Казанда Г. Коләхметовның төрле урыннарда саклаңган берничә фоторәсеме һәм анык дип исәпләнелгән, ләкин ике кеше кулы белән язылган, тәрҗемә брошюрадан башка берни дә билгеле түгел иде. 1975 елның апрель аенда СССР Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм тарих институты фәнни хезмәткәре Искәндәр Абдуллин Алма-Ата шәһәрендә яшәгән язучы һәм тәрҗемәче Гайшә Шәрипова архивында Гафур Коләхметовның моңарчы бөтенләй билгесез булган унбер хатын һәм дистәләрчә фоторәсемнәрен, шәхси әйберләрен табып, Татарстан дәүләт музеена тапшырды.

Гайшә Шәрипова (кыз фамилиясе Апанаева) — Гафур Коләхметовның бертуган апасы Шәмсекамәр кызы — кечкенәдән үк Гафурларда әбисе янында, абыйсының көчле рухи йогынтысы астында тәрбияләнә. Тормыш дулкыннары бер урыннан икенче урынга ничек кенә кагып йөртмәсен, Гайшә ханым абыйсының якты истәлеге итеп аның үзенә язган хатларын, фоторәсемнәрен кадерләп саклый, аңа бәйләнешле материалларны, шәхси әйберләрен туплый.

Күпчелеге гади көнкүреш темаларына язылган бу хатларның бер карашка әдәбият тарихы өчен әллә ни зур әһәмиятләре юк та кебек. Ләкин бу кыска хатлар 1905 елгы революция чорында янып эшләгән, РСДРПның Казан комитеты җитәкчеләре И. А. Саммер, С. А. Дридзо-Лозовский, Н. И. Дамперов һ. б. белән иңгә-иң торып халык милициясе сафларында карагруһчыларга каршы кулына корал тотып сугышкан татар язучысы һәм революционерының, озакка сузылган каты авыру белән җәфалануына карамастан, көчле рухлы, тормыш сөючән булып калуы турында сөйләүче документлар 20—30 елларда басылган кайбер истәлек-мәкаләләрдә Г. Коләхметов, имештер реакция елларында, бигрәк тә Х. Ямашев үлгәч, пессимизмга бирелгән дигән сүзләр бар. Кайберәүләр соңыннан да бу фикерне куәтлиләр. Ләкин бу хатларның берсендә дә (ә алар 1911-1917 елларда язылганнар) аның рухи төшенкелеккә бирелүе сизелми. Киресенчә, һәр хатында ул, «мин саг вә сәламәт», «мин сәламәт», «сәламәтлегем бик яхшы» дип кенә яза. Бу — ютәл авыруы көчәеп, 1916 елның көзеннән инде укыта алмас дәрәҗәгә төшкән, Кырымга китергәнче носилкага салып йөртелгән кеше сүзләре!

Ул гына да түгел, сеңелесенең иптәшләренә шаяру катыш сәламнәр күндерергә һәм Ялтада кара миләш чыпчыклары чыркылдашуы, яшь кызларның яр буенда чәчәк иснәп йөрүләре хакында да язарга онытмый. 1916 елның 5 апрелендә язган хатында ул биш кубыз сората. Мәймүнә ханым Сәйфуллинаның Тел, әдәбият һәм тарих институты фәнни архивында саклаңган истәлекләренә караганда, Гафур Коләхметовка бу кубызлар сәламәтлеге бераз яхшыра төшүгә Ялтада дәваланучы көрәшчеләре Гариф һәм Мәймүнә Сәйфуллиннар, Нургали Әминев һәм Ф. Апанаева белән һәвәскәр оркестр төзергә кирәк була!

Хатлар Г. Коләхметов биографиясенең кайбер моментларын һәм аның белән аралашкан кешеләр даирәсен ачыкларга ярдәм итеп кенә калмыйлар. Гражданнар сугышы елларында Г. Коләхметовның «Ике фикер» пьесасы Казан, Уфа, Мамадыш, Омск һ. б. шәһәр сәхнәләрендә «Кызыл һәм Кара» исеме белән куела. Шуңа таянып, әдәбият белгечләре арасында да пьесаның чын исеме «Кызыл һәм Кара» булган диган

сүзләр йөри иде. Г. Коләхметовның 1917 елның 5 июлендә Шәмсекамәр Коләхметовага язган хаты бу нигезсез бәхәсләргә чик куя.

А. С. Пушкин, килер бер вакыт, классик язучының үз кулы белән кечкенә кәгазь кисәгенә язган счеты да әдәбият өчен зур әһәмияткә ия булыр диган. Г. Коләхметовның сеңелесе Гайшә Апанаева-Шәриповага язган кыска хатлары бөек шагыйрь сүзләрен раслый. Әдипнең мирасын туплау, тормышның әлегәчә җитәрлек өйрәнелмәгән чорын бераз күз алдына китерүне дә истә тотып, бу хатларны укучыларга тәкъдим итәргә булдык. Хатларның бер өлеше русча (алары тәрҗемәдә бирелә), калганнары татар телендә язылганнар. Бу очраклы түгел, Коләхметовлар гаиләсе ике телдә дә иркен сөйләшкән, иркен язган.

Хатлар матбугатта беренче мәртәбә чыгалар. Революционер язучының барлык язмаларын, шул исәптән, бу хатларны да һәм фоторәсемнәрен Казанга кайтарырга рөхсәт иткән Асия ханым һәм В. А. Поцелуйколарга (Г. Шәрипованың кызы һәм киявенә) рәхмәт әйтүне бурычыбыз дип саныйбыз.

Искәндәр **АБДУЛЛИН**,
Дания **БАҺАВЕТДИНОВА**

## Гайшә Апанаевага

*1911 елның 13 марты, Ялта*

*Казань, Екатерининская ул., дом Сагадеева, Кулахметьевой, Батенькага.*

*Батенька!*

*Менә мин Сухумнан чыгып, Ялтада торам инде. Сухумнан дүртендә чыгып, Ялтага 7 се урынына 8 ендә килеп төштем. Чөнки диңгездә зур штормга эләктем. Керчьтә, якорь төшереп, 23 сәгать тордык. Халык күбесе авырдылар, мин авырмасам да башым бик әйләнде. Әмма чыдадым. Күп сәлам. Мин сау вә сәламәт.*

*Языгыз: Ялта, до востребования.*

Коләхметова Шәмсекамәр — фельдшерлар курсын тәмамлап чәчәк салучы булып эшли. Аның квартирасы РСДРПның Казан комитеты татар яшьләре өчен оештырылган түгәрәк утырышлары һәм башка шәһәрләрдән килгән большевиклар өчен явка хезмәтен үти.

Батенька — әтисез үскән Гайшә Апанаева Гафурны «әтекәй» (батенька) дип йөрткәнгә, гаиләдә Гайшәгә якын итеп һәм яратып көлеп тагылган кушамат.

*1911 елның 24 марты, Ялта*

*Ярый, батенька, ярый. Моннан ары һичбер хат сиңа язмам. Мин бишләп хат яздым, ә син берне генә. Ялкау гимназистка! Ялтада гомумән һавалар җылы түгел. Аз булса да сырость бар әле. Торуыбыз бик яхшы. Сез ничек торасыз? Барыбер син язмыйсың бит. Күп сәлам.*

**Гафур.**

*1915 елның 30 июле, Нижний Новгород*

*Екатерининская ул., дом Юнусова, Г. Кулахметьеву, Г. А. Апанаевой, Казань*

*Гайшә!*

*Без Нижнийга 29 кич сәгать 7 дә килеп җиттек. Пароход монда ике көн торачак. Мин Казанда берендә булырмын. Хәзергә үзем сау вә сәламәт. Чәй эчәм дә ярминкәне карарга барам. Күп сәлам.*

**Гафур.**

Хат акчарлаклар рәсеме төшерелгән открытка артына язылган. Язылу урыны һәм датасы почта штемпеле буенча билгеләнде.

Дом Юнусова — хәзерге Г. Тукай һәм Ф. Кәрим урамнары чатындагы 67 йорт, сәүдәгәр Вәли Юнысовның балалар йорты һәм аерым квартиралар урнашкан бина. Г. Коләхметов апасы торган бу йортка Апанаев мәдрәсәсе каршындагы рус классында эшли башлагач күчә (шуның өчен хатны үз адресына сала).

*1916 елның 23 феврале, Ялта*

*Кулахметьеву, Екатерининская ул., д. В. Юнусова, Казань Гайшә Апанаевага.*

*Күп сәлам!*

*Гайшә! Мин сәламәт. Акрын гына терелә инде. Минем иптәшем Сабитов кичә Салих абзый берлә Казанга киттеләр. Сабитов сезгә керер һәм барысын да сөйләр. Гайшә, менә бу «вид» минем караватымнан күренә.*

**Гафур.**

Хат «Ялтада иртән» дигән рәсем төшкән открытка артына язылган. Рәсемдә Ялта портындагы пирс (пароходлар туктар өчен диңгезгә кертеп салынган мәйдан) һәм өч җилкәнле көймә күренә. Язылу елы почта штемпеле буенча билгеләнде.

**Сабитов Хәйрулла** — «Шәрык» клубы старшиналарының берсе, аның казначее.

**Салих абзый** (Гобәйдуллин Салихҗан) — татар сәүдәгәре, тарихчы һәм язучы Газиз Гобәйдуллинның атасы.

**Вид** — сурәт, күренеш (русча)

*1916 елның 3 апреле, Ялта*

*Екатерининская ул., дом В. Юнусова, Г. Кулахметьеву, Казань, Гайшә туташ Апанаева җәнапләренә.*

*Бүген дә язам, ялкау дип әйтмә. Мин сәламәт, әмма (...) йөри-йөри арып беттем. Бу эш ярый. Ул пасха праздннигына күп итеп урын әзерли. Сиң, Гайшә, мин сораган посылканы 5 кубыз берлә җибәрергә онытма. Күп сәлам...*

**Гафур.**

Кырымдагы Суык-су курорты, казино һәм Аю-даг күренеше төшерелгән открытка артына язылган.

*1917 елның 15 феврале, Ялта*

*Гайшә!*

*Күп йөри торгач, мин барыбер Ялтага килеп җиттем һәм пансионга урнаштым. Хәзер мин яхшы торам. Сәламәтлегем бик яхшы. Ялтада һәм бөтен Кырымда бик каты суыклар, хәтта карлар явып тора. Шулай булса да, яшеллек күп вә бик матур. Күп сәлам.*

**Гафур.**

*1917 елның 2 марты, Ялта*

*Гайшә!*

*Мин анаңа зур хат язган идем, алгандыр. Яңа пансион бик яхшы булып чыкты. 25 бүлмәсе бар. Халык күп, әмма Ялтада һава гына һаман начар. Яхшылана барса да, бик акрын. Сәламәтлегем яхшы, температура төште — 37,5 кә кадәр. Чыгып йөрим — балконга чыгып утырам һәм ятам. Хат языгыз. Барчаңызга сәлам. Чучиевка поклон.*

**Гафур.**

**Чучиев** — Гайшәнең яшьлек мәхәббәте.

*1917 елның 19 марты, Ялта*

*Синең 3 мартта язган хатыңны кичә, 18 мартта, алдым. Син Казанда һаман да салкын әле дип язасың. Ә Ялтада инде яз килде, кара миләш чыпчыклары чыркылдаша һәм кара сандугачлар сайрый. Бик күп чәчәкләр күренә; яшь кызлар су яр буенда җәйге кофталар киеп, роза, миләүшә һ. б. чәчәкләрне иснәп йөриләр. Мин яхшы гына яшим, үземне бик шәп хис итәм. Сәлам.*

**Гафур.**

Бу хат рус телендә язылган.

*1917 елның 4 мае, Ялта*

*Гайшә!*

*Мин сәламәт. Төнә сезгә мин заказной хат җибәрдем. Сораткан нәрсәне җибәргәнсездер бит? Ялтада һавалар яхшы. Чәчәкләр вә төрле кошлар күп.*

*25 майда кайтырга торам.*

*Сәлам.*

**Гафур.**

Язылган урыны һәм вакыты почта штемпеле буенча билгеләнде.

## Шәмсекамәр Коләхметовага

*1917 елның 5 июле, Базарная Дубровка*

*Яхшы гына килеп җиттек. Гади телеграмманы Соня алмаган, ул без кайткач килеп җитте. Ат ялларга туры килде. Барысы да исән-сау вә сәламәт. Һава яхшы. Әле беркайда да булмадым. Тик Ивановкага гына ике мәртәбә барып килдем. Бакулин белән таныштым. Анда яңа варенье һәм яңа бал белән чәй эчтем. Безгә Әмрулла килгән иде — ул бик юанайган һәм гадиләшкән: ул инде Казандагы кебек көяз түгел. Аннан башка беркемне дә күргәнем юк әле. Бирегә бәйрәмне җомга көн котәләр, шимбә көнне дә булырга мөмкин. Соня үзен яхшы хис итә һәм курортка бармаска булды. Аларның яңа квартирлары өлгерде, зур һәм әйбәт. Әмма тиз генә күчмәсләр — әлегә җиһазлары юк, ә аннан башка мөмкин түгел.*

*Кырымнан берәрсе булдымы? Булса, тулырак языгыз. Кадыйр ничек — калдымы-юкмы икән?*

*Үземне яхшы хис итәм, урамда бераз йөрим. Каюмнан һәм Әминнән берәр нәрсә юкмы? Галя «Шайтан кыз» — Нюркага Черновскоега барамы? Барса, әнисенә һәм, ярар инде, бераз Нюркага да, һәм шулай ук онытып бетермәсен өчен Верочкага да миннән сәлам әйтсен.*

**Гафур.**

*Галя!*

*Син Габ. Кариевны күрсәң, аннан минем «Ике фикер» пьесасы турында сораш әле. Ул аны укырга алып торган иде. Әгәр ул аңа кирәк булмаса, сиңа кире кайтарсын. Ә син яшереп куй.*

*Хәзергә барысы да әйбәт.*

**Гафур.**

Хат рус телендә язылган.
Язылу урыны С. Коләхметова һәм К. Әмири истәлекләре буенча билгеләнде.

**Соня** — Суфия Коләхметова-Агиева (1889—1966), Г. Коләхметовның сеңелесе. Ф. Агиев Казан губернаторы әмере белән Казаннан куылгач, 1915 елны Ф. Агиевның туган ягына эшкә күчә.

**Ивановка** — хәзерге Мордва АССР Торбеево районындагы авыл.

**Бакулин** — Агиевларның Ивановкадагы танышлары, алпавыт.

**Әмрулла** — Ф. Агиевның ир туганы, сәүдәгәр.

**Кадыйр** — Кадыйр Салихҗан улы Гобәйдуллин, тарихчы Г. Газизнең энесе, Апанаев мәдрәсәсе каршындагы рус классында Г. Коләхметов кул астында укыта, революциядән соң Дагстанда эшли.

**Каюм** — Габделкаюм Коләхметов (1883—1920), Г. Коләхметовның энесе. Казан татар укытучылар мәктәбен тәмамлагач, 1903—1908 елларда Казан өязе Чыпчык волосте Ямаширмә авылында укыта. Авыл халкы арасында революцион пропаганда алып барганы өчен Сембер губернасына сөрелә. Хат язылган елларда Әндиҗанда укыта.

**Әмин** (Мөхәммәтәмин) — Г. Коләхметовның энесе, хат язылган вакытта прапорщик чинында хәрәкәттәге армиядә беренче бөтендөнья сугышында катнаша.

**Галя** — Гайшә Апанаева-Шәрипова (1901—1969).

**Верочка** — Анна Южалинаның кыз туганы, Гайшәнең танышы.

**Габ. Кариев** — Габдулла Кариев (1886—1920), татар профессиональ театрына нигез салучы артист һәм режиссер. 1917 елның 18 августында «Г. Кариев идарәсендәге татар драмасы» татар сәхнәсендә беренче мәртәбә Г. Коләхметовның «Яшь гомер» драмасын куя.

## «Мин — Пенза губернасыннан вәкил...»



*Уңнан сулга: Г. Коләхметов, Г. Сәйфуллин, Н. Әминев һәм аның бертуган сеңелләре Мәймәнә белән Кәримә.*

Гафур Коләхметов гомеренең соңгы елларында, каты авыру булу сәбәпле, җәмәгать эшләрендә турыдан-туры катнаша алмый. Ләкин, истәлекләргә караганда, язучы илдә барган революцион күтәрелешне күреп шатлана, халык бәхете өчен көрәшүчеләр белән горурлана. Февраль революциясеннән соң ул Уфада булачак Милли мәҗлескә Пенза губернасыннан вәкил итеп сайлана, әмма авыру сәбәпле бара алмый кала. Әгәр бара алган булса, Коләхметов, һичшиксез, Г. Ибраһимов, Ш. Әхмәдиев, Ф. Сәйфи-Казанлы кебек сул вәкилләр тарафында булыр иде. Түбәндә әдипнең шушы хакта Уфага — Гариф Сәйфуллинга язган хаты урнаштырыла (Г. Сәйфуллин — тел галиме Ф. Сәйфи-Уфалының бертуган абыйсы, совет хезмәткәре, 1935 елны Казанда үлде.)

Бу хатны һәм фоторәсемне Г. Сәйфуллинның хәзер Казанда яшәүче хатыны Мәймәнә апа Сәйфуллина тапшырды. Алар бергәләшеп Ялтада 1916 елның язында фотога төшкәннәр. (Рәсем матбугатта беренче тапкыр басыла. М. Блатт фоторепродукциясе).

Нургали Әминев — «Нур» труппасының актив члены, революциядән соң — совет хезмәткәре, 1966 елны Казанда үлде, заманы өчен тәрәккыйпәрвәр кеше иде. Нургали — минем җизни, ә Гариф абый — Нургалигә кияү тиешле кеше.

Хәзергә билгеле булган бу иң соңгы хаты Коләхметов биографиясенең соңгы сәхифәләрен тулыландырырга ярдәм итә.

**Хәсән ГОБӘЙДУЛЛИН**



*Гариф җаным!*

*Мин кичә Казаннан мәктүб алдым. Алар миңа язалар, син минем адресымны сорап язгансың дип. Бу минем өчен бик гаҗәп бер нәрсә. Чөнки Октябрь аенда мин Уфага Нургали әфәнде исеменә мәктүб яздым. Ул мәктүбтә Нургали әфәндегә вә сиңа да бер йомышымны яздым. Күрәсең ул мәктүбне сез алмагансыз.*

*Минем йомышым шул иде. Мин Пенза губернасыннан милли мәҗлескә вәкил булып сайланган бер адәм. Бу сәбәптән мин Уфага барып торырга тиеш булган идем. Менә Нургали дә вә син дә бөтен Уфага таныш булганга, сез миңа бер яхшы гына бүлмә яки бөтен пансионы берлә бер урын табып бирерсез дип мәктүб язган идем. Һәм иске адресымны язып күрсәткән идем. Ярый, булган эш булган. Мәҗлес ачылды инде. Әмма мин Уфага һаман бара алмыйм. Чөнки миңа бик каты салкын тиеп, каты авырдым. Хәзердә дә авырыйм әле һәм шул сәбәптән мәҗлескә дә бара алмыйм. Сәламәтлегем яхшыргач та барачакмын һәм сезнең берлә күрешәчәкмен вә бик шат булачакмын.*

*Мин хәзер, Гариф җаным, авыру килеш кардәшем Суфиядә ятам. Адрес шул: Базарная Дубровка, Пензенской губ., имение Л. Д. Бакулина. С. Агеевой. Һәм миңа әгәр моңа каршы бер мәктүб язып җибәрсәң, бик шат булырмын. Суфия берлә Ислам бик яхшы торалар. Суфия үз эшендә, Ислам волость рәисе булып бик деловой сымак булып йөри. Алар бик күп әйтеп сәламнәр укыйлар.*

*Тагын ни языйм, җаным? Монда авылда хәбәрләр юк. Хәбәрләр сездә күп булырга кирәк. Чөнки сездә Милли мәҗлес бар, аның вәкилләре бар, күбесе яңа адәмнәр, интересный адәмнәр булырга кирәк. Чөнки вәкил бит алар. Хәзергә сәламәт бул. Нургалигә вә барчасына күп-күп сәлам.*

**Дустың Гафур Коләхмәдов.**

## Гайшә Шәрипова

# ГАФУРЛАР ГАИЛӘСЕ

РОМАННАН ӨЗЕК

*Гайшә Габделхәмит кызы Шәрипова — беренче татар пролетар язучысы Гафур Коләхметовның бертуган апасының кызы. Ул 1901 елның 30 августында (иске стиль белән) Казанда туа һәм абыйсы йортында тәрбияләнә. 1918—1920 елларда Казан дәүләт университетының медицина факультетында укый. 1920—1936 елларда Мәскәүдә яши һәм тәрҗемәче булып эшли. 1936 елда Алма-Ата шәһәренә күчеп килгәч, журналистлык эше белән шөгыльләнә.*

*Гайшә Шәрипованың язмалары матбугатта 1929 елдан бирле күренә башлый. Ул — «Ватан» (1939), «Ач дала» (1946), «Бибиҗамал» (1946) дигән очерклар, «Бер тормыш турында хикәят» (1947), «Безнең заман кешесе» (1949), «Ал канатлар» (1964) дигән повесть һәм хикәяләр җыентыклары авторы.*

*Үзенең «Гафурлар гаиләсе» дигән романында Г. Шәрипова Коләхметовларның фаҗигале язмышын сурәтли, Гафурның революцион юлга басуын, күренекле большевик Хөсәен Ямашев белән дуслыгын чагылдыра.*

*СССР Язучылар союзы члены Гайшә Шәрипова 1969 елда Алма-Ата шәһәрендә вафат була.*

Бүген Гафур ике хат алды. Хат ташучы китергәне ерак Әстерханнан иде.

— Кемнән килгән? — дип кызыксынды Газизә абыстай, конвертны улына биреп.

— Габделмәннән, әнкәй!

— Аллага шөкер! — дип шатланды ана.— Күптән хәбәр-хәтер юк иде инде улымнан, зарыгып беттем. Укып җибәр әле, улым.

Гафур хатның беренче юлларында ук төртелеп калды, кашлары җыерылды.

— Ни булган? Авырып киткәнме әллә? — дип тынычсызланды Газизә абыстай.

Гафур хатка тиз генә күз йөртеп чыкты. Аптырау тойгысын күңелле көлемсерәү алыштырды.

— Барысы да яхшы, әнкәй. Борчылма. Энекәшнең таракан йөргәндәй язуын гына таный алмадым башта. Ә хаты шәп. Менә, тыңла.

Бистә кешеләреннән кем дә булса дөнья читенә — Себергә урман кисәргә яисә Идел койган җиргә балык промыселларына, я булмаса хода каргаган Юзовкага эш эзләп киткән якын кешесеннән килгән хатны укуын сорап керсә, мөгаллим, әле кәгазьне ачып караганчы ук, хатта туган-тумачаларның олысыннан алып кечесенә кадәр «титулларын» атап, чуктин-чук сәламнәр тапшырылуын белеп тора иде. Күгәрченнәрдән туган якларына сәламнәр җиткерүен үтенгән хат гадәттә, дүрт юллык шигырь белән тәмамлана. Үзе турында язу, аерылганнан бирле җыелган күпләгән сорауларны бирү өчен урын бик аз кала, өстәвенә, күңел түренә тулган шатлык һәм кайгыларны кәгазьгә бөртекләп төшерү өчен осталык та җитми. Алары хакында туганнарына фараз итәргә генә кала. Очы-кырые күренмәгән исемнәрне тыңлаганда, хатын-кызлар күз яшьләрен сөртә, ирләр башларын түбән иеп, тирән сулый.

Хатны укый башлагач та юкка гына аптырап калмады шул Гафур— бу хат күршеләренә укый торган хатлардан беренче карашка гына әлләни аерылып тормый иде.

Габделмән яза: «Исәнмесез, кадерле әнкәем! Сезгә иң изге теләкләрен индереп, кодрәтле тәңредән сезгә ныклы сәламәтлек һәм дә озын гомер теләп калучы — улың Габделмән дип белерсез. Аннары үземнең бердәнбер туендыручы абыем Гафурга иң кайнар сәламнәремне озатып вә аннан намаз вакытларында мин гөнаһлы бәндәне дә онытмавын үтенеп калам. Һәр намазга күп көч вә вакыт сарыф ителүен яхшы аңлыйм. Вакыты җиткәч, ә бәлкем әле, ходай кушса, иртәрәк тә, бөтенесе өчен артыгы белән түләнер. Шулай ук үземнең яраткан игезәк туганнарым Хөсәен белән Зарифка иң изге теләкләремне белдерәм. Икесенең дә исән-сау икәнлеген ишетеп бик шатландым. Көннән-көн көч җыйсыннар вә безне эшләрендәге уңышлары белән сөендерсеннәр...»

— Кайчаннан бирле Зариф белән Хөсәен минем улларым булдылар әле? — дип үпкәләп сорады Газизә абыстай.— Хаты да әллә нинди сәеррәк. Габделмәннең гомерендә дә болай язганы юк иде. Юк-юк, ул язмагандыр моны! Газаплама мине, дөресен әйт.— Газизә абыстайның күзләренә яшь килде.

— Тынычлан, әнкәй! Ант итеп әйтәм, хат Габделмәннән, аның үз кулы белән язылган. Ахырынача укып бетерергә рөхсәт ит, шуннан бөтенесе дә аңлашылыр.

— Укы, укы,— Газизә абыстай иреннәрен тешләп куйды.

Үз алдына гына елмаеп, Гафур хатның дәвамын укыды. Энесе татарча пешерелгән пирог өчен бик тә зур рәхмәт әйткән. Пирог аның үзенә генә түгел, иптәшләренә дә бик ошаган икән. «Пирог шундый тәмле

булды, без аны күз ачып йомганчы ашап бетердек. Һәркайсыбызга берәр кисәк тиде. Булса, икенчесеннән дә баш тартмас идек».

Гафур кычкырып көлеп җибәрде.

— Хәйләкәр!

Газизә абыстай чынлап торып үпкәләде:

— Габделмәннең беркайчан да хәйләкәрләнгәне юк. Саф, эчкерсез кеше ул...

— Мин дә шул хакта әйтәм бит, әнкәй. Ә хәйләкәр дип мин аны һич тә ачуланып атамыйм. Хәтта ул язган хәйлә бары тик изге теләктән туа торган хәйлә. Хәтерлисеңме, син үзең яшь чагында әткәйнең бөтен гаиләсенә ипи пешерүең хакында сөйләгән идең. Мичкә алты ипи тыккансың, ә үзең бишесен генә күрсәткәнсең.

— Булды андый хәл. Хода ярлыкасын инде гөнаһымны. Кулларына өстәмә бер телем ипи тоттырыйм дип, балаларым хакына үземә гөнаһ алдым.

— Габделмән дә шулайрак эшләгән, әнкәй. Кешеләр өчен тырыша ул. Тормышның тагын да яктырак булуын тели. Хатында да шул хакта яза, тик хәйлә белән, кирәкмәгән кеше аңламаслык итеп яза. Шуның өчен тыныч бул, әнкәй: Габделмән беркайчан да начарлык кылмас.

Газизә абыстай горурланып әйтте:

— Габделмән өчен генә түгел, барлык балаларым өчен дә тыныч мин. Белеп торам: улларым да, кызларым да кыек эш эшләмәс. Кайвакыт бик тә читен сезне аңлавы, тик йөрәгем тоя, дөрес юлдан барасыз. Анда бәхетегезне табарсызмы-юкмы, анысын инде әйтә алмыйм...

— Табарбыз, әнкәй, һичшиксез табарбыз!— диде Гафур һәм әнисенең кулын үпте. Аннары, шуның белән нокта куйгандай сүзне бөтенләй икенчегә борды.— Әйдә, әнкәй, чәй эчеп алыйк әле. Вакытлы-вакытсыз эчелгән чәй аеруча тәмле була бит ул.

Шул ук көнне икенче хатны таныш булмаган бер ир кеше китерде. Кычкырып мәктәп ишегалдына үрәчәле чана җигелгән бәләкәйрәк кенә бер ат килеп туктады. Чикмәненең озын итәкләренә уралып, бүреген күзләренә кадәр батырып кигән бер ир чанадан төште. Хуҗаларча атлап, ул кече капкадан керде, олы капканың аркылы колгасын алды, йөгәненнән тотып, атын ишегалдына кертте. Чанасыннан ниндидер төенчек алды һәм шуны күтәреп баскычка менде. Өйалдына керер алдыннан киез итекләрендәге карны чистартты, өстен какты, шуннан соң гына бусаганы атлап керде.

Газизә абыстай аны күптән күзәтә иде инде, аннары түзмәде, улына дәште:

— Гафур, кара әле тегенең кыланышын. Үз өенә кайтканмыни! Әминем аны гомеремдә дә күргәнем юк.

Гафур кухняга таныш булмаган абзый өйалдыннан килеп кергәндә чыкты.

— Әссәламәгаләйкем, Гафур! Син буласыңмы инде ул Гафур дигәннәре? Исәнлекме-саулыкмы, абыстай? Сезгә улыгыз Каюмнан сәлам китердем. Ул әле сезгә күчтәнәчләр дә җибәрде. Безнекеләргә илтеп бир, авыл күчтәнәченнән авыз итеп карасыннар, диде. Гаеп итмәгез инде, атымны сораусыз-нисез ишегалдыгызга кертеп куйдым, үзем дә өегезгә рөхсәтсез килеп кердем,— дип елмаеп сөйләп китте таныш түгел кеше.

— Юкны, сөйләмәгез, юкны сөйләмәгез! — дип тезеп китте Газизә абыстай, улыннан көтелмәгән хәбәр алуга куанып.— Ходай кунагы — безнең кунак. Әйдә, чишенегез, узыгыз, хәзер самаварым кайнап чыга, җылынып китәрсез... Исемегезне кем дип әйтим соң?

— Туганда Хисаметдин дигән ат кушканнар, үсеп җиткәч инде Хисами дип кенә йөртә башладылар,— дип аңлатып бирде юлчы, муенын

ураган озын шарфын салып һәм салкын ияртеп кергән кием-салымнарыннан бер рәхәтлек белән котылып.

Өстәл янында сүзне Газизә абыстай башлады. Ул Каюмның тормышяшәеше турында сорашты, шул арада бушаган чынаякларга чәй агызырга да онытмады. Бала-чага, абыйлары җибәргән бал ягылган авыл ипиен тәмләп ашап, тыныч кына утырды.

— Калага ни йомыш белән килеп чыктыгыз, әгәр бик сер булмаса? — дип сорады Газизә абыстай, үзенең кызыксынуын тыя алмыйча.

— Сала кешесенең нинди сере булсын инде аның!— диде Хисами, елмаеп. Әмма шундук җитдиләнеп калды.— Ашлык уңмый, шул ашый җанны, абыстай. Ничек кенә тырышма, яңасына кадәр барыбер җитми ипикәй. Чәчәренә дә кирәк бит әле. Җир аз, уңдырышсыз, үз хуҗасын да туйдыра алмый. Күз җиттеме, бөтен авыл эш эзләп чыгып китә. Кемнең аты бар — ул кыш буена кала юлында, аты белән кеше ташый. Аты булмаганы еракларак китә — урман кисә, шахтага төшә... Тамак туйдырыр өчен теләсә нинди камыт кияргә әзер...

— Аптырыйм, Каюм нишләп хат җибәрмәде икән? — дип кинәт Хисаминың сүзен бүлдерде Газизә абыстай, кунак килеп кергәннән бирле үзенә тынгы бирмәгән соравына җавап эзләп.

Хисами өстәл янында утырган гаилә әгъзаларына тиз генә күз йөртеп чыкты, карашын Гафурда аз гына озаграк тотты, аннары гафу үтенгәндәй:

— Монысына инде мин гаепле, абыстай,— диде.— Хатны мин кереп алырга тиеш идем дә, бераз мыштырдабрак яттым шул, мин килгәндә Каюм өйдә юк иде инде. Каравылчы аны кемгәдер ашыгыч эш белән китте диде. Авыл буйлап эзләргә вакытым калмады, үзем генә түгел бит, авылдашлардан аерыласым килмәде. Үзегез беләсез, юл озын, ә юлда ни булмас дисең...

Гафур Хисаминың мәгънәле карашын сизде һәм, чәй эчеп туйгач, беренче булып өстәл яныннан торды:

— Әйдә, минем бүлмәгә керик, Хисами иптәш. Ә монда хатын-кызлар үзләре генә гапләшсеннәр.

Гафур белән икәүдән-икәү калгач та, Хисами куеныннан таушалып беткән калын хат чыгарды.

— Синең кулга тапшырырга кушты Каюм. Шаһитларсыз гына.

Хат озын иде. Каюм абыйсы авыл турындагы тәэсирләрен язган. «Без, кала кешеләре, авылны начар беләбез,— дигән ул.— Ерактан ул безгә тоташтан бер буяуга — кап-карага буялган, аның бернинди яктылыгы юк сыман. Авыл мужигы кандала талаганны да сизми йокы бүсә, берни турында да уйламый кебек. Баштарак минем үземә дә шулайрак тоелган иде, ә хәзер күрәм — авыл да без уйлаганча беркатлы түгел, аның мужигы да йокымсырамый икән, һәркайдагыча, монда да төрле кеше яши. Һәркемнең күңелендә үз уе. Ерактан ишетелгән тавышка мужик бик тиз колак сала. Әлбәттә, аның иң беренче уе җир турында. Күбесенең имана җире ташка үлчим инде: бер аягың белән бассаң, җирең чабата табаны астында кала, икенче аягың белән басар урын да юк. Ә янәшәдә генә алпавыт җирләре. Ат атланып та көне буе әйләнеп чыкмаслык. Мужикның ачуы кабармаслыкмыни?! Аның күршесе — шул ук мулла яки кибет хуҗасы,— шулкадәр җир билгән, хәтта батраклары белән дә эшкәртеп бетерә алмый, арендага биреп, өч кат тиреңне туный. Бу хакта уйланмыймы мужик? Ничек кенә уйлана әле! Хәтта икмәк уңган елны да яңа уңышка кадәр җитми аның үз икмәге. Ә тегеләрнең амбарында эскертләр күп еллар торудан карала башлаган. Кышын авыл бушап кала. Атлылар шәһәргә кеше ташырга китә. Кыш көннәре «барабыз»да йөрергә барыбыз да яратабыз: үзе трамвайдан очсыз, үзе өйгә кадәр үк китереп куя. Ә дилбегәне кем тотып бара, аны туган йортыннан сасы кала «почмагына» кем куып чы-

гарган — бу хакта уйланмыйбыз. Ә кирәк иде югыйсә! Беренче тапкыр класска кереп, аның яртылаш буш икәнен күргәч, бөтен кәефем китте. Исемлек барлый башлагач, аптыраштa калдым: тегесе — кибетче малае, монысы — мөәзиннеке, өченчесенең әтисе — староста. Барысының да өс-башы бөтен, ә урамда яланаяк йөрүчеләр бихисап. Аңлаганнар капкорсаклар укуның файдасын! Өй борынча киттем. Укытучыга хөрмәт зур — һәр өйдә чәй белән сыйлыйлар. Кемдә коры чәй, кемдә азрак сөт салынган. Умартасы булганы бал куя. Ә шикәрнең әсәре дә юк. Шикәр — байлар азыгы, аны алыр өчен акча кирәк. Ул көнне чәй артык күп эчелде, лапас астына бер унлап мәртәбә чыгарга туры килде. Берничә бала җыйдым. Ә иң әһәмиятлесе — күп нәрсә күрдем, күп нәрсә белдем. Мужик — сак кеше. Күргән һәр яңа кеше алдында тугарылып бетми. Ул сине бөтен яклап иснәр, татып карар, аннан соң да әле йөрәгенә бик ук якын җибәрмәс... Бер көндә генә бөтен авылны әйләнеп чыга алмадым. Икенче көнне иртән үк тагын чәй чөмерергә тотындым. Менә шул вакыт таныштым да инде Хисами белән. Игътибар беләнрәк кара әле син аңа, кызык кеше ул. Нык дуслаштык без аның белән. Тормыш өчен күп нәрсә бирде ул миңа. Әйтергә онытканмын икән, мулла янына барырга да киңәшне миңа ул бирде, һәм, ышанасыңмы-юкмы, көндерде бит тәки. Киттем моның сүзен тыңлап. Шул бер бару белән генә дә котыла алмадым әле. Мин барганнан соң мулла үзе минем янга бернична тапкыр килде. Мин буйдакның тормышы кунак каршыларга бик үк ярашмаган шул. Тик Баһау хәзрәтнең моңа бик исе китми. «Мин, ди, синең янга сөйләшеп утырырга керәм. Сыйланырга кирәк булса, әйдә, безгә рәхим ит». Һәр җомга саен алып китә мине үзләренә. Нишләп әле шул кадәр кайгырта бу минем хакта, дип уйлыйм. Көннәрнең берсендә шул ук Хисамидан мулланың ярәшерлек кызы барлыгын беләм. Күз алдыңа гына китереп кара әле, Гафур: мин — мулла кияве! Баһау хәзрәт миңа үзенең байлыгы белән юкка гына мактанмый, димәк. Умарталыгына алып барды, мунчасын күрсәтте, хәлдән тайдырганчы чабындырды, туйганчы пироглар, каз итләре ашатты. Ә кызын күрсәтми, ю-ю-к! Мин инде кызыксына ук башладым. Нинди киңәш бирәсең, бәлкем, булмаса булган икән, тәвәккәлләргәдер, ә?»

— Шаярта энекәш,— диде Гафур, елмаюын яшерә алмыйча.

Хисами аңа кырын гына карап, тыныч кына дәште:

— Башы яшь, шуңа шуклана.

— Юләрлек эшләп ташламасмы икән?

— Кем белә! Каюм кызу канлы, ул төлке авызына кабуы бик җиңел.

— Хәзрәт турында әйтәсезме?

— Кем турында булсын тагын? Аның кулы бөтенесенә дә җитә, бөтенесен үз кубызына биетә ул.

— Минем аның турында уйлаганны каян белдең?

— Соң бит ул туйны бөтен авыл көтә инде.

Гафур башка сүз әйтмәде, хатның ахырын укый башлады. Аның ахыры да башы кебек үк җитди иде. Каюм абыйсыннан күргәннәрен бер рәткә салырга ярдәм итәрдәй китаплар, аннары «татарча гадирәк берәр нәрсә» җибәрүен үтенгән иде.

— Энекәш белән күрешергә кирәк миңа. Каникуллар башлангач, Яуширмәгә барып киләм,— диде Гафур уйчан гына.— Хөсәен белән киңәшеп алырга кирәк әле бу хакта.

— Шәп уйлап таптың монысын,— диде Хисами, шатланып.— Ул вакытка бераз акча эшли алсам, үзем үк алып кайтырмын.

Бу төнне Хисами Гафурларда кунды, ә иртәгесен авылдашларын, үзе кебек үз «барабыз»лар туктаган квартирны эзләп, шәһәргә китте.

Никадәр генә озакка сузылмасын, ниһаять, кыш язга авыша башлады. Әле тамчылар да тама башламаган, кар да эреми. Аның каравы карлы киңлекләр ниндидер бер гаҗәеп җемелдәү белән җемелди. Ә кояш! Яз көненнәгечә җылытмый әле ул җылытуын, әмма зәңгәрләнә башлаган күк йөзенә инде ул шатланып, тулыланып чыга иде, әйтерсең лә, пешкән кабартма.

Язга таба Гафурның эше тыгызлана төште. Мәктәптәге дәресләр хакында артык сөйләп торасы юк — алары үз чираты белән бара. Дәресләр саны көздән бирле үзгәрмәде, беренче көннәрдә ничек куелган булса, шулай кала бирде. Тикшерелә торган дәфтәрләр генә бераз күбәйде бугай. Тик иң мөһиме анда гына да түгел. Гафурның күп вакыты эшче түгәрәкләрендә чыгыш ясарга әзерләнүгә китте. Һәр сүзнең шома чыгуы мәҗбүри түгел анысы, ә менә фикерең, төгәл ачык булырга һәм тыңлаучыларга аңлаешлы итеп әйтелергә тиеш. Сөйләгәннәрең йөрәккә барып җитсә, тыңлаучылар да сорау бирүдән тартынып тормый. Димәк, теләсә нинди сорауга җавап бирергә әзер булырга кирәк. Гафур үз белемен арттырырга тырышудан башка чара тапмады. Һәм ул китаплар укырга кереште.

Белемгә омтылучы кеше иде Гафур. Китаплардан гына түгел, кешеләр белән аралашудан да эзли иде ул белемне. Бигрәк тә Хөсәен һәм аның иптәшләре белән аралашуны югары бәяли иде Гафур. Хөсәен үзенең әңгәмәдәшен киеренке хәлдә тота белә, аңа сораулар бирә һәм, тегесе җавап таба алмый азапланса, үзе үк төшендереп бирә. Тумыштан мөгаллим иде Хөсәен.

Тагын бер эшкә багышлады Гафур үзенең бөтен буш вакытын. Кичләрен, өйдәгеләр йоклагач һәм бистә тынып калгач, Гафур үзе шаяртып «кабинетым» дип йөрткән бүлмә тәрәзәсеннән күренгән уттан мөгаллимнең эшләп утыруын абайлау кыен түгел иде.

Тәрәзәдәге ут күпләрдә кызыксыну уята. Җирдә яткан коры чыбыкның шартлап сынуын да, өй ниргәсенә өелгән комның ишелүен дә төн тынлыгында ишетергә була иде.

Баштарак Гафур үткен күзләрдән тәрәзә капкачлары ярдәмендә котылмакчы иде. Аннары уен үзгәртте, капкачларны ныклап япмый башлады. Кызыксынган кеше мөгаллимнең бернинди дә гаеп эш эшләмәвен күреп торсын әйдә. Нәкъ әнә шул вакыт Гафурның өстәлендә күн тышлы авыр, калын китап пәйда булды.

Бер вакыт, тәрәзә янындагы шикле кыштырдаулардан соң, тышкы ишекне сак кына шакуларын ишетте Гафур. Бүлмәдән чыкканчы күн тышлы китапны өстәлнең уртасынарак шуыштырды, вак кына итеп язылган озын, тар кәгазь кисәкләрен тартмага салды һәм ашыкмый гына ишеккә юнәлде.

— Кем бар анда?

Ишек артыннан карлыккан тавыш ишетелде:

— Алла хакы өчен ач!

Бусага төбендә мулла басып тора иде.

— Валлаһи, көтелмәгән кунак — хода кунагы. Әйдәгез, узыгыз, хәзрәт. Мондый могтәбәр кешене минем куышка ниндидер бәла китергәндер дип һич тә уйламыйм.— Ачык йөз белән елмаеп, Гафур мулланы кабинетына алып керде, аңа урындык тәкъдим итте.

— Бәласен бәла түгел дә, җан тынычлыгым китте. Тешем сызлый, һич кенә дә түзәр чама юк. Ярдәм ит, Гафур, бирә күр берәр тамчы шифалы даруыңны.

— Табипка барырга иде сиңа, хәзрәт. Ул яхшырак белә бит.

— Табипка калага барырга кирәк. Шушындый кара төн уртасында ничек тапмак кирәк аны?! А-а-а-й, зинһар ярдәм ит, Гафур.

Гафурның бернинди дә даруы юк, ә менә күз буяу өчен генә аптека шешәсенә салып, китап шүрлегенә яшереп куйган чиста спирты бар

иде. Гафур аны уң ягы чәнчеп авыртканда, бернинди порошокның да ярдәме тимәгәндә куллану өчен тота. Спирт белән усаң, авырткан урыннар, салкын аяклар җылынып китә, җылы белән бергә йокы да килә.

«Хәзер тыгындырам мин син шымчыны!» — дип зәһәр көлемсерәде Гафур, өстәлгә спиртлы шешә белән мамык кисәге куеп.

Гафур дарулары белән кайнашкан арада мулла өстәлгә якынрак килде һәм күзе төшкән китапны ачты. Ачты да гаҗәпләнүеннән сүзсез калды. Ул бит тыелган китап эзләгән иде!

— Тәңре сүзе белән дә кызыксынасыңмыни әле син, менла кем Гафур? — дип сорады аптырашта калган мулла, тозсыз сүз сөйләвен тоеп.

— Тәүбә, тәүбә, кяфергә исәплисезме әллә сез мине, хәзрәт? Корьәнне ифрат яратып укыйм мин.

— Көннән-көн ныграк гаҗәпләндерә барасың син мине,— диде мулла, инде үзенең аптыраштa калуын яшереп тормыйча. Аннары сүзне шаяртуга борырга тырышты:— Мин, халык мөгаллиме дип йөрим, ә син чын корьән Хафиз икәнсең бит. Мин инде картайдым, күп яшисе калмагандыр, күрәм: үземә алмаш эзләп торасы да юк икән. Уфага барып мөфти алдында сынау тот та, кайтып минем урынга утыр.

Әмма шаярту барып чыкмады, шулай ук житди сөйләшү дә башланып китә алмады. Гафур мамык кисәген спиртка манчыды да:

— Авызыңны зуррак итеп ач! — дип боерды.— Кайсы тешең авырта?

Монысын ук көтмәгән мулла ашаганда гел азык кисәге кереп җәфалый торган бер тишек теше барлыгын исенә төшерде. Һәм ул, нидер мыгырданып, бармагы белән авыз эченә төртеп күрсәтте.

— Ай-яй, хәзрәт, тешләрең, мин сиңа әйтим, бүре тешләремени! Сөяк кимергәндә дә берни булмас!

Гафур үзе мулланың таза тешләрен мактады, үзе, җаен табып, спиртка манчылган мамыкны теш уртасында күренеп торган тишеккә тыгып куйды. Әллә өтеп, яндырып алуданмы, әллә авыртудан, мулла ыңгырашып куйды.

— Түз, мулла абзый, түз! — Гафур саклык өчен ике куллап аның авызын каплады,— Хәзер үтәр.

Мамыгын алгач, мулла идәнгә төкереп куйды, тирләгән битен сөртте.

— Рәхмәт яусын. Бераз тирләтте тирләтүен, вәхаләнки авыртуын канат белән сыйпагандай итте. Ходай мең рәхмәтләрен яудыра күрсен үзеңә.

Гафур төнге пациентны урамга озата чыкты. Мулла китеп, кәвешләренең кыштырдавы ишетелми башлагач кына өенә керде.

Мулла Гафурны бер тапкыр да гаеп эштә тота алмаган кебек, Россия социал-демократик партиясе прокламацияләрен һәм өндәмәләрен тәрҗемә итүдән, газетага мәкаләләр язудан тыш, Гафурның үз әсәрләрен дә чын күңеленнән бирелеп эшләвен берәү дә әлегә белми иде.

Әле туып кына килгән татар театрының репертуары чикләнгән булуы, яңа әсәрләргә мохтаҗлык кичерүе Гафурга жанр сайлауда, һичшиксез, этәреш биргәндер. Ул чакта сәхнәдә уйналган барлык спектакльләрдә дә диярлек бер сюжет чишелә: ике яшь йөрәк бер-берсен ярата, тик тирә-юньдәгеләр аларга каршы төшә. Бер-берсен сөюче яшьләр күп киртәләр аша узалар. Тигезсез көрәштә гашыйкларның берсе һәлак була.

Гафур күнегелгән бу сюжетны чынбарлыктан алынган эчтәлек белән тулыландырырга, сәхнәдә жансыз курчакны түгел, ә бәхетсез татар кызының фаҗигале язмышын күрсәтергә карар итә.

**Русчадан Миргалим ХАРИСОВ тәрҗемәсе.**

Фәрваз Миңнуллин

# ТӘНКЫЙТЬЧЕ БӘХЕТЕ

*Р. Мостафинның иҗат портретына эскизлар*

Сезнеңчә, Рафаэль Мостафин башка тәнкыйтьчеләрдән кай ягы белән аерыла?

— Ул — безнең иң популяр тәнкыйтьчебез.

— Тәнкыйтьчегә популярлык бик кирәкме?

— Билгесез булуга караганда популяр булу күңеллерәктер дип беләм...



Рафаэль Мостафин хакында сүз чыкканда, еш кына шундыйрак бәхәсләр кузгала. Һәм юкка түгел: Р. Мостафин, чыннан да, безнең иң популяр тәнкыйтьчебез. Бәлки әле, популярлыкка омтыла торган тәнкыйтьчебез, дип тә өстәргә кирәктер... Аны һәр җирдә беләләр, яраталар.

Р. Мостафинны, әлбәттә, иң элек, язган әсәрләре буенча беләләр. Безнең республикада аның очерклары, мәкалә-рецензияләре басылмаган газета-журнал, мөгаен, юктыр. Ул — «Правда», «Известия», «Советская Россия» кебек могтәбәр газеталарда басылу бәхетенә ирешкән кеше. Ул — «Советская культура», «Литературная газета» һәм «Литературная Россия» кебек газеталарның, «Волга», «Вопросы литературы» һәм «Дружба народов» кебек журналларның даими авторы. Аның әдәби тәнкыйть мәкаләләре «Казан утлары» һәм «Дружба народов» журналларының, шулай ук «Литературная газета»ның махсус премияләре белән бүләкләнде, ә Сибгат Хәким иҗаты турындагы монографиясе һәм «Җаваплылык тойгысы» исемле мәкаләләр җыентыгы СССР Язучылар союзының әдәби тәнкыйть өлкәсендәге еллык премиясенә лаек булды. Р. Мостафин — Татарстан комсомолының Муса Җәлил исемендәге республика премиясе лауреаты.

Рус һәм татар телләреннән тыш, аның мәкаләләре әзербайҗан, башкорт, грузин, казакъ, литва, молдаван, осетин, таҗик, төрекмән, украин, удмурт, фин, эстон һәм чуваш телләрендә чыкканы бар. Һич шикләнми, Р. Мостафин әсәрләрен бөтен ил укый дияргә була.

Укып белү белән бергә, аны тагын күреп һәм ишетеп беләләр. Ул әледән-әле радио һәм телевидение аша чыгыш ясый. Аны республиканың авыл һәм шәһәрләрендә, мәктәпләрдә, клубларда, культура сарайларында, китапханәләрдә, уку йортларында еш очратырга мөмкин. Әйе, аны беләләр, таныйлар, яраталар. Мондый популярлыкны ул, беренче чиратта, эшләгән эшләре, язган әсәрләре белән яулады.

Р. Мостафин — 300 дән артык мәкалә һәм 16 китап авторы. Китапларының гына гомуми тиражы да ярты миллионнан артык. Тәнкыйтьче өчен бу — бик күп. Күп һәм нәтиҗәле эшләү белән бергә, ул беркемне кабатламый, беркемгә иярми торган ифрат үзенчәлекле тәнкыйтьче дә. Иҗатының иң нык күзгә ташланган ягы шул: аның барлык әсәрләре диярлек киң катлау укучыларны күздә тотып язылган була. Ул әдәби иҗат эшенең кыен һәм катлаулы мәсьәләләрен ифрат гади һәм үтемле итеп аңлата белә. Моңа ышану өчен, «Үсештәге, хәрәкәттәге тәгълимат» яки «Тор-

мыш дәреслеге һәм сәнгать дәреслеге» кебек мәкаләләренә мөрәҗәгать итү дә җитә. Аларның икесе дә теоретик мәкаләләр, теориянең дә катлаулы мәсьәләләренә багышланган мәкаләләр. Беренчесе, социалистик реализм методы хакындагы бәхәсләр уңае белән язылып, үзенең бөтен рухы белән әлеге методны артык тар, догматикларча аңлатуларга каршы юнәлгән. Автор совет әдәбиятындагы төп иҗат методының чикләнмәгән мөмкинлекләре булуга, аның үсештәге, хәрәкәттәге тәгълимат икәнлегенә басым ясый. Мәкалә гади һәм аңлаешлы телдә, популяр стильдә язылуы белән аерылып тора. «Тормыш дәреслеге һәм сәнгать дәреслеге» исемле икенче мәкаләдә әдәбият теориясенә караган күп кенә катлаулы һәм җитди мәсьәләләр (сәнгать чынлыгы һәм тормыш чынлыгы, тормыш факты һәм сәнгать факты: чынбарлык һәм автор фантазиясе; заман темасы һәм заман герое; әдәби әсәрнең эчтәлеге һәм формасы һ. б.) кузгатыла. Һәм шуларның һәр кайсы, тормыштан, әдәбияттан алынган конкрет мисаллар ярдәмендә, бик популяр тәстә аңлатып бирелә. Менә шул хакта сөйләүче бер мисал. Укучыга әдәби әсәргә салынган тормыш материалы, ул материалның тулылыгы һәм ышандыру көче хакында үтемлерәк итеп аңлату өчен, ул конкрет бер вакыйгага мөрәҗәгать итә. «Һинд халкында шундый әкият бар. Шулай бервакыт дүрт сукыр бер филне очраталар да аның нинди җан иясе икәнен белергә телиләр. Боларның берсе филнең борынын, икенчесе — аягын, өченчесе — корсагын, ә дүртенчесе филнең койрыгын тотып-капшап карый. «Әһә,— дигән беренче сукыр,— фил уралып яткан зур еланга охшаган икән». Филнең аягын капшап караганы: «Юк, ул юан баганага охшаган»,— дигән. «Фил — су тутырылган мичкә сыман»,— дигән өченчесе. Ә дүртенчесе: «Фил ул аркан төсле икән»,— дигән...

Күрәсез, чын хакыйкатьнең бик гади нәрсә түгеллеген халык элек-электән искәртә килгән. Тормыштагы берәр күренешне өстән-өстән генә өйрәнеп ясаган нәтиҗәләр объектив чынбарлыкка туры килмәскә мөмкин, син никадәр генә чын күңелдән сөйләргә тырышма, ясаган нәтиҗәң барыбер хата булуы да ихтимал... Бер сүз белән әйткәндә, филне тасвирлаганда (ул арканга охшап калмасын өчен) аның бөтен гәүдәсен күз алдында тотарга кирәк».

Р. Мостафинның барлык язганнары, хәтта теоретик мәкаләләре дә, шулай конкрет характерда булулары белән аерылып торалар.

«Бүгенге романнарны укыганда» дигән мәкаләдә сүз 60 нчы еллар башында дөнья күргән өч конкрет роман турында бара. Үзе тикшерә торган әсәрләргә гомуми бәя бирү, тулы анализ ясаудан бигрәк, тәнкыйтьче һәр романның иң характерлы берәр ягын тотып алырга тырыша. Әйтик, Г. Әпсәләмовның «Сүнмәс утлар» романында төп игътибарын ул, образлар системасына, язучының образ иҗат итү принципларына юнәлтә. Ф. Хөснинең «Җәяүле кеше сукмагы»н тикшергәндә романның төп герое һәм сюжеты, ә М. Әмирнең «Саф күңел» романына килеп җиткәч, аның төп герое һәм ул герой башкарган эшләр кебек мәсьәләләргә тукталa. Соңыннан, әлеге өч романга ясаган анализга нигезләнеп, бездә роман жанрының торышы, үсеш үзенчәлекләре турында кызыклы нәтиҗәләр ясый.

«Җаваплылык тойгысы» — безнең тәнкыйтьтә мәгълүм бер эз калдырган, капма-каршы фикерләр, бәхәсләр уяткан мәкалә. Тәнкыйтьче анда безнең шагыйрьләрне төрле буыннарга бүлә, һәр буынның поэзиябез үсешендә тоткан урынын билгеләргә омтыла. Билгеле, ул һәр буын турында, һәр шагыйрь турында иң тулы, иң соңгы сүзне әйтә алмаган. Бер мәкаләдә моны эшләп тә булмый. Ахырдан, шушы мәкаләгә таянып, татар поэзиясендәге төрле буыннарны бер-берләренә каршы кую тенденциясе көчәеп китүен дә истән чыгарып булмый. Шуңа да карамастан, бу мәкалә җитди игътибарга лаек. Бүгенге поэзияне аңларга, безнең поэзиядәге үзенчәлекле тенденцияләрне ачыкларга омтылуы белән, һәр буынның, хәтта һәр шагыйрьнең әдәби процесстагы урынын билгеләргә омтылуы белән,— җыйнап әйткәндә, конкретлыгы белән аерылып тора. «Тема, идея, әдәби осталык», «Тәнкыйтькә — тәнкыйть утың», «Бәхәс дәвам итә», «Үз җырың, үз көең булсын», «Яңа теманы үзләштерү юлында» һәм башка бик күп мәкаләләре хакында да шул ук фикерне кабатларга мөмкин.

Р. Мостафинның байтак чыгышлары әдәбиятта миллилек һәм интернациональлек, милли әдәбиятларның үзара йогынтысы һәм бер-берләрен баетулары, бу процесста әдәби тәрҗемәләрнең роле кебек бөтен совет әдәбияты һәм әдәбият белеме өчен уртак мәсьәләләргә багышланган. Аның рус һәм дөнья әдәбияты традицияләрен яшьли үзләштергән, нык хәзерлекле, зур эрудицияле, ил күләмендә барган бүгенге әдәби процесс белән дә яхшы таныш булуы татар совет әдәбиятын ил күләмендәге әдәби хәрәкәт белән бәйләп карарга, татар язучыларының әсәрләрен күп милләтле совет әдәбияты ирешкән казанышлар югарылыгыннан торып бәяләргә мөмкинлек бирә. Моның өчен аны хупларга кирәк. Әмма татар әдәбияты кебек мең еллык тарихы, үз традицияләре, үзенчәлекле үсеш юлы булган әдәбият турында сүз барганда, аны бөтен ил һәм дөнья сәнгате ирешкән казанышлар югарылыгына күтәрергә чакырганда, язучыларыбызны яңа формалар һәм яңа алымнар эзләргә өндәгәндә, Р. Мостафин кайчак татар әдәбиятының үз хасияте, эчке үсеш законнары белән санашып җитми, һәр әдәбиятның үсеш юлы үзенчә булырга тиешлеген истән чыгара төсле.

Шуларның һәммәсе өстенә тәнкыйтьче тагын әле кыю да булырга тиеш. Тормыш бит үзе, бик кирәк чакта да, ник мине бозып күрсәттең дип, язучыга бәйләнә алмый. Ә язучы тәнкыйтьчегә бәйләнә ала. Язучы бәхете — авыр бәхет. Тәнкыйтьче бәхете тагын да авыррак. Әдәбиятны уртакул язучылар һәм уртакул әсәрләр күмеп

китмәсен өчен кыю һәм батыр тәнкыйтьчеләр кирәк. Теләсә нинди шартларда гадел булып калу, дөреслекне күзгә карап әйтә алу өчен кирәк бу сыйфатлар.

Шунысын да әйтик, Р. Мостафинның барлык әсәрләре диярлек бүгенге әдәби процессны, бүгенге язучылар иҗатын өйрәнүгә багышланган. Бу — тәнкыйтьче иҗатының гражданлык позицияләре турында сөйли торган матур ягы. Ул һәрвакыт бүгенге әдәби процессның уртасында кала, бүгенге көн мәнфәгатьләрен кайгыртып, бүгенге әдәбиятның уңышларына куанып, аның проблемалары өчен борчылып, янып-көеп яши. Менә шуңа күрә дә ул әдәбият һәм язучылар коллективы алдында торган актуаль һәм мөһим мәсьәләләрне вакытында күреп алып, вакытында күтәрә. Авторның «Тәнкыйтькә — тәнкыйть уты» исемле мәкаләсе шул хакта сөйли торган бер характерлы мисал була ала. Ул «Казан утлары» журналында КПСС Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы мәгълүм карары белән бер үк санда (1972 ел, 4 сан) басылды. Игътибарга аеруча лаек ягы шул: мәкалә үзенең төп рухы, яңгырашы ягыннан Үзәк Комитет карары белән ифрат дәрәҗәдә авазлаш булып чыккан. Мәкаләдә сүз әдәби тәнкыйть, бигрәк тә яңа чыккан әсәрләрне рецензияләү өлкәсендә яшәп килгән кимчелекләр, җитешсезлекләр турында бара. Карардагы кебек үк, ул кимчелекләр, зур таләпләр югарылыгыннан торып, кыю һәм кискен төстә тәнкыйть ителә. Өстәвенә, автор шулардан арыну, котылу юлларын да күрсәтә.

Күтәргән проблемасы, ул мәсьәләнең актуальлеге ягыннан тагын «Йөз телдәге әдәбият» исемле мәкалә нык аерылып тора. Билгеле булганча, совет властеның беренче елларында рус әдәбияты илебездәге күпчелек милли әдәбиятлар өчен остазлык вазифасын үтәп килде. Аның милли әдәбиятларга шифалы тәэсире искиткеч зур булды. Ярты гасырдан артык вакыт эчендә илебездәге башка милли әдәбиятлар да нык алга киттеләр һәм камилләштеләр. Нәтиҗәдә уртак хәзинәгә лаеклы өлеш кертә башладылар. Көн тәртибенә әнә шул өлешне ныклабрак, конкретрак өйрәнү бурычы килеп басты. «Йөз телдәге әдәбият» исемле әлеге мәкаләдә күп милләтле совет әдәбиятында барлыкка килгән үзгәрешләр, төрле милли әдәбиятларның үзара бәйләнеше турында языла, әдәби тәрҗемә мәсьәләләре күтәрелә, әдәбиятның милли үзенчәлеге дигән төшенчәнең эчтәлеген ачыкларга, татар әдәбиятының милли үзенчәлеген билгеләргә омтылыш ясала.

«Минем горурлыгым» исемле чыгышында исә Р. Мостафин, В. И. Ленинның «О национальной гордости великороссов» исемле мәкаләсенә таянып, милли горурлык һәм интернационализм идеяләре турында уйлана, шул төшенчәләр белән бәйле аерым моментларга ачыклык кертә, акцентларны төгәенли. Ул — формасы белән дә пафослы, бер тын, бер сулыш белән язылган бик файдалы, киң колачлы исповедь-мәкалә.

КПСС Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы карарыннан соң әдәби тәнкыйть мәсьәләләре җәмәгатьчелекнең игътибар үзәгенә менде, туры сүзле, принципиаль тәнкыйть хезмәтләренә ихтыяҗ артты, тәнкыйтьчеләрнең иҗат эшчәнлеге өчен уңай шартлар тудырылды, әдәбият-сәнгать тәнкыйтен тагын да үстерү юнәлешендә конкрет чаралар билгеләнде. Моңа җавап итеп, тәнкыйтьчеләр иҗади активлыкларын арттырдылар, бүгенге әдәбият мәсьәләләренә, җанлы әдәби процесска якыная төштеләр. Әдәбият фәне һәм әдәби тәнкыйтькә караган хезмәтләрнең сыйфаты яхшырды, фәннилек дәрәҗәсе һәм ышандыру көче артты. Нәтиҗәдә тәнкыйтьче хезмәтенең абруе, дәрәҗәсе күтәрелде. Тәнкыйть үсеше башкарак юлдан китте: шау-шулы, бәхәсле тон — салмак стиль, пафослы гомуми сүз — фәнни анализ белән алмашынды. Әдәбият фәне һәм әдәби тәнкыйтьтә заманга хас фәнни стиль, тыныч, эшлекле тон урнашты, фәнни анализ, тикшерену рухы артты. Төпле һәм гадел булу, объективлыкка һәм тирәнлеккә омтылу тәнкыйть үсешендәге төп тенденциягә әйләнде. Әмма әдәби тәнкыйтьнең күпмедер дәрәҗәдә усаллана да төшүе әле җитәрлек булмады кебек.

Шул ук үсеш-үзгәреш Рафаэль Мостафин иҗатында да сизелә. Шау-шулы бәхәсләр, капма-каршы фикерләр уяткан мәкаләләрнең күпчелеге тәнкыйтьче иҗатының беренче чорына карый. Бер чиктән икенче чиккә ташланулар, ахыргача уйлап җиткерелмәгән фикер һәм тезисларның да күпчелеге, ихтимал, шул беренче чор мәкаләләрендә очрыйдыр. Аның каравы, ул мәкаләләрдә ялкын һәм дәрт, кыюлык һәм усаллык та күбрәк иде. 70 нче еллардан башлап, Р. Мостафин сабырлана һәм салмаклана төште, фәнни-тыныч тонга күчте, кыскарак, конкретрак итеп язарга өйрәнде. Әгәр беренче чор иҗатында проблематик характердагы мәкаләләр өстенлек итсә, соңга таба рецензияләр һәм күзәтүләр, тегe яки бу язучы иҗатына караган мәкаләләр күбәйде.

Бар иде заманнар, тәнкыйтьчеләрдән барыннан да бигрәк әдәбият-сәнгать әсәрләренә социологик анализ ясау, «безнеке булган»ны «безнеке булмаган»нан аерып бирү осталыгы сорала иде. Ул чаклар инде артта калды. Тәнкыйтьчеләр иңенә, социологик анализ белән бергә, әдәби әсәрләрнең эстетик кыйммәтен ачу, әдәбиятның сәнгатьчә хосусиятен аңлау һәм аңлату бурычы да йөкләнде. Көн тәртибенә бөтен зурлыгы белән укучыларның әдәби зәвыгын тәрбияләү мәсьәләсе килеп басты. Яңа шартларда тәнкыйть күп кенә үзгәрешләр кичерергә тиеш иде. Һәм ул шулай булды да. Әдәбиятның әдәбият икәнлеген тоеп, аңлап язылган мәкаләләр һәм рецензияләр нык артты. Әдәби тәнкыйть үзе дә әдәбиләшә төште. Тәнкыйтьне сәнгатьчә матур итеп, укылырлык итеп язарга омтылыш көчәйде. Бу өлкәдә Р. Мостафинның

да зур хезмәте бар. Моңа ышану өчен, аның бүгенге татар язучыларының иҗат портретлары һәм иҗат портретларына эскизлар рәвешендә язылган мәкаләләренә мөрәҗәгать итәргә мөмкин. С. Хәким, Х. Туфан һәм Г. Әпсәләмов турындагы портретлар укучыларга яхшы таныш. Боларның өчесе дә тулы һәм төпле булулары белән аерылып торалар. Әгәр Хәсән Туфанга багышланган иҗат портреты әлкән шагыйребез иҗатының үзенчәлеген, үзенә генә хас якларын тотып алуы, шагыйрьнең иҗат эволюциясен тулы һәм эзлекле итеп күз алдына бастыруы белән хәтердә калса, Г. Әпсәләмов иҗаты турындагысы кыю һәм принципиаль характерда булуы белән аерылып тора.

Ә Сибгат Хәким турында исә ул кимендә ике дистәләп мәкалә язды һәм алар, билгеле булганча, аерым монография булып 1979 елда «Советская Россия» нәшриятында чыкты. Бу монография иң элек үзенең тулылыгы белән аерылып тора. Моңа тагы китапның язылу формасы, композициясе нык ошады. Китап төрлесе төрле зурлыктагы егерме бүлектән тора. Ул бүлекләр олы юлның баганалары кебек: тәнкыйтьче, гүя шулар буенча барып, шагыйрь узган зур юл картинасын тудыра. Һәр бүлек шагыйрь иҗатының берәр тармагын яки характерлы бер сыйфатын ачуга багышланган.

Ниһаять, Р. Мостафин монографиясе тагын бер мөһим мәсьәләгә ачыклык кертә. Әдәбият фәне һәм әдәби тәнкыйтьтә фәнни-публицистик, популяр стильне өнәп бетермәү, әдәбият фәненә һәм әдәби тәнкыйтькә караган хезмәтләрне авыр итеп, кеше аңламаслык итеп язу тенденциясе яшәп килә иде. Гади һәм үтемле итеп язу һич тә фәннилеккә, әдәбият мәсьәләләренә караган хезмәтләрнең тирәнлегенә, ышандыру көченә зыян итми икән. Киресенчә, популяр стиль киң катлау укучылар арасында әдәбият фәне һәм тәнкыйтьнең дәрәҗәсен һәм кадерен генә арттыра икән. Р. Мостафин үз хезмәте белән тагын бер тапкыр шул фикерне раслады.

«Казан утлары»нда уткән ел (5 нче сан) бу монография киң планда күзәтелде.

Р. Мостафинның иҗат портретлары рәвешендә язылган мәкаләләре бик күп. Кемнәр, кайсы буын вәкилләре турында гына язмый ул. Ә. Еники һәм Мин Шабай, Ф. Хәсни һәм М. Әмир, Р. Төхфәтуллин һәм М. Юныс, И. Юзеев һәм Ш. Галиев, Ш. Анак һәм Р. Фәйзуллин... Ул мәкаләләрнең һәркайсы диярлек кызыклы, һәркайсы диярлек игътибарга лаек. Алар барысы да әдәбиятның үзенчәлекләрен, әдәби әсәрнең хосусиятын тирәнтен тоеп, аңлап язылган мәкаләләр. Әдәби әсәрнең эстетик кыйммәтен ачыклау белән бергә, тәнкыйтьче һәр язучының иҗат хасиятен, төп үзенчәлеген билгеләргә тырыша, һәр кешенең «үз ачкычын» эзли. Күп кенә очракларда таба да. Әйтик, Ә. Еникинең татар язучылары арасында иң музыкаль прозаик, Ф. Хәснинең тел остасы һәм тынгысыз характерлы кеше булуына, Г. Әпсәләмовның хезмәт сөючәнлегенә, Ш. Рәкыйповның тырышлыгына, К. Мостафинның фикерчән шагыйрь булуына басым ясый... Шул сыйфатларыннан чыгып, әлеге язучылар иҗатының төп характерын билгеләргә омтыла. Мин Шабай турындагы мәкалә, мәсәлән, чын хикәя кебек укыла. Н. Исәнбәт, Р. Төхфәтуллин, И. Юзеев, В. Нуруллин турындагы мәкаләләрнең кайсы җылылыгы, кайсы тулылыгы, ә кайберләре тиешле «ачкыч» табылган булуы белән алдыра. Кыскасы, Р. Мостафин язучының үз характерыннан иҗатының характерына күчә белә, бер әсәреннән чыгып бөтен иҗатына бәя бирә белә. Р. Мостафинның иҗат эшчәнлеге моннан тыш та бай һәм күп кырлы: әдәби ел йомгакларында ясалган докладлар, йөзләрчә рецензияләр, республика тормышының төрле якларын сурәтләгән дистәләрчә очерклар, язмалар. «Диңгез көндәлеге» исемле китап... Ә менә герой шагыйребез Муса Җәлилгә багышланган хезмәте белән аерым таныштырып үтмичә һич мөмкин түгел. Бу — аның иҗатының иң төп тармагы.

Муса Җәлил иҗатын өйрәнүче күп санлы белгечләр сафына Рафаэль Мостафин башкаларга караганда соңрак, 60 елларның урталарында гына килеп кушылган иде. Шуңа да карамастан, җәлилчеләр арасында ул бик тиз үз урынын тапты.

Аны, күпмедер күләмдә, Гази Кашшаф башлаган эшне дәвам иттерүче дип санарга була. 1965 елда алар Г. Кашшаф белән бергә «Эзләнү дәвам итә» (Поиск продолжается. Рус телендә. Казань. 1965) исемле китап язалар. Хезмәттә шагыйрьнең батырлыгы турында сөйләүче яңа материаллар һәм фактлар китерелә. Соңыннан Муса Җәлилнең тормыш һәм иҗат юлын өйрәнү өлкәсендәге бурычлар санала.

Менә ничә еллар инде Р. Мостафин шул бурычларны тормышка ашыру өстендә эшли. Ул фәнни китапханәләрдә һәм архивларда казына. Муса Җәлилне якыннан белгән, аның белән бергә яшәгән, бергә көрәшкән бик күп кешеләрне эзләп таба, шагыйрь эзләре буйлап меңнәрчә километр юл үтә — шагыйрь иҗатына, тормыш һәм көрәш юлына караган бай материал туплый. Озакламый аның шул материалларга нигезләнеп язылган мәкаләләре һәм очерклары басыла башлады. Аннары бер-бер артлы чыккан китаплар: «Эзләнү дәвам итә», «Батырлык поэзиясе» (Поэзия мужества. Рус телендә. Мәскәү. 1966), «Муса Җәлил эзләреннән» (Казан. 1968)... Ләкин Р. Мостафин эзләнүләрен алга таба тагын дәвам иттерде — төрле җирләрдә, төрле илләрдә яшәүче бик күп кешеләр белән ныклы бәйләнешкә керде, яңа документлар тапты. Нәтиҗәдә Җәлилгә һәм аның көрәштәшләренә багышланган яңа китаплар дөньяга чыкты. Аның 1971 елда «Детская литература» нәшриятында рус телендә чыккан «Герой шагыйрь эзеннән» исемле китабы аеруча зур яңгыраш тапты. 1973 елда аның та-

гын да тулыландырылган һәм баетылган яңа варианты 100 000 данә тираж белән Татарстан китап нәшриятында кабат басылды. Тагын бераз вакыт үткәч, «По следам оборванной песни» дигән исем һәм 220 000 данә тираж белән ул Мәскәүнең «Известия» нәшриятында «Дружба народов» китапханәсе» сериясендә басылып чыкты.

Р. Мостафинның Җәлил турындагы китаплары язылышлары һәм характерлары белән үк ифрат кызыклы һәм үзенчәлекле. Аларның бик күп өлешләре Җәлилне күргән-белгән кешеләрнең истәлекләренә, архив документларына нигезләнгән.

Ватанның турылыклы уллары, чын патриотлар булган татар егетләренең героик язмышын ачыклау эшенә шулкадәр кешене тарта алу — авторның зур уңышы.

Әлеге китаплары уңае белән Р. Мостафинга илебезнең төрле почмакларыннан бик күп хатлар килә. Заманында «Казан утлары» журналы аларның бер өлеше белән укучыларны таныштырган иде. Биредә дә чиксез күп санлы шундый хатлардан берникe өзек китереп узыйк:

«Зур шатлыгым белән уртаклашам.

Кичә бездә Муса Җәлилгә багышланган әдәбият дәресе булды. Мин Җәлил турында сөйләгәндә, класста нинди тынлык хөкем сөргәнен белсәгез иде. Ул чагында мин кайда икәнемне дә онытып, бөтен уем мөмкин кадәр җан җылысы белән сөйләү иде. һәм мин шуңа ирештем дә бугай. Мин инде сүзне тәмамладым, ә класста ниндидер гадәттән тыш тынлык, беркем селкенми, иң соңгы партада — укытучы. Класстышларыма күтәрелеп караган идем, әллә Һишләп киттем: һәммәсенең күзләрендә яшь. Шуны белгәч, күршедәге унынчылар, директорга кереп, үзләренә дә минем Муса Җәлил турында сөйләвемне үтенгәннәр. Анда да шул ук хәл кабатланды...»

**Вера Жадько**, 10 класс укучысы, Кустанай өлкәсе.

«Өзелгән җыр эзеннән» (нинди әйбәт исем) дигән китабыгыз героеның язмышы һәм зурлыгы белән генә түгел, ә бәлки искиткеч кайнарлыгы, үз-үзеңне, йөрәгеңне һәм акылыңны аямыйча язылган булуы белән дә сокландыра.

Үзегезнең трагик һәм бөек героегыз эзеннән йөргәндә ничек дулкынлануыгызны, сез кичергән сагыш һәм хисләрне бик ачык күз алдына китерәм. Миңа китапның композициясе дә яңа һәм оригиналь тоелды: кайда сез тасвирлап барасыз, ә кайчакта турыдан-туры укучыга мөрәҗәгать итәсез, уйланасыз, фактларны янәшә куеп карыйсыз, кайчак үз-үзегезне (алдагы китапларда әйтелгәннәргә өстәп) тулыландырасыз, кайчак бәхәсләшәсез яки раслыйсыз. Тәэсир искиткеч, хакыйкатькә хыянәт иткән бер генә урын юк. Сез әле нинди яшь һәм күпме зур эш башкаргансыз!»

**Мария Прилежаева**, язучы. Мәскәү.

«Китабыгыз өчен рәхмәт. Кызыклы һәм һәр яктан мактауга лаек ул китапны укучылар җылы каршылады, дигәнсез. Бу хәбәр мине бик шатландырды. Котлыйм»

**Борис Полевой**, язучы. Мәскәү.

Р. Мостафин — үзенең «трагик язмышлы бөек героена» чын-чыннан гашыйк кеше. Әгәр шулай булмаса, куркыныч сукмаклар буйлап чебен-черкидән талата-талата Волхов сазлыкларында иза чигеп йөрер идеме?!. Яңа бер деталь, һич югы кечкенә генә бер штрих артыннан кат-кат чит илләргә хәтле барыр идеме?!. Ләкин ул, мин Җәлилне яратам дип, күкрәк сукмый, буш пафоска бирелми. Тыштан үзен бик тыныч тотарга, сабыр һәм салмак тонда язарга тырыша. Дөрес, «Өзелгән җыр эзеннән» китабының барлык бүлекләре дә тигез булып чыкмаган. Аның электән билгеле, башкалар тапкан фактларга таянып язылган өлешләре ничектер сүлпәнрәк чыккан, ялыктыра төшә. Инде озак вакытлар эзләнеп, көч-тир түгеп үзе тапкан фактлар турында язганда тәэсир көче дә, киеренкелек тә нык үзгәрә.

Китап мавыгып укыла. Чыннан да серле йомгак артыннан баргандай, аның һәр битен ни булыр, ни булыр дип тетрәп ачасың. Үз карамагындагы бөтен факт һәм материалларны автор Җәлилнең һәм аның көрәштәшләренең Ватанның какшамас патриотлар булуларын раслау өчен куллана. Хәтта Җәлилнең тоткынлыкта язган шигырьләрен дә, аның иҗатын өйрәнү, иҗатын бәяләүдән бигрәк язмышын ачыклау өчен файдалана. Татар егетләренең соңгы сәгатьләрен, соңгы минутларын күргән чит ил кешеләренең һәммәсе: Андре Тиммерманс та, Георгий Юрытко һәм Рениеро Ланфредини да аларга искиткеч югары бәя бирәләр. Татарлар үзләрен искиткеч тыныч һәм горур тоттылар, диләр. Алар бик пөхтә һәм чиста йөрде, диләр. Татарлар елмаеп үлделәр, диләр. Батыр егетләрнең язмышын дөньяның игътибар үзәгенә куя алу — зур эш. Бу — Р. Мостафин китабының аеруча нык тәкъдир ителергә тиеш ягы.

Автор М. Җәлилнең тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнү эшен дәвам иттерә. Ул кечкенә Җәлил турында бер бәйләм хикәяләр язды. 1977 елда Мәскәүнең «Детская литература» нәшриятында шагыйрьнең балачагы һәм яшьлеге турында очерклар китабы чыгарды. Тик М. Җәлил иҗаты ифрат зур һәм күпкырлы, тормышы бай һәм кызыклы. Аны өйрәнәсе дә, өйрәнәсе әле. Р. Мостафин бик матур башлаган һәм күркәм нәтиҗәләргә ирешкән бу эшен дә алга таба дәвам иттерсен иде.

# КӨЛЕП МОҢАЯ, УЙЛАП ЕЛМАЯ

Моң диңгезләренә дә, хис давылларына да, дәрт чишмәләренә дә, фикер чоңгылларына да бай һәм шул ук вакытта гаҗәеп үзенчәлекле дә Гамил Афзалның шигъри дөньясы. Аның бер «ярымшарын» халыкчан юмор-сатира тәшкил итсә, икенче «ярымшары» җылы, ягымлы, моңлы лирикадан гыйбарәт. Ләкин әлеге ярымшарларны аерып торучы шартлы сызык — экватор юк биредә. Юморга лирика элементлары килеп кергән кебек, лирикага да еш кына көлке детальләр килеп керә. Шагыйрь көлә-көлә моңая, уйлана-уйлана елмая.



Гамил Афзал инде менә ничә еллардан бирле шигърияттә үзе тапкан юлның дөреслегенә ышанып атлый. Укучыларны да ышандыра, ышандырып кына калмый — сокландыра да. Нинди шигъри алымнар, нинди образ-сурәтләр ярдәмендә ирешә соң моңа шагыйрь?

Беренчедән, хисләрен һәм фикерләрен эчке шигъри кануннарга буйсындырып, эмоциональ киеренкелеккә җиткерә: икенчедән, шигырьләрнең ритмик агышын мөмкин кадәр төгәл, аһәңле итәргә тырыша, аларны җырлап торган рифмаларга кора. Өченчедән, үзенең күп кенә әсәрләрендә бер уңайга гына шаулап агып яткан шигъри ташкынны көтелмәгән тарафларга борып җибәрә. Шигырьләргә еш кына прозаик тәкъбирләр килеп керә һәм шунысы сокландыра: алар гомуми аһәңгә зыян китермиләр, киресенчә, үзләре хис өермәсенә кушылалар, шигырь тукымасын тыгызландыралар.

**Иң кадерле сүзләремне**
**Ил теленнән эзләдем.**
**Иң яраткан гөлләремне**
**Буш бизәктәй тезмәдем...**

Гамил Афзал — шигъриятка шактый озын, авыр юллар үтеп, сугыш еллары кырыслыгын тоеп, утлы цехлар ялкынында зур рухи чыныгу алып килгән шагыйрь! Беренче шигырьләрендә үк аның тыныч тормыш, табигать иминлеге, гаделлек, кешеләр бәхете сагында торырга, ак дөньяга бер генә кара тап та кундырмаска тырышуы шул еллар тәэсиредер әле, мөгаен: «...Рәхәт эзлимени бу дөньяда шагыйрь белән солдат...»

Лирик геройның табигатькә, әйләнә-тирәгә мөнәсәбәтен билгели торган эпизодларда, кеше кичерешләрен табигать күренешләре аша чагылдыра торган строфаларда шагыйрьгә телнең афористик көчен тою аеруча зур ярдәм итә. Табигать күренешләрен, гомумән, искиткеч тирән хисләр, гаҗәеп нәфис моң белән тасвирлый

шагыйрь. Әйтерсең лә үтә нечкә-нәфис җепләр белән чигү чигә һәм шул шигъри чигеше аша кешеләрнең уй-хыялларын, кичерешләрен бер ноктага җыйнап, җисмиләштереп күрсәтә.

Кешегә, кешенең көч-куәтенә, кодрәтенә ышану, «йөз кайгысын онытып, бер шатлыгын йөз кешегә сөйләп өлгергән» кешеләргә олы ихтирам хисе, җәйге йомшак Идел өстендәге якты ай юлы булып, шагыйрьнең бөтен лирикасы буенча сузыла. Шагыйрь яна — үзе өчен түгел, кешеләр өчен яна.

**... Бәхет балкыр заман,**
**Ә мин ятып язам...**
**Күпме сагыш килде өелеп!**
**Үзем сүнеп ятам,**
**Үзем көлеп ятам,**
**Кеше бәхете өчен сөенеп.**

«Ил намусын ак кулында тоткан егетләрне халык онытмый» дисә, «мин адашсам, ялгыз егылырмын, җәүһәр тапсам, сезгә бирермен» дигән сүзләрне дә тышкы эффект өчен генә әйтми ул. Шигырьдән-шигырьгә бу сүзләрнең чын йөрәктән әйтелүенә ышана барасың. Көтелмәгән детальләр, ялтыравыклы метафоралар белән берәүне дә шаккатырырга җыенмый кебек үзе. Ләкин аның шигъри дөньясына аяк баскач тиз генә борылып чыгармын димә. Кубәләкне — чәчәк, акчарлакны — диңгез, бөркетне тау ымсындыргандай ымсындыра, үзенә тарта, ягымлы һәм якты, тыйнак һәм самими көче белән сихерләп тота ул сине. Үзеңне озак еллар читтә йөреп туган нигезгә әйләнеп кайткандай тоясың, юксынылган, сагынылган кешеләр белән очрашкандай хис итәсең, алтын яшьлегеңнең кабатланмас җырларын тыңлагандай буласың.

Гамил Афзал шигырьләре озын түгел. «Якты йолдыз», «Салават батыр», «Шәехзадә Бабич», «Ана», «Мыштыбый» кебек темасы, мәгънәви тирәнлеге, куелган проблемасы, сюжеты белән поэмаларга тартым әсәрләрендә дә аз сүз белән күпне әйтә. Сюжетлы шигырьләрендә ул үзе сөйләргә алынган вакыйгаларның иң әһәмиятле эпизодларына гына туктала, фәлсәфи башлангыч белән лирик чигенешләрне үзара тигез итеп, тыгыз итеп үреп бирә.

Гамил Афзал лирикасы — якты лирика. Ул замандашыбыз ирешкән уңышларга чын күңелдән, сабый балаларча сөенә. «Явызлыкка нәфрәте чиксез булган кебек, матурлыкка да мәхәббәте чиксез». Кайчагында шигъри сизем бөтенләй башка килми торган урыннарның шигъриятен күрә һәм шул урыннарны, эссе чүл уртасында гөлбакча ясагандай, яшәртеп, җанландырып җибәрә.

Шундый шигырьләрнең берсе — «Бөгелмә аэропортында». Бу шигырьгә реаль тормыш белән романтика да, әкият белән чынбарлык та, үткән заман белән бүгенге көн дә, киләчәк тә сыйган. Сурәтләр яңа, детальләр, эпитетлар яңа. Монда «кояш батып барган арада айны футбол итеп тибеп була...», монда «ерак планеталар сагышы шәфәкъ булып тәрәзәдә яна». Ниһаять, монда:

**... Ике моторлы ак самолетның**
**Аркасыннан сөясе килә.**
**Пәри кытыклаган малай кебек**
**Көләсе килә...**

Гамил Афзалның сатира-юмор әсәрләре һәркемгә мәгълүм. Шагыйрь иң элек үзен шушы авыр, четерекле, җаваплы жанрда танытты. Аның Дон-Жуан Ногман, Әсмабикә, Сәлимгәрәй, Изге хәзрәт кебек геройлары бик тиз вакыт эчендә халык күңеленә кереп урнашты, тискәре персонажларның классик мисалына әверелде.

Дөньяда теленә «шайтан төкергән» кешеләр була. Сөйләргә маһир, җор сүзле, тапкыр кешеләр турында шулай әйтә халык. Шагыйрь Гамил Афзалның юмор-сатира әсәрләрен укыгач, әнә шундый, сөйләп-сөйләп туйдырмый, ялыктырмый торган мәзәкчән кеше күз алдына килә.

Моңсу юмор, усал сатира, сарказмга якын ирония, шаян лирика... Болар Гамил Афзалның шигъри юморында да, прозасында да барысы бергә үрелеп бара. Кыска шигырьләрдән алып сатирик поэмаларга, автобиографик парчалардан алып публицистик новеллаларга кадәр шулай.

... Күңелдә мәзәк булмаса,
Күңелләр көяр иде,
Дөнья ялганга тончыгып,
Саргаеп үләр иде.

Әйе шул, шагыйрь көлке әсәрләрен кызык өчен генә язмый. Күңелләрдә яшәү дәртен арттыру өчен, ялганга, мәкергә юл бирмәс өчен яза. «Бүреләр» дигән шигыре «Айлы кичләр» (1977) китабының икенче бүлегенә кертелгән. Димәк, шагыйрь үзе аны җитди шигырьләре исәбендә йөртә. Чынлап та, җитди шигырь ул. Хәтта җитди-усал. Бүреләрнең дә табигать иркәсе булуы, бүреләрне дә дөнья буйлап язмыш йөртүе, бүреләрнең дә «дары шартлаганчы» бәйрәм итәргә, «гармонияле табигатьтә» яшәп калырга хаклы булуы гаҗәеп оста ачыла анда. Үзе усал-җитди, бүреләрнең аяныч хәлен сурәтли торган драматик шигырь һәм шул ук вакытта яшәү дәрте белән сугарылган оптимистик шигырь.

Данлы Магнитогорск каласының елъязмасы «Таш поэма» ничектер роман шикеллерәк, тирән мәгънәле лирик чигенешләрдән башланган. Ләкин монда да автор үзенең җор сүзләрен, шаян тәкъбирләрен шул кадәр урынлы китереп кыстыра — уйчанланып кына укып барганда ихтыярсыз елмаеп куясың. Төлкедән качкан йомран турында автор, мәсәлән болай яза: «...тамак ялгап алу бик кирәк, әмма җан кадерле, ә фани дөнья хәвеф-хәтәр белән тулы икән...» Шуның артыннан ук тагын лирика, тагын җанлы табигать... «Атач тавының кызгылт ташлы такыр түбәсенә чабулары белән орынып ак болытлар йөзә, күк болытлар йөзә, кайларга таба, нинди өметләр белән, йөз ел, мең ел...»

Атач тавында крепостной эшчеләр тимер рудасы чыгаралар. «Сеңерләрне суыра торган иң авыр эш...»

«...Петербургта, алтын тәхеттә, ефәк күлмәкләр киеп байлар патшасы — әби патша утыра...»

Ә кайдадыр «...Сөңгеләрен ялтыратып, илне иңләп килгән яу алдында ак айгырга атланган кызыл чикмәнле Пугач патша килә, яшел билбавына ике пистолет кыстырган, кызыл сәхтиян итегендә көмеш шпорлар чеңгелди, күзләре усал, кулында кәкре кылыч, кара сакалы җилгә җилферди...» Әнә шундый шаян һәм мавыктыргыч стиль белән шагыйрь Атач тавының бөтен тарихын сөйләп чыга. Әсәрдәге күренешләр, җанлы кадрлар булып, берәм-берәм күз алдыннан уза, хәтергә сеңә. Чал тарих терелә, буыннар язмышы ачык гәүдәләнә.

Автор юмористик әсәрләрендә дә аз сүз белән күпне әйтә ала — чөнки ул лирикадан юморга, юмордан иронияга, кайчагында хәтта сатирик гротескка кадәр үстерелгән төгәл детальләр, карурманнар эчендәге таш-таулардан тибеп чыккан чишмәдәй саф тел байлыгы, шаян-шук чагыштырулар, көтелмәгән сынландырулар — кыскасы, берсеннән-берсе оригинальрәк образлар белән эш итә.

Образлар дигәннән, сатира-юмор әсәрләрендә аларны автор төрлечә күрсәтә. Бер ишеләре үзләренең хәйләләрен кеше сизми дип уйлап йөриләр. Ләкин укучы аларны бик яхшы сизә, бик яхшы аңлый. Автор башта алардан йомшак кына көлә, аннары кызгана. Ягъни нишлисең инде, характерлары шундый бит аларның, үзләре бер дә әшкәрле, явыз кешеләр түгел алар, югыйсә. Мәсәлән, бригадир Ахун белән председатель Шәйхетдинов шундый образлар. Авылга язучылар килеп төшкәч, председатель Шәйхетдинов «... кассада бер тиен акча юк чагында мәтәшеп йөрмәсеннәр әле...» дип сукранса да, кунакларны ачык чырай белән каршы ала. Язучылар аның сукрануын ишетәләр, әмма Шәйхетдиновның үзенә сиздермиләр. «Бу вакыйгадан соң байтак еллар үтте, дөньяда кем бар да кем юк. Гыйләҗев белән Шәйхетдинов юл чатындагы карт өянке төбендә әле һаман да кулларын, эшләпәләрен болгап, басып торалар кебек...» дип, моңсу юмор белән тәмамлый автор хикәясен.

Тискәре образларның икенче берләре әсәрнең буеннан-буена чыбыркылана. Алары кеше сүзенә колак салмый торган мин-минлекләре чиргә әверелгән затлар, мин белəмнәр, туң йөрәкле, калын тиреле адәмнәр, карьеристлар, җилкуарлар, чебеннән фил ясарга тырышып көн үткәрүче эшлексезләр.

Әнә бер инструкция колы симпозиумга барышлый җирнең шар кебек түгәрәк булуы турында белешмә алырга йөри («Җаваплылык хисе»). «Дөнья хәлен белеп булмый, андый белешмәнең дә кирәк булуы бар...» Белешмә бирергә тиешле абзый-

ның да «алдатасы» килми. Әгәр дә мәгәр җир түгәрәк булмаса!? Кул куеп печать басып белешмә бирә икән, тау кадәр җаваплылык төшә ләбаса аның өстенә.

— «Җирнең түгәрәк икәнен һәрбер мәктәп баласы да белә бит инде, коллега...

— Белә, мин дә беләм, шулай да үзем үлчәп караганым юк, ә бу документ бит, ул-бу булса...»

Шул рәвешчә, эпизодтан эпизодка көлке ситуация үсә, сатирик буяулар куера. Ниһаять, тискәре персонаж үзенең кәрлә сөенечләре белән ап-ачык мәйданда япа-ялгыз торып кала.

Гамил Афзалның тормыш-көнкүреш темасына язылган көлке хикәяләре дә байтак. Аларның күбесе җылы юмор белән сугарылган һәм төп геройның монологы формасында бирелгән. («Беренче гонорар», «Матриархат чорында», «Күрде безнең башлар», «Цицерон Шәрифуллин» һ. б.).

Гипербола, реаль вакыйганы реаль булмаган ситуациягә куеп (яки киресенчә) күрсәтү, көтелмәгән финал — болар барысы да Гамил Афзалның көлке әсәрләр язганда яратып куллана торган алымнары.

Мисалга «Иләһи комедия»не алыйк. Дөнья әдәбиятында бу комедиянең төрле вариантлары бар. Әмма Гамил Афзал комедиясе катнашучыларның көтелмәгән персонажлар (Иләһе, Җәбраил фәрештә, адәм, ишәк, эт) булуы белән дә вакыйганың җиңеллеге, ситуациянең көлкелеге белән дә үзенчәлекле. Күк канцеляриясендә Иләһенең: эт белән ишәккә үз итеп: «Нихәл, улым!» — дип эндәшүләре. Адәмнең Иләһе белән тарткалашулары. Адәм белән Һава гурындагы мифны күктән җиргә кайтара, иләһилык мөнбәреннән реаль җирлеккә төшерә.

Әдәбиятка юмористлар килгәли, ә менә сатириклар бик сирәк килә. Без күп очракта тискәре геройларыбызны җиңелчә генә кытыклап алу белән чикләнәбез. Үзебез дә кете-кете көләбез, тискәре геройларыбыз да учлары белән авызларын томалап, тыйнак кына елмаешалар. Ярар, инәсе, кытыклыйсыгыз килсә, кытыклагыз, сезнең кытыклаудан безгә ни зыян?!

Ә менә Гамил Афзал кытыклап кына калмый, кирәксә, көлү объектларын үткен сатира уклары белән дә коендыра, төрле ялагайларны, җайлашучыларны әче балан белән генә түгел, әрем белән дә сыйлый, үз-үзеннән канәгать битараф бәндәләрдән ирония белән каһ-каһәләп көлә, мул тормыш өмет итеп чит мәмләкәтләргә киткән һәм адәм хуры булган җилбәзәк кешеләрнең йөзләренә утлы шигырьләрен ыргыта:

**... Сөен әйдә, киен әйдә, ямь табып, кырын ятып,**
**Сиптер әйдә, типтер әйдә, ил сатып, иман сатып...**

1977 елда «Айлы кичләр» китабы һәм «Борылам да карыйм...» («Казан утлары», 7 нче сан, 1976 ел) циклына кергән шигырьләре өчен Гамил Афзал республикабызның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды. Аннан соң өр-яңа шигырьләрен туплап яңа китаплар чыгарды, өр-яңаларын хәзер дә яза тора. Аларда да шагыйрьнең тынгысыз йөрәк тибешен тоясың, ярсулы гомер агышын күрәсең, намус тавышын ишетәсең.

Озак-озын еллар дәвам итсен иде бу иҗат.

**Фаил ШӘФИГУЛЛИН.**

# МАКСАТКА НИ ИЛТӘ?

**Кем ул шагыйрь!**
**Кем булса да,**
**Гармунда күрек түгел:**
**тартылмый-сузылмый көн дә...**
**Кем имам, бәлки, фикердә,**
**Тик шагыйрь мөрит түгел...**

Шулай ярып әйтә алганы өчен генә дә шагыйрьне яратырга ярыйдыр

Рухи эзләнүләре иҗатын кай таба илтүе, талантының ни юнәлештә хәрәкәт итүе серен ачып бирә аның бу юллары. Әйе, шагыйрь кем арбасына утырса шуның җырын җырлаучы түгел. Үз җыры, үз уе мөһим аның.

Бер әңгәмә вакытында өлкән язучыбыз Әмирхан ага Еникинең яшьләргә әйткән сүзе хәтергә килә: «Даһи әзер хакыйкать белән яши алмый, ул аңа үз зиһене белән ирешә...» Р. Гатауллин да шушы хакта сөйли. Чөнки кешелек өчен җаваплылыкны үз иңнәреңә алырга уйлыйсың икән — башта аны ныклап өйрәнергә, аңларга кирәк бит. Үзең аңларга... Димәк, фикереңә хуҗа булырга...

Бу — бик кирәкле, мөһим нәтиҗә. Үз фикереңне булдыру гына аз, аны яклый да алу — чын ирләр, шагыйрьләр сыйфаты. Рухи өлгергәнлек билгесе ул. Әйдәгез, әлеге юлларны яхшыга юрыйк — шагыйрьнең эшләре сүзенә рас килеп торсын, дип телик. Югыйсә, Р. Гатауллин үз иҗаты турында әйтелгән сүзләргә кайвакыт кирәгеннән артык игътибарлы бугай. (Гомумән, язучы халкы үзе хакында күп сөйләгәнне, мактап сөйләгәнне ярата. Ләкин нишләптер искәрмиләр: һәркемгә ошарга, һәркемне сокландырырга тырышуда, һәркемнән комплимент көтүдә үзен ир-атка санаган кешенең горурлыгына тияргә тиешле бер мәгънә төсмере дә бар ич...)

Р. Гатауллинны мин якты күңелле шагыйрь дип беләм. Тормышны ул бик әсәрләнеп һәм бераз бәйрәмчәрәк күтәренкелек белән кабул итә. Ләкин бу бәйрәмчәлек гомергә бармас, тормыш кайчан да булса бер үзенекен итәр, шагыйрьнең дәрте сүрелә төшәр, яшәеш турында ул тынычрак тавыш, гамьлерәк күңел белән сөйли башлар дип көтеп йөри идем. Җитмешенче еллар шагыйрь өчен җиңел чор булмады. Дөньяга карашы сафлыгын, самимилекне җуймаган хәлдә, яшьлек сентиментальлегеннән арынырга, кырыслана төшәргә — заманны тулырак, колачлырак чагылдыру өчен характерыңны ныгытырга кирәк иде. Яшьлек ярсынулары гына, күңелдәге татлы сагышлар, әрнүле шатлыклар стихиясен барлау гына җитми, аз. Үсеш логикасы җаныңны аңлы рәвештә эшкә җигүне, тынгысыз рухи эзләнүләр юлына чыгаруны таләп итә. Шагыйрьнең менә шул ныклап өлгерү, иҗтимагый җитлегү процессы билгеле бер этапта акрынаебрак торды сыман. Шигырьләрендә турыдан-туры әйтмәсә дә, сизәргә мөмкин иде: яшьлеге узуын соңлабрак аңлап, газаплы кичерде Р. Гатауллин. Яшьлек дәртен, яшьлек омтылышларын җырлау белән генә мавыккан шагыйрь аптырабрак калды. Үтте ич кайнар вәгъдәләр, шау-гөр, ыгы-зыгылар вакыты! Өзгәләнеп иҗатының яңа үсеш юнәлешен эзләде ул. Әсәрләренең төп сыйфатын — романтик пафосны, эчкерсезлекне югалтмыйча, ничек ары китәргә — шуны хәл итә алмый азапланды. (Бу эзләнүләр, үзен төрлечә сынап караулар чорын «Тел ачкычлары», «Йолдыз җиле» исемле җыентыклары чагылдыра). Нәтиҗәдә аңа укучыларның мәхәббәте шактый сүрелде. Әдәби тәнкыйть тә, нишләптер, шагыйрь иҗатының әлеге чоры турындагы нигезле, җитди фикерен әйтмәде. Һәм бу — Р. Гатауллин киңәш сүзенә, яңа әсәрләренә объектив бәягә бик мохтаҗ бер чакта...

Иҗат үсеше, минемчә, ике өлештән тора. Беренчесендә шагыйрь шигырь техникасын өйрәнә. Үз стилен таба, осталыкка ирешә. Халык күңелендәге рухи байлыкларны үзләштерә. Аның бу чордагы әсәрләре, гомумән алганда, мәгълүм нәрсәләргә үз карашын белдерү кебегрәк. Талант үзен иң элек шулай раслый. Әйтергә яраса, талант — ул үз карашың булу. Үсешнең икенче баскычында шагыйрь халык рухиятендәге фактларны үз иҗаты фактына әйләндерү белән генә чикләнми инде. Ә бәлки, киресенчә, халык рухиятенә, иҗтимагый фикергә үзеннән өлеш кертә башлый. Шулай зур шагыйрь туа. Бирердә инде тормышка, күре-

---

Радиф Гатауллин. Чакыру. Шигырьләр. Татарстан китап нәшрияты. Казан, 1980.

нешләргә үз карашың, үз бәяң булу гына аз, үз фикерең, үз идеяң булу кирәк. Шуны ачкыч итеп, зур шагыйрь, тормышның моңарчы әле беркем дә игътибар итмәгән, күрмәгән якларын, мәгънәви тирәнлекләрен ачып, туган халкы күңелен баета башлый.

Житмешенче еллардагы газаплы эзләнүләре Р. Гатауллинны кеше биргән акыл, әзер хакыйкать белән генә яшәү мөмкин түгеллеген, йөрәк хисләре белән ныгытылган үз акылың кирәклеген, аның бәһа биргесез кыйммәт икәнен аңлауга китерде. Димәк, шагыйрь иҗат үсешенең бик мөһим бер моментында тора хәзер. Бу киртәне уза алса, аның алдында биниһая мөмкинлекләр ачылачак.

Р. Гатауллин газеталардан, озын колаклардан укып-ишетеп белгәнне түгел, җаны аша кичергәнне, асылына үзе төшенгән нәрсәләрне язганда гына көчле. Өстән-өстән генә таныш күренешләр, вакыйгалар шагыйрьнең күңел, хәтер тирәнлегендә яткан рухи хәзинәләр белән баглана алмыйлар. Ә бәйләнеш булмаса— шигырь юк. Чит илләргә шагыйрь ят дәүләтләрне, халыкларны ныклап аңлау өчен генә түгел, бәлки барыннан да элек, алар янәшәсенә куеп үз халкын тагы бер кат күрү, тагы бер кат аңлау өчен бара. Талантның нигезе — туган халкының рухи дөньясы, туган иленең тарихы. Р. Гатауллинның чит илләргә ясаган сәяхәтләрдән алган тәэсирләре нигезендә язылган шигырьләренең нәкъ менә туган халкы, туган мәдәнияты, үз шәхесе турындагылары әйбәтрәк, уңышлырак чыккан («Европада татар шагыйрьләре», «Сәяхәттән — мәхәббәт турында», «Феникс — үлемсез кош», «Аллоуэйда, Бернс авылында», «Француз яулыгы»...) Ләкин моңардан чыгып, Р. Гатауллин иҗаты кысан чикләргә бикләнгән, шагыйрьнең мәнфәгатьләр даирәсе тар, мәгълүматы аз икән, дип уйларга ярамый. Киресенчә, әсәрләре аның поэзия өлкәсендә эрудит булуын күрсәтәләр. Шушыңа бәйле рәвештә, үз буыны шагыйрьләреннән аны аерып торган бер үзенчәлеккә тукталыйк. Ул — шигырьләрдә әдәби цитаталарның, дөнья шагыйрьләре иҗатына ишарәләүче символларның күплеге. Биредә төрле культура регионына караган атрибутларны очратасың: һәм Көнчыгышныкын (Ганкә — мифологик образ; сакый, Ләйлә белән Мәҗнүн — борынгы әдәбияттагы традицион образлар; Әбүгалисина), һәм Көнбатышныкын (Феникс, Сфинкс — мифологик образлар; Гамлет, Жанна Д'Арк, Эйфель манарасы...) Стильләштерү алымын оста куллануы исә шагыйрьнең шактый ук югары поэтик культурага ия икәнлеген раслый («Шәрыкча бер шигырь», «Чехов язганча», «Иске китапка зимагор бабайлар язган җыр»). Гомумән алганда, болар Р. Гатауллин иҗатын бизи торган сыйфатлар.

Ләкин бер җитди кимчелек тә күзгә бәрелеп тора. Чит образның асылына тирән төшенеп, үз әсәре структурасына аны оста гына үреп җибәрә алганда шагыйрь уңышка ирешә («Тел ачкычлары», «Феникс — үлемсез кош», «Кызлар каласы», «Шагыйрь».) Ят культура, ят иҗат атрибутларын тирәнтен уйлап кулланмаган очракларда, символны, легендар исемне атап үтү генә дә җитәр, исем артына яшеренгән мәгънә үзе үк шигырьгә күчәр, дип исәпләгәндә исә аны, кагыйдә буларак, уңышсызлык көтә («Нормандия-Неман», «Империя белән сөйләшү»). Чөнки образ, символ аңлаешсыз кала, тәэсир көченнән мәхрүм була. Бернинди мәгънәви кинаясез, ишарәсез куллану (контекст кына аны аңларга ярдәм итә алмый) исемне, образны буш шалтырavыкка әйләндерә. Шагыйрь бу очракта тормыштан аерыла, дөньяга тулысынча әдәбият аша карап иҗат итә башлый. Мәгънәви, хисси киеренкелектән, динамикадан мәхрүм ителгән мондый иҗат борынгы культура, традицияләр җирлегендәге тузан эчендә үрмәләп йөрүне хәтерләтә. Хәтта шагыйрьнең хисләре ихласлыгына шикләнеп куясың. Традиция гамьсез шаярып, уйнап йөрү өчен йомшак хәтфә келәм түгел лә, ул — көрәш мәйданы, аяк терәп басып, туган халкыңа, үзеңә үлемсезлек яулау өчен көрәш мәйданы.

Р. Гатауллин ирекләрәк характердагы шигырьләр яза. Бу форма гаять көчле чама тойгысына, нечкә зәвыкка ия булуны сорый. Фикерне читкә тарта, яки тоткарлый торган тәгәлсез сүзләр, образлар бу төр шигырьгә аяк чала, буш, көпшәк җөмләләр аны үтерә. Шагыйрьнең кайбер әсәрләрендә шуның гыйбрәтле мисалларын күрергә мөмкин:

**Париж!**
**Минем өчен**
**булдың матур төш...**
**[Төшем дәвам итә, имеш!]**
**Әле һаман төштә күргәннәрем истә:**
**— Европа! — дип**
**Шаккатмасам да мин**
**авыз ачып,**
**матурлыкка булды күңел ачык.**

Шигырьне авырайтып, кирәкмәс йөк булып, бернинди яңа мәгънә алып килмәүче сүзләр күп биредә: «Төшем дәвам итә, имеш!», «төштә күргәннәрем». Алар бөтенләй артык.

Шагыйрьнең стиле корырак. Сөйләмнең музыкаль җегәрен, колакны иркәли торган аһәңлелекне ул сирәк куллана. Сурәтлелек тә күп түгел. Еш кына хисне сөйләп аңлата. Фикер хәрәкәте, киеренкелеге — бу төр шигырьнең төп таләбе. Әгәр аз гына иркенәйтебрәк, бушайтыбрак җибәрсәң, яисә җиңелчә логик күнегүләр рәвешендә яза башласаң (әйтик, «Ватерлоо күперендә» шигыре) —барысы да бетә, әрәмгә китә, шигырь югала. Афоризм дәрәҗәсендәге җыйнак, тыгыз фикерле фразалар, строфалар гына максатка илтә. Әйтер сүзең, әһәмиятле фикерең булу шарт. Югыйсә:

**— Алло, Римма! Сагындым ла,—**
**дип телефоннан дәшәлмим —**
**син янымда...**

— кебек юллар шигырьгә килеп керәсен көт тә тор.

Дөнья поэзиясе белән танышу Р. Гатауллинның тормышка, туган халкына, үз иҗатына булган мөнәсәбәтенә эз сала, яңачарак фикерләргә этәрә. Менә ул культурабызга, әдәбиятыбызга карап уйлана:

**Әй, феникс, тылсымлы кош!**
**Сөйлә, күпме мәдәният,**
**күпме тел, җыр, әдәбият,**
**(Әй Көнбатыш!.. Син, Көнчыгыш!)**
**олы тарих дәвамында**
**юкка чыккан — алар кайда!**
**Ул халыклар үткәненнән —**
**үз көленнән!—**
**Кабат терелеп яралырмы!**
**Тагын алар җанланырмы!**

Безнең поэзиядә 60—70 нче елларда туган шаукымга нияреп, тарих мәрхәмәтсезлеген уйлап әрнү, үткәннән безгә килеп ирешкән рухи байлык калдыклары өстенә сыгылып төшеп сыктау икән бу тагы, дип ялгышмагыз. Югалтулар авыр, ләкин алар белән килешми хәлең юк. Шагыйрь, тарих китергән әрнүләрне күңеленә яшереп, киләчәккә карый.

**Тарихта бар, бар янарыш —**
**янып, янә чәчәк ату — ренессанс!**
**Әй, феникс! Безгә күрсәт**
**Син — шулардан тере сурәт:**
**янып, терел бер каршымда,**
**хәтерләт — аң, җанны уят...**

Гел сыктап кына гомер итеп булмый. Аннан соң, Р. Гатауллиннар буынына ул хас та түгел әле. Алар — дәгъвачыл рәвештә әдәбиятка килеп кергән вакытта үзләре белдергәнчә — көрәшчеләр. Халыкның аңын, җанын уяту — әлбәттә, көчле шәхесләр, кыюлар эше.

Ләкин, кызганычка каршы, Р. Гатауллинга кайвакыт нәкъ менә кыюлык, тәвәккәллек җитеп бетми сыман. Моны аның бик дөрес язылган, ләкин шуңа да карамастан укучыга тәэсир куәте чамалы булган шигырьләре раслый. Эзләнүләр, фикер хәрәкәте шагыйрьне катлаулы, хәл итү өчен кыюлык, рух көче сорый торган тормыш проблемаларына китереп чыгара. Һәм Р. Гатауллин бу очракларда еш кына, мәсьәләгә тирән керергә җөрьәт итмичә, әзер хакыйкатьләр ышыгына кача. «Лондонда татарча сөйләшү», «Адашкан җанга бер нәсыйхәт», «Шагыйрь тавышы», «Кайтып барыш» дигән шигырьләрдә күренә бу.

Ә бит әдәбият принципиальлекне, эзлеклелекне ярата. Үз сүзенә тугры була алсын иде Р. Гатауллин. «Шагыйрь мәрит түгел!» Кемнеңдер чабуына ябышып йөрү аның дәрәҗәсен генә төшерә. Бары көрәшчеләр генә ясый ала янарышны. Максатыңа ирешим дисәң, кыюрак, ныклырак булырга кирәк.

Фәиз ЗӨЛКАРНӘЕВ

# ЮЛЫ ҖИҢЕЛЛӘРДӘН КӨНЛӘШМИК

Укучыга ул романтик рухлы, кайнар хисле шагыйрь булып килде. Шуңа күрә дә хисләр ташкынының бер мәл басылаесына төшүе дә күзгә тиз чалынды. Озак та үтми, аның хакында сүз чыкканда: «Шагыйрь электәге үрендәрәк кала» дигәндәй, сак, әмма борчулы фикерләр ишетелеп китте. Кабатлана башлавын, иске сукмаклардан аерыла алмый торуын үзе дә сизенде шагыйрь. «Җырның җире булсын» өчен яңа тәэсирләр, яңа уйлар эзләп юлга чыгарга, заманга яңа шигырьләр белән җавап бирергә кирәк иде... Рәдиф Гатауллинның шигъри орбитадагы беренче әйләнеше әнә шулай төгәлләнде.

Юк, иҗатында беркайчан да җиңел язмыш эзләмәде ул. Башта ук: «Әнкәй, җибәр мине сәяхәткә,— күңел дингезләрен күрим...» дип башлаган иде. Ул чакта: «Ярдан һаман ераклашкан саен, җиңелрәк икән җилкәнгә!» рәвешендәрәк, беркатлы нәтиҗәләр дә ясарга өлгерде. Дөньяны сабыйларча, беркатлы тоюдан арырак китү, янә — аңлы гармониягә ирешү үзеннән-үзе генә килмәгәндер, әлбәттә. Иллюзияләрне җимерү, матурлык һәм камиллек өчен көрәш аша узган булырга тиеш ул юл. Әле аңык аңлашылып та җитмәгән күңел алгысуы тора-бара гына ачыграк төсмерләнде: кешенең бу китүе, бу сәфәре — үз асылына әйләнеп кайту өчен икән! Рухи асылына, рухи тамырларына.

**Гомер чишмәсеннән ерак китеп,**
**якынайган саен диңгезгә,**
**ешрак сагынам һаман әнкәм өен,**
**ныграк табынам туган нигезгә.**

Иҗатында үткән юлдан, тирәннән кила бу сүзләр... Аларга беренче адымны сәйях җанлы үсмер малай ясый. Ул үзенең киләчәгенә илтәсе юлларны әле «туган йорт тәрәзәсеннән» генә күрә. Икенче адымда — инде шактый озын юллар узарга өлгергән ир-егет, аның дөньяны «халык урамыннан» күрергә омтылуы. Өченче адым — Эйфель манарасыннан яңгыраган сагышлы һәм горур җыр: «Бүген — минем сагыну көнем. Бүген — ераклардан күренә миңа илем, туган җирем, әнием!» Әйе, бу — үз башыңнан кичереп, үз җаныңнан үткәреп табылган хакыйкать. Шуңа күрә шагыйрьгә дә, аның укучысына да бердәй аңлаешлы, бердәй кадерле ул.

Күңел Рәдиф Гатауллинның мәхәббәт шигырьләреннән, «Француз яулык», «Англия дәфтәре» бәйләмнәреннән әнә шундый кичерешләр чынлыгын эзли.

Изге хисләрне вакламау, кадерле кешеңне рәнҗетмәү, сөю-сөгадәтне шик-күләгәләрдән аралап, пакь көе саклау... Аның бөтен иҗатын шул саф, садә нур яктырта.

**Апрель булып кал син!**
**Бөреләрнең**
**тик ачылган чагын, саф чагын**
**каеннарның суты ташыган мәлен**
**Күзләреңнең язы сакласын.**

Минемчә, шагыйрь шәхесенең зурлыгын, фидакарьлеген мәхәббәт шигырьләреннән эзләргә кирәк. Мәхәббәт шигырьләренең көченнән, колачыннан.

Беренче чор иҗатында — автор әле тулысынча хис ирегендә. Аңа билгеле бер рольдә уйнау («Безгә рольне белеп биргәннәр»), ак һәм кара төсләр чиратлашуын бер читтәнрәк күзәтеп тору да җитә кебек. Хис стихиясе укучыны да үзе белән бергә бөтереп алмакчы була, хәтта аның кая чакыруын абайлап өлгерерлек тә түгел... Шагыйрьне бу юлда дөнья катлаулылыгын гадиләштерү, аны тавыш көрлеге белән генә «хәл итү» ихтималы да сагалап тора. (Мәсәлән: «Мөмкинме тик, дуслар, үлү?! Мең дуска — мең кайгы бүлү?!» рәвешендә.) Кызганычка каршы, шундый җиңел-җилпе талпынышлар кайчакта тормышчан пафос, романтик күтәренкелек дип тә бәяләнмәде түгел. Мондый мөнәсәбәт шагыйрьгә мунча себеркесе яфрагы булып ябышты, аның иҗади үсешен беркадәр җиңел агым уңаена юнәлтте шикелле. Рәдиф Гатауллинның беренче чор шигырьләре менә шул яктан, гомумән, шактый четерекле һәм бәхәсле. Бары шунысы ачык: тормыш сөючәнлек белән тормышчанлык — икесе ике нәрсә, чынбарлыкның асылы исә бик тирәндә ята икән. Тирәнрәк катламнарга әле үтеп керәсе бар. Шул катламнарга ачкыч эзлә, шагыйрь!

Әлеге эзләнү, хыял белән чынбарлык көрәше, нигездә, ике юнәлештә барды. Бер яктан, шагыйрь сүз тылсымы һәм хыял көче белән тормышка тәэсир итеп, аны үзгәртергә, матурларга омтыла: «Эретәсе иде туңган җирне, терелтәсе иде гөлләрне...» Икенче яктан, шул чынлык-чынбарлык поэзиягә үзе килеп керә, аның туфрагына һәм һавасына әверелә; «Арыш дулкынлана: күңелемә бәреп керә музыкасы...» Шагыйрьнең дөньяны, мәхәббәтне аңлавы катлаулырак һәм каршылыклырак була бара. Ул инде тормыш-яшәеш диалектикасын капма-каршы көчләрнең драматик көрәше рәвешендә ачарга омтыла. «Кал җырымда, апрель булып кал син!» яки «Я, нәрсәгә яшерен яну? Күпсенүләр?»не укып карагыз: ничаклы тирән хис аларда, язмыш сынауларын нинди сабыр кичерү! Шушы җитдилек Р. Гатауллинның бөтен шигъри системасына тәэсир ясый. Ул үзе дә моны сүз арасында гына: «Сизәм: проза хәзер аралаша сиңа атап язган шигырьдә»,— дип искәртеп куя. Проза катламы бу шигъриятнең «төшен» эрерәк, тазарак итте, аны җиргә якынайтты.

«Иске китапка зимагур бабайлар язган җыр»ның үзәк өзгеч моңына гына колак салыйк! Төенләнгән көе калган бер сорау бугай ул. Ерак еллардан килеп җитә алмаган билгесез хат бугай: «Үткән гомер — туган җир, гөлбакча. Кайтасы иде... Юлга үлән үскән; үлән нәрсә — акча кирәк, акча...»

Сагышлы җырлар юлыннан якты сәхифәләр эзли шагыйрь, үзенең иҗат-хыял кодрәте белән әлеге сәхифәләрне аяз күккә күтәрә. Алар, бәлки, очар кошка әйләнерләр, я шифалы яңгыр болыты булып калырлар, әмма пакь моңга сусап ачылган җаннарны рәхимсез боз булып сукмаслар. Чөнки шагыйрьнең күңеле изгелектә, һәм шул изгелектән аның һәр сүзе — хәерле эшкә фатиха, яман уйны кисәтү сурәтенә керә.

Тасвир-шигырьләр урынын шигырьмөнәсәбәт, шигырь-хат били: күңел серен сөйләүче, илтифатка һәм аңлауга өмет итүче, чакыру-өндәү яисә кисәтү булып яңгыраучы хат... Шәкли үзенчәлек кенә микән бу?! Шигырьнең эчке үсеше тормыш турында лирик монолог дәрәҗәсенә күтәрелә. Мондый ихласлыкның нигезендә — фикер җитлеккәнлеге һәм кичерешләр аныклыгы. Шуның өстенә — шигъри юлларда «оеп» калган автор тавышы, табигый интонация.

Табигыйлек — ике яклы тәңкә. Аның бер ягында — халыкчан гадилек («Әбелхарис һәм Әбүгалисина турында», «Иске китапка зимагур бабайлар язган җыр»). Табигый агымга юл ачуның икенче чиге дә мәгълүм. Кайберәүләр өчен ул — примитивлык. Гатауллинда исә — яңгыраш-кайтавазлар кылында көй-мәгънә чыгарырга ярату: «Ага Сена, ага Сена...Ниләр әйтим, Париж, сиңа?!», «Мин Марстан, тик марсиян түгел, мин — җирский...» Бу — аның үзенчәлеге дә, артык мавыгып киткән чакларында — йомшаклыгы да.

**Ак кәгазьгә мин шатланып яздым ласа!..**

Шигырь дөм-караңгы төнне телеп үткән яшен яктысы кебек башлана. Ак кәгазьгә һәм укучысының ак күңеленә өмет белән баккан шагыйрь — беренче юлда. Шигырь безнең күз алдында ярала. Сүз-сурәтләр гаҗәеп бер эзлеклелектә бер-берсен эзләп килә. Әлеге чиратлашу шулкадәр иркен, табигый: хәтта күренешләрнең очраклы гына янәшәлеге дип тә уйларлык. Хәлбуки, бу — образлы фикернең үзенчәлекле хәрәкәте, лирик геройның күңел халәте белән бәйләнгән.

Р. Гатауллин стиленең янә бер үзенчәлегенә игътибар итми мөмкин түгел. Аның һәр шигырендә диярлек килешмәүчән ике башлангыч бәхәсләшә. Бер яктан, ихлас кичерешләр, ургып торган хис булса, икенче яктан, исәпчел символика, ялангачрак конструкцияләр үзара тыныша алмый. Хис детальләрен шагыйрь көчәйтеп, зурайтып тасвирларга ярата: сөюне буран яисә кораб белән чагыштыра, сөйгәне киткәндә

«аяк астында тетрәп җир шуыша»; сөенгән чагы булса канында елга агышын сизә... Шул ук вакытта хәтта табигать күренешләренең дә (бер шигырендәге пластмасса торна шикелле) бары символ-төшенчә генә булып калуына рәнҗеп куясың. Төсләр тыйнаклыгы, сурәт-сынның бөтенләй диярлек тасвирланмавы да шуннан килеп чыга: «Минем шушы сурәт — күңелемнең тик шәүләсе. Җырның меңнән бер авазы... Кайтавазы...».

Сурәтлелек мәсьәләсендәге мондый эзлеклелек, мөгаен, беренче чиратта, шагыйрьнең табигатенә бәйледер. Әлеге хәлне, гомумән, стиль таләбе белән генә аңлатып та булыр иде. Чуар бизәкләр, тәфсилле детальләр образ бөтенлеген югалтуга, фикер агышын тоткарлауга китерә. Шигырь турырак, кыскарак юлга омтыла! Ләкин шушы «туры» дигән юлның тормыш сутыннан баш тарту бәрабәренә табылуы гына сагайтып куя. «Кызыл алмам» кебек шигырьләрдә тышкы форма спайлыгы мәгънәви үзәкнең кечерәя, ваклана баруын капларга тырыша. Бу — үзенә күрә «интеллектуаль примитивлык» тегермәненә су кою түгелме? Символик гөлләр генә калдыру бакчаны бөтенләй коргаксытуга алып бармасмы? Ясалма пафоска, пластмасса торналарга болай да кытлык сизелгәне юк лабаса...

«Чакыру» җыентыгында табигатьне генә түгел, укучыга таныш образларны да символ-төшенчә хәлендә калдыру, мәгълүм исемнәрне, китап сүзләрен шактый мул куллану күзгә ташлана. Бу күренеш аерым очракларда чынбарлыктан аерылу, икенчел дәрәҗәдәге ачыш булып тоела. «Исемнәр яратуы», тулаем, Р. Гатауллин иҗатының икенче әйләнешен үзенчәлекле кысаларга уратып ала. Шулай да аны үз-үзенә бикләнгән яки үткәнгә генә төбәлгән дип карау берьяклы булыр иде. Заман үзгәрешләренә тарихтан һәм әдәбияттан гыйбрәт эзләгән булып, үткән көнне яктыга алып чыгарга тырыша шагыйрь. Иҗатының беренче чорыннан башлап («Һейне тауларда») хәзергесенә кадәр («Әбелхарис һәм Әбүгалисина турында») шундый юнәлештәге хәрәкәт сизелә. Лирик герой үзенең идеалын дәверләр, каһарманнар фонына куеп сыный. «Тик һәркемнең үз Парижы!» кебек көтелмәгән ракурс-яңашалыклар, «Орлеан кызлары», «Феникс — үлемсез кош» шигырьләрендәге таныш образларның яңа бәйләнешләре... Алар яшәү мәгънәсе, дәвамлылык, тугрылык турында уйлануларның җырлеген кыйаитә.

Кичәге көн китапка әверелгән тарих кына түгел. Кайвакыт ялганган биеклекләрдән ары юл күренми, кыйбла югала, аннан инде үз-үзеңне кабатлый башлау ихтималы сагалап тора («Иртәдән бирле йөзем чытык минем...», «Бер ноябрь көне»).

Укучы белә: шигырьләрнең зурлыгы һәм тәэсир көче шагыйрь узган юллар озынлыгы, ул кичергән хисләр кайнарлыгы белән дә үлчәнә. Ләкин үз чиратында мондый әсәрләргә укучы да таләпне зурдан куярга хаклы бит. Чөнки ул чит җирләрдә йөреп гыйбрәт алган Горький, Маяковский, Евтушенколар белән таныш... Татар шагыйренең «Англия дәфтәр»ләре исә «каршылыклы, даулы заман турында» зуррак гомумиләштерү, кыюрак сүз әле алдагы китапларда булыр дип өметләндерә шикелле. Өченчесе нинди булыр? Ире-

Инде Рәдиф Гатауллин икенче әйләнешне — «Европада татар шагыйрьләре»ннән башланган әйләнешне — тәгәлләп кила шелгәннәрне ныгыту рәвешен генә алырмы ул, әллә яңа, көтелмәгән ачышлар юлыннан китәрме?.. Нәтиҗәләр ясарга, күрәзәлек итәргә ашыкмыйк әлегә. Сораулар «төенләнгән килеш калсын». Һәрдаим камиллеккә омтылуы, өметләндереп һәм киләчәккә чакырып торуы белән гүзәл ләбаса ул шигърият!

«Чакыру» җыентыгы әнә шул үсеш бонҗраларын, үсеш контрастларын күрсәтүе белән гыйбрәтле. Беренче тәҗрибәләреннән алып, эзләнүләре, табышлары һәм югалтулары белән шагыйрьнең тулаем үзенчәлекле иҗаты күз алдыннан кичә. Әмма бу — киләчәк хакына үткәнгә әйләнеп карау. Иң соңгы биттәге «Җитмешенче еллар белән саубуллашу» шигыре дә, йомгак-тәгәлләү булудан бигрәк, яңа — язылачак китапны ача кебек...

Өченче әйләнеш нинди булыр?

Һәрхәлдә, шагыйрьне алга таба да җиңел юллар көтми.

**Кенләшмибез юлы җиңелләрдән —**
**Һаман максат кушкан юлдан йөрик...**
**Юлда каршы алыйк Кояш-киләчәкне!..**

Җырдан өч кенә юл. Ашкынулы җырдан Бәхетле җырдан. Ул безне олы идеаллар, якты максатлар илена чакыра.

**Салих МАННАПОВ.**

# СОЛТАН ГАБӘШИНЕҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Татар профессиональ музыкасының тууы һәм беренче адымнары танылган музыкант, мәгърифәтче һәм фольклорчы Солтан Габәши исеме белән дә бәйләнгән.

Солтан Хәсән улы Габәши элекке Казан губернасының Кече Солабаш авылында туган. Казан һәм Уфа мәдрәсәләрендә укыганнан соң ул Уфа һөнәр училищесында белем алуын дәвам иттерә. Бала чагында ук Солтанның күңелен төрле уен коралларында уйнау теләге били. Музыкага, халык җырларына мәхәббәт елдан-ел көчәя, беренче мавыгулар нота әлифбасына төшенү, фортепьянода уйнарга өйрәнү кебек омтылышлар белән кушылып китә. Уфа мәдрәсәсендә укыганда ук С. Габәши музыкаль кичәләрдә актив катнаша, рояльдә уйный. Берничә ел музыка гыйлеме буенча дәресләр алу аңа зур ярдәм итә. Солтан көй язу өлкәсендә дә үзен сынап карый. Шул заманда ук иҗат ителгән җыр, романс, фортепьяно өчен миниатюраларының кайберләре бик тиз халыкка тарала һәм әле дә җырчылар теленнән төшми.

1915 елда Солтан Габәши Казанга кайта һәм университетның юридик факультетына укырга керә. Ләкин университетта белем алу чоры ике ел гына дәвам итә. Бөек Октябрь революциясеннән соң татар халкының сәнгатен, мәдәниятен үстерүгә ачылган киң мөмкинлекләрдән файдаланып, Габәши тулысынча музыкаль-педагогик башкару һәм иҗат эшчәнлегенә күчә.

С. Габәши спектакльләрне музыкаль яктан бизәү эшенә зур теләк белән керешә. Аңарчы драма театрында җыр-музыка куллану шактый чикләнгән хәлдә була: тәнәфес вакытларында яки спектакльләрдән соң гына халык көйләре башкарыла, җырчылар, хор һәм инструменталь ансамбльләр катнашуында аерым концертлар оештырыла. Бары 1917 елдан соң гына музыка татар театрының эчтәлегенә үтеп керә, аны баетучы бер бизәк буларак кулланыла башлый. Профессиональ музыка иҗатыбыз үсешенә башлангыч булып торган бу прогрессив күренешкә нигез салучыларның берсе — Солтан Габәши. Шул елларда «Аң» журналы да «Зөләйха» пьесасына С. Габәши тарафыннан музыкаль оформление эшләнүе һәм беренче тәҗрибәнең уңышлы чыгуы хакында яза (1917 ел, № 2).

1920—21 елларда С. Габәши музыкасы белән тагын ике спектакль куела. (Ф. Бурнашның «Таһир-Зөһрә»се һәм К. Рәхимнең «Бүз егет»е). Биредә инде музыканың драматургик вазифасы бар. Композитор җыр-музыка белән геройларның уй-хисләрен ачарга омтыла. Мәсәлән, «Бүз егет»тән «Сәхипҗамал җыры», «Кызлар җыры», «Таһир һәм Зөһрә»дән «Кызлар җыры» әнә шундый максатны күздә тотып иҗат ителгән.

Солтан Габәши — мөстәкыйль җырлар авторы да. Исемнәре белән үк композитор иҗатының ил-көн тормышына актив мөнәсәбәтен раслап торучы бу әсәрләр арасында комсомолның VI съездына багышланган, дингә каршы рухлы «Комсомол мөнаҗә-

те» һәм 1905 елгы революциянең егерме еллыгына багышлап язылган «Ике заман» җырын аерым билгеләп үтәргә кирәк.

Г. Әлмөхәммәтов һәм В. Виноградов белән берлектә, С. Габәши беренче милли опералар — «Сания» (1925) һәм «Эшче»не (1930) иҗат итүдә дә катнаша. «Сания» операсы Франкфуртта үткәрелгән Бөтендөнья күргәзмәсендә, «Эшче» — милли театрларның бөтенсоюз олимпиадасында бик зур уңыш казана, аларны чит ил матбугаты да мактап яза. Либретто камиллегенә, музыкаль бөтенлеккә ирешә алмау кебек аерым кимчелекләрдән азат булмасалар да, беренче татар опералары халкыбызның культура үсеше дәрәҗәсен күрсәтеп торулары ягыннан тарихи әһәмияткә ия.

Солтан Габәши укыту һәм культура-агарту өлкәсендә дә зур эшчәнлек алып бара. М. Вахитов исемендәге мәктәптә, Арчадагы мөгаллимнәр курсларында, мөселман пехота командирлары курсларында ул музыка теориясе, хор дәресләре укыта. Соңрак С. Габәши Көнчыгыш музыка техникумы мөдиренең урынбасары итеп билгеләнә.

Республикабыз музыкаль культурасы өчен бөтенләй яңа булган хор сәнгатенең үсешенә С. Габәши аеруча зур өлеш кертә. Шул максатны күздә тотып, ул татар халык җырларын катнаш хор белән башкару өчен эшкәртә. Әлеге әсәрләр яңа гына оешкан бик күп хор коллективларының төп репертуарын тәшкил итә. С. Габәши татар яшьләрен хор белән җырлау сәнгатенә җәлеп итү өчен дә күп көч куя.

Без бүген С. Габәшинең музыкаль фольклористика өлкәсендәге хезмәтләрен шулай ук зур хөрмәт белән искә алабыз. 1931 елның июнендә халык иҗатын өйрәнү өчен Татарстан районнарына махсус экспедиция нәкъ менә аның инициативасы белән оештырыла. Составында С. Габәши, җырчы Г. Әлмөхәммәтов, артистка Н. Рәхмәтуллина һәм башкалар булган бу экспедиция гаҗәеп игелекле максатлар белән юлга чыга. Алар халыкның җыр-көй иҗатын өйрәнүдән тыш, җирле һәвәскәрләргә ярдәм итәләр, талантлы музыкантлар һәм җырчылар эзләп табалар.

С. Габәшинең татар көйләре тарихына, халык музыкасы үзенчәлегенә багышланган мәкаләләре җитди игътибарга һәм өйрәнүгә лаек. Шул заманнарда ук ул халык музыкасының милли стиль үзенчәлекләрен ачыкларга, әлеге юнәлештәге катлаулы мәсьәләләрне кыю хәл итәргә омтыла. С. Габәшине татар халык җырларын теркәп калдыру, эшкәртү һәм башкару проблемалары аеруча дулкынландыра. Халык көйләрен энҗе-җәүһәрләрен җуймыйча язып алу һәм гармонияләштерү эшенә ул зур игътибар бирә, киләчәктә милли моңнарыбызны бөтен төсмерләре белән җиткерә алу мөмкинлекләре табылыр дип ышана.

Гомумән, С. Габәшинең татар профессиональ музыка сәнгате үсеше хакындагы фикерләре хәзер дә зур кызыксыну уята. Ул, мәсәлән, татар традицион җыр сәнгатенең Европа профессиональ музыкасына якынаюы берничә юл белән барырга мөмкин дигән фикерне яклый. С. Габәши карашынча, катлаулы сәхнә музыкасы, симфонияләр, хор өчен язылган әсәрләрдә милли үзенчәлек һәм традицион алымнар югары композиторлык техникасына ия булган дөнья культурасы казанышлары белән үрелеп үсәргә тиеш. Бу иҗади эзләнү нәтиҗәсендә традицион музыка теле тагын да баеый, тулылана төшәр, дип өмет баглый ул. Әлеге фикер-фаразларның хаклыгы музыка сәнгатебезнең алга таба үсеш адымнары белән расланды.

1932 елда С. Габәши Уфага күчеп китә һәм Башкорт сәнгать техникумында теория һәм сольфеджио буенча укыта башлый, музыка буенча дәреслекләр төзүдә катнаша. Бер үк вакытта, Башкорт милли культура фәнни-тикшеренү институты хезмәткәре буларак, ул башкорт музыкаль фольклорын җыю, өйрәнү һәм пропагандалау өлкәсендә зур эш алып бара.

Солтан Габәши каты авырудан соң 1942 елның 8 январенда вафат булды. Аның тынгысыз иҗаты һәм күпкырлы җәмәгать эшчәнлеге сәнгатебез үсешенең куәтле ташкынында якты агым булып төсмерләнә.

**Земфира СӘЙДӘШЕВА.**

# ШИРИЯЗДАН САРЫМСАКОВКА 70 ЯШЬ

Гасырлар буена күпне күргән, күпне кичергән дала уртасындагы Атбасар шәһәре, аның атаклы ат ярминкәләре хәтта Казан сәүдәгәрләрен дә үзенә тарткан. Петропавловскидан һәвәскәрләр килеп спектакль күрсәткәннәр, концерт куйганнар...



Менә шушы шәһәр байларына бил бөгеп көн күргән Мөхәммәтҗан абзый гаиләсендә 1911 елның 12 маенда ир бала дөньяга килә. Моңа кадәр кызлары гына булган агай, тансык улына, арслан күк батыр булсын диптер инде, Ширияздан дигән исем куштыра (шир — фарсыча арслан мәгънәсендә).

Ул елларда ат төп транспорт, ат йөртүче бөтен яңалыктан хәбәрдар: шәһәрдә ни эшләнгәнен, кемнәр килүен, кемнәрнең китүен — барысын да белә. Шулар арасында артист халкы да булса, аңа инде аеруча зур ихтирам-хөрмәт. Мөхәммәтҗан абзый театр уеннарының берсен дә калдырмый, үзе белән гаиләсен дә алып йөри.

— Әле дә хәтеремдә, әти безнең бөтенебезне җигүле арбага төяп уенга алып барадыр иде,— дип искә ала Сарымсаков.— Сәнгатьне гаҗәеп ярата торган гаиләдә үстем: Рәбига апа мандолинадан аерылмый, әти белән Биби апа гармоньда уйный, ә мине җырлаталар иде...

Бөек Октябрь революциясеннән соң Ширияздан татар мәктәбенә укырга керә. Атбасар каласының беренче пионерларыннан берсе була. Аның укуын тагын да дәвам итәсе килә. Ниһаять, Казан якларына китәргә җай чыга. Ширияздан бер кыш Арча контоны, Олы Мәңгәр авылында крестьян яшьләр мәктәбендә укый. Татар авылларында куелган беренче спектакльләрдә катнаша һәм менә шушы мавыгулар аның киләчәк язмышын билгеләүдә зур этәргеч була.

1928 елның көзендә Сарымсаков Казан берләшкән сәнгать-театр техникумына укырга керә. Техникумда артистлык осталыгыннан Наум Андреевич Шульга, музыка дәресләрен Салих Сәйдәшев, җыр-хор дәресләрен Солтан Габәши, әдәбияттан Садри Җәләл укыта. Кыскасы, педагоглардан уңа Ширияздан.

1930 елда Татар дәүләт академия театры СССР халыклары театрлары олимпиадасына катнаша. Яшь студент Ш. Сарымсаковка да шул бәйрәмгә бару бәхете тия. Талантлы артистларның уены, зур театрларның режиссура культурасы яшь актерлар өчен осталыкка өйрәнү мәктәбе була. Шул ук вакытта олимпиадада татар театрының көчле актерлар составына режиссерлык эшенең торышы туры килми дигән фикер дә әйтелә. Озак та үтми, Мәскәүнең Үзәк театр техникумында махсус милли бүлек ачыла. Ш. Сарымсаков менә шунда укырга җибәрелә.

1931 елны ГИТИС (дәүләт театр сәнгате институты) ачылып, берничә сәләтле студентны техникумнан шунда күчерәләр. Шул җөмләдән Ш. Сарымсаков та институтның режиссерлык бүлегенә кабул ителә. Мәскәүдә укуның файдасы зур була. Нинди генә мөмкинлекләр ачылмый студентларга: тәҗрибә өйрәнү, тирән теоретик мәгълүмат алу, премьералар карау, театр музейларына йөрү, танылган режиссерлар белән фикер алышулар. Режиссурадан МХАТ режиссеры И. Я. Судаков укыта.

1936 елны укуын тәгәлләп, яшь режиссер академия театрына эшкә кайта. Ул Мәскәүдә уку чорында алган белемен, тәҗрибәсен тулысы белән файдаланырга тырыша. Академия театры сәхнәсендә теләсә нинди катлаулы әсәр куярга мөмкинлек бар, чөнки ул елларда театрның талантлы артистларга бай чагы: З. Солтанов, К. Шамил, М. Сульва, М. Мутин, Х. Әбҗәлилев, Х. Уразиков, Г. Болгарская, Ф. Ильская, Г. Булатова, Н. Таждарова, Н. Арапова, Г. Уральский һ. б. лар.

Ш. Сарымсаковның беренче иҗат җимеше — «Бронепоезд — 14-69» (Вс. Иванов әсәре буенча куелган спектакль). Мәскәү театрларының балконнарына басып спектакльләр карау бушка китмәгән икән, кичәге студент, хәтеренә сеңгән файдалы материалларны үзенең иҗади эшендә куллана. Режиссер бигрәк тә халык күренешләренә басым ясый. Хәтта артыграк мавыгып китеп, төп персонажларны, атап әйткәндә Вершинин (Мөхтәр Мутин) образын каплый яза. Хәлил Әбҗәлилев Незеласовны зур темперамент белән психологик яктан көчле итеп уйный. Кайбер кимчелекләренә дә карамастан, халык фаҗигасен, яңа тормыш өчен көрәш кискенлеген чагылдырган, революцион романтика белән сугарылган спектакль иҗат ителә. Бу беренче җитди эш театр тәнкыйтендә уңай бәя ала.

Бу елларда Ш. Сарымсаков сәхнәгә куйган уңышлы әсәрләр рәтенә Ә. Фәйзинең «Тукай», М. Әблиевнең «Шәмсекамәр» драмалары да керә.

Режиссерның «Тукай» пьесасы белән танышу тарихы да кызыклы гына. 1937 елның җәендә Сарымсаков язучылар, нәшрият кешеләре белән Осланда ял итә. Әхмәт

Фәйзи үзенең пьесасын беренче мәртәбә шунда укый. Тажи Гыйззәт, Риза Ишморат, Ш. Камал һ. б. ларга пьеса бик нык дулкынландыргыч тәэсир ясый. Шул көннәрдә Әхмәт Фәйзи белән Ширияздан Сарымсаков арасында да иҗади бәйләнеш туа. Тукай турында яңа материаллар туплау, эзләнү нәтиҗәсендә тарихи дөреслеккә нигезләнгән сәхнә оформлениесе иҗат ителә. Вакыйга барган урыннар, Тукай яшәгән кырыгынчы Болгар номеры үзенчәлекле итеп күрсәтелә, һәм бу детальләр уен барышында бик оста файдаланылалар. Мәсәлән, Хөсәен Ямашевның үлү хәбәрен ишеткән Тукай йөткерүдән буыла һәм бүлмә һавасына чыдаша алмыйча, җилле салкын балконга йөгереп чыга. Караңгы төн, ерактагы урам фонареннан төшкән сүрән бер яктылык күңелдәге шомны арттыра төшә...

«Тукай» драмасы уңае белән Гадел Кутуй «Кызыл Татарстан» газетасында: «Режиссер Сарымсаков авторның уйларын тамашачыга җиткерү өчен пьесага күп кенә җанлылык керткән. Һәрбер образга үзенә хас буяу бирү, барлык күренешләрне Тукай образы тирәсенә җыю, ялган эффектлардан качу — Сарымсаков иптәшнең реалистик җитди режиссер булуын күрсәтәләр. Режиссер Сарымсаков сүзсез, яки аз сүзле рольләр өстендә ныклап эшләргә ярата, ул образларга портрет охшашлыкны булдыру турында күп уйлана,— дип яза.— «Тукай» спектакле Әхмәт Фәйзи иптәшнең дә, театр коллективының да зур уңышы...»

Режиссерның Тажи Гыйззәт белән иҗади дуслыгы нәтиҗәсендә дә Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә онытылмас спектакльләр туа. Сарымсаков куелышындагы «Ялкын» спектакле, мәсәлән, театр тарихында бер вакыйга булып тора һәм Т. Гыйззәт иҗатының көчле якларын ачарга ярдәм итә.

1957 елда Мәскәүдә үткәрелгән татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында әлеге хезмәттәшлек нигезендә иҗат ителгән «Шомлы көннәр» спектакленә югары бәя бирелә. РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе К. Я. Шахазизев: «Шомлы көннәр» спектакле мине чын-чынлап куандырды. Режиссерның төгәл эше, пьесаның дөрес чишелеше дулкынландыра»,— ди (1957 ел. Мәскәү. Декада стенограммасы). Ш. Сарымсаков «Шомлы көннәр»не халык эпопеясы итеп сәхнәгә күтәрә, анда татар халкының аңы үсүен, революцион көрәшкә килү юлларын чагылдырырга омтыла.

Ш. Сарымсаковның режиссерлык иҗатында сатирик план аеруча калку тора. Зур уңыш белән барган сатирик спектакльләр рәтенә К. Тинчуринның «Җилкансезләр»е (1958 ел) керә. Бу спектакль турында «Советская культура» газетасы: «Режиссер-постановщик иптәш Сарымсаков авторның теләгән тамашачыларга җиткерү юнәлешендә зур эш эшләгән. Сатира биредә иң югары баскычка җитә»,— дип язды. Шул ук спектакль өчен Ш. Сарымсаков республикабызның Г. Тукай исемендәге премиясенә лаек булды.

Ш. Сарымсаков утыз ел Татар дәүләт академия театрында эшләү дәверендә зур әсәрләр иҗат итте. Беренче мәртәбә татар театры сәхнәсендә юлбашчыбыз В. И. Ленин образын гәүдәләндергән «Мылтыклы кеше» спектакле (Н. Погодин. 1947 ел) генә дә моңа ачык дәлил булып тора.

Ш. Сарымсаков иҗаты югары идеалларга омтылучан характеры белән үзенчәлекле. Әнә шуңа күрә аның спектакльләрендә героик ноталар еш кына югары патетик ноктага күтәрелә. Образның тышкы һәм эчке динамикасын ачуны режиссер беренче планга куя. Ул тормышның характерлы детальләренә, аерым шәхесләрнең холык-фигыльләрендәге нечкә үзенчәлекләргә таяна. Сарымсаков гади, ләкин ышандырырлык сәхнә алымнары белән күп кенә әсәрләрнең эчтәлекләрен шигъри рухта һәм зур психологик тирәнлек белән тасвирлый алды.

Режиссерның иҗат дөньясы искиткеч бай. Бу, әлбәттә, аның дөньяга караш киңлеге, тирән белеме, бай тормыш тәҗрибәсе белән бәйле. Әсәрләрне сәхнәләштергәндә режиссер вакыйгаларның фәлсәфи эчтәлеген, персонажларның эчке хисләрен тамашачыга бөтен тулылыгы белән җиткерергә тырыша. Аның спектакльләрендә һәр персонажның үз төсе, үз йөзе, үз буявы бар.

Сарымсаковның иҗаты тулаем өч башлангычтан гыйбарәт: беренчесе — реалистик пландагы, тирән кичерешләргә бай драма, икенчесе — рухи көч бирә торган трагедия, өченчесе — үткен фикерле аяусыз сатира. Әнә шул өч башлангычның көчле үсеш алуы нәтиҗәсендә режиссер үзе иҗат иткән сәнгатьнең нәфислегенә, матурлыгына ирешә.

Ш. М. Сарымсаков хезмәте режиссер буларак кына чикләнми. Ул күп кенә инсценировкалар яза, К. Нәҗминең «Язгы җилләр» романы буенча «Сәүбановлар», Г. Әпсәләмовның «Сүнмәс утлар» романы буенча «Хәерле юл» һәм А. Расихның «Ике буйдак» романы буенча шул исемдәге спектакльләр иҗат итүгә күп көч куя. Ш. Сарымсаков шулай ук Г. Кариев турында монография, артист Ш. Шамильский, Г. Болгарская һ. б. иҗат кешеләре турында истәлекләр, мәкаләләр авторы.

Яшь кадрлар сайлап алуда, талантлы яшьләрне үстерүдә дә Сарымсаковның өлеше зур. 1949 елны театр училищесында чыгарылыш спектакле («Ташкыннар») куелганнан соң, ул Ш. Бикчимеров белән А. Арслановны театрга алырга киңәш бирә һәм ялгышмый. Аның шөкертләреннән берсе — Ш. Бикчимеров хәзер СССРның халык артисты.

РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, профессор Ш. Сарымсаков юбилеен иҗади хезмәттә каршылый. Казан культура институтында сәнгать осталарына яшь алмаш әзерләүгә үзенең өлешен кертә.

Әминә ГОБӘЙДУЛЛИНА

# БАЙ ЭРУДИЦИЯЛЕ ГАЛИМ

СССР Фәннәр академиясе тел белеме институтының төрки һәм монгол телләре секторы мөдире, тюркологларның Совет комитеты рәисе урынбасары, филология фәннәре докторы профессор Ә. Р. Тенишевка 60 яшь тулды. Галим илебезнең иң зур төрки тел белгечләреннән санала, тел белеменең кайсы гына өлкәсен алып карама, аның хезмәтләре лаеклы урын алып тора.

Әдһәм Рәхимович Тенишев Пенза шәһәрендә туа (26 апрель). Аның әтисе Мөхәммәтрәхим абзый Казандагы реальный училищеда М. Вахитов белән бергә укыган һәм яшьлек елларында аның прогрессив хәрәкәттә актив катнашуы да мәгълүм. Гомуми һәм музыкаль белемле әнисе Әминә ханым пролетар язучыбыз Г. Коләхметовка туган тиешле була. Галимнең яшьлеге менә шундый сәнгать һәм әдәбият белән кызыксынган, аны үз күргән гаиләдә уза.

Унынчы классны тәмамлаганнан соң, Әдһәм Мәскәүгә — тимер юл инженерлары институтына юл тота. Булачак мәшһүр тюркологның беренче фәнни хезмәте дә студент елларында басылып чыга һәм ул танылган математик Эйлерның интегралын чишүгә багышлана. Кем белә бит: Бөек Ватан сугышы башланып китмәсә, бәлкем аннан талантлы инженер да чыккан булыр иде. һәрнәрсәгә үз төзәтмәсен керткән кебек, сугыш Әдһәмнең тормышын да башка юлга борып җибәрә — 1945 елда ул Ленинград университетының Көнчыгыш факультетына укырга керә.

Бу елларда Ленинград Көнчыгыш халыкларының культурасын, тарихын, телен өйрәнү буенча зур үзәккә әверелгән була, аның университетында һәм фәнни тикшеренү институтларында дөньякүләм дан тоткан галимнәр В. М. Жирмунский, Е. Э. Бертельс, Д. В. Бубрих, И. Ю. Крачковский, А. Н. Кононов, С. Е. Малов, И. А. Орбели һәм башкалар эшлиләр. Алар белән аралашу, лекцияләрен тыңлау Ә. Тенишевка көнчыгыш дөньясы, ислам тарихы, иске монгол, фарсы, кытай, итальян һәм башка телләр буенча ныклы белем алырга ярдәм иткән. Ә инде борынгы төрки истәлекләре белгече С. Е. Малов түгәрәгендә катнашу һәм аның белән якыннан аралашу, фикер алышу «Кыпчак теле һәм аның хәзерге кыпчак телләре белән бәйләнеше (төрләнеш системасы)» дигән темага диплом эше язуга этәргән. Аспирантурада да ул С. Е. Малов җитәкчелегендә борынгы уйгур истәлеге «Алтын ярук» әсәре буенча диссертация яза һәм 1953 елда аны уңышлы яклый. Аспирант елларында ук Ә. Тенишев университет студентларына борынгы төрки истәлекләре, төрек, казакъ, үзбәк телләре, төрки телләрнең чагыштырма грамматикасы буенча махсус курслар укый. Моннан тыш ул ана телен, кыргыз, яңа уйгыр, немец, инглиз, француз телләрен яхшы белә, көнчыгыш эпиграфикасын һәм палеографиясен, төрки халыклар, каганлыклар, ханлыклар тарихын яхшы үзләштерә.

1954 елда СССР Фәннәр академиясенең тел белеме институты директоры академик В. В. Виноградов аны Мәскәүгә эшкә чакыргач, Ә. Тенишев, озак уйланмыйча, Мәскәүгә күчә һәм төрки телләр секторында эшли башлый. Әмма күп тә үтми, Фәннәр академиясе Президиумы, Кытай хөкүмәте үтенечен канәгатьләндереп, Ә. Тенишевны Кытайдагы төрки халыклар телен тикшерү һәм төрки телләр белгечләре әзерләргә булышу өчен шунда җибәрә. Бу эстафета аңа В. В. Радлов һәм С. Е. Маловтан соң тапшырыла. Кытайда өч ел яшәү вакытында ул студентларга, аспирантларга төрек теле грамматикасы, төрки тел белеменә кереш, борынгы төрки истәлекләрнең теле, кыпчак телләренең чагыштырма-тарихи грамматикасы буенча лекцияләр укый һәм махсус семинарлар уздыра. Әмма галимне барыннан да бигрәк төрки телләрдә сөйләшүче халык үзенә тарта, аларның телен, авыз иҗатын, тормыш-көнкүрешен өйрәнәсе килә иның: экспедицияләрдә катнаша, уйгырлар, саларлар, сарыг-югурлар (сары уйгырлар) янында була. Алар барысы катлаулы шартларда, хәтта кайвакытта маҗаралы рәвештә уза. Бу турыда галимнең әлегә кульязма хәлендә сакланган 20 табаклы «Үзәк Азия буйлап сәяхәт» дигән китабында тәфсилләп язылган. Тел белеменең яңа бу этабы турында дөньякүләм танылган галимнәр Г. Ю. Клапрот, Ж. П. Абель-Ремюза, А. Ф. Габен, Г. Ярринг, И. Н. Березин һәм башкалардан соң яңа сүз әйтүе җиңел түгел, әлбәттә. Ләкин Ә. Тенишев үз сүзен әйтте һәм ныклы ышаныч белән әйтте. Ул Синьцзян уйгыр теленең өч диалекттан торуын раслады, сарыг-югур, салар телләренең мөстәкыйль телләр икәнлеген дәлилләде. Әдһәм Рәхимович, гомумән, ниндидер идея генә әйтеп, кешене шаккатырырга яратмый: яңа фикерен ул төрле күләмдәге конференцияләрдә чыгып сөйли, яисә мәкаләләр итеп укучылар хөкеменә чыгара. 1976 елда «Наука» нәшриятында чыккан «Строй сарыг-югурского языка» белән «Строй саларского языка» дигән китапларының да аерым

кисәкләре мәкаләләр рәвешендә фәнни җәмәгатьчелеккә җиткерелеп, соңыннан һәрьяклап уйланылган, үлчәнелгән хезмәт булып торалар. Шуңа күрә дә аның эшләре, кагыйдә буларак, белгечләр тарафыннан югары бәяләнә.

Хәзерге көндә филология фәннәре докторы, Мәскәү университеты профессоры Ә. Тенишев 150 ләп фәнни хезмәт авторы, моннан тыш тагын егермеләбе матбугатка тапшырылган. Ул, иң әүвәле, телче галим, әмма аның иҗатына күз салсаң, иҗат киңлекләренең тел кысасы белән генә чикләнмәвен күрергә мөмкин: хезмәтләре арасында халыклар тарихына, этнографиясенә, әдәбиятына һәм фольклорына багышланганнары да шактый.

Борынгы Орхон-Енисей язма истәлекләренең теле — илебез һәм чит ил тюркологларының традицион кызыксыну өлкәсе. Төрки халыкларның VII—IX гасырларда язылган ядкарьләренең телен еш кына хәзерге кайбер телләр белән чагыштырып, нәселләрен борынгы төркиләргә турыдан-туры бәйләүче галимнәр дә юк түгел. Төрки рун язмаларын һәм борынгы истәлекләрне тикшергәч, Ә. Тенишев борынгы төрки дип саналган Орхон һәм Енисей таш-язмаларында ниндидер сөйләш түгел, ә шул чорның әдәби теле чагылыш тапкан дигән фикергә килә. Әдәби тел буларак, аны угызлар да, уйгырлар да, кыпчаклар да кулланганнар. Соңрак бу әдәби телдән борынгы уйгыр әдәби теле, ә аннан караханид уйгыр әдәби теле, чагатай әдәби теле һ. б. формалашкан. Мәсьәләне болай итеп кую, галимнәргә милләт оешканчы яшәгән әдәби телнең, милли әдәби тел белән мөнәсәбәтен дөресрәк чагылдырырга киң юл ачачак.

Соңгы елларда Ә. Тенишев моңарчы төрки тел белемендә игътибар җитенкерәмәгән тарихи чыганакларга лингвистик аңлатма бирүнең мөһим мәсьәлә булуын күтәреп чыкты. Бу — тел белеменең аерым бер тармагы, шуны алга җибәрми торып телнең (шул исәптән татар теленең дә) тарихын яки тарихи диалектологиясен фәнни нигездә эшләп булмаячак.

Профессор Ә. Тенишевның татар тел белеме белән дә бәйләнеше күпкырлы. Дөрес, турыдан-туры татар теленә караган хезмәтләре аның берничә генә, әмма татар тел белемен үстерүдәге роле шактый зур. Мәгълүм ки, фәннең үсеше, беренче чиратта, югары квалификацияле белгечләрнең булуы белән бәйле. Бу күзлектән карaганда, Казан университеты, Казан һәм Алабуга педагогия институтлары тюркологларының шактые (филология фәннәре докторлары Г. Ф. Саттаров, В. Х. Хаков, доцентлар З. М. Вәлиуллина, Р. А. Юсупов, Ф. С. Сафиуллина, А. Х. Нуриева, Л. Ш. Арсланов һ. б.) Мәскәүдә квалификация күтәрү курсларында булып, профессор Ә. Р. Тенишев җитәкчелегендә стажировка үттеләр, үзләренең теоретик белемнәрен арттырдылар, лингвистик анализның яңа ысуллары белән таныштылар. Шуның нәтиҗәсендә докторлык диссертацияләре язылды, монографияләр туды.

Ә. Тенишев татар тел белеменең үсеше белән даими кызыксынып тора. Татарстан галимнәренең китаплары уңаена язылган рецензияләрендәме, диссертация яклауда рәсми оппонент буларак чыгышындамы, ул конкрет хезмәтнең кыйммәтен һәм кимчелекле якларын күрсәтү белән бергә, аның татар тел белемендә, гомуми тюркологиядә тоткан урынын билгели, татар галимнәренең әлегә хәл итеп бетермәгән мәсьәләләрен ачыклап үтә. Мисал өчен «Советская тюркология» журналында (1974, 2 сан) Г. Саттаровның «Татарстан АССРның антропотопонимнары (Татарстан авылларының исемнәре)» китабына бәяләмәсен алып карыйк. Ул анда татар халкы белән татар теленең формалашуы бер үк төсле бардымы икән дигән мәсьәләне күтәреп чыкты. Татар этносы нигезендә болгар элементы ятса да, аның татар телендә «төп» элементмы яки «үзара мөнәсәбәт эземе» икәнлеген ачыклыйсы барлыгын бурыч итеп куйды. «Бу сорауга җавап бирер өчен,— дип язды ул,— татар телендә һәм аның диалектлары белән сөйләшләрендә болгар күмәклек исемнәрен җентекләп тикшерәсе бар. Бу — татар тел белеменең хәл итәсе актуаль мәсьәләләренең берсе».

Ә. Тенишев, татар галимнәренең фәнни хезмәтләренең җаваплы редакторы булганда, аларның эшләнешләре югары дәрәҗәдә булсын өчен дә көчен һәм вакытын кызганмый. Соңгы елларда гына да Л. Махмутованың «Опыт исследования тюркских диалектов. Мишарский диалект татарского языка» (М., 1978), Ф. Хәкимҗановның «Язык эпитафий волжских булгар» (М., 1978), Г. Әхәтовның «Татарская диалектология» (Уфа, 1979), «Мишарский диалект татарского языка» (Уфа, 1980) дигән китаплары, СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты чыгарган «Источниковедение и история тюркских языков» (Казан, 1978) дигән фәнни мәкаләләр җыентыгы аның редакциясендә дөнья күрделәр. Хәзерге көндә тюркологларның Совет комитеты Казан телчеләренә гаять мөһим бурыч йөкләде: алар болгар кабер ташлары язмаларының һәм әрмән хәрефләре белән язылган XVI йөз кыпчак теле документларының альбомнарын әзерләргә тиешләр һәм бу җитди хезмәтләргә профессор Ә. Тенишев җитәкчелек итә.

...Төн уртасына кадәр аның бүлмәсендә ут сүнми: аспирантларының кулъязмаларын укырга кирәк, яңа чыккан фәнни хезмәтләрне дә карап чыгасы бар, ә өстәл читендә үз нәүбәтләрен көтеп галимнең кулъязмалары ята. Алар арасында борынгы уйгыр юридик документларының тәрҗемәләре, «Алтын ярук»ның тексты, сүзлеге, саларларның тарихи легендалары, күк-мөнджәкләр теленең сүзлеге һ. б., һ. б.

**Фәрид ХӘКИМҖАНОВ,**
филология фәннәре кандидаты.

# ВАТАН СУГЫШЫ ЕЛЛАРЫНЫҢ КӨЛКЕ КАПЧЫГЫННАН

*«Туплар гөрләгән чакларда музалар тынып тора» диелгән кайчандыр. Үткәннән килгән бу гыйбарә совет гаскәрләре туган илне яклап батырларча сугышкан барча елларда, шул җөмләдән Бөек Ватан сугышы елларында да, кире кагылды. Җыр һәм шигырь, үткен һәм тапкыр сүз ульләренең төп мәгънәсендә һәр адымда һәм һәркайда өзлексез яңгырады, безнең сугышчылар кулында корал һәм байрак булып җиңү яулашты. Фронт матбугаты битләреннән сайлап алынган юмор һәм сатира үрнәкләре хөрмәтле укучыларыбыз игътибарына бу санда да тәкъдим ителә.*

## Кайнар сәлам

— Мин бүген гитлерчыларның бөтен бер ротасына аларның үз телләрендә кайнар сәлам юлладым.

— Ничек аңларга моны?

— Гап-гади бер нәрсә бу: үзем кулга төшергән трофей минометтан — димәк немецларныкыннан ут яудырып рота дигәннәрен берьюлы кырып салдым.

## Уртак тел

Ике командир сөйләшә:

— Минем рота унбиш милләт егетләреннән тора. Әмма алар бөтенесе бер уртак телдә аңлашалар.

— Ә ничек?

— Украиннар — кыю пулеметчы, казакълар — минометтан утны бик оста яудыра, грузиннар белән үзбәкләр — менә дигән тупчы, себернекеләр — ут күзле мәргән... Сугышчан телдә бөтенесе бергә сөйли башласалар, үз хәлләре мөшкел икәнен немецлар бер минутта аңлап ала.

## Морадына иреште

— Партизаннар белән йөзгә-йөз очрашмый торып җаным тынычланачак түгел,— дип шапырына СС командиры үзенең җәзалау отрядын урман ягына алып барганда. Һәм чыннан да хаклы булып чыга ул: партизаннарның беренче пулясы ук аны аяктан ега. Җаны мәңгегә тынычлана бушбугаз фашистның.

## Фронтка хат

Бер малай әтисенә язган хатында түбәндәге яңалыкларны да белдерә:

«Мин үземнең этемә яңа кушамат бирдем — хәзер инде Фриц ул. Чөнки соңгы вакытларда нәкъ немец кебек кылангалый башлады: узган айда әнинең бер чүлмәк сөтен чөмергән иде, әле күптән түгел генә бер тавык белән ике чебешнең башына җиткән булып чыкты. Ә күршебез Фәрит исә үз бурзаен Геббельс дип йөртә: никтер ул, һичкем игътибар итмәсә дә, көннәр буе бертуктаусыз өрә.»

## Кем эше?

Басып алынган Парижда торганда вермахт офицерлары атаклы рәссам Пикассоның остаханәсенә дә кергәлиләр. Хуҗа чакырылмаган бу «кунакларны» бер сүз дә дәшми генә каршылый һәм мастерскоен да күрсәтә. Шулардан берәү инде кире чыгып китәр алдыннан бер рәсем репродукциясен кулына ук алып караштыра башлый. Анда фашистлар бомбага тотып җимергән Испан шәһәре Герник харәбәләре сурәтләнгән була. Шулчакны аңа оккупация власте башлыгы да кырын гына булса да күз төшереп ала һәм рәссамга сорау бирә:

— Сезнең эшме бу?

— Юк,— дип җавап бирә Пикассо ике генә кырыс сүз белән,— сезнең эшегез!

## Бурычны түләү

### ПАРТИЗАН БЛОКНОТЫННАН

Фашист әйтте көндез бер «абзыйга»:
— Сал бүрегеңне! һәм бир честь... диләр.—
Ә фашистның бүрек кигән башын
Шул абзыйлар төнлә кистеләр.

## Киресенчә уйла

— Инде дә куркыта да бу белорус урманнары мине, Ганс дустым. Адым саен бер генә нәрсә көтәм кебек: шуннан менә-менә чыгарлар да өстебезгә партизаннар ташланыр төсле...

— Әгәр көтәсең икән, кордаш, андый һөҗүм булмаячак: партизан бит ул син һич көтмәгән төштән килеп чыга!

## Һөҗүмнән соң

— Тешләрегезне тоташтырган күперчек зыянланган, яңаны ясарга кирәк булыр, капитан әфәнде.

— Белмим, кирәкме икән: аны барыбер партизаннар шартлатыр төсле...

## Кемгә нәрсә...

— Безнең обер-лейтенант тизрәк дөмексен иде.
— Ник алай дисең?
— Чөнки итеге бик әйбәт.

## Җир белән бергә...

— Чын ариец беркайчан да калтырамаска тиеш.
— Ә мин калтырамыйм бугай. Рус снарядлары һәм бомбалары җирнең үзен шулай тетрәтәләр. Мин җир дерелдәгәнгә күрә калтырыймдыр... Кыскасы, компаньеоннар без.

## Гадидән дә гадирәк исәп

Офицер. Минем ротаның ничә кешесе исән калды?
Солдат. Менә сез, офицер әфәнде.
Офицер. Ә син үзең?
Солдат. Ә мин бүтән ротадан бер ялгызым калдым.

## Ялган сүз

— Курт Пепке, сез фронтта безнең полк бик күп сугышчыларын югалтты дигән гайбәт таратасыз икән.
— Моны миңа бүген икенче батальон солдатлары әйтте, гер обер-лейтенант!
— Менә болай дип икеләтә ялганлыйсыз инде! Икенче батальон солдатларыннан сез бернәрсә дә ишетә алмадыгыз һәм ишетә алмыйсыз, чөнки ул батальонны кичә руслар тулысынча юк иттеләр бит?!

## «Алга» исемле генерал турында

### БЕРНИЧӘ КҮҢЕЛЛЕ ХИКӘЯТ

*Сүз исеме бөтен дөньяга билгеле һәм атаклы полководец, Бөтенроссия армиясенең генералиссимусы Александр Васильевич Суворов турында бара. Чыннан да, әле үзе яшәгән заманда ук (1730—1800) халык аңа үзеннән, чын күңелдән яратып һәм олылап, генерал Алга дигән исем таккан. Чөнки ул җитәкләгән яуларның берсендә дә (Очаков һәм Фокшан, Рымник һәм Измаил сугышлары, атаклы Альп походы) рус гаскәрләрен бер генә дошман да җиңә алмаган.*

*Суворов традицияләре, аның «Җиңү фәне» дигән китабында язганнары, хәрби стратегия һәм тактика принциплары, гаскәриләрне өйрәтү һәм тәрбияләү үрнәге — бүгенге Совет Армиясе өчен дә кирәкле көчле корал. Аның шулай ук халык үзе иҗат иткән «биографиясендә» дә бик күп легендалар, җырлар, күңелле хикәятләр, мәзәкләр һ. б. бар. Шундыйларның партизан учаклары янында командирыбыз Константин Заслонов сөйләгәннәрен (1942 ел), мәсәлән, мин дә хәтерлим. Күптән түгел исә шуларны әдәби чыганаклардан табарга мөмкин булды. Түбәндә шуларның берничә үрнәге китерелә. Алар хәрби остазның чын мәгънәдә кешелекле бөек гадилеге һәм солдат җанлы булуы турында сөйли.*

## «Начар солых та... яхшы»

Бервакыт Суворов барында сугыш хәрәкәтләре турында сүз чыга. Полководецны мактап аның алдында яхшы атлы булып күренергә теләгән берәү шунда Суворовка сорау бирә икән:

— Сез галиҗанәпләрнең сугышны бик яратуы сөендерә мине!

— Аллам сакласын!— ди Суворов.— Шулай ук минем бөтен илдәшләремне дә сугышны яратудан алла сакласын! Минем бар теләгәнем һәм максатым җирдә тынычлык булсын өчен сугышу, ә сугышта дан алу хакына тынычлыкны бозарга беркайчан да теләмәдем. Чөнки начар солых яхшы талаштан яхшырак.

## «Минем итекләр гаепле...»

Крепость салганда Суворов бер полковникка яңа ныгытмалар эшләтүне күзәтергә куша. Әллә ялкауланып, әллә инде вакытын кызганып, полковник моны үзеннән түбәнрәк дәрәҗәле бүтән берәүгә тапшыра.

Эшләр барышын карарга килеп ныгытмалар тиешенчә төзек түгеллеген күргәч, Суворов полковникны бик каты шелтәли, ә полковник исә гаепне теге түбән чинлы өстенә аудармакчы икән.

— Ул да, син дә гаепле түгел,— ди Суворов һәм бер чыбык китертә дә шуның белән үз итекләрен кыйный башлый.

— Бүтән беркайчан да ялкауланмагыз! Үшән булмагыз! Барсына да сез гаепле! Әгәр эш урыннарында үзегез йөргән булсагыз, берниндә дә төзексезлек калмас иде!

## «Бирредән күккә чаклы ара күпме булыр?»

Суворов үзе сораганга «Белмим бит» дигән җавап бирүне яратмаган — «белмәмеш»лекне күрәлмәгән ул, һәркемнең аңа төгәл һәм тиз җавап бирүен таләп иткән.

Берчакны гренадерларының берсеннән сорый икән:

— Менә бирредән күккә хәтле ара күпме булыр?

— Аны узар өчен ике Суворов походы кирәк! — дип бик тиз җавап бирә тапкыр солдат һәм Суворов моңа бик канәгать була.

## «Безнең полкка бу сүз билгесез»

Яшь кенә кавалерист офицерны туктата да кинәт сорый Суворов:

— Ретирада[1] нәрсә ул?

— Белмим бит,— ди офицер бер дә исе китмичә.

Суворовның күзләре уттай кабына, саксызрак бу кавалеристны усал сүзләр агымы белән күмәргә әзер ул. Ә офицер һаман салкын канлы була бирреп ашыкмыйча гына дәвам итә:

— Чыннан да белмим бит, Галиҗанәб, безнең полкка бу сүз билгеле түгел. Минем аны беркайчан да ишеткәнем юк!

— Шәп полк! Искиткеч әйбәт полк! — дип кычкыра Суворов һәм шулай ук кычкырып көлә дә тирә-юньдәгеләргә әйтә:

— Каргалган белмәмеш мине бу хәтле куандырыр дип һич көтмәгән-уйламаган идем.

**Материалны ЗӘКИ НУРИ әзерләде.**

---

[1] Ретирада — чигенү.

## АЧЫК ПАРТИЯ ҖЫЕЛЫШЫ

Язучылар союзы партия оешмасының чираттагы җыелышы булып үтте. Анда «Район, шәһәр, өлкә конференцияләре карарлары яктылыгында Язучылар союзы партия оешмасының бурычлары» турында доклад белән партбюро секретаре Ринат Мөхәммәдиев чыкты. Ул, КПССның XXVI съездын каршылау вахтасына басып, республикабыз эшчеләре, игенчеләре, галимнәре һәм әдәбият-сәнгать әһелләре яулаган уңышлар турында сөйләде, төп игътибарны язучыларның тормыш һәм иҗат активлыгын тагын да күтәрү мәсьәләләренә юнәлтте.

Доклад буенча фикер алышуларда язучылар Гариф Ахунов, Фәрваз Миңнуллин, Барлас Камалов, Ләбибә Ихсанова, М. Н. Елизарова һәм Равил Фәйзуллин катнашты.

## ЯШЬ ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ РЕСПУБЛИКА-ЗОНА КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

5 февральдә Чирмешәндә яшь язучыларның VII республика конференциясе үткәрелде. ТАССР Язучылар союзы һәм ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты тарафыннан оештырылган бу конференция КПССның XXVI съездына багышланган иде. Иҗади киңәшмә барышында Чирмешән, Чистай, Октябрь, Аксубай, Әлки районнарында яшәүче һәм Казаннан килгән яшь авторларның иҗатлары тикшерелде.

Яшь язучыларның әдәби ел йомгаклары итеп үткәрелгән бу конференцияне Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе урынбасары, шагыйрь Илдар Юзеев ачты. КПССның Чирмешән район комитеты секретаре М. З. Шакиров кунакларны һәм әдәби көчләрне районның экономик һәм культура тормышы белән таныштырды.

Аерым жанрлар буенча докладларны Язучылар союзы идарәсе председателе урынбасары Фәрваз Миңнуллин, шагыйрь Рөстәм Мингалим, драматург Ризван Хәмид, тәнкыйтьче Мансур Вәлиев һәм башкалар сөйләде. Докладлар һәм яшьләр иҗаты буенча фикер алышуларда шагыйрьләр Шәүкәт Галиев, Рәдиф Гатауллин, Зөлфәт, Фаил Шәфигуллин катнашты.

Яшь шагыйрьләр Рашат Низамиев, Харрас Әюпов, яшь драматург Юныс Сафиуллин конференция исеменнән СССР Язучылар союзына тәкъдим ителделәр.

## ЭШ КҮРСӘТКӘН ИРНЕ ИЛ ОНЫТМАС

13 февральдә күренекле совет шагыйре — Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлил исемен йөртүче опера һәм балет театрына башкалабыз җәмәгатьчелегенең күп санлы вәкилләре җыелган иде.

Муса Җәлилнең 75 еллык юбилеена багышланган тантаналы кичәне КПССның Казан шәһәр комитеты секретаре А. Г. Кадыйрова ачты. Җәлил турында ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе СССР Верховный Советы депутаты Г. А. Ахунов сөйләде.

РСФСР Язучылар союзы идарәсе секретаре, СССР һәм РСФСР Дәүләт премияләре лауреаты калмык халык шагыйре Давыт Көгелтинов, РСФСР һәм ТАССР Дәүләт премияләре лауреаты Сибгат Хәким Җәлилнең бөтен совет әдәбиятын горурлыгына әверелүе, прогрессив кешелек дөньясының тирән мәхәббәтен казануы турында сөйләделәр. Кичәдә Муса Җәлилнең хатыны Әминә Җәлилова да чыгыш ясады.

Татарстан сәнгать осталары концертында шагыйрьнең бай иҗади мирасыннан әсәрләр яңгырады, Н. Җиһановның «Җәлил» операсыннан һәм Т. Миңнуллинның «Моңлы бер җыр» исемле пьесасы буенча Татар дәүләт академия театрында куелган яңа спектакльдән өзекләр күрсәтелде. Концертта шулай ук М. Җәлилнең оныгы — П. И. Чайковский исемендәге Мәскәү дәүләт консерваториясе каршындагы махсус музыка мәктәбе укучысы Татьяна Малышева да чыгыш ясады.

Тантаналы кичәдә ТАССР Министрлар Советы Председателе Г. И. Усманов, КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев, КПССның Казан шәһәр комитеты беренче секретаре М. К. Рәмиев иптәшләр катнашты.

* * *

СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы урнашкан бинага (Лобачевский урамы, 2/31) Муса Җәлил истәлегенә мемориаль такта куелды.

Мемориаль такта куюга багышланган митингны кереш сүз белән Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Г. А. Ахунов ачты.

РСФСР Язучылар союзы идарәсе секретаре, калмык халык шагыйре Д. Көгелтинов, ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт һәм М. Җәлил исемендәге комсомол премияләре лауреаты шагыйрь И. Юзеев, әдәбият галиме, филология фәннәре докторы Г. Халит Муса Җәлил образының үлемсезлеге турында сөйләделәр.

Герой-шагыйрьнең барельефы төшерелгән мемориаль тактаның авторлары — скульптор Н. Гаделов һәм художник Ф. Фәсхетдинов. Аңа рус һәм татар телләрендә: «Бу

бинада 1923—1925 елларда Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты шагыйрь Муса Җәлил рабфакта укыды»,— дип язылган.

Тантанада КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин, М. Җәлилнең тормыш иптәше Әминә Җәлилова һәм башка иптәшләр катнашты.

* * *

Татарстан Художниклар союзының күргәзмә залында патриот-шагыйрь М. Җәлилнең тууына 75 ел тулу уңае белән махсус экспозиция ачылды. Биредә тематик картиналарны да, портретларны да, шагыйрь әсәрләренә ясалган иллюстрацияләрне дә, Җәлилгә бәйле спектакльләр өчен эшләнгән декорация үрнәкләрен дә күрергә мөмкин.

* * *

Ленин орденлы Татар дәүләт академия театрында драматург Туфан Миңнуллинның җәлилче каһарманнар истәлегенә багышланган «Моңлы бер җыр» исемле яңа әсәре буенча куелган спектакль күрсәтелә башлады. Спектакльдә СССРның халык артистлары Г. Шамуков, Ш. Биктимеров, РСФСРның халык артисткасы В. Минкина, РСФСРның атказанган артистлары Р. Җиһаншина, Ә. Шакиров, иҗат яшьләренең Бөтенсоюз смотры лауреаты И. Хәйруллин һ. б. лар катнаша. Муса Җәлил ролен РСФСРның атказанган артисты Р. Тажетдинов башкара. Спектакльне сәхнәгә РСФСРның халык артисты М. Сәлимҗанов куйды. Художество оформлениесен ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе А. Киоблок эшләгән. Театр коллективы яңа иҗат җимешен партиябезнең XXVI съездына хезмәт бүләге итеп әзерләде.

* * *

Муса Җәлилнең тууына 75 ел тулу уңае белән республикабызның төрле төбәкләрендә кызыклы чаралар булып узды.

Нефть районнарындагы Культура сарайларында, китапханәләрдә, колхоз клубларында патриот-шагыйрь юбилеена багышланган әдәби-музыкаль кичәләр үткәрелде. Җәлил һәм Азнакай поселокларында, Лениногорск районының Муса Җәлил исемендәге колхозында, Әлмәттәге беренче шәһәр китапханәсендә һәм сәүдә техникумында үткәрелгән шундый чараларда нефть якларында яшәүче әдипләр Гамил Афзал, Әдип Маликов, Клара Булатова, яшь шагыйрьләр Р. Рәкыйпов, Н. Әхмәдиев, Р. Вәлиуллин катнашты.

М. Җәлил эзләрен саклаган Минзәлә якларында да шагыйрьне искә алу кичәләре, аның әсәрләрен иң яхшы укучыга конкурслар, әдәби-музыкаль композицияләр оештырылды. Район үзәге китапханәсендә М. Җәлил китаплары атналыгы, шагыйрьне күреп белгән кешеләр белән очрашулар, әдәби кичәләр үткәрелде, «Үлмәс җыр» дигән китап күргәзмәсе оештырылды.

* * *

Кыргызстан шәһәрләрендә һәм авылларында Муса Җәлил юбилее уңае белән әдәби кичәләр уздырылды. Ош каласында «Белем» җәмгыяте әгъзалары татар совет шагыйренең иҗаты һәм тормыш юлы турында бай эчтәлекле күп санлы лекцияләр белән чыгыш ясадылар. Юбилей чаралары СССРның 50 еллыгы исемендәге киҗе-мамык берләшмәсендә, өлкә балалар китапханәсендә, Оркыя Салиева исемендәге өлкә кыргыз мәктәбендә аеруча җанлы үтте.

Ош өлкә газетасында юбилей мөнәсәбәте белән аерым материаллар басылды. Мусаның абыйсы Ибраһим Җәлиловның Ош педагогия институты архивында сакланган бер хатын, мәсәлән, матбугат өчен рус һәм чит ил әдәбиятлары кафедрасы мөдире Н. М. Морадымов әзерләде.

* * *

Көнбатыш Берлиндагы «Плетцензее» мемориаль комплексында Муса Җәлилне җәзалаган урын чәчәк бәйләмнәренә күмелгән. Биредә шәһәр прогрессив оешмалары һәм совет учреждениеләре вәкилләре катнашында күренекле татар совет шагыйренең 75 еллыгына багышланган митинг булды. Карангы нацист төрмәсендә Муса Җәлил язган «Моабит дәфтәрләре»ннән ялкынлы шигъри юллар яңгырады.

Көнбатыш Берлиндагы Германия — Совет дуслыгы җәмгыяте фашизмга каршы куркусыз көрәшкән патриот-шагыйрь истәлегенә багышлап зур әдәби кичә үткәрде.

## МӘКТӘПТӘ — МУЗЕЙ

Казанның 112 нче урта мәктәбендә татар әдәбияты музее оештырылды. Ул РСФСРның М. Горький исемендәге һәм ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты, күренекле шагыйрь Сибгат Хәким иҗатына багышланган бай экспозиция белән ачыла. Биредәге һәр экспонат шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлы хакында сөйли.

Мәктәп музеен ачу тантанасында шагыйрь С. Хәким, Язучылар союзының партбюро секретаре, тәнкыйтьче Ринат Мөхәммәдиев, артистлар, ТАССР Дәүләт музее вәкилләре катнашты.

## ЮБИЛЕЙЛАР

Татарстан язучыларының Г. Тукай исемендәге клубында Казанда яшәүче рус совет язучысы Геннадий Паушкинга 60 яшь тулуга багышланган әдәби кичә булды. Анда язучы М. Скороходов юбилярның иҗаты һәм тормышы турында доклад сөйләде. Г. Паушкинны партия, совет, профсоюз оешмалары, җәмәгатьчелек вәкилләре котладылар. Кичәне тәнкыйтьче Р. Мөхәммәдиев алып барды.

Кичәдә КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин катнашты.

*
* *

Актерлар йортында Татарстанның халык артисты Ибраһим Гафуровның тууына 70 ел тулу уңае белән искә алу кичәсе үткәрелде.

Кичәне Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге идарәсе председателе, РСФСРның атказанган, ТАССРның халык артисткасы Рәшидә Җиһаншина ачты. Артистның тормыш һәм иҗат юлы турында Татар дәүләт академия театрының баш режиссеры Марсель Сәлимҗанов сөйләде. СССРның халык артисты Габдулла Шамуков истәлекләре белән уртаклашты.

*
* *

РСФСРның атказанган, ТАССРның халык художнигы, Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты В. И. Кудельkинга 70 яшь тулу уңае белән Актерлар йортында аны хөрмәтләү кичәсе булды.

Юбилей уңае белән Татарстан Художниклар союзының күргәзмә залында В. И. Кудельkинның персональ күргәзмәсе оештырылды.

## ЯЗУЧЫЛАР — ХЕЗМӘТ АЛДЫНГЫЛАРЫНА

Январь аенда Буа шәһәре һәм авылларында кызыклы әдәби очрашулар циклы шагыйрь Рәдиф Гатауллин катнашында үткәрелде. Ул бүгенге татар әдәбиятының үзенчәлекле яклары турында сөйләде, шигырь сөючеләрне үзенең яңа әсәрләре белән таныштырды.

*
* *

Шагыйрьләр Роберт Әхмәтҗанов, Флюра Гыйззәтуллина, язучылар Рәфкать Кәрами, Самат Шакир Саба районында мәктәп укучылары, терлекчеләр һәм механизаторлар алдында чыгыш ясап, үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар, иҗат планнары белән уртаклаштылар.

*
* *

Казанның сәүдә хезмәткәрләре Культура йортында үткәрелгән әдәби-музыкаль кичәдә язучылар Равил Фәйзуллин, Рөстәм Миңгалимов, Рәдиф Гатауллин, Роберт Әхмәтҗанов, Рәфкать Кәрами, Рәшит Әхмәтҗанов һәм башкалар катнашты. Алар әдәбият мәсьәләләре, иҗади планнары турында сөйләделәр, яңа әсәрләре белән таныштырдылар.

*
* *

Татарстан мех берләшмәсе эшчеләренең икенче тулай торагында уздырылган әдәби кичәгә язучы Габдулла Шәрәфи, шагыйрьләр Рәшит Гәрәй, Фәннур Сафин, җырчылар Рафаэль Сәхәбиев, Рафаэль Ильясов һәм баянчы Рәгъде Халитов чакырылган иде. Аларның чыгышлары эшче яшьләрдә матур тәэсир калдырды.

*
* *

Шагыйрьләр Р. Гәрәй, Р. Әхмәтҗанов, Ф. Сафин һәм Р. Хәлиуллина Буа районы авылларында булып, игенчеләр, терлекчеләр һәм мәктәп балалары белән очраштылар, үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар.

## ӘЛМӘТ ЯЗУЧЫЛАР ОЕШМАСЫНДА

Оешма җыелышында язучы Хәниф Хәйруллинның «Адымнар» исемле романы тикшерелде. Әсәр бүгенге колхоз тормышын чагылдыра. Катлаулы производство мәсьәләләре фонында кешеләр язмышы, аларның омтылыш-максатлары үзәк урынны алып тора. Роман турында фикер алышуда катнашкан Ш. Бикчурин, Р. Төхфәтуллин, Ә. Маликов, Ж. Рәхимов, Ю. Әминов, А. Хәсәнов әсәрнең уңай якларын билгеләп үтү белән бергә, җитди кимчелекләрен дә күрсәттеләр.

*
* *

Чираттагы утырышларның берсендә Сарманда яшәүче Дамир Гарифуллинның нәниләр өчен язылган шигырьләре буенча фикер алышу булды. Шигырьләр арасында балалар психологиясен белеп, тоеп иҗат ителгәннәре шактый. К. Булатова, Г. Афзал, Ә. Маликов, Э. Мөэминова һ. б. иң яхшы шигырьләрне, сайлап алып редакцияләгәннән соң, нәшриятка тәкъдим итәргә мөмкин дигән фикер белдерделәр.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР

Совет театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен В. И. Качалов исемендәге Казан дәүләт Зур драма театры артистлары Евгений Андриянович Кузинга һәм Петр Семенович Масловка «РСФСРның атказанган артисты», Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының режиссер-куючысы Празат Нәкый улы Исәнбәткә «Татарстан АССРның халык артисты», Казан дәүләт курчак театры артистлары Геннадий Васильевич Вишняковка һәм Тимергали Зиннур улы Зиннуровка «Татарстан АССРның атказанган артисты» дигән мактаулы исемнәр бирелде.

## ЕВРОПАДА ТАТАР КӨЙЛӘРЕ

Татарстанның атказанган культура работнигы, сәнгать фәннәре кандидаты Мәхмүт Нигъмәтҗанов Беренче бөтендөнья сугышында әсирлеккә төшкән татарларның Берлинда сакланган көй-җыр язмаларын (фонограммаларын) алып кайтты. Бу гаять үзенчәлекле табыш халкыбызның музыкаль традицияләрен өйрәнү өчен кыйммәтле фәнни материал булып тора.

М. Нигъмәтҗанов әлеге командировкасы вакытында ГДРның күренекле музыка белгечләре белән дә очрашты. Немец галимнәре аның татар музыкасы үзенчәлекләре турында сөйләвен зур кызыксыну белән тыңладылар, халкыбызның җыр-көй культурасына багышланган «Йөрәк моңы» исемле фильмны яратып карадылар.

## ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫБЫЗ!

Мәгълүм булганча, бу көннәрдә республикабызның данлы нефтьчеләре зур хезмәт күтәренкелеге белән яшиләр. Быел Татарстан туган илебезгә 2 миллиард тонна нефть озатачак. Мондый нәтиҗәгә әле моңарчы башка һичбер өлкә ирешкәне юк иде. Шул уңайдан, киләсе санда, танылган прозаик Ш. Бикчуринның нефтьче якташларыбызның хезмәттәге батырлыгы һәм рухи матурлыгына багышланган «Тирән катлам» романының соңгы бүлекләре басыла.

Драматург Туфан Миңнуллин укучыларга яңа әсәр, повесть жанрындагы тәүге тәҗрибәсен тәкъдим итә. «Хәсән Вәгыйзович» дип исемләнгән бу повесть гыйбрәтле язмышлар аша чорыбызның аеруча әһәмиятле мораль-этик мәсьәләләрен күтәрә.

Шигъри әсәрләрдән Р. Мингалимовның «Ике авыл арасы» поэмасы фәлсәфи масштаблы уй һәм нечкә хисләргә нигезләнгән булуы белән игътибарны җәлеп итәр. Укучыга шулай ук яшь шагыйрьләр М. Галиев һәм Н. Измайлова шигырьләре дә тәкъдим ителә.

1 июнь — балаларны халыкара яклау көне. Журнал сәхифәләрендә шул уңай белән махсус рубрика астында Венера Ихсанованың публицистик язмасы, З. Нури, Ш. Галиев, Р. Миңнуллин һәм Р. Вәлиевнең балалар өчен язылган яңа шигырьләре, А. Тимергалин һәм Ш. Рәкыйповның проза әсәрләре дөнья күрәчәк.

Гадәттәгечә, бу санда да очерклар, әдәби тәнкыйть мәкаләләре, рецензияләр һәм культурабыз тарихына караган башка материалларга урын биреләчәк.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210